ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2011





**Афзал Шамов**
**(1901—1990)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2011

5
(1063)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
***«ТАТМЕДИА»***
***ачык акционерлык җәмгыяте***

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

*: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*: Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80. kazanutlari@yandex.ru*
: **Факс**—*(843) 562-11-28.*
: **E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru*

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Хисам КАМАЛОВ. Сугыш зигзаглары. *Бер солдат хатирәләре.* ........ 5
Ренат ХАРИС. Сонетлар. ........ 36
Рабит БАТУЛЛА. Апуш—Тукай. *Кыйсса.* ........ 43
Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА. Ачам һаман бер үк фал. *Шигырьләр.* ........ 62
Нурислам ХӘСӘНОВ. Золым. *Роман.* ........ 66
Ленар ШӘЕХ. Әйтелә сүзләр, әйтелә. *Шигырьләр.* ........ 76
Әхәт МУШИНСКИЙ. Һаваларда—ак күгәрчен... *Роман.* ........ 80

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Минһаҗ маҗаралары ........ 92

**ХӘТЕР**

Асия ХӘМЗИНА. Атаклы разведчик Ибраһим Аганин. ........ 100
Һаҗәр НАРБЕКОВА. Кырык дүртнең июлендә. ........ 107
Фәнзаман БАТТАЛ. Юксыну. ........ 129

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Акыл һәм хис берлеге шагыйре ........ 109

**ТАРИХ**

Рафаэль МОСТАФИН. Җамал Вәлиди фаҗигасе. ........ 122
Индус ТАҺИРОВ. Татар ничек барлыкка килгән? ........ 142

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 136

**СӘНГАТЬ**

Әнвәр ХӘЙРИ. Габдулла Кариев феномены. ........ 149

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Әйдаман. ........ 154
«Чын журналистика—иманга тугрылык ул» *(«Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире М. СӘФӘРОВ белән әңгәмә).* ........ 160

**АК ҖИЛКӘН**

Ирек САБИРОВ. Икенче мәхәббәт. ........ 165
Рафаэль МОСТАФИН. Бәләкәй Рафаэль. ........ 171
Ким ШАКИРОВ. Табигать үзе шәбрәк белә. ........ 177

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Радик ФӘИЗОВ. Чаналар китте. ........ 180

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Х. КАМАЛОВ. «Зигзаги войны» (воспоминания солдата); романы Р. БАТУЛЛЫ «Апуш—Тукай» (прод.); А. МУШИНСКОГО «Шейх и звездочет» (прод.); Н. ХАСАНОВА «Насилие» (прод.); стихи Р. ХАРИСА; Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ; Л. ШАЕХА.
«Память»: А. ХАМЗИНА. «Легендарный разведчик Ибрагим Аганин»;
Х. НАРБЕКОВА. «В июле 44го»; статья Ф. БАТТАЛА к 90-летию Г. Афзала.
«Сенной базар». Конкурс сатирических произведений.
«Литературная критика»: статья Т. ГАЛИУЛЛИНА к 70-летию Р. Хариса.
«История»: Р. МУСТАФИН. «Трагедия Джамала Валиди»;
И. ТАГИРОВ. «Исторические корни татарского народа».
«Искусство»: А. ХАЙРИ. «Феномен Габдуллы Кариева».
«Наши юбиляры»: Р. ГАЛИУЛЛИН. «Вожак» (к 70-летию Т. Айди);
беседа Р. Галиуллина с главным редактором газеты «Ватаным Татарстан» М. САФАРОВЫМ.
«Белый парус»: И. САБИРОВ. «Вторая любовь»;
Р. МУСТАФИН. «Маленький Рафаэль».
«Рассказы из жизни» Р. ФАИЗОВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Казанский речной порт; писатель Дамир ШАРАФУТДИНОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: H. KAMALOV. «Zigzags of war» (soldier's memories); novels by R. BATULLA «Apush-Tukai» (continuation), A. MUSHIMSKY «Sheikh and astrologer» (continuation); N. HASANOV «Violence» (continuation); poems by R. HARRIS; SH. ZIGANGIROVA; L. SHAEH.
«Memory»: A. HAMZINA. «Legendary secret service agent Ibrahim Aganin»;
H. NARBEKOVA. «In July, 44»; article by F. BATTAL to 90th anniversary of G. Afzal.
«Hay Bazaar». Competition of satirical works.
«Literary Criticism»: article by T. GALIULLIN to 70TH anniversary of R. Haris.
«History»: R. MUSTAFIN. «Tragedy of Jamal Validi»;
I. TAGIROV. «Historical roots of Tatar people».
«Art»: A. HAYRI. «Phenomenon of Gabdulla Kariev».
«Our jubileers»: R. GALIULLIN. «Leader» (to 70th anniversary of T. Aydi);
discussion of R. Galiullin with chief editor of newspaper «Vatanym Tatarstan» M. SAFAROV.
«White Sail»: I. SABIROV. «Second Love»;
R. MUSTAFIN. « Little Rafael».
«Stories from Life» R. FAIZOV.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Kazan river port; writer Damir SHARAFUTDINOV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 03.05.2011, график буенча 03.05.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–594. Тираж 4033.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел.



Хисам Камалов

# СУГЫШ ЗИГЗАГЛАРЫ

БЕР СОЛДАТ ХАТИРӘЛӘРЕ

1942 елның җәе иде. Украинаның Волчански шәһәре юнәлешендә канкойгыч сугышлар бара. Дошманның күпкә өстен танклы армияләренә каршы тора алмыйча, безнең кайбер пехота частьлары чигенә. Шунысы бик гаҗәп, төнлә ун чакрымга артка китеп, яңа позиция—траншеялар, окоплар казып әзерләп өлгермисең, ә немецлар тагын безнең тылда булып чыга. Бу ни хикмәт?! Каршылык күрсәтергә, «круговая оборона» ясап карыйбыз. Әмма немец үзенең танклары белән безне тар-мар китерә дә бетерә. Ник дисәң, бездә танкка каршы бер корал да юк. Мылтык белән нишли аласың? Без, исән калганнар, ничек кирәк алай чәчелеп качу ягын карыйбыз. Яралы иптәшләребезне ташлап китәргә мәҗбүрбез. Һәркем үз башын саклый. Бер сыныкны икегә бүлеп капкан якын дустың: «Зинһар, ташлама, Алла хакы өчен, мине калдырма!»—ди-ди күз яше белән шинель итәгенә ябыша. Ыңгырашуы, ялваруы бәгырьне телгәли, әмма... Яралы иптәшкә ярдәм итәм дип мәшәләнсәң, икең дә әсир каласың...

Шул рәвешле тагын унбиш көнләп чигендек. Өс киемнәре урман-чытырманнарда тетелеп бетте. Эчке күлмәкләребез тир белән черегән чүпрәккә әйләнде. Ботинкаларның табаны купкач «обмоткалар» белән бәйләгән иттек. Бер таңда, ниһаять, тыныч сулый торган станциягә килеп юлыктык. Баш очында немец самолетлары сирәк күренә. Бу да фронт полосасы, әмма алда безнең частьлар немецларны туктата алганнар, ныклы оборонага урнашканнар икән. Станция тирәсендә зениткалар, пирамидага куелган станоклы пулеметлар. Биредә запас подразделениеләр төзелә. Төрле тарафлардан пополнение килә, күбесе ополченецлар.

Безне, чолганыштан чыкканнарны, бик тиз җыйдылар. Учетка алып довольствиегә теркәделәр. Чөнки без барыбыз да кадровыйлар. Ягъни без теге яки бу белгечлек буенча хәрби өйрәнү мәктәбе үткәннәр. Күпләребез

---

Хисам КАМАЛОВ (1926) – *Татарстанның халык язучысы; «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым», «Түләнмәгән күз яше» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Бөек Ватан сугышы ветераны. Казанда яши.*

өлкән сержант, сержантлар. Без бик кирәкле, аш янына кашык булып чыктык. Безгә лейтенант, өлкән лейтенант званиеләре биреп, рота, батальон командирлары итеп куйдылар. Ополченецлардан рота, взводлар оештырып, корал белән эш итү әлифбасын өйрәтә башладык. Станция калын урман кырыенда иде. Шуңа занятиеләрне көндез урман ышыгында уздырабыз. Немец самолетлары еракта ауга чыккан ерткыч тилгәннәр кебек күренеп-күренеп китәләр. Зениткалар атарга керешә. Һава киңлегендә ак мамык чүмәләләре тезелә, озак таралмыйча асылынып торалар.

Ополченецлар арасында кемнәр генә юк. Гади завод-фабрика эшчеләреннән алып институт доцентларына кадәр, мәктәп укытучылары, авыл советы рәисләре бар. Бик чуар халык.

Белгечлегем техник инженер булганга, миңа сапер ротасы оештырырга һәм ополченецларны шул профильгә аз булса да төшендерергә боерылды. Башта мылтык, автомат, кул пулеметы, гранаталарның матчастен колакларына кат-кат тукыйсың. Бик туң мангайлылар очрый, башларына берни керми. Үзләре җәфаланалар, командирны газаплап бетерәләр.

Аз гына булса да тәнәфес ясарга туры килә. Солдатлар агач төбенә үләнгә авалар. Ул арада зениткалар атарга тотына. Самолет тавышы һаваны яра. Зур чаган агачының яшел пирчәткәгә охшаган яфраклары битләргә төшеп куна. Яфрак салкынлыгы тирләп кызарган биткә рәхәтлек бирә. Күз кабагынны йомып күккә карап ятсаң, яфрак арасыннан төшкән кояш нурларының җылы кыллары күзләрне кытыклый. Бер минутка сугыш, күңелне телгәләп торган киеренкелек юк шикелле тоела. Тик бер минутка гына. Икенче мәлдә үз башың кайгысы эчне кытырдатырга тотына. Нәрсә булыр, ни белән очланыр бу мәхшәр? Булырга тиешле хәлләр тизрәк булсын иде. Йә бу якка, йә теге якка. Үлем ике килми...

Аңны борчып, чәнчеп торган уйлардан качу өчен солдатлар сүздән сүз чыгарып сөйләшәләр. Бәхәсләшеп тә алалар. Теге очлы борынлы, какча чырайлы, килешле гәүдәле доцент тарихчы икән. Ул яшел пирчәткә зурлыгындагы өрәңге яфрагын сабагында пропеллер кебек әйләндерә-әйләндерә сөйли.

—Германия канцлеры Бисмарк әйтеп калдырган: зур территорияле булу сәбәпле, Россияне җиңү мөмкин түгел. Аның белән дус яшәү ягын карагыз, дигән. Гитлерчылар ул васыятьне таптадылар.

—Котырган Гитлерга васыять ни дә, хасият ни,—диде берсе доцент сүзен куәтләп. Теге дәвам итте:

—Немецларның тарих буенча шулай, алар башта җиңәләр, соңыннан җиңеләләр. Порохлары җитми. Ә англичаннар башта җиңеләләр, ә соңыннан җиңүче булып калалар. Алар бик хәйләкәр. Һәр эшне ун кат үлчәп эшлиләр. Солдат гомерен бик нык саклыйлар... Значит, немецларның хәзерге җиңүләре бары вакытлы нәрсә генә! Әйе! Әмма немецларда хәрби техника күп булу өстенә тагы бик көчле корал бар: ул оешканлык—дисциплина һәм төгәллек! Бу хәтәр көчне җиңәр өчен күп кан түгәргә туры килер. Ләкин, әйтелгәнчә, немецлар җиңеләчәк! Күпме генә көчәнсәләр дә, җиңелү ачысын кичерәчәкләр!

—Әллә син политрукмы?—дип кайсыдыр бүлдерде.—Агитатор блокнотындагыча сөйлисең.

—Һе, бүрек белән бүрене егып булмый, ансат кына сиңа, дип һаман кирегә сукаларга ярата торган берәү каршы төшә.—Әнә, Донны кичеп чыккан ди түгелме сон? Һе, ансат кына...

—Мин ансат димим, күп кан коярга туры килер, дим.

—Неужели, немецларга Донны кичәргә ирек биргәннәр? Ай-йай-йай! Кая киткән эшләр?

—Катастрофа бит бу! Ышанмаслык хәл!

—Безнең таркаулык, төгәлсезлек, авоська ышану бәласе!

—Әй, теленне чамалап син, теге...

—Нәрсә? Үлгәч төрмәгә утырта алмаслар! Теомать!

—Үләргә ашыкма әле...

—Сугышта үлмичә буламыни? Шуңа күрә сугыш...

—Урыска бер талпынып кузгалырга гына кирәк,—диде теге доцент.—Ул кузгалса, барысының да тузанын очырачак!

—Әнә немчураны Мәскәү тирәсеннән 3-4 йөз чакрымга куганнар бит?!

Полк штабы станциядән өч чакрым чамасы урман эчендәге элеккеге ферма өйләренә урнашкан иде. Мин сапер ротасына инструмент-корал йөртү өчен атлы олау юнәтеп булмасмы дип штабка еш баргалыйм. Отказ бирмиләр, һаман вәгъдә дә вәгъдә. Менә бүген, кырт кисеп, менә иртәгә махсус амунициляле часть килеп житәргә тиеш, ди... Әмма шабаш, эзе күренми. Ахырда особый отделга сугыласы иттем. Чынны алар гына белә, хәлләрне берничә худка алдан күрә. Ишек төбендә часовой, эчкә үткәрми. Мин бик саллы шәхси дәлилләр әйткәч, икеләнеп торды да, бар, дип ияге белән ым какты. Бүлмә ишеген ачып керсәм, тәрәз буендагы өстәл артыннан капитан званиесендәге бик таныш чырай күтәрелде. Менә сиңа мә дигәндәй, бу бит безнең пехота училищесы начальнигы Иван Вторник түгелме соң? Кай арада капитан булып өлгергән? Аның сәер фамилиясе табылдык булуыннан дип сөйлиләр иде. Тагы шул, баш миемне сызып үтте: секретный частьларда күбрәк беспризорный һәм детдомда үскәннәр эшли икән... Мин уставча честь биреп, гозеремне әйттем. Ул мине шунда ук таныды һәм иптәшләрчә урындыкка күрсәтте. Безнең аерылганга ике еллар узгандыр, ахрысы. Без ике сүз алышырга өлгермәдек, бүлмәгә бил каешы—партупейларына ике якка наган таккан ике сержант йончылган кыяфәтле, таушалган-пычранган комсостав киемле, юка гәүдәле, урта буйлы бер хәрбине алып керделәр. Пилоткасының кырыйлары тиргә катып, кара сызык булып тора иде.

—Менә тагы дезертир!—дип сержант бу кешедән алган кәгазь-документларны Вторник алдына китереп салды.

—Юк, мин дезертир түгел!—диде теге ныклы, ышанычлы төстә.

—Отставить!—Вторникның тавышы өстенлеген күрсәтә торган тонда иде. Ул кәгазьләрне актарып укырга керешге. Эчке як бүлмәдән тагын ике хәрби килеп буш өстәл артына урнаштылар. Планшетларын ачып кәгазьләрен өстәл өстенә куйдылар. Бу кешедән сорау алырга әзерләнәләр шикелле иде. Вторник бик кырыс, бүртенгән чырай белән башын күтәрде.

—Лямин, кече лейтенант, миномет ротасы командиры, нигә часть расположениесен ташлап качтың?

—Мин качмадым, юк, эш болай,—дип башлады Лямин, аның кара көйгән иреннәре хәлсез генә кыймылдыйлар. Аның бу кешеләрдән өмет өзгәнлеге сизелә иде.—Полк чолганышта калды. Моннан 50 чакрымнар чамасы Борщевка янында. Булган патрон-гранаталарны атып бетердек. Полк командиры һәлак булды диделәр. Комиссарның кулы яраланган, ул кечкенә төркемнәргә бүленеп чигенергә приказ бирде. Комсоставлар төнлә ике броневикка төяләп сыпыртканнар. Ә немец безнең өскә көн-төн ут яудырып тора. Күпләр яраланды, әсирлеккә эләкте. Без, исән калган өч миномет белән егерме бишләп кызылармеец, куе урман каплаган ярга яшерендек. Бар төштә немецлар. Ә безнең каршы торырга бер патрон, граната юк. Миномет снарядлары турында әйтмим дә! Нишләргә? Киңәштек тә, боеприпас һәм бер отделение разведчик алып килә алмассыңмы, дип

мине бирегә җибәрделәр. Боеприпас булса, без ничек тә үзебезнең якка чыга алыр идек. Кызылармеецларның үтенечен аяк астына салу җинаятькә тиң булыр иде...

Ул тынгач, Вторник часть номерларын тагын бер кат төпченде. Командир фамилияләрен сораштырды. Теге протокол язып утыручы астыртын-мәкерле итеп: анда нинди немец частьлары иде соң?—дип кызыксынды.

—Белмим,—диде Лямин,—андый информация безгә кирәк түгел бит.

—Немец белән контактлар булмадымы?

—Юк, чолганышта чакта: «Рус, сдавайсь!» дип кычкыралар иде. Төнлә без ул төштән ычкына алдык. Хәзер кызылармеецлар куе урман эчендә. Немец анда баш тыгарга курка. Кызылармеецларны коткарырга кирәк...

—Нишләп сине җибәрделәр, бүтән командир юк идемени?

—Анда өч лейтенант бар, бу эшкә алынырга теләмәделәр.

—Ә син бу эшкә нигә алындың?—мыскыллы сорауга Лямин тиз генә җавап бирми торды.

—Дурак булганга!—диде ул ачынып.

—Илле чакрым дисең, ул араны ничә көн килдең?

—Өч тәүлек.

—Немецның алгы сызыгын ничек үттең?

—Бер тирән яр эчендә аларның окоплары юк иде. Төнлә шуннан ычкындым...—Ул тир белән пыялаланган битләрен ике учы белән сыпырып алды. Чыраендагы өмет яктысы тагы сүрелә төшкән кебек булды. Сорау алучыларның кыяфәтләре бик усал, ireннәре тартылган, борын тишекләре зурайган, күзләре чәнечке очкыннар чәчә. Кинәт ябырылырга торган кебекләр иде. Аерымлык билгесе булмаган, кайтарма якалы йон гимнастеркалысы сикереп торды да Лямин каршына килеп басты. Иелә төшеп, аның күзенә текәлде.

—Дөресен әйт, сине немецлар вербовать итеп җибәрдеме? Ә? Беләм мин сине!—Ул аның йөзенә бармак янады.—Таны хатаңны! Язмышыңа җай булыр. Таны!

—Ни сөйлисез, тузга язмаганны!—Ляминның аптыраудан күзе алarды.

—Алайса, нигә немец янына бармакчы буласың, ә?—Вторникның тавышы моны стенага терим дигән тонда иде.

—Анда иптәшләр һәлак була, мин аларны коткара алуыма ышанам,—дип Лямин сорау алучыларның әле берсенә, әле икенчесенә: нинди адәмнәр сез?—дигән шикелле карап-карап алды.

—Син аларны коткара алмыйсың, юк!—Вторникның тавышы тимерләнгән иде.—Ник үзең белән алып чыкмадың?

—Әйтәм бит, боеприпас бетте дип. Барыбызны кырып ташларлар иде. Һе! Неужели аңлашылмый? Тылда ятып бөтенләй реальлекне югалткансыз.

—Шакшы, син безне агач атка атландырырга маташма! Барып чыкмас!—«кайтарма якалы» маңгае алга чыккан шәрә калын башын артка каерды, муены артыннан май катламнары колбаса-колбаса тезелде. Үзенең хаклы булуын шул кыяфәт белән раслыйсы килде кебек.

—Синең бу эшең уголовный кодексның 180/17 б. статьясы белән хөкем ителә. Ватанга хыянәт, төшенденме?—Вторник бу юлы тавышын зәһәрләтеп әйтте.

—Трибуналга бирергә туры килә,—диде «калын баш» һәм өстәл артына барып утырды.

—Эчкерсез рәвештә таны гаебеңне, үзеңә җиңел булыр, —Вторник Ляминны түбәнсетә торган караш белән карады.

—Трибуналда танытырлар, нибуч!

—Ә сине немец вербовать итмәгәнен ничек исбат итә аласың? Ә?

—Әйдә, доказательстволарыңны китер!—Вторник аны яр кырыена китергәндәй итте.—Ә-ә, доказательстволарың юкмы? Юк!

Лямин, боларга бернәрсәне дә берничек тә исбат итү мөмкин булмавын аңлап, башын ике учлап тотты да алга иелеп сулкылдап, гаҗизлектән үксеп җибәрде. Йодрыклары белән чигәләренә суккалап алды.—Совет кешеләре түгел сез, немецлар сез!..

Сорау алучылар аптырап калды, телефон шалтырады. Вторник трубканы игътибарсыз тотып сөйләшә башлады. Мин кесәмнән башланган «Беломор» кабы алып Лямин учына салдым, шырпы да биреп, китү ягына ишеккә борылдым. Вторник телефон трубкасына учын куеп:

—Тукта?!—дип миңа дәште. Борылганда күзгә чалынды: Лямин авызына папирос каба алмый, кабызганда шырпысы папирос очында як-якка селкенә иде.

—Соңыннан сугылырмын,—дидем дә чыгып киттем.

Кызылармеецлар петлицаларына кара тасма—сапер билгесе тегә-тегә сөйләшәләр, гәп саталар.

—Ничек курыкмаска өйрәнергә?

—Бездә юк инде, немецлар әнә өйрәтәләр икән. Әйе.

—Әнә өсте-өстенә пропагандистлар: Ватан өчен башың салырга син бурычлы, дип көн-төн тукыйлар. Димәк, баш санына исәп тоталар.

—Немец төгәллеккә, коралга, хәйләгә исәп тота. Аерма шактый бит, ә? Беткән баш беткән, теомать!

—Сугышта кыю булу кирәкле фактор, сүз дә юк. Әмма барча эшне корал, техника хәл итә!

—Немецта хәзергә корал, техника, шуңа котырына ул!

—Үз башына, күп тә үтмәс, койрыгына басарлар!

Безгә олау булмады. Барча инструмент-коралларны үзебезнең сыртка салып йөртергә тиешбез. Штабта миңа «Двухкилометровка» дип аталган топографик карта бирделәр. Безгә задание шул: моннан күпмедер чакрым барып, хәзер оборона тота торган частьларның тылында запас траншея, блиндаж, ут ноктталары—запас позиция әзерләргә тиешбез. Бу дошман оборонаны өзгән очракта артка күп тәгәрәмәс өчен бик мөһим. Аз гына чигенгәң исә, тагын әзер траншеяларга кереп сыенасың. Дошманны тагын күпмедер тоткарлыйсың...

Төнлә нindidер разъездда безнең подразделениене руда, күмер ташый торган тәбәнәк бортлы ачык платформага төяделәр. «Кукушка-паровоз» безне узкоколейкадан уң тарафка баручы тармакка алып кереп китте. Юл нindidер тирән-куркыныч ярлар, вак таучыклар янынннан борылып, дугаланып үтә иде. Ул арада зәңгәр офык буйлап аксыл-саргылт тасмалар сузылды. Шахта корылмалары, вышка һәм аның уртасында маховик тәгәрмәче күзгә чалынды. Поезд посадка урманы эченә килеп керде. Посадка юка, үтәли күренә иде. Кинәт алда мина шартлап туфрак фонтаны күтәрелде. «Кукушка» бик күп пар болыты чыгарды, пошкыра-пошкыра әкренәйде, тагын нидер шартлап җирне дер селкеткәч, туктады. Ни булды, бу нинди әкәмәт дип әсәренешеп торганда посадканың ике ягыннан автомат очередьлары безнең баш очыннан сызгырып үтә башлады. «Нәрсә бу, ходавәндә?»—дип аңны җыя алмый торганда, платформа буенда бик күп тезелеп киткән немецлар: «Халт! Халт!» дип акырырга тотындылар. «Живо, спускайтесь, вы в плену!»—дип тамак ярып кычкыралар... Нишләп безне бирегә җибәрделәр? Командованиенең башбаштаклыгымы, тимер юлчыларның ялгышымы? Фронт сызыгының өзелүе, дивизиянең чолганышта калуы турында имеш-мимешләр хак булып чыга түгелме соң? Без, бәхетсезләр, командование башсызлыгының корбаннарымы? Хәер,

ничек уйларга белгән юк, зиһен чуалып бетте. Немецлар, полицайлар һау-һаулап кызылармеецларны платформалардан куып төшерәләр. Немецка куштанланып, ерткыч полицай автомат түтәсе белән төрткәли. Кай арада немец баскыннарга хезмәт итәргә алынганнар? Кичәге совет кешеләре бүген басып алучыларга хезмәт итә. Моны ничек анларга белмәссең. Безнең рота командиры өлкән лейтенант Бакин платформаның арт ягына сикерде, аска кереп посмакчы булды. Аны шунда ук ике немец тотып алды һәм автомат түтәсе белән иненә, аркасына суккаладылар. Кулын артка каерып бәйләп, каядыр алып та киттеләр. Мин, шул мәлдәге ыгы-зыгыдан файдаланып, почмактагы борт артына постым, андагы саламга күмелеп яттым. Пистолетымны яшердем, портупеямны, планшетымны читкә ыргыттым. Гимнастеркамда аеру билгеләре юк иде. Мине ун көн элек кенә кече лейтенант иткәннәр иде. Рота политругы итеп шулай ук ун көн элек билгеләделәр. Ротада мине танучылар күп булмаска тиеш. Урынга баргач, танышырмын дип уйлаган идем. Хәзер инде танышып маташырга туры килмәячәк. Тукта, документларны тикшерәчәкләр бит. Нишләргә? Минем политрук икәнне белсәләр, берсүзсез стенага терәячәкләр. Немецларда шундый приказ. Нишләргә? Кесәләремне капшаштырам. Гимнастеркамның түш кесәсендә ике кызылармеец кенәгәсе. Маршевой запаста торганда ике кызылармеец расположениедән качканнар иде. Алар шушы тирәдәге хуторлардан икән, дип сөйләнделәр. Кенәгәләрен учет өстәленнән алмаганнар... Нишләргә? Берсен үземнеке итәм, икенчесен чалбар поясына яшерәм... Шул мәл минем аякка бик каты типтеләр. Башны күтәрсәм, полицай басып тора. Бик ачулы, чырае җыерылган.

—Ә-ә, исәнме, мин сине беләм бит,—дидем торып басканда.—Син райкомда эшләдең, әйе, әйе!

—Молчать! Курва, живо!—дип кычкырып җибәрде, шулай да шүрләп як-ягына карана иде. Мин аны мушкага алмакчы булган идем. Ул бу кармакка капмады, әмма арты бик үк ышанычлы булмавы беленеп китте. Әле кичә генә үз гражданнары булган кешеләргә карата шундый ачу, нәфрәт каян килә? Бу—адәм баласының тизрәк властьларга ярашып, үзенең башын саклап калу галәмәте. Власть кайда да бер, үз каршында адәм балаларын биетә генә!

Платформадан сикереп төшеп, як-ягыма карандым. Бар төштә немец армайлары сураеп тора, билләрендә—автомат, ут ачарга әзер. Менә бу капкын тек капкын, авызын корт чаккыры! Һау-һай акыра-бакыра немецлар кызылармеецларны юлдан читтәрәк сарык көтүе кебек туплыйлар. Ул рус полицайлары, кая басканнарын да абайламыйча, немецка ярар өчен чабышалар. Платформадан арт якка сикереп качарга маташучылар булган. Аларның берничәсен атып үтергәннәр. Дүрт-бишен яралаганнар. Полицайлар көрәкләр алып килде. Мәетләрне күмәргә кирәк. Бик күп кызылармеецлар шок халәтеннән чыга алмыйча, аптырап торалар. Әмма ушлылар да бар икән. Кызылармеецлардан полицайларга куштанланучылар табылды. Йөгереп килеп көрәкләрне алдылар. Икенчеләре мәетләрне күтәреп шундагы өй сыярлык зур бомба чокырына төшереп җибәрде. Скатларын сүтеп, өсләрен капларга иткәннәр иде. Немец армае акырып җибәрде, полицайлар эт кебек өрергә тотынды. Рөхсәт итмәделәр. Ачык йөзләренә, башларына балчык ыргыталар. Кантар тигәч башлар әле болай, әле тегеләй тәгәри, муеннары каерыла иде. Карап торуга бик имәнгеч иде. Бу эшне әштер-өштер башкарып, көрәкләрен полицайларга биреп, яралыларга барып тотындылар. Немецлар хәтәр акырыша, автоматтан һавага очередьлар бирә. Каядыр алып китәргә әсирләрне бишәр итеп колоннага тезделәр. Менә кузгалырга команда булды.

Әсирләрне тимер юлга кырт каршы борып, бил тине чүп үләне үскән кырдан алып киттеләр. Баш очында кояш кызган тимер мичтәй кыздыра. Сусаудан авыз кибә, телне әйләндерер хәл юк. Теш арасында тузан бөртекләре чатыр-чытыр килә. Әсирләр, артларыннан эткәнгә генә атлагандай, бик авыр хәрәкәтләнәләр. Узган елдан сөрелми-чәчелми калган иген кырлары булырга тиеш монда. Йомшак җирләр очрый, аяк тузаны тагын да нык күтәрелә. Битләргә, муеннарга кунып, тир белән сылана. Чырайларда соры күндәй катлам барлыкка килә. Кичәге иптәшенне танып булмый башлый. Күпләр әле үзләре белән ни булганны аңлап җитми, ни тере, ни үле кыяфәттә. Монда кара балчыклы туфрак икән. Икмәк күп уныш бирәдер. Хәзер исә ак, кара әрем, билчән белән капланган. Җир кысыр калган. Бу җирләр икмәге белән туенып яшәгәннәр хәзер ач утыра булыр. Каян чыгып, бу ахыр заман дәҗҗаллары—немец мәлгунь безнең илгә ябырылды? Ил-көнне канга батыра бит. Барча кешелеккә каршы барып, ни кылмакчы була?

Әсирләрнең эсселектән эче китә башлады. Колоннадан чыгалар да читкәрәк чүгәлиләр. Кайберләре галәфиләрен төшерергә дә өлгерә алмый, буялып бетә. Озаграк мәшәләнсәң, полицай килеп типкәли башлый. Үзе ише рус кешеләре югыйсә. Каян шул тикле кан-дошманлык? Немецларга ярарга тырышу, карьерага омтылу. Үз кан-кардәшләренә немец-баскын килмешәкләрдән дә каты, рәхимсез булу? Нишләп болар үз милләтен бик тиз саткан икән?

Биек корыган үләннәрне таптап үшән генә селлин-селлин атлый торгач, калкулыкка күтәрелдек. Бу төштән уйсу җирләр, болыннар, ниндидер инеш ярлары буенча үскән уйдык-уйдык урманнар күренде. Шул урманнар артында авыл өйләре калкып чыкты. Якынайган саен авыл зурайганнан-зурая. Тирән-тирән коры үзәннәр—ярлар эчендә саман кирпечтән эшләнеп, ап-ак итеп акшарланган йортлар тезелә. Авылда бер җан әсәре сизелмәде. Немецлар барысын корытырга өлгергән, ахрысы.

Безне авыл читеннән алып киттеләр һәм калку җиргә салынган озын сарайга китереп тутырдылар. Атлар торган сарай булса кирәк, уртада юл, ике якта да такталар белән бүленгән араннар. Өстә, түшәмгә терәлеп, тар озынча тәрәзә кебек ачыклык сузылган. Һәр әсирнең беренче төп уе—ничек тә качу җаен карау булганлыктан, шунда ук бер-берсе өстенә менә-менә тырнашып, теге ачыклыкны тикшерделәр. Юк, кеше үтәрлек түгел, диештеләр. Шәрә килеш ычкынырга була, дигән сүзләр дә колакка керде. Тышка кысталганнар ишеккә бардылар, ике катлы ишекләр исә тыштан бикләнгән иде. Кычкыра-кычкыра дөбердәттеләр, бер җан иясе юк. Нишләргә? Нинди генә авыр хәлдә дә ушлылар, югалып калмаучылар табыла. Безне тентергә өлгермәгән иделәр, шуна күрә кайсыларында шырпы да сакланган. Печән учмасын бик нык бөтереп шәм әмәлләделәр. Арандагы сайгакларның икесен кубарып алдылар. Менә сиңа бәдрәф әзер...

Яралылар белән хәл бик мөшкел иде. Алар уфылдыйлар, йөрәккә төшә торган рәвештә ыңгырашалар. Хәле булганнары кычкыра-сүгенәләр. Аларга бер ярдәм итүче юк. Үзеңне фәкать үзең генә саклый аласың. Бата башласаң, беркем кул сузмаячак. Шартлар шундый, сине коткарса, ул үзе харап булачагы ачык. Беркемнән рәхим-шәфкать көтеп булмый, нихәл итмәк кирәк, һәркем үз җанын саклый.

Төн курку, өметсезлек, шик-шөбһә, ышану-ышанмаулар арасында җан өзгәләнүе белән үтте. Эт булып арылган булса да, беркем йокы турында уйламады. Ни булыр, ни кылыр бу немец мәлгуньнәр, дигән исәп эчендә яндык. Араннарда ишетелмәслек итеп кенә быдыр-быдыр пышылдап сөйләшәләр. Салам кыштырдаган аваз һавада эленеп тора.

Биштәрләрдә өч көнлек сухой паек бар иде. Иртән өстәге ярык тәрәзәләрдән бераз якты иңгәч, тамак хәстәренә керештек. Немец тартып алыр, әрәм китмәсен дип кайберәүләр барысын тамакка озатуны тиеш таба иде. Алда ни буласын шайтан белә, запаска ашап кую эчне тишмәс. Тамак ялгангач, тел чишелә, эчтә кайнаган гарь һәм үч тышка бәреп чыга. Үртәлеп житәкчелекне һәм язмышны каһәрләргә тотыналар.

—Кем сатты безне, теомать, ә?

—Ничек безне туры немец авызына җибәрделәр?

—Хыянәт бу, бик әшәке диверсия! Немец үзе аласы нокталарга алдан диверсантлар җибәрә ди.

—Юк, штабтагыларның ялгышы бу, анда, алгы сызыктан качып, җыен гөмбә башлар утыра!

—Туктале, бу җирләрне немец күптән алган түгелме соң?

—Әйе, бер атна элек кенә! Немец танклар белән көненә 30 чакрым килә, имеш.

—Неужели азрак каршы торырлык та армия юк икән бездә? Просто адәм әйтеп адәм ышанырлык түгел. Валлаһи!

—Алар безнең таркаулыкка исәп тотканнар һәм ялгышмаганнар, шайтан алгыры!

—Оешканлык җитешми инде, төгәл!

—Бездәге таркаулык бик ерактан килә һәм тирән утыра.

Икенче төркемдә сүз бүтәнчәрәк бара. Боларның җанын баш мәсьәләсе талый:

—Немец заман ахыры чумасы инде, барыбызны берьюлы кырып ташлар микән, ә?

—Дурак, ничек шушы тиклем халыкны атып бетерергә мөмкин? Кеше каны җирдә ятмый, ди?

—Немец берни белән дә санашмый, законнар нипочём!

—Гитлер Алланы отменять иткән, ди бит.

—Сталин да Алланы юкка чыгарды анысы!

—Ә немец солдатларының каеш пряжкаларына: «Алла безнең белән»,— «Готт мит унс»—дип язып куелган. Үзем күрдем.

—Гитлер хәйләкәр, солдатларын Алла исеме белән үтерергә, таларга, яндырырга җибәрә. Һе! Алла исеме белән кан коялар...

—Баш бетә, харап була,—диде берәү авыр көрсенеп.—Кура җиләге кебек кызга өйләнгән генә идем. Кала инде этләргә! Юк, бәхет булмады!

Минем белән бер аранга туры килгән эре сөякле, какча гәүдәле, йомык чырайлы кеше утлыклардан куралы печән калдыклары алып килде. Шуны аска түшәдек тә сузылдык. Кичәдән бирле бергә ятабыз, бер авыз сүз сөйләшкән юк. Сүз кушып карыйм, ул: «Әйе, юк»—дип әйтүдән узмый. Миннән шүрли, билгеле. Үз нәүбәтемдә мин дә аңа шикләнеп, куркып карыйм. Күпләр бирегә эләккәч, телләрен йоттылар. Табигый хәл. Телен тыя алмаучылар да бар, анысы, бик сирәк. Бу иптәшкә дә ничек ачкыч табарга икән, дип уйланып ятам. Ул да йокыга китә алмый, йөткергәли, бер-бер чире дә бар шикелле. Кадровыйга охшамаган.

—Син ополченецмы?—дип сорыйсы иттем.

—Мин хезмәт армиясе кешесе,—диде ул авызын учы белән яба-яба ютәлләп.—Одесса өлкәсеннән. Сугыш башлангач, безнең аккумулятор мастерскоен Чернь шәһәрчегенә күчергәннәр иде. Шунда ополчениегә яздылар...—Аның бер дә сөйләшәсе килми иде, башын шинель иңсәсе белән каплады да, «йозагына» бикләнде. Фамилиясен белмәкче булган идем, барыбер чынын әйтмәс дип тыелдым. Әсирләр арасында үз фамилияңне белгертергә ярамый дигән сүзләр бик куерды. Чөнки пленга эләккәнеңне

безнекеләр белсә, әти-әни, гаиләнне Себергә сөрәләр икән, имеш. Хәзерге хәрби законнарның рәхимсезлегенә караганда, моңа ышанмый булмый. Аз булса да эзне югалту өчен, күпләр үз фамилияләрен атамый. Мина да үземне белдерү һич ярамый. Менә шул бик куркыта, эчне тырнап тора. Ләкин лейтенант икәнемне белүчеләр мине сатмасмы? Миндә ышыкланыр чара бар барын. Теге кызылармеец кеңәгәләре. Аның фамилиясе—Блюхер. Мондый немец фамилияләренең каян барлыкка килүе турында ишеткән идем. Полтава өлкәсендә Блюхер дигән алпавыт үзендә хезмәт итүчеләрнең барча балаларына үз фамилиясен куеп чиркәү кенәгәсенә яздыра торган булган. Зур гына авылның яртысыннан артык кешесе Блюхер фамилиясен йөртә икән. Хәер, немец фамилиялеләр рус җирендә борынгыдан килә. Галимнәр, математиклар, химиклар. Мәсәлән, Бутлер...

Фамилия белән бергә тышкы кыяфәтне дә алыштырырга кирәк иде. Иң элек җиту чәчне кечкенә кайчы белән күршедән кыркыттырдым. Чәч бит комсоставка гына рөхсәт ителә. Моны немецлар беләләрдер... Чәч кыркылгач, иякләрне сакал баскач, мине бик танымыйлар. Элек мине командир дип белгән кызылармеецлар мина карап-карап үтәләр. Иптәш лейтенант дип дәшәргә базмыйлар. Бер-икесе таныган иде, юк, мин әйтәм, сезне күзегез алдаган. Мин комсостав түгел, ә рядовой дим. «Ә-ә»,—ди-ди чекрәеп торалар да, ялгышканбыз икән, дип китеп баралар.

Безне Германиягә озаталар, дигән имеш-мимешне тагын күпертә башладылар. Бу барча өметне өзә торган куркыныч хәл иде. Туган җирдән аерсалар, барысы да бетте дигән сүз. Качып котылуны уена да кертмә. Үз җирендә бу капкыннан ычкына алмасаң да, әле нинди дер таяныч кала. Ә җәһәннәм артына олактырсалар, аннан башың кайта алмый инде. Юк. Соң, нишләргә? Аяк үзебезнең җирдә чакта ничек тә шылу ягын чамаларга кирәк. Ике кеше бер булып әзерләнергә. Башта бик ышанычлы, көчле иптәш табу шарт. Һәр яктан сынарга... Юк, тукта, әллә ялгыз гына таю ансатрак булырмы? Ярый ла иптәшең үзең кебек сизгер, елдам, үткен булса? Андыйны ничек беләсең, ничек таныйсың? Ул сиңа бик булдыклы тоелып, гаярь булып сөйләшер, иярер. Ә эшкә керешкәч, камыр кебек җебеп төшәр. Әйе, иң шәбе ялгызың гына тәвәккәлләү. Ни булса шул, кая килеп кая китмәгән!

Су юклык үтерә иде. Ике яралы кызылармеец: «Су, су!»—дип ялваралар. Су белән саташалар. Яралары авыр иде, бәйләүче, бүтән ярдәм күрсәтүче булмады. Газап эчендә дөнья куйдылар.

Адәм заты бик сәер яратылган. Әнә, ополченецлар, үзләренең нинди тәмугка килеп кабуларын төбенә кадәр аңлап, ышанып җитмиләр шикелле, һаман бәхәсләшеп маташалар. Барча нәрсәсен бирер, ләкин сүзен бирмәс кешеләр бар. Берни булмаска, бәхәстә, сүздә җиңү булсын. Шунсыз җаннары канәгатьләнми ахрысы. Ул «галим-голәмә» сөйләгәннәрне мин аңлап та бетермим. Ышанырга да, ышанмаска да белмим. Без аларны үтмәдек....

—Гитлерны Америка, Англия узындырды,—дип үзенең бүтәннәрдән белемле һәм акыллырак булуын белгертер өчен сөйләп китте бер «галим». Аңа көчәергә ирек һәм материаль база тудырдылар. Аннан Советларга каршы котырттылар. Чөнки Советлардан үзләре дә шүрлиләр иде. Гитлер көч туплап җиткергәч, аны туры Советлар өстенә өстереп җибәрделәр. Ник дисәң, бер дәүләт тә үз янәшәсендә көчле дәүләт булуын теләми. Америка, Англия немецларны да, Советларны да дошман күрә, Гитлер белән Советларны—ике дошманны бер-берсе белән сугыштырып, алар ике куянны берьюлы тоталар. Ике дошман, бер-берсен кырып, бик нык көчсезләнә. Гитлерның чиксез авантюрист икәнен белеп, Советлар белән сугышта ук муенын сындырачак дип исәплиләр. Әнә, ишетмәдегезмени,

Америка, Англия безгә ярдәм кулы суза. Азык-төлек, машиналар төягән йөк пароходлары Владивосток портына килгән. Англиядән Мурманскига танклар, пушкалар, сугыш җиһазлары китерелә башлаган. Күрдегезме? Алар нечкә политиклар...

—Немец безнең җирдә тончыгачак,—диде кайсысыдыр аны куәтләп.— Ләкин кайчан?

—Болар барысы да сафсата сату,—диде берсе урынында калкына биреп.— Хәзерге хәлебез турында уйланырга кирәк. Бу капкыннан фәлсәфә белән котылып булмаячак! Гөмбә башлар!

Шул мәл тышта автоматтан аткан тавышлар ишетелде. Очередь биреп, тырылт-тырылт итеп сиптерәләр. Тыштан стенага бәрелгән пулялар чылтырт итеп коелып төшә. Нәкъ шул мизгелдә кемдер ачыргаланып: «А-а-а-а!»- —дигән аваз салды һәм аның гөп итеп аска төшеп бәрелгәне колакны ярып керде. Әсирләр тавыш килгән тарафка йөгерделәр. Саламны бөтереп шәм яндырдылар. Аранның җир идәнендә таза гәүдәле кызылармеец стена буенда капчык кебек ишелеп ята. Өстәге тар тәрәзәгә ничектер үрмәләп менгән, теге якка башын сузып, гәүдәсен чыгармакчы булган, күрәсең. Аның сузылган башына немец часовойлары атканнар.

Салам-шәм янып бетеп сүнде. Әсирләр уйга калып таралыштылар. Ярты төн узгандарак тагын теге хәл кабатланды. Тагын бер качарга маташкан кызылармеецны атып төшерделәр.

Качарга план корган һәм ярсыган кызылармеецлар тынып калдылар. Ат сарае немецларның тыгыз сафы белән уратып алынган!

—Да, каптык, авызын корт чаккыры!—дип ачынды кайсыдыр.

—Немец, билгеле, әшәке ерткыч инде ул,—диде икенчесе.—Дөнья афәте. Халыкларны асып-кисеп өстен ария расасына якты тормыш кормакчы була! Кукиш менә!! Харам кан коеп төзелгән тормыш барыбер юньле булмый. Гөнаһсызга коелган кан тота ул! Бер тотмаса, бер тота!

—Менә күрерсез, бу немец хәшәрәтләр үз башларына котыралар,—диде салынкы ямансу тавыш.—Явызлык бит үз башына үзе җитә. Әйткән иде бер дурак диярсез!

—Үз башы беткәнче иң элек безнең башны бетерер әле ул. Монысы күренеп торган факт.

—Баскыннар кул астында коллар булырга язган икән, ни хәл итмәк кирәк, шайтан алгыры! Хәлләр адәм баласыннан көчлерәк шул. Аһ-һа-һии.

Күпләрнең беренче теләге капкыннан ничек тә ычкыну, качу. Качарга әзерләнә торган төркемнәр оеша башлаганы сизелә. Алар барысы да бер теләк, бер ният белән немецка каты нәфрәт белән ярсыганнары күренә. Әмма башка төрле сөйләнүләрне дә ишетергә була иде.

—Карале, менә алгы сызыкка килгәч, немец ягына таям дип сөйләнгән идең, әҗ Теләгенә бик ансат ирештең түгелме, ә?

—Төрттермә, зинһар,—диде тегесе.

—Совет властен шул тикле яратмавың гына гаҗәпләндерә. Каян килә ул? Колхозда начар булдымыни?

—Менә син миңа әйт, дөньяда берәр җир бармы эшләгән өчен берни бирми торган? Андый җир бүтән юк. Колларны да яшәрлек ашаталар. Ә колхоз сине бушка эшләтә. Эшләгән өчен берни түләми.

—Ну, туган җир хакы бар бит.

—Ач кеше күзенә туган җир күренми. Юк! Аннары бездә таркаулык бит? Дисциплина юк бит! Немецта каты тәртип. Тәртип булмаса, бай да ярлылана, бөлә.

—Бездә дә тәртип булыр, шунсыз алга китеш, тәрәккый мөмкин

түгел. Немецның бу уңышлары вакытлы нәрсә генә бит. Неужели шуны аңламыйсың? Аның материаль ресурслары күп түгел.

—Юк, мин барыбер немецлар ягына авышам. Беләм, аларның бу җиңүләре вакытлы хәл. Россияне тезләндерә алмаячак ул. Үзе тезләнәчәк. Шулай да, барыбер, тәртип хакына немецлар ягына авышам. Немец җиңелсә дә, ныклы тәртип һәм хезмәт яратуы белән тиз аякка басачак. Бездә исә хезмәтне яратмыйлар, намуслы хезмәтне бәяләмиләр. Менә шул намуслы хезмәтне бәяләмәү безнең илне гомергә ярлылыктан чыгармаячак. Әйе! Ничә буын инде юньле-рәтле тормыш күрми! Ничә буын! Иң төп мәсьәлә—икмәк мәсьәләсен хәл итә алмый. Күпме еллар!..

Бераз тынып торганнан соң, тагын бәхәс кузгалып китә.

—Немецта мораль отменять ителгән бит,— диде берсе кыжрап.—Шуна берни белән дә санашмыйлар. Ерткычлардан яман! Ваһ-ваһ-ваһ!

—Безнең башлар бетте инде, канечкеч ерткычтан котылыйм димә...

—Бу төрмәдән чыгарып, безне тезәчәкләр, санаячаклар, менә шул моментта төрлебез төрле якка ялт итеп чәчелеп китәргә, бетте-китте! Күпләребез котылыр иде, ә?

—Кем риза булсын моңа? Юк!

—Кайсыларыбыздыр ычкына алыр иде, валлаһи!

—Кемнәрнеңдер ычкына алуы өчен син башыңны салырга ризамы соң? Туты шул менә. Сөяксез тел сөйли, ә гамәлдә бөтенләй икенче хәл килеп чыга.

... Өч-дүрт көн тирес эчендә богырдап-быкырдап ятканнан соң, безне чыгарып тезделәр. Адым саен немец армайлары, полицайлар мәш килә. Авылга кертмичә биек булып чүп үлән баскан кырдан каядыр алып киттеләр. Алда үлән арасыннан ниндидер кошлар пыр-пыр очып күтәрелә. Билчәннәр шәмәхә чәчкәләрен койган... Бер урман-мазар шәйләнми. Еракта, офык күгелҗемлеге буенда, посадка тасмалары сузылганы күзгә чалына.

Көн кичкә авышканда, бара-бара, калкулык өстеннән күреп алдык: аз гына түбәндә—чәнечкеле тимерчыбык белән биек итеп әйләндереп алынган зур гына мәйдан, эчендә тәбәнәк бараклар, әллә ничә төштә часовой вышкалары, немецлар кай арада төзеп өлгергәннәр? Һаман шул: адәм баласы нинди милләт булуына карамастан, начар эшкә бик алгыр, тиз тартылучан.

Чәнечкеле тимерчыбык эченә кергәч белдек, бу безнең үзебезнең советский ИТЛ икән. Хезмәт-төзәтү төрмәсе. Бер уйласаң, гаҗәп: төрмәдә адәм баласы төзәләме соң инде? Ә чәнечкеле тимерчыбык немецта да, бездә дә бер икән. Юк, немецныкы катырак тимердән эшләнгән шикелле. Немецның бөтенесе катырак: тимерләре дә, солдатлары да. Эре гәүдәле, тазалар. Безнекеләр ише арык, ябык көчсезләрне анда күрмәссең. Ләкин бу фактны таныргa ярамый, киресенчә, без таза, без көчле дип сөйләргә кирәк. Юкса патриот булмыйсың...

Карасана бу немец армайларын, ничек үзләрен хаклы хуҗаларча тоталар! Эчкә гарь һәм ачы үч сава. Нинди куркыныч, нинди әзмәверләр! Берсе безнең өч кызылармеецка торырлык, валлаһи. Ә бит безгә шул килмешәк армайларны җиңәргә кирәк! Нинди генә югалтуларга барып булса да, ул хәшәрәтләрне изге җиребездән куып чыгарырга тиешбез!

Лагерь күз күреме белән дә бик зур мәйдан били икән. Анда бараклар, тагын ниндидер такта йортлар күренә. Якындагы зур гына әллә ничә бүлемле бинада лагерь канцеляриясе урнашкан. Шрайнтрубе дип йөртелә. Әсирләрне өчәр-өчәр итеп шунда алып керәләр. Шкафлар тезелгән бүлмәдә озын өстәл артында немецлар утыра. Бер кырыйда тәрҗемәче—ул тулы озынчарак битле, төз борынлы, нечкә кашлы кызлар кебек немец, ишек

төбендә ике полицай басып тора. Ишектән әсирне төртеп кертәләр. Өстәл артындагы күзлекле армай кычкыра:

—Юде? Комиссар? Командир?

Теге чибәр немец лейтенанты тәрҗемә итә. Русчасы бер дә акцентсыз, әллә рус кешесе микән, хәерсез. Әсир исә юде дә, комиссар да түгел, ә рядовой.

—Командирың кем?—дип сорыйлар. Белмим, ди рядовой, безне төнлә китерделәр, поездга төяделәр. Калганы билгеле...

Әсирнең ябык—бетәшкән кыяфәтенә сынап карап торалар. Аннары күзлекле:

—Хау аб!—дип кулын селти. Янәсе: «ычкын моннан!» Аны икенче бүлмәгә алып кереп китәләр, анда тагы допрос алалар. Фамилиясен язалар һәм муенына номер язылган кечкенә картон тагып чыгаралар.

Мине дә алып керделәр. Күзлекле үзенең барча әсирләргә бирә торган соравын кабатлады. Мин бераз гына немецча аңлый идем. «Найен» дип башны селкедем.

—Син комиссар, командир бит?—дип кычкырды өстәл артындагы кукраеп утырган берсе.

—Найен!—дидем мин ныклы итеп. Кинәт шкаф артыннан спай кыяфәтле әсир чыкты һәм миңа төртеп күрсәтте:

—Ул офицер, рота командиры!—диде башын өстәл артында утыручыларга таба сузып. Мин аңа карадым, бер дә күз күргән кебек түгел, кем булыр бу, сатлык җан? Мине мушкага алалар, ахрысы?

—Нехт, юк!—дидем. Шуннан теге хыянәтче ниндидер фамилия әйтте. Минем чын фамилиямә охшаганрак. Тагын нәрсәдер мыгырданды.

—Минем фамилиям Блюхер!—дидем. Менә кызылармеец книжкам. Теге чибәр лейтенантка суздым.

—Beutsche?—өстәл артындагы кычкыра.

—Полтава өлкәсендә безнең бабай, әти Блюхер дигән немец алпавытында эшләгәннәр,—дип аңлата башладым.—Алпавытның шундый гадәте булган: батракларының яңа туган һәр баласына үз фамилиясен биреп яздырган чиркәү метрикасына. Шуннан киткән...

Чибәр лейтенант тәрҗемә итте, өстәл артындагыларның карашлары йомшарды, күзләренә кызыксыну чыкты. Ә теге стукач ярарга тырышып тагын: «Ул командир, комиссар!»—ди-ди өтәләнә. Чибәр лейтенантның фамилиясе Зинкель икән. Өстәл артындагылар аңа шулай эндәшә. Зинкель, стукачны тыңлап бетерде дә:

—Кая доказательствоң, йә? Йә,—дип тегенә кадалды. Стукач икенче бер әсирне чакыртты. Ябык җәбәхәер әсир кереп басты. Зинкель аңа төбәлеп, кулы белән мине күрсәтеп:

—Ул сезнең командирмы?—диде йөзен чытып. Тегене мин таныдым, ул взвод командиры иде, рота исемлеген төзеп, барлап йөрде. Мине яхшы белә, билгеле. Фамилиясе Әхмәтов. Әмма зиһенен тиз җыеп өлгерде. Берни белмәгән чырай белән:

—Юк, бу кешене мин белмим,—дип кулын кирегә селтәде.

Стукач тагын атылып чыкты:

—Ялганлама, беләсең,—дип гау-һай килде.—Безнең командир ул дип сөйләштегез.

—Без частька төнлә килдек, командирларны белергә өлгермәдек. Мин татар, русча начар аңлыйм...—Әхмәтов аска төбәлеп тора башлады. Чибәр лейтенант тизрәк өстәл артындагыларга аңлатты, нацмен, русча белми, диде. Тегеләрнең чырайларына хәерхаһлык галәмәте чыккандай булды. Күзлекле: «Алыгыз!»—дигәнне белгертеп кулын селтәде. Стукач, нишләргә белмичә,

учын мангаена куеп, шкаф янында бер адым болайга, тегеләйгә атлап селкенгәләп торды. Авыз эченнән мыгыр-мыгыр сөйләнде. Шунда мин аның безнең подразделениегә теге сарайда чакта махсус китереп кушкан шымчы икәнен аңладым. Ул үзе генә булмаган, билгеле, алар тагын булырга тиеш. Безнең подразделениедәге солдатларның сөйләшкәнен тыңлап-иснәнеп йөргәннәр. Бу стукач сугыш башында ук әсир төшкәндер. Гомерен саклап калу һәм тамак ялы өчен үз ишләрен сату эшенә алынгандыр, мөгаен. Бу эшкә беркем дә үзе теләп риза булмый. Хәер, төрле кеше бар. Училищеда мин белгән берәү шул эшне үзе теләп алды. Особый отделга гариза язып. Юкса, санга сукмыйлар, дәрәҗәгә күтәрмиләр, дип акланып маташты.

Ул арада стукач сарай аранында берничә көн минем белән торган әсирне әйтеп китертте. Стукачның булышчылары да бар, күрәсең.

Менә минем күршене теге армайлар каршына китереп бастырдылар. Ул калку буйлы, юка инле, озынча йөзле, ничектер көлемсерәп тора. Допрос алучы үзенең һәркемгә бирә торган соравын кычкырды. Әсир, гәүдә авырлыгын бер аяктан икенче аягына күчереп:

—Минем фамилиям Гитлер, исемем Отто. Отто Гитлер[1] булам мин,- —диде саф рус телендә. Өстәл артындагылар бер-берсенә карашып алдылар. Кыбырсып куйдылар. Күзлеклесе торып басарга итте, кире утырды. Зинкельгә төбәлделәр. Ул Отто янына килде, документ таләп итеп кулын сузды. Бүлмәдә янаучан тынлык урнашты. Отто һаман чыраенда аз гына көлемсерәү катып калган хәлдә иде. Зинкель учындагы кызылармеец книжкасын ачып укып китте: Гитлер Отто Генрихович, Одесса өлкәсе, Балтин районы, Тодс поселогы. Нестроевой, трудовой армия...—Ул иптәшләренә тәрҗемә итә, Оттога карап-карап ала. Күзләренә, үзенә дә ышанып бетми шикелле иде. Кызылармеец книжкасы өстәл артындагыларның кулыннан кулына йөрде. Шактый гаҗәпләнеп, бераз югалып калган кебек тордылар. Миңа да күз акларын ялтыратып, күз кырыйларын төшереп алалар. Берәр этлек юкмы бу тамаша артында, янәсе. Мин дә, билгеле, бик аптырап басып торам...

Зинкель допрос алуын дәвам итте. Отто немецча белми икән. Немецлар Одесса өлкәсенә моннан 200 еллар элек килеп төпләнгәннәр, тоташ рус авыллары арасына. Немец мәктәпләре булмаган. Русча укыганнар. Немецча өйдә карт-коры гына ара-тирә сөйләшә торган булган. Яшьләр русча укыгач, руслашып киткән. Нинди телдә укысаң, шул милләт кешесенә әйләнәсең инде. Житейский закон. Беркем аңардан өстен була алмый. Менә шул.

Отто сүзен бетергәч, стукач каударланды, аның тизрәк үз эшенең нәтиҗәсен күрсәтәсе килә иде. Ул аяклары белән каз шикелле тыпыр-тыпыр килеп Оттога кадалды.

—Күршең үзенең чын кем булуын сиңа чишми калмагандыр, яшермә! Йә?—диде.

—Юк, без сөйләшмәдек диярлек,—диде Отто.—Әйе, юк белән генә чикләндек. Шундый обстановка: беләсең, ул миннән курка, мин аңардан шүрлим. Беркем дә үзен белгертәсе килми. Эчтә курку калтырап утыра. Хәлне аңлыйсыз булыр. Мин күршемнең нинди кеше булуын белмим. Ул да мине менә яңа гына белде.

Оттоның дәлилләре ышандыргыч, нигезле тоелды. Каршы төшүче, аның ялганын тотарга маташучы булмады. Өстәл артындагыларның берсе шулай да кызыксынды: Отто Германиягә хезмәт итәргә теләмиме? Отто бер җилкәсен күтәреп төшергәндәй итте: мин пленный, диде, мине үтермәсеннәр өчен ни

[1] Отто Гитлерны автор уйлап чыгармады. Совет армиясендә Гитлер фамилияле өч солдат хезмәт иткән, шуларның берсе Сталинградта һәлак булган дип язды матбугат. Сугышка чаклы Мәскәүдә Моисей Гитлер дигән еврей булганы турында ишеткән идем.

кушсалар, шуны башкарырга мәҗбүрмен...—Ул немецларның үзенә хәерхаһ карашларын сизде, үзен иркен тотты.

Стукач чакырткан теге әсирләрне, мине икенче бүлмәгә алып кереп, тагын кыскача допрос алып, карточка яздылар. Муенга номер элеп, артка типтеләр. Отто чыкмады. Мин канцелярия ишек төбендә йөренәм. Стукач үзенең булышчылары аша һаман әсирләрне допроска чакырта иде. Унлап әсир чакыртылды, ахрысы. Ләкин берсе дә үзләренең командир, политрукларын сатмадылар шикелле. Сатучылар булса, колактан колакка ишетелер иде.

Үзем йөрим, үзем Отто Гитлер турында уйлап һаман гаҗәпләнүдән арына алмыйм. Без Гитлер исемен атарга чирканабыз, куркабыз. Ә мин аның кырында башны башка куеп дигәндәй гырлап йокладым. Берни сизми, берни фараз йөртми. Гаҗәпнең гаҗәбе! Үлмәсәң, әлләниләр күрерсең, валлаһи!

Отто авыр кузгалышлы, калын тиреле иде кебек. Агач мичкәдән баланда өләшкәндә аны кемдер төртеп екты. Ашын түктерде. Ул аңа җавап кайтармады. Торды да, үз тарафына китте. Кагу-сугуларга бер дә исе китми, күнеккәнме, әллә холкы авыр-сабырмы? Белмәссең...

Янә бер нәрсә мине аптырашта калдырды. Эш шунда, теге денсез стукач мине белгән тагын бер кызылармеецны китертте. Зинкель сорау ала башлады. Әсир каушады, әле минем якка карый, әле немецларга. Мине беләм дип тә, белмим дип тә төгәл әйтә алмый. Зиһене таркауланган, җыярга ихтыяры юк. Ык-мык. Зинкель моны сизде һәм сорауны мине белми торган итеп җавап бирергә сүз җае китерә. Биш-алты сорауны мине белмәгәнлеген ачык күрсәтерлек итеп оештырды. Кире җавап алгач, тегеләргә тәрҗемә итте. Өстәл артындагы немец теге әсиргә:

—Хау аб!—дип бугаз ярды. Мине бер яклап чыгаргач, бу шаһит алдына «очная ставкага» кабат алып кергәннәр иде. Теге өстәл артындагыларның ачуы ташыды, миңа да:

—Хау аб!—дип җикерделәр.

Чыккач, тиз генә исемә килә алмыйча йөрдем. Очная ставкага чакыргач: «Дөнья, хуш! Беттем!»—дип уйлаган идем. Чибәр лейтенант Зинкель мине үлемнән алып калды бит! Төгәл алып калды, котылу шатлыгыннан гына әйтелми бу! Юк, мине сиземләвем дә, мондый моментта үтә елгыр зиһенем дә алдамый! Ул минем командир булуымны беренче кызылармеецтан допрос алганда ук сизгән кебек тоелган иде... Миңа синң кирәк булса, табышмак тек табышмак инде. Моны ничек аңларга? Әллә бу теге төрле хәлләрнең очраклы рәвештә бергә туры килүләреме? Башкача ничек дип бәя бирергә? Минем немец фамилиямә сылтаргамы? Ни әйтсәң дә, немец фамилиясенең әһәмияте зур булды. Соңыннан моның берәр чатаклыгы килеп чыкмас микән? Үлем тырнагыннан ычкындым, дип авыз ачып булмый, шайтан алгыры! Һәр сәгать саен сине үлем сагалап кына тора.

Хәер, бик җебеп төшмик әле, бу минутта җан исән. Җан таләбен кайгыртырга кирәк. Яшәү өчен иблиснең үзе белән дуслашырга, аның куенына егылырга! Теләсә нинди юл белән җаныңны сакларга! Бер генә нәрсәдән куркам мин: үз янәшәмдәге иптәшләрне заложить итүдән. Үлем янаганда да аңлы рәвештә мин аны эшли алмаячакмын. Юк, мин курку белмәс батыр йөрәкле кеше түгел. Просто намусыма пычрак йөк алырга теләмим.

Безне барактагы камераларга шыплап тутырдылар. Режим бик каты иде. Сафка тезелгәндә аз гына соңга калсаң, резин гөрзи белән сугалар. Өч катлы нарлар, тиз генә менеп-төшеп булмый. Ник дисәң, безнең тәндә элеккеге энергия запаслары бетте. Ашау начар булу сәбәпле, без хәлсезләнә

башладык. Ике көнгә бер сакал-мыекны кырырга мәҗбүр итәләр. Еш кына су булмый, сабын турында әйткән дә юк.

... Бер көнне кичке тикшерү алдыннан бараклар алдында җыелып тора идек, теге тәрҗемәче—ягымлы Зинкель иң ата стукачны ияртеп, төркем янына килде һәм аңа төртеп күрсәтте:

—Менә бу данлыклы немец командованиесен алдады,—диде. Командованиегә ялган информация биреп, безне ялгыштырырга теләде. Немец ялганны гафу итми, һәр ялганлаган кешегә җәза бирә. Командование бу ялганчыны үзе яла яккан әсирләр кулына тапшырырга карар итте!—ул бер кулын өстән аска таба, башы бетсен дигән сыман итеп, төшерде дә, борылып, китеп барды. Әсирләрнең болай да эчләре тулы ут, ачу, үч иде. Шуны ничек чыгарырга сылтау таба алмый торган моментлары иде, шунда ук тегенә барып ябыштылар. Теге башын ике кулы белән тотып җиргә егылды, җылый-җылый: мин гаепле түгел, мине провокацияләделәр,—дия-дия чиный башлады. Әллә каян надзиратель килеп чыкты, резин гөрзие белән кизәнә-суга төркемне куып таратты. Әмма иртән аның үле гәүдәсен чәнечкеле тимерчыбык койма буендагы салам астыннан табып чыгардылар.

Отто Гитлер безнең камерага кайтмады. Шахта поселогындагы баракка урнаштырганнар. Вольнонаемный эшчеләр янына. Лагерьның шарфюрерлары шунда яшиләр иде.

Әсирләрне эшкә җигә башладылар. Бу җирләр рудага бик бай төбәк. Безне рудникка җир казырга алып килделәр. Хикмәт шунда, руда катламы шактый тирәндә икән. Өске катлам җирне алырга, читкә ташырга кирәк. Руда катламын чыгарыр өчен. Бер тәгәрмәчкә беркетелеп эшләнгән ике тоткалы тачка-арбага балчык төйиләр. Син шуны 200 метр чамасы ераклыктагы тирән яр эченә илтеп аударасың. Биш тачка илткәч, кул алмашасың. Син көрәк белән төйисең, ә кулалмашчың тачканы этеп китә.

Ә аста, котлован төбендә, зур дүртпочмаклы тимер әрҗә. Ул дүрт колагыннан электерелеп бер корыч троска тоташтырылган. Рудалы балчык белән тутырылгач, тросның түбәндәге очына аркылы тартә куеп, берничә кеше тарта. Әрҗә берничә ярус югары күтәрелә. Андагы мәйданчыкта тагын шундый лебедка. Ул, руданы вагонга чаклы күтәреп, шунда бушата... Әсирләр хәлсез, көчкә-көчкә генә кыймылдыйлар. Әгәр эшләмәсәгез, Германиягә озатабыз, дип куркыталар.

Мин тачкамны аударып килә идем, каршымда Отто пәйда булды. Ул биредә чыгыр-лебедкаларның төзеклеген күзәтүче техник-механик икән. Немецлар аны үз яннарына урнаштырганнар. Көн-төн немецча сөйләшергә өйрәтәләр ди. Ничек Гитлер тиклем Гитлер булып немецча белмәскә мөмкин? Күпмедер вакыттан Отто, шарфюрерлар белән сөйләшеп, мине үз янына поселоктагы баракка алды. Үзенә ярдәмче итте. Гитлерга ышаналар, каршы килергә базмыйлар, ди. Юк, бу аның белән уйнау, кызык ясау гына булгандыр, бәлки. Шулай да аның янында эшләп йөрим. Күрше бүлмәдәге немецлар, безне өстәл артына утыртып, немец телен төшендерәләр. Бик кызыклы тел икән, каһәр суккыры! Дошманның телен белү кирәк икән. Отто исә телгә бик сәләтле икән, бик тиз отып ала, инде ипилек-тозлык немецча сөйләшә башлады. Әллә аңарда монарчы томаланып яткан немец каны кузгалганмы? Әллә ул бөтенләй милләттәшләре иркенә бирелгәнме? Алар ягына чыкканмы? Җан тартмаса, кан тарта, ди. Белмәссең, бу әкрен кузгала торган калын тиреле кешене. Бик серле күренә. Ул әллә мине сынарга телиме, минем кемлегемне ачып, милләттәшләренә чагарга, ә? Һәр кешегә үз милләте бүтәннәрдән кадерле, милләт хисе канда бит ул. Аның кайда, ничек үзен күрсәтүен кеше үзе дә белеп җиткерми. Аның белән

идарә итә алмый. Милли хис шундый ул. Әллә кайдан тирәннән күтмәгәндә калкып чыгып, үзен бирәр хәлдә күрсәткәч кенә аны беләбез.

Әмма Оттода мин шикләнгән мәкер сизелми иде. Шыпырт кына, безне Германиягә озатканчы, ничек тә биредән ычкыну хакында сөйләшәбез. Аның да кайгысы шул. Җайлы вакытны файдаланырга кирәк. Отто гражданский киемнәр юнәтә башлады. Вольно-наемный эшчеләр аша. Минем галәфи чалбар поясына теккән йөзлекләр бар иде. Совет акчалары әле йөри. Мин кожан сатып алдым. Эчтән кияргә яңа суккан киндердән теккән күлмәк-ыштан да әйбәт кенә булды... Безнең ниятне тагын шул нәрсә дә көчәйтте: Отто ашханәдә савыт-саба юучы тулы тәнле, астан гына сынап карый торган блондинка хатын белән танышып, ыкы-чыкы килеп йөри. Шул әйткән, фюрер үз фамилиясен йөрткән кешеләрне түзә алмый, ди. Алар серле рәвештә юкка чыгалар, имеш. Берничә фамилиядәше эзсез югалган... Бу нәрсә Оттоның качу турындагы икеле-микеле уйларын бетерде. Ныклы фикер төйнәлде.

Эштә әбәд вакытында безнең янга ике әсир килеп утырды. Мин берсен танедым. Теге ат сараенда ятканда: «мин—ополченец, доцент»,—дип мыгырдаган адәм иде. Ул, совет армиясе һичшиксез җиңәчәк, дия-дия күп дәлилләр китергән иде. Әмма без җиңсәк тә, бездә юньле-рәтле тормыш булмаячак, чөнки демократия юк...

Алар киңәш сорап килгән икән. Хикмәт шунда, алар Германиягә эшкә китәргә телиләр. Нилектән дигәндә, әгәр немец заводынамы, хуҗалыгынамы хезмәткә беркетелсәләр, әсирлек концлагерыннан котылалар. Сугыш биргә кире чигенеп килеп житә башлауга, әсирләрне коточкыч үлем лагерьларына озатачаклар. Аннары без бөтенләйгә Германиядә калырга карар иттек. Россия белән безне кыерсыту, кыйнаудан башка берни дә бәйләми, диләр.

—Мине кырыгынчы елны арестовать иттеләр,—дип сөйләп алды зур башлы, ат чырайлы, кыска аяклы доцент.—Тикшерүче бик әшәке ерткыч адәм каныкты, давай, партия алдында коралсызлан, бар эчеңдәге каршы уй-фикерләреңне ачып сал, ди-ди аяк тибеп акыра. Мин әйтәм, минем партиягә, стройга каршы коралланганым юк, коралым булмаган килеш, ничек мин коралсызланыйм, ди? Булмаганны каян табыйм?.. Ә ул: синең эчең тулы дошманлык, совет строен яратмыйсың, син «Враг номер один» ди-ди тагын очып куна. Берсендә колак төбенә сукты, мин идәнгә барып төштем, учында кургаш пластинка икән ерткычның... Кыйнавына түзәсең, эштә кыерсытулары бик авыр, иптәш, бик кыен... Тагын шул: бу хәлләр бит бетмәячәк, һаман дәвам итәчәк...

Икенчесе какча гәүдәле, киң җилкәле, акыллы чырайлы егерме бишләрдәге кеше, колхозчы икән.

—Бездә бар көчеңне салып, намус белән башкарган хезмәтне бәяләү юк,—дип сөйли.—Шул хәл суя. Ә кызыл сүз сөйләүче эшлексез болтунны бәялиләр, күтәрәләр. Эш бәяләнми, буш сүз югары бәяләнә. Бу принципка әйләнгән. Шуңа күрә безнең илдә житеш тормыш булмаячак. Юк, немецта чын эшне бәялиләр ул. Төгәллек, дисциплина иң важный нәрсәләр...

Ул сүзен бетергәч, доцент:

—Менә, иптәш, безнең сүзләрдә дөреслек бармы?—дип безгә төбәлде.

—Сез сатлык җаннар,—дип ачудан ата каздай ысылдадым мин башкаларга ишетелүдән сагаеп. Ил язмышы кыл өстендә чакта сез аның аркасына пычак кадыйсыз!

—Ярар, кешечә сөйләшү булмады,—диде доцент кулын селтәп.— Урапатриотик адәм икәнсез. Зинһар, килешик, без әйтмәдек, сез ишетмәдегез! Ул кинәт торды да кыска аяклары белән зур кантарлар аша

ава-түнә атлап китте. Икенчесе башын якаларына чумырып аңа иярде.

Адәм балалары—бик чуар затлар. Ат аласы тышында, кеше аласы эчендә, ди. Арада, әнә, нинди чүпләр дә бар шул. Бу әңгәмәдән соң Оттога шикле уй төште. Үзебезнең якка чыгарбыз анысы, ләкин анда мине төрмәгә япмасlarмы? Юк, мин әйтәм, син бит совет мәктәбендә укыган совет кешесе. Шунын өстенә совет Гитлеры, экспонат өчен булса да, сина тимәсләр. Совет власте каршында бер гаебең юк.

—Бездә бит бер сүз өчен дә утырталар, беләсең,—дип куйды Отто һаман шикләнүен арттырып. —Немецта сүз өчен түгел, фәкать властька каршы кылган эш өчен утырталар. Ә?

—Юк, сүз өчен дә утырталар, ялгышма!—дидем Оттога ачуым ташый башлап. Бер сәбәпсез, көчсезлегемнән җанда ачу кузгалучан.

Бер көнне чибәр лейтенант Зинкель Оттоны очраткач, түбәндәгеләрне әйткән: Одесса, Ровно өлкәләре бөек рейх—Германия дәүләтенә кушылган, шул дәүләт милке дип игълан ителгән. Хәрби булмаган, ополченец итеп алынганнарны өйләренә кайтарып җибәрергә дигән указ бар. Нишлисең, Одессага китәсеңме?—дигән. Отто аңа информация өчен рәхмәт белдереп, ярый уйлармын дип калган...

Бу сенсация кебек яңалык иде. Моңа тиз генә ышанырга баш җитми иде. Берәр капкын гына булмагае дигән шик килә дә тора. Хәер, икенче яктан немецларның сугыштагы уңышлары фикерне ышану ягына авыштыра. Немецлар Сталинградны алулары, совет армиясенең тәмам җиңелүе, бүтән каршылык күрсәтә алмавы турында лаф оралар. Немецлар бик аек фикер йөртүчеләр, әмма шапырынырга яраталар. Шапырыну үзе үк көчсезлекне күрсәтә.

Оттоның баш җитмәс хәбәреннән минем эчкә кыбырсу керде. Нишләргә? Отто немецлардан белеште. Безгә иң элек эшкә яраксыз дигән врач язуы таләп ителә икән. Шул язу нигезендә генә. «Аус-Вайс»—паспорт бирелә. Паспорт булгач, немецлар территориясендә теләсә кая хәрәкәт итә аласың. Безнең күренеп торган авыру юк. Мин кайчандыр хәтергә кереп калган им-томчы чарасын кулланып карарга булдым. Оттоның ашханәдәге таныш хатыны биш-алты пачка махорка юнәтеп бирде. Рус махоркасы. Мин бер пачканы кайнар суда төнәтеп шешәгә тутырдым. Ул грузин виносы төсле көрән-саргылт төстә булды. Шуны иртән ярты стакан, кич тагын шуны кабатлыйм. Йөрәк күкрәк читлеген ватып чыгар төсле сикерә-сикерә тибә. Бер тамчы йоклап булмый. Ике көннән соң карыйм йөзгә, күз акларына тәмәке сарысы керде. Аяк йөзләре кабарып, шешеп чыкты. Отто белән бергә врачка йөрибез. Ул тәмәке суын эчәргә курыкты, болай да аның бер кулы чулаграк иде. Барыр алдыннан ярты стакан теге ырымны кабул итәм. Күп тыкшынып йөри торгач, миңа «Кранк» авыру, хәлсез, эшкә яраксыз, дигән кәгазь бирделәр. Отто да шундыйрак язу алды. Хәзер без эшкә чыкмыйбыз. Отто теге хатын янында төн уздыра. Иртән исерек кеше кебек әүмәлтүлпән кайтып керә. Миңа туры карамый. Ничек хәлләр, мин әйтәм. Ул баш бармагын тырпайтып күрсәтә. Хатын ничек соң?—дип кызыксынам. Ул бер генә сүз белән: Ут!—ди һәм өстен сала да сәкегә ава, шунда ук гырлап йоклап китә. Ә минем эчтә пошаман өермәсе кузгала. Без бит бергә качарга әзерләнәбез. Отто ул хакта онытып бара шикелле. Без аерылырбыз микәнни? Сыналган нәрсә: берәр эшкә хатын-кыз боты килеп кысылдымы, син теләгәнчә булмый инде. Неужели Отто шул блондинканың мәхәббәт тылсымына батып калыр, ә? Гомер-гомергә ир-ат башын хатын-кыз харап итә бит. Шуңа күрә хатыннарны шайтан токымыннан диләр... Көн төштән авышкач кына Отто уяна, бик рәхәтләнеп киерелә. Буыннарын яза. Бу минутта аның чырае армай немецларга охшап китә. Котелоктагы әбәтенә

күз дә төшерми. Мәгъшукасы тәне белән дә, тәм-томы белән дә сыйлаган күренә. Анардагы немец чаткылары минем ачуны кузгата.

—Отто, безгә паспорт артыннан йөрергә кирәк бит,—дим. Ул ишетми, һаман үзен теге блондинка янында итеп сизә кебек. Жилкәсенә төртеп куям, башын күтәреп карый, иреннәре үзләреннән үзләре канәгатьлек белән җәелә.

—Мин оҗмахка эләктем, парин!—ди.

—Әллә ычкына башладыңмы, монда тәмугның үзе бит?

—Хак әйтәсең, мин ычкындым, ахрысы, ихлас?

—Ни булды тагын?—Мин әле анның хәлен аңлый алмыйм. Чөнки андый хәлгә юлыкканым юк иде.

—Мине Полина тәмам әсир итте, парин. Хәзер нишләргә дә белмим.

—Син әсир ич инде?

—Ай-һай, хатын-кыз шайтан кебек көчле зат икән...—Отто аптыраулы төстә башын як-якка чайкап торды.—Мин—кантар ташны эретте бит! Ихлас! Бу хакта авыз ачарга куркам. Әллә матур төш кенәме? Төш белән иләс-миләс киләмме? Кинәт ул рәхәт төш бетәр һәм мин уянырмын да буш кыр каргасы кебек ялгыз калырмын?—Ул ашыгып җыенырга, киенергә тотынды. Полина янына барыр вакыт җиткән икән. Мин төне буе уйланып яттым. Оттоны биредә калдыру галәмәте түгелме бу? Үзеннән-үзе стихияле рәвештә килеп чыктымы, әллә астан берәр кул уйныймы? Немецта разведка бик нечкә куелган. Әллә Полинаны вербовать итмәгәннәрдер дисеңме?

Отто бүген тагын да гаҗәпләнгән, шаккаткан кыяфәт белән кайтты. Нар кырына утырды да, башын як-якка чайкый, янәсе, ул нәрсәнедер төшенеп җитә алмый иде.

—Әллә бу синең беренче мәртәбәме?—Минем сорау сәеррәк чыкты.

—Хикмәт шунда шул,—диде ничектер кайгырган төсле. Хатын шул тикле татлы буламыни, ә? Бар йөрәгемне уеп ала. Бу татлылык акылдан шаштыра, валлаһи! Синең шундый хәлгә тарыганың бармы?

—Юк, мин хатын-кызны үземә тирәнгә җибәрмим.

—Ничек алай итәргә мөмкин? Якынлык кылуны һаман сузасы килә. Полина да бик дәртле... Кочагыннан чыгармаска итә. Бер минут онытып булмый...

—Ә мин эшне бетерәм дә, ярты сәгатьтән онытам,—дим.

—Синең җайлы икән,—диде ул миңа кызыгып карап.—Ә мине татлылык тота. Татлылыкның чиге бармы икән?

Уйга калабыз. Миңа акылдан тыш бер фикер килә:

—Татлылыкның чиге үлемдер,—дим үзем дә тәгаен аңлап җитмичә.—Бер чибәр хатын: ирем өстемдә үлде, дигән иде...

—Булса да булыр, шул тикле татлылыкка ничек йөрәк чыдасын, юләр.

—Адәм баласында яшәү инстинкты гаять дәрәҗәдә көчле шул,—дидем белдекле баштай фәлсәфәгә бирелеп.—Буыннан-буынга, мең еллар буе күчеп, көчәеп килгән бит ул!

—Көчле шул, аны җиңү мөмкин түгелдер, ахрысы.

—Ихтыяры сыеклар җиңә алмыйдыр шул...

Теге кызлар чырайлы лейтенант Зинкель безгә Германия гербы төшерелгән паспорт—«Аус-Вайс» алырга ярдәм итте. Миңә безнең кулда барча оккупацияләнгән өлкәләрдә тоткарлыксыз йөрергә мөмкинлек биргән документ. Кайда да шул икән: «Без бумажки—ты букашка». Бу кәгазь күңелне җилкендерсә дә, кай моментта куркытып куя. Миңә хәзер килеп керерләр дә тотып алырлар сыман тоелып китә. Авыру төсне үзгәртмәс өчен тәмәке суын аз-азлап капкалап торам. Шушы минутта ук моннан

ычкынасы, юк буласы килә иде...«Аус-Вайс»ның кулга чагыштырмача җинел керүенә гаҗәпләнеп, теге ыспай лейтенант Зинкель турында уйланам. Нинди немец икән соң ул? Миннән допрос алганда, ул җөмләләрнең фикер очларын чуалткан иде. Шуның белән мине судан коры чыгарды. Моны ничек аңларга да белмәдем, хәзер дә серга төшенә алмыйм. Нинди кеше икән ул? Әллә немец киеме кигән рус кешесеме, Ходаем? Белмәссең. Ә бит төс-кыяфәтендә ниндидер затлылык галәмәте сизелә. Укыганрак, башлары томаланмаган кайбер немецлар бу Көнчыгыш компаниясенең алар өчен юньлегә булмаганын инде тоя башлаганнар булыр?

Мин бирәдән тизрәк сызуны ашыктыра башладым. Хаман вакыт үтә, янгырлы көннәр ешайды. Ә Отто һаман суза да суза. Полина сихереннән чыга алмый. Ул чын мәгънәсендә сихер-тылсым эчендә иде. Мин аяк өсте төш күреп йөрим шикелле ди ул.

—Китәбезме, юкмы, Отто?—дип тегене стенага терим. Ул үз-үзе белән көрәшкән төстә озак кына дәшми торды. Башын як-якка чайкап әйтте:

—Мин, мөгаен, китә алмам. Полина тәмам җанымны үзенә алды. Ни булыр, белмим, һаман татлылана бара, шайтан алгыры!

—Туктале, Отто, сина ирек кадерлеме, әллә шул хатынмы?

—Эх, брат, үз башыңа төшмәгәч, аңлап бетермисең,—диде Отто авыр сулыш алып.—Адәм баласының дөньяда бердәнбер бәхете бит ул! Шундый чакта минем өскә ауган бәхет.

—Әллә чынлап та ычкынгансың инде,—дидем мин аны аңларга да теләмичә.—Бу мавыгу ничек бәхет була алсын?

—Ташла, син мине аңламыйсың. Беребез печәнгә, беребез саламга... Уф!

—Ирекне хатынга алмаштырасың инде, алайса? Ә мин сиңа ышанып торам, юләр. Иректә исә йөз Полинаны үзеңә каратыр идең бит?

—Юк, Полина кебек бүтән булмаячак!

Мин бу бәхәснең файдасыз икәнен чамалап, кабат Отто күңеленә тукынмадым. Төне буе талауланып, юньләп йоклый алмыйча чыктым. Үзем генә ычкынырга туры килер, ахрысы. Ә уйлар-ниятләр Отто белән бергә китәргә көйләнгән иде. Әллә ул немецлар бирәдә калырлар, безнекеләр кайта алмас дип уйлый микән? Белеп булмый, кеше эче—кара урман. Немецны күтәп алучыларны күрдек, инде немецлар бирәдән китмәс дип ышанучылар да булыр. Адәм баласы перспектива белән яшәми, бүген-иртәгә тамагы ач булмаса, ул шуңа канәгать. Алдагысын Алла белә. Барыбер без уйлаганча бармый, дип баш ватмаска тырыша. Моңа аны ачы тәҗрибә өйрәткән. Әмма Отто ушлы, башын эшләтә белә торганга охшаган. Аңарда немец каны. Немецлар безнең кебек таркау башлы түгел. Исәпләргә, хисапларга иренмиләр.

Иртән уянгач, урын өстендә көе, Отто үзе сүз башлады.

—Мин сиңа кичә әйтергә кыймадым,—диде.—Полина авырга узган икән. Конторда безнең никахны теркәргә дә мөмкин, имеш.

—Ай-һай, эш тирәнгә киткән икән,— дим, ни әйтергә белмичә.

—Көтмәгән идем, кинәт хәл катлауланды, парин.—Ул пошаманга төшеп авыр сулап куйды. Җилкәләре салынды. Шулай булмый, күпме мәшәкать өстеңә аусын әле...

—Бер рәхәтнең бер михнәте булмый калмый инде.—Мин аны тынычландырмакчы булып сөйләнәм. Эчтән уйлыйм: юк, Отто немецлар бирәдә калыр дип уйламый. Ул «нутросы»—тәрбиясе белән совет кешесе бит. Хәер, күргәнебезчә, совет кешесенең төрлесе бар. Оттода немец каны булса да, туган туфрак тойгысы аңарда нык утыра.

—Полина әйтә: минем фамилиягә күч, Гитлер хатыны булырга теләмим,

ди. Нишләргә соң? Баланың Гитлер баласы булуы дөньяви хурлык инде, дип җылый.

—Хатын-кыз күз яше ул—крокодил күз яше инде. Чамала...—Канатланып һавада очып йөргән иде, хатын җылавы аны җиргә өстерәп төшерде. Отто тагын уйланып торгач, сүзен ялгады:

—Анысы да анысы, менә үзебезнекеләр кайткач, безне нишләтерләр? Шул эчне тырнап тора.

—Син Советка каршы берни эшләмәгән,—дип тынычландырырга тырыштым мин.—Синең ни гаебең бар? Син шуннан саклан: немецлар чигенгәндә берәр нәрсә эшләтмәсеннәр.

—Ерткычлыклары бөтен дөньяга беленде,—диде Отто, уен яшерергә теләмичә.—Хәзер аларга җиңү юк инде...—Аның сөйләү тонында милләттәшләре өчен үртәлү бар иде шикелле. Ул, төпле кеше, аерылганда да төпле сүз әйтте:

—Мин ут эчендә калам, син ут эченә китәсең, мать якасына!

Үлмәсәк, сугыштан соң очрашырга сүзләр куештык. Әйе, дуслар булып калырга антлар итәбез, адреслар алышабыз. Соңыннан берсен дә тормышка ашыра алмыйбыз. Чынбарлык барча теләк-ниятләрне пыран-заран китереп ташлый. Кайчандыр якын дус булганнарны искә дә төшермибез!

Зур булмаган станциядә алгы сызыкка якын ук бара торган составны шыпырт кына белештем. Юнәлеше дә таныш, ул тирәләрдә хәрби учениедә булырга туры килде. Билгеле, бик куркыныч иде. Машинист ярдәмчесе безнең кеше, мине күмер тендеры бортына яшерде. Төне буе паровоз туктальшлар ясый-ясый барды. Сугыш сызыгына таң атканда якынлаштык. Бөтен тирә-якта—атыш. Паровоз ак болыттай пар чыгарып туктады. Станциягә җитмәгән, япан кырда ни булыр дип шыр җибәреп торабыз. Уң якта юлга пареллель рәвештә коры үзән сузыла икән. Кинәт шуннан безнең берничә танк һәм автоматчылар күтәрелде. Аларны состав вагоннары каплый, ышыклый иде. Танк рельсларда тоткарланмасын өчен юлга щитлар тезгән булганнар. Немецларның траншеялары каршы якта икән. Алар безнең танкларны, автоматчыларны шәйләргә өлгермәгәннәрме, ни сәбәптер, безнекеләр кинәт состав артыннан көчле «Ура-а-а!» кычкыргач, кача башладылар. Немец машинисты шуны күреп икенче якка сикермәкче булып талпынды, ярдәмчесе тегене арт якасыннан эләктереп алды, авыр ачкыч белән кизәнгәне генә күзгә чалынды. Машинист «Ык-ык-ык» итте дә идәнгә капчык кебек ишелеп төште.

Алгы сызыкны әнә шулай очраклы рәвештә җай килеп бәла-казасыз үттем. Үзебезнең якта снаряд теткәләп бетергән посадка буеннан барам. Исән калган каеннар сап-сары яфракларын җир селкенгән саен коеп утыралар. Көнгә салкынлык кергән. Сентябрь урталары җиткән икән инде. Иң элек шуны әйтергә кирәк: алгы сызыкка кергән турыдан мин 50—60 чакрым төньяктарак урнашкан фронт полосасына барып чыкканмын. Формалашкан запас часть номерлары белән эзләү мәгънәсезлек иде.

Билгеле булганча, алгы сызыкның төзелеше мондый: беренче, икенче, өченче рәт итеп подразделениеләрне бер-берсеннән билгеле ераклыкта фронт белән урнаштыралар. Өченчесе шактый тылда була. Әнә шунда инде тикшерү, фильтрация, комендант частьлары.

Липки дигән фронт алды поселогына килеп чыктым. Көндез немец самолетлары һавада чебиауларга йөргән тилгәннәр кебек айкалалар, аннары бомба ташлыйлар. Әмма безнең зениткалар аларны якын җибәрми. Бомбалар читкә, буш кырга эләгә. Анда әллә ничә чакрымга оборона линиясе—блиндаж-траншеялар сузылып киткән. Поселокта көндез йөрү тыелган. Күз бәйләнү белән хәрәкәт, ыгы-зыгы башлана.

Дозорлар мине бик кырпу-кырыс тотып, комендант гаупвахтасына илтеп яптылар. Тентеделәр, барча кәгазь—вак-төяк әйберләремне, безопаска

бритвага хәтле алдылар. Тәрәзәләре тимер рәшәткәле таш сарай. Анда берничә кеше җир идәндәге саламда кайсы утырып, кайсы ятып тора, берсе ачулы, дулкынланган кыяфәтле, әрле-бирле йөренә иде. Бер-икесе хәрби киемнән, калганнарында тузган пиджәк-чалбар. Барысының да чырайлары кара коелган. Мине пиджәклеләр үзләре янына дәштеләр. Сорашу-белешү китте. Кайдан? Ничек? Кем?

Мин яшереп, шикләнеп тормадым. Берничә сүз белән сурәтләп бирдем. Болай гына кызыксыналар иде, һәркемнең үзенеке көчле, эчен тырный, үз эчләренә йомылып ачы язмышларын кичерәләр. Ни булыр, ни чыгар дип уйлары тарткалаша. Беркемнең беркемдә эше юк. Алдан берни белеп булмый. Билгесезлек астан гына җанны сава да сава. Сүздән сүзгә, хәлдән хәлгә атлатып күчеп, бәйләнешсез генә сөйләшкәндә, әрле-бирле атлаучы туктап:

—«Аус-Вайс»ны ташламыйча ялгышкансың,—дип куйды. Мин аңа берни аңламаган карашымны төбәдем. Ул сүзен ялгады.—Хәзер сине немецларга довериягә кергән дип исәпләячәкләр,—диде алга сузган кулының бер бармагын тырпайтып.—Ә моның нәтиҗәсе нинди булуын үзең фаразла...

Мин ни әйтергә белми зиһенемне туплый алмый торганда тезләрен чәнчеп башын ике учында тотып утырган какча ак йөзле, битләре эчкә баткан берәү кузгалып минем яныма килде.

—Карале, дезертирларны аталар дип әйтәләр, неужели шулай икән, ә?—дип җавап көтеп карап тора башлады. Мин аңа текәлдем, кыяфәтендә, күзләрендә рухы сүнгәнлеген чамаладым. Үзе шундый бәлагә тарыганлыгы сизелеп тора иде. Һәр тере җанда яшәү өмете дөрли. Мин ишетеп белгәннәремне әйттем:

—Юк, атмыйлар, штрафнойга җибәрәләр,—дип аңа карадым. Күзләрендә яктылык чаткылары күренгән шикелле булды. Икенче берсе:

—Унбиш елга утырталар дип тә әйтәләр.—Ул шинеленең якасын кысып, муенына шарф урады. Дер-дер калтырана, ә иреннәре резина төсле күгелҗемләнеп тора иде. Авыру булуы йөзенә чыккан.

—Штрафнойга барганчы лутчы төрмәгә утыру инде,—диде кайсыдыр.—
—Эт типкесендә булсаң да исән калуың бар.

—Юк, штрафной әйбәтрәк. Йә пан, йә пропал! Ә төрмәдә эт газабы чигәсең. Башың каламы әле, юкмы, анысы да суга сәнәк белән язган.

—Әй, гөмбә башлар,—диде әрле-бирле йөрүче аларның беркатлылыгыннан көлгән төсле.—Кем сорап тора сездән кая җибәрергәсен?

—Сталинград бик күп йотып тора ди.

—Анда хәзер чын тәмугның үзе инде. Өстән самолетлар көне-төне ут яудыра ди. Немецлар, машина кузовына басып, безнең позицияләргә пулеметтан сиптереп йөриләр икән. Безнекеләр тирән траншеяларга яшеренеп яталар, үзләрен белгертергә куркалар. Белгерттең, шунда ук мина тондыра башлыйлар. Траншеяны актарып ташлый...

—Немецлар Сталинградка кергәннәр ди түгелме соң?

—Сугышлар шәһәр эчендә бара. Һәр йорт, һәр корылма өчен. Бер этажда безнекеләр булса, икенче этажында немецлар ди.

—Мин Сталинградка җибәрүләрен сорыйм,—диде теге дезертир.—Йортлар, корылмалар арасында сугышуы уңайрак. Яшеренеп, посар җир була. Монда эшне елгырлык, үткенлек хәл итә. Иң элек ничек тә немец автоматын кулга төшерү кирәк. Үзе җиңел, тотарга җайлы, төгәл һәм шәп ата. Төзәмичә дә тидерергә була...

Аксыл йөзле, бик күп тирән җыерчыклар белән чырае челтәрләнгән теге дезертир минем янга килеп басты да, акланган кебек сөйләнде:

—Немец танклары атакага килде. Мин икенче номер белән ПТРдан атам. Пулялар танкка тия, тегеләргә берни юк. Һаман безгә таба үрмәлиләр.

Пулеметтан сиптерәләр. Икенче номер яраланды. Үзем генә атам. Танклар якынайганнан-якыная. Инде йөз метрда гына. Тирә-ягыма карыйм, траншеяда берәү дә күренми. Нәрсә бу? Танк брустверга житә башлады. Мин каушадым, ПТРга патрон куя алмыйм. Теге танк менә килеп житә. Нишләргә белми артыма борылып карыйм: ник бер жан иясе булсачы. Шунда нindидер пружина мине траншеядан өскә ыргытты һәм мин позицияне ташлап качуымны сизми дә калдым. Ә командир белән минем ротадашлар траншеяларга посып ятканнар да, танкларга гранаталар ыргытканнар. Ике танкны яндырганнар, немец пехотасы аз булган, танклар янгач, алар бүтән тыгылмаганнар... Мин менә дезертир булып «яндым». Мин үземнең чигенеп качуымны сизми-белми калдым. Бу мин түгел, әйтерсең лә бүтән зат. Юк, аң катнашмады монда, һич тә. Нindидер эчтәге мина буйсынмаган эчке көч эшләде бу хурлыклы эшне! Шушы куркаклык буламыни инде, ә? Бу бит аңсыз рәвештә килеп чыкты... Әйтегез әле, сезнең кайсыгыз шундый хәлгә төшкәне булды? Ә?—Ул әле берсенә, әле икенчесенә карап-карап алды. Барысы да карашларын кырыйга алалар, сорауга җавап бирергә җөрьәт итмиләр. Бу бит бик четерекле хәл. Һәркемнең үзенеке.

—Әллә сез курыкмый торган бүтән камырдан әвәләнгәнме, ә?—Ул туптуры миңа төбәлде. Әлбәттә, һәркем курка, курыкмый торган кеше булмый торгандыр...

***

Иртән мине сорау алырга алып киттеләр.

Тикшерүчеләр бер-берсеннән уздыра-уздыра кырысланалар иде. Мине ничек тә почмакка китереп терәргә тырышалар...

—Сине, мөгаен, вербовать иткәннәрдер, югыйсә «Аус-Вайс» бирмәсләр иде?—дип кайтарма якалы комсостав гимнастеркасы кигән пеләш башлысы төпченде дә төпченде. Мин булган хәлләрне сөйләп бирдем. Кызылармеец Отто Гитлер турында әйтми булмады. Ул ышанмады, андый фамилияле кешенең кызылармеец булуы мөмкин түгел диде. Икенче бер астан гына сынап карап утыручы аңа каршы төште. Сугышка чаклы немец автономияле өлкәсендә андый фамилияләр ник булмасын, ди. Аларны армия сафларына да алдылар... Ә бу Одесса өлкәсендәге немецлардан ди. Моннан 200 ел элек килеп утырганнар. Үзләре руслашып бетсәләр дә, фамилияләре сакланган...

—Искитмәле берни юк, мин Мәскәүдә Моисей Гитлер дигән яһүдне беләм,—ди тагын берсе. Хикмәт фамилиядә түгел дигәнне аңлатып кулын селтәде.

Пеләш баш, калын кашларын күзенә төшереп, ачуына чыдый алмыйча утыра.

—Вербовать итмәделәр дисең, алайса, нигә бу якка чыктың?—ди бу.

Үзе миңа башын күтәреп тә карамады. Шайтан алгыры, тәки мине көрчеккә китереп кысты бит. Бу сорау мине тез астыма суккан кебек итте. Ничек инде? Мин әллә нишләп киттем. Гаделсезлек каршында югалып калам мин. Бик уйлап җавап бирергә кирәк. Бу мине чыгырдан чыгарыр өчен бирелгән сорау. Үчекләр өчен шулай итә бу чокыр-чакырлы баш. Миндә ачу кайный. Ничек тә тыныч, искитмәгән рәвештә булырга кирәк.

—Ни өчен дип, фашистларга каршы көрәшү минем ил алдында торган бурычым,—дидем. Һәм кызып киттем. Соң—шундый провокацияле сораулар биреп минем патриотлык хисләремне сүндерергә тырышмагыз. Минем фашистлар белән бик каты, аяусыз сугышасым бар. Сез миңа ышанычсызлык белдереп, мине түбәнсетәсез. Мин—совет армиясе командиры. Мин үзем теләп әсир төшмәдем. Ничек булганын мин сезгә әйттем. Минем җанда үзебезнекеләргә ачу төере урнаштырмагыз. Минем әле күп сугышларда катна-

шасым бар. Ышанмыйча, кешенен жанына төкерергә һич тә ярамый...

—Отставить, молчать!—дип кычкырып жибәрде монарчы эндәшмәгән бу процессның баш кешесе. Ул аю гәүдәле, имән муенлы, тубал башлы, кирпеч битле, пенснәле.—Син онытылма! Пленга эләгү фәкать Ватанга хыянәт дип бәяләнә. Син—хыянәтче! РСФСР уголовный кодексының 193/17 б. статьясы.

—Минем Ватанга хыянәт иткәнем юк!—Мин дә, чыгырдан чыгып, бар көчемә кычкырдым.—Әйттем бит, без пленга төшүебезне абайламадык. Кем безне немец авызына илтеп тыкты, шул хыянәтче! Логика белән санлашырга кирәк. Мин моны барча инстанцияләрдә кабатлаячакмын.... Сез мине фашистларга каршы көрәштән читләштерә алмассыз. Теләсә ничек булса да, барыбер сугышчылар сафына басачакмын, хәләл канымны биреп акланачакмын...

Тамагыма ачы корым төене килеп утырды, шул туктатты. Ул көйдергеч ачы төенне эчкә йота алмый, тотлыгып калдым. Ниндидер тынлык урнашты. Барысы да теге кирпеч чырайлыга карадылар. Ул да ничектер икеләнеп торган шикелле, өстәлдәге амбар кенәгәләренең әле берсен, әле икенчесен актара. Нидер эзли, таба алмый төсле иде.

—Барыгыз!—дип гыргылдады ул, кәгазьләреннән башын күтәреп.

Мине бүлмәгә кертеп япкач, икенче бер әсирне сорау алырга алып киттеләр. Иптәшләр мина төбәлделәр. Барысының да кыяфәтендә соңгы чиккә житкән сагаю, курку. Берсе нинди сораулар биреләр дип кызыксынды. Мин дөресен әйттем.

—Штрафбатка чамаламыйлармы? Приказ бар, ди, имеш...

—Мин тылга төрмәгә жибәрүләреннән куркам.

—Анда исән калуың бар, ә алгы сызыкта үзең беләсең...

—Төрмәдә черегәнче, штрафбат «туган йорт» инде.

Ике ягыннан тоткалы су багы белән аш китерделәр. Шуның янына 600 грамм ипи порцияләре. Беркемдә дә котелок юк. Калай савытлар алып килгәннәр икән. Идәнгә утырып шулардан чөмерәбез.

***

...Ниһаять, бәдрәфкә алып чыктылар. Күрәм: безгә таба бер таныш чырай килә. Бу бит—минем элекке командирым! Кырык беренче елның декабрендә Остошково янындагы Овдотьево авылында ул—каты, мин жинел яраланган идек. Мин аны төнлә нейтраль зонадан үзебезнен якка күтәрә-тора алып чыккан идем. Ул:

—Рәхмәт, сержант! Мин сине онытмам!—дигән иде. Инде хәзер мине танымыйча үтәр микәнни?! Юк, карамый да узып бара. Мин: «Иптәш капитан!»,—дип кычкырып жибәрүемне сизми дә калдым. Ул туктады, әсәрләнеп карап торды.

—Сержант, синме?!

—Шул үзе!—дим шатланып. Шунда часовойны күрде дә, эшнең нәрсәдә икәнен бик тиз төшенде бу, берни сорап тормыйча. Без канцеляриягә кайттык. Капитан Малайчук (аның фамилиясе шулай иде) эчкәре бүлмәләргә кереп китте. Байтак озак торды. Ниһаять, чыкты. Әмма чыраеннан берни белеп булмый иде.

—Әйдә, минем белән!—дигәч кенә мине коткарганын чамаладым. Минә кинәт шулай язмышым үзгәрде дә куйды.

Без поселоктан төньяккарак ике-өч чакрым китеп калын урманга барып кердек. Анда бик күп землянкалар тезелеп киткән.

Капитан Малайчук разведка төркеменә сугышчылар туплый икән. Мин теге әсирләр арасында Назыйров фамилияле разведкада хезмәт иткән солдат

барлыгын әйттем. Малайчук Назыйровны да коткарып алып килде.

Капитан аз сүзле кеше иде. Чыраеннан да берни сиземләп булмый. Эчтән көлемсерәгән йөз белән миңа тыныч, дәшми генә карап тора. Карашы авыр, озаграк текәлеп торса, арканнан салкын елдырым аяк табаннарына кадәр төшеп китә. Аз сөйләп, күп аңлата торган зат. Аз кушып, күп эшләтә торганнардан. Җыерчыксыз түгәрәк йөз, калын кашлар астында төймә төсле кара елгыр күзләр. Чырае тыныч булганда да күзләр борчулы, әле болайга, тегеләйгә тәгәрәп кенә торалар.

Ул дошман тылына диверсия ясарга җибәрер өчен кечкенә-кечкенә разведка группалары төзергә керешкән. Биш кешелек яна төркемгә мине командир итеп билгеләде. Хикмәт шунда, әсирлеккә эләккәндә мин лейтенант идем. Аннан качып чыктым, әмма миңа элеккеге звание бирелми икән. Рядовойга төшереп калдыралар. Дәгъва белән йөрсәң, штрафбат белән яныйлар. Шунда ук шып булып артыңны кысасың. Элеккеге игелегемне искә алыпмы, Малайчук миңа сержант званиесе юллап алды. Бу чын ышаныч, аклану иде. Хәрби училище тәмамлавым да исәпләнгәндер, билгеле.

Хәер, безнең группада барысы да элеккеге сержантлар булып чыкты. Званиеләрен төрле сәбәп-хәлләрдә, төрле җирдә югалтканнар. Кайсылары минем кебек әсирлеккә эләгеп, кайсылары приказсыз чигенеп, берсе командир белән каршылыкка килеп.

Малайчук, блиндаж янындагы киртәләрдән ясаган эскәмиягә безне тезеп утыртты да, арлы-бирле йөренде. Аяк табаны астында вак чыбыклар шытыр-шытыр килеп, атлаган саен тавыш бирә иде.

—Әгәр заданиене уңышлы башкарып чыксагыз,—диде аска караган килеш атлавын белеп,—барыгызга да звание кайтарыла. Бер баскычка югары күтәрелеп кайтарыла. Әгәр элек өлкән сержант икән, аңа—лейтенант...

Эш болай тора: моннан ун чакрымнар ары уң флангта тоташ баткак сазлыклы урман бар. Урман уртасында калкулык. Немец шунда еракка ата торган пушкалар урнаштырган һәм тимер юл узелына көнен-төнен даими атып тора. Бик зур зыян сала. Ничек булса да, шул ут ноктасын—пушкаларны юк итәргә кирәк...

Шулчак связной килеп капитанны каядыр дәште. Малайчук миңа ышаныч белгерткәндәй карады һәм: «Таныша торыгыз!» дип китеп барды. Миңа, группа җитәкчесе буларак, иптәшләрне якыннанрак белергә кирәк иде.

Ратник... Пехота подразделениесеннән. Озынча йөзле, төз маңгайлы, кылыч борынлы, очлы иякле, күгелҗем күзләрендә ниндидер моңсулык сизелеп тора. Ләкин үзе шаян сүзне ярата. Елгыр, тиз кузгала торган, моның реакциясе дә тиздер мөгаен. Гәүдәгә юкарак, көче ниндидер инде, анысы эштә генә күренер. Алгы сызыкта булган, бер тапкыр җинелчә яраланган.

Дюжев—таза гәүдәле, бернигә дә исе китми торган кыяфәтле, ләкин чыраенда, бит-йөз сызыкларында ниндидер тәрбиялелек, итәгатьлелек сизелеп тора. Бу нәселдән килә торган нәрсәләрдер инде. Биредә аның бер әһәмияте дә юк, билгеле. Шулай да Дюжев ышаныч уята, ул сине авыр хәлләрдә ташлап калдырмас, сине агач атка атландырмас. Үз өстенә төшкән йөкне бүтәннәр җилкәсенә авыштырмас шикелле тоела.

Шумба—сәер фамилия, шулай да ул рус кешесе, бераз укыганчарак сүзләр кыстырып сөйләшә. Соры күзле, табак битле, текә маңгайлы. Йөргәндә үрдәк кебегрәк як-якка авыша биребрәк атлый. Бер эш эшләргә кирәк булса, иң элек ул кузгала һәм эшкә тотына.

Назыйров белән без фильтрациядә ятканда бер-беребезне «иснәшеп» дигәндәй таныштык. Омски татары. Җәлпәк чырайлы, куш иякле, эшкә дә, иптәшлеккә дә бик риясыз шикелле тоела. Әмма беркатлылыгы бар, кискен минутта шул холкы үзенә дә, якындагыларга да зыян итүе мөмкин. Икенче

көнне разведкага барасы урынны картадан өйрәндек. Буйга биш, аркылыга сигез йөз метр чамасы калку җир чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган. Тирәягы баткак сазлыклы урман... Мин поселоктагы бер карттан бу хакта белештем. Анда колхоз фермасының җәйләве булган. Калкулык уртасында тәбәнәк агач йорт, кар базы бар иде ди, хәзергесен белмим, ди.

Пушкалар ягына каян, ничек үтәргә? Шул хакта озак баш ватарга туры килде. Беләбез, гамәлдә эш һич тә алдан фараз иткәнчә булмый. Шулай да, ихтималларны аркылыга-буйга салып карамыйча күңел тынычланмый иде.

Кышкы киемнәр бирделәр. Күз үзенең көченә кергән чак. Төнлә бик нык катыра, ә көндезен бераз эретә. Янгыр белән аралаш ак күбәләкләр очканы күренә. Эчең тулы борчу, җан кайгысы, тәшвиш булганга, тирә-юнь табигать күзгә күренми икән. Малайчук кешелекле, уңган зат булып чыкты... Химиклардан блат белән алып безгә юеш үткәрми торган, бот төбенә кадәр җиткән куныччы брезент итекләр бирде. Разведчиклар өчен алыштыргысыз байлык!

Өстән караганда, чәнечкеле тимерчыбык эченә үтүнең ике төрле әмәле күренә иде. Беренче әмәл: ике разведчик ничек тә эчкә үтеп теге йортка граната ыргыта. Шулай дикъкатьне үзләренә юнәлтәләр. Төп көчләрне часовойлардан аералар. Шул моментта башка разведчиклар пушкалар тирәсенә керәләр, гранаталар белән аларны шартлаталар. Болай бик ансат килеп чыга чыгуын, шулай да бу фараз безнең хәзерге исәп-хисапка туры килә иде, шуңа тукталырга булдык. Ләкин бер тупикка барып төртеләбез: чәнечкеле тимерчыбык уратылган нигытманы ничек үтәргә? Руслар әйтмешли, менә эт кайда күмелгән!! Уйладык-уйладык та, астан керергә дигән карарга килдек.

Миндә химиклардан юнәткән бер шешә спирт бар иде. Тел ачкычы буларак, шуны чыгардым. Стаканга су өстәп иптәшләргә бирдем һәм Ратникка төбәлдем.

—Үзеңне белештерми куркынычка ташланасың,—дип сөйләде Ратник ниндидер өстенлек белән.—Ут эченә ыргылган кебек. Бер тапкыр, ике... Шулай куркуың бетә...

—Мин куркуны аң белән җиңәм,—диде Дюжев. Үз-үземә: әһә, калтырыйсыңмы, сволочь!—дия-дия бик каты сүгенәм.

—Үз-үзеңне каты тиргәү куркуны «дагаларга» ярдәм итә.—Назыйровка да курку мәсьәләсе әһәмиятле икән.

—Аң белән булмый,—диде Шумба, аның түгәрәк матур чыраенда моңсулык чагылды.

—Кемдә ничек инде!—Мин соңгы эчемлекне салып биреп әңгәмәгә йомгак ясаган кебек иттем...

Без юлга әзер идек. Тиз генә җыендык та кузгалдык. Немецларның алгы сызыгы аша узасы юк. Сазлыклы урманда окоп-траншея кору мөмкин түгел. Шуның өстенә, бу фланглары урман сазлыгы белән безнең якка чыгып тора иде. Көнгерә кебек, түмгәктән түмгәккә сикердек. Кайчак бот төбеннән бата идек. Бер-береңне тартып чыгарасың да, янә алга! Яктырганда тиешле квадратка барып җиттек. Бер юан чаган төбенә плащ-палаткадан чатыр корып, иптәшләрне ял итәргә җайлап, агач башына менеп киттем. Немецлар чираттагы ату эше белән мәшгуль. Менә тәбәнәк тягач трактор снарядлар алып килде. Әнә, туры түбәле яртылаш җиргә сеңгән йорт кәмәше. Әнә, сул кулда—пушкалар тезелгән. Арырак ниндидер корылмалар шәйләнә. Көн кояшлы иде. Күзәтергә Ратник менеп китте. Без эчтә яткан килеш тирә-юньдәге тавышларга колак торгызабыз. Болай урман тын. Менә җир дерт итеп китте, пушка ялкыны күзгә чалынды һәм ату тавышы колакны ярды. Орудие аткан чакта иң элек сигналны җир китерә. Нигә болайдыр инде ул, башта һавадан килергә тиеш югыйсә.

Ратник төшкәч, хәзинәдә бары белән тамак ялгап алдык. Аннары күзәтү эшенә Дюжев кереште. Нигәдер Ратник кирегә сукаларга тотынды. Йортны блокадалауга алынмыйм, пушкаларга граната ыргытырга мин оста, диде. Мин бер сүз дә әйтмәдем. Бәхәс корып маташа торган вакыт түгел.

Дюжев кояш төшлектән авышкач кына төште. Аның гамәли, һәр эшне булсынга эшләүче икәне һәр сүзеннән, хәрәкәтеннән беленә иде. Мин аңа чәнечкеле тимерчыбык борылып тегеләйгә киткән җирдә—почмакта ермак бар шикелле, шуны тикшер, дигән идем. Дюжев күзәткән һәм ныклы фикергә килгән: анда ермак бар, теге якка фәкать шуннан гына керергә мөмкин, бүтән урын күзәтелми, диде. Тимерчыбыкта ток булырга тиеш түгел. Ул ермакка исә мина куелган булуы бик ихтимал...

Мин, чатырда кесә фонаре яктысында кәгазьгә сызым белән сызып, кемнең кайсы ноктада нәрсә эшләргә тиешлеген тагын бер кабатлап чыктым. Ратник белән Назыйров блокировкага туры килде. Дюжев кисәтте: немецка барып тотынырга ярамый, ул физик яктан көчле. Автомат, граната белән генә эш итәргә!

Төн—корым кебек кара тоташ болытлы, талгын гына җәяүле җил исә. Кипкән куралarda сыбызгы сызгырта, әмма агач ботакларын селкетергә көче җитми. Төнге сәгать ике тулып китте. Немецлар тягачларын кабызды, аңа каяндыр снаряд төяп пушкалар янына китерәләр. Шау-шу киләләр. Без шыпырт кына теге ермак кырына барып яттык. Менә беренче пушка атты. Икенчесенә күчәләр. Мин шинельне ермак төбенә ташладым, бик иплəп-сагаеп кына ермак стенасына чокыр ясап аягымны шунда терәдем, аннары икенче аягымны стенага ныгытып, ермак төбенә иелдем. Шинель аша капшаган иттем. Берни сизмәдем. Башны күтәрдем, бер таяк белән аскы рәт чыбыкны күтәртеп куйдым. Иң элек үзем чыктым, куе кара үлән эченә аудым. Немецлар ату белән мәшәкатьләнгән арада, без эчке якка шуышып өлгердек. Берни шикләнмәделәр шикелле. Тын алырга да куркып ятабыз. Атып бетерделәр. Тягачка төялеп, кайберләре йортка юнәлде. Эчтәге курку үзен сиздерә, шайтан. Димәк, Ратник әйткәнчә, үз-үзеңне белештермичә, немец өстенә ташланырга кирәк. Шулай чирканчык алсаң, курку онытыла ул... Төн шундый караңгы, күзгә төртсәң дә күренми. Ниһаять, трактор пытырдавы тынды. Пушкалар янында ничә часовой икән? Нигәдер йөренгән тавышлар килми. Бер урында гына сакта торалармы? Тукта, чү, безгә якын пушка яныннан безгә таба пулемет ата башлады. Без куе үләннәргә сеңдек. Әллә сизеп, әллә дежур атумы? Әһә, дежур ату гына икән. Бүтән пушкалар яныннан да пулеметлар үз алларына каратып очередь бирәләр. Бер-ике минут аткач, туктадылар. Күзәткәндә шәйләнмәде, һәр пушкада—часовой һәм пулемет. Пулеметлар теге якка төбәлгән. Нишләргә? Дюжев яткан җирдән колакка пышылдый; бик шыпырт барырга һәм пушкаларга граната ыргытырга кирәк, ди. Пулеметлар тагын пырылдарга тотынды. Мин Ратникка «блокадага» ыргылырга куштым. Ул тирән канауга сикерде. Шумба белән Дюжев караңгыда юк булдылар. Мин өченче пушкага таба атылдым. Пушкага граната ыргытканда теге башта шартлау ишетелде. Молодец, Шумба үз бурычын үтәде. Үз гранатасының шартлавы Дюжевныкы белән бергә булды, ахрысы? Кинәт йөземә күсәк белән суккан кебек тоелды, мин бер якка авып җиргә егылдым. Дюжев миңа килеп төртелде, мүкәләп килә икән, Шумбаны пулемет кисте, диде. Икәүләп чыгу ягына үрмәли-шуышабыз. Дюжевның бил турысына—аркасына тигән. Бер аягын кымшата да алмый. Без Назыйровка килеп бәрелдек. Аның күкрәгенә эләккән, башын күтәрә алмый, безне сизгәч, исенә килде, сүзләрен көчкә-көчкә авызыннан төртеп чыгара иде: «Мин беттем, тикайте! Прикрою! Дай, рожок...» диде. Нишләргә? Йорт ягыннан, ары флангтан каты ут ачтылар. Килергә куркалар, башта ут

белән үтүклиләр. Дюжев шуышып китте. Мин йөрәкне өзеп йөзтүбән яткан Назыйровны тотып карыйм. Ташлап китә алмыйм. Бер минут сонарсам, ул да, мин дә бетәбез. Запас рожокны янына куйдым да теге ермакка таба атылдым. Назыйров автоматтан берничә очередь бирде. Бездән унгарак немец бәрә. Ермакта Дюжев икән, чыга алмый, мин дә сыймыйм. Киемнәрне умыра-ерта чокырга төштем. Дюжевны чыгардым. Аннары үзем күтәрелдем. Немецлар тәмам исләрен җыйдылар, чәнечкеле тимерчыбык буена вак мина тондыра башладылар. Мин Дюжевны өстерим. Ике аягы да йөрми икән. Миналар чәнечкеле киртәнең бу ягына да төшә. Кайсылары саз баткагына эләгеп, шартламый иде. Килгәндә түмгәктән түмгәккә киртәләр сузган идек. Дюжев шулар өстеннән мүкәли. Ратник кайда? Аны көтеп булмый инде. Дюжев кулын селти: анын өчен нужарма, ул югалмас, таш астыннан чыга торган зат, ди. Немец миналары бик еш төшә башлады. Ярый әле, агачлар коткара. Кәүсәләргә тиеп ярылалар. Берсе, нәләт, нәкъ ике адымда киртә өстенә төште. Дюжевнын кулын, минем ботны яралады. Ә кулбаш ярасын бәйләшле түгел, чишенеп булмый, төн бик суыткан. Яранын алгы ягына инпакетны каплаган булдым, әмма арка ягыннан кан акканы сизелә, анда да бер марля кисәге кыстырдым. Ул читкә шуды. Мать якасына! Ничек тә шуышырга, теге төштән ераклашырга кирәк иде. Аяктагы яра тамчы да авыртмый, сөяккә эләкмәгән. Дюжевнын бармакларыннан кан күп ага иде, аны яхшылап бәйләдем. Тагын шуышабыз, ярты метр, бер метр... Әле һаман караңгы, шулай да бераз сыеклана башлаган сыман тоела. Тойгылар алдаучан инде. Вакыт хакында уйламаска, алга таба мүкәләргә, түш белән сазлык ләмен ерырга да ерырга... Бүтән әмәл юк, безне әҗәл камчылап куа иде.

Тагын күпме метрлар шуышканбыздыр, минем тәмам хәлем бетте. Бүтән бер карыш шуышырлык җегәрем юк иде. Аркам, алдым кан белән чыланган, күлмәк ярага ябыша, кыймылдаганда куба, авырту баш миен кисеп керә. Юк, бүтән булдыра алмыйм, үлсәм үләрмен инде, барыбер бер үләсе... Дюжев бармы янда, юкмы, аны да белештерә алмыйм...

Күпме шулай ятылгандыр, ат пошкырган тавышка һушыма килдем. Инде көн икән, тирә-як ап-ак кар. Нәрсә бу?

Утынга килгән хуҗалык солдатлары безне күтәреп арбага салдылар...

Санбатта яраларны чистартып бәйләгәч, мине шунда ук тылга озатырга карар иттеләр. Мин командирымны күрмичә китә алмыйм, разведка данныйларын аңа тапшырырга бурычлымын, дидем. Дюжевнын хәле начарланды. Умырткасына операция ясагач, паралич сукты. Сүзен әйтә алмый, ике күзеннән яшь ага... Аны шундук тылга озаттылар.

Капитан Малайчук мине ике атнадан соң гына эзләп тапты. Белешкәндә: «Без аларны фронт госпиталенә озаттык»,—дип ялгыш хәбәр биргәннәр икән.

Мин разведка эшенең ничек гамәлгә ашуын тәфсилләп сөйләдем. Яшерен позициядәге пушкаларнын атудан туктавы, тимер узелындагыларнын иркен сулыш алулары командованиенең игътибарын үзенә юнәлткән икән. Безне III дәрәҗә Дан орденына куюю өчен документ әзерләгәннәр. Каршылыксыз үтәр төсле, диде Малайчук ышанычлы итеп. Без Ратникка ни булып бетте икән дип кайгырыштык. Мин анын холкындагы керделе-чыктылырак чалымнар сиземләвемне әйтеп тормадым. Шулай билгесез булып калды.

Малайчук белән шунда юллар аерылды. Мине тыл госпиталенә күчерделәр. Күчерә-күчерә, Казан шәһәренә китереп житкерделәр. Бирелә операция ясадылар. Яра үлек җыймый, димәк, төзәлми. Нишләргә? Минем тән ничектер башкачарак икән. Тагын операция өстәле. Беренче группа кан җибәрәләр. Бераз өметләндерә торган билгеләр күренә башлый...

Госпитальдә озак яттым. Минем янда гаурәте, йомыркасы яраланганнар

ята иде. Алар да бик озак дәваланалар икән. Әллә ничә тапкыр операциягә яталар. Бик катлаулы операцияләр. Гаурәтне юкка гына кешенең иң нечкә жире дип әйтмиләр икән. Аларның һәрберсенең билендә шешә, сидек куыгын тишеп урнаштырылган катетор шуңа тоташтырылган. Сыеклык катетор буенча агып шешәгә тула. Кыскасы, бик яман хәл инде.

Кыш буе ятарга туры килде. Кулбаш ярасы төзәлә башлаган шикелле булса, аяктагы кечкенә ярада бозылу билгеләре күчәя. Зур булмаса да, «заражение» бик хәтәр икән. Температура кырыкка күтәрелә. Тагын аңыңны жуеп ятасың. Кризистан соң рәткә килү озакка сузыла.

Мин жәй урталарында гына йөри башладым. Өченче дәрәжә Дан ордены белән бүләкләү турында указ чыкты. Миңа өлкән лейтенант бирделәр. Фронтка китәргә берничә көн кала, йоннан тукылган английский яшел гимнастерка-галифи, яловый күн итекләр, йолдызлы погоннар киеп шәһәрне карарга булдым. Госпиталь колхоз базары кырыенда гына иде. Анда инвалид, гарип-горабаның күплеге гажәпкә калдырды. Аннан Бауман урамына чыктым. Ходавәндә, монда кәстиллеләр, подшипниклы такта өстенә ике аяксыз утырган, кул култыкларын шуңа каеш аша бәйләп, кулындагы колотушкалары белән этенеп, тротуар буенча выж да выж йөриләр. Зур булмаган шәһәрдә житмешләп госпиталь бар, имеш. Барысы да хирургия буенча специальләшкән ди. Кая карама, анда инвалид-калекалар. Сугышның халыкны ничек ватканы монда ачык күренә. Шәһәр мыжлап торган гарип-горабалар оясына әйләнгән. Биредә яшәүчеләргә сабырлык, чыдамлык бирсен Ходай. Ярабби!

Мин фронтка килгәндә Витебск юнәлешендә бик зур һөжүмгә әзерлек бара иде. Госпитальдән өлкән лейтенант званиесе белән чыгардылар. Алгы сызыкта бераз эшләгәч, тагын бер йолдыз өстәлде. Миңа сапер ротасы командиры вазифасы йөкләнде. Үтеп булмаслык сазлыкларга нечкә чыбык, киртәләрдән басма төзеп кичүләр әзерләү гаять авыр иде. Гел суда, гел юештә. Аяк киеме атнага да чыдамый. Һөжүм башлангач, без төзегән кичү-юлдан пехота частьлары искәрмәстән немец тылына төште, зур группировканы чолгап алды, паника куптарды. Бөтен ныгытмаларга урнашкан фрицлар барча нәрсәләрен калдырып табан ялтыраталар иде.

Без төзегән кичүләр ярдәмендә август башында Минск шәһәре фашистлардан азат ителде. Атаклы «Центр» армиясенең берничә дивизиясе чолганышта калган иде. Аларны бүлгәләп-бүлгәләп тар-мар итеп бетерделәр. Белоруссия операциясе моңарчы күрелмәгәнчә уңышлы булды. Ай эчендә 290 чакрым алга хәрәкәт итеп, фронт Польша чигенә барып житте.

Безнең дивизия подразделениеләре бик нык сыекланган иде. Шуңа күрә тылга, пополнениегә чыгардылар. Молодечно станциясеннән ерак түгел бер жимерек поселокка барып аудык. Пополнение бик аз килә, ә сугыш кирәк-яракларын үзебез юллап чабабыз. Шулай йөргәндә мин концлагерьга тап булдым. Зур гына мәйдан ике кат чәнечкеле тимерчыбык биек койма белән уратып алынган. Күзәтү вышкалары, тәбәнәк кенә бараклар. Моны немецлар төзегән. Хәзер үзләрен китереп япканнармы? Юк икән. Немецка хезмәт итүчеләрне, төрле пособникларны жыеп тутырганнар булып чыкты. Мине өзлексез бер нәрсә борчый: ничек фашистларга хезмәт итәргә мөмкин? Совет тәрбиясе алган кешеләр туган жиргә басып кергән ерткычларга булыша, алар ягыннан торып үз Ватанына каршы сугыша. Моны ничек аңларга? Сәбәбе ничек, нәрсәдә? Бер сәбәпсез берни дә эшләнми бит. Чәнечкеле тимерчыбык аша күзәтеп торганда ниндидер таныш чалым шәйләнде. Ерактан танып булмый, билгеле. Комендантка кердем. Наганлы сержант белән барак янына килдек. Валунгаш өстендә сүнгән чырайлы, бетәшкән кыяфәтле зәңгәрсу иске мундирдан берәү утырып тора иде. Мин

аның каршына ук килеп:

—Син Ратник түгелме?—дип дәштем. Ул ялт итеп миңа карады, шунда ук таныды кебек, ләкин танымаганга салышты, йөзенә аптыраган төс чыгарды. Минем икеләнүем бетте, каты гына итеп:

—Ратник, ничек бирегә эләктең?—дидем боргаланырга урын калдырмыйча. Ул торып басты:

—Ә-ә, иптәш командир!—диде ишетелер-ишетелмәс. Сержант безне проходнойдагы бер аулакка кертеп куйды. Сөйләшә башладык. Ратник ач, хәлсез иде. Сумкамда итле бәрәңге концентраты бар иде. Пешермичә дә бик тәмле. Ратник майлы кәгазен ертты да бер почмагын кимерә башлады. Ашый-ашый сөйләде.

—Анда без ата башлауга немец та ут ачты. Назыйровка дәшәм, җавап бирми. Караңгыда югалды. Мин сиптерәм. Кинәт күз алдым яшендәй ялт итеп китте. Шуннан берни белмим. Аңга килгәндә немецлар кулында идем. Бик каты кыйнап сорау алдылар. Мин аңсызлыкка салыштым. Чынлап та берни хәтерли алмый идем. Башка нииндидер прибор куеп тикшерделәр дә, үлем лагерена яптылар. Германиягә озатыр алдыннан бер таныш очрады. Инспектор булып эшли икән. Офицер чинында. Үзе янына алды. Шуннан китте инде. Юк, мин җәза операцияләрендә катнашмадым. Мин элемтә техникгы булдым.

—Качарга җай чыкмадымыни?—Минем сораудан аның йөзе чытылды.

—Мин качсам, иптәшне атарлар иде,—дип концентратны зур гына итеп капты.—Аннары тормыш үзенә суырды.

—Барыбер ычкынырга кирәк иде.

—Иптәш мине коткарды, мин аңа хыянәт итимме?

—Ялган. Честь саклап мена нинди хәлгә төшкәнсең... Фашистка булышу.

—Юк, немецларга булышмадым. Үземне кайгырттым. Шәп яшәүдән аерылып булмады. Үзенә йотты да йотты. Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндыра, ди.

—Партизаннар ярдәм сорап килмәделәрме?

—Юк. Партизаннар турында миф бик күп. Немецлар Белоруссиядә 260 концлагерь төзиләр. Анда меңәрләгән әсирләр, җирле халык ачтан кырыла. Шул үлем лагерьларыннан берәрсенә партизаннар һөҗүм итеп карасынчы! Исе дә юк.

—Хәзер нишләрсең инде, ә?

—Безне чолгап алдылар, Көнбатышка качып булмады,—диде Ратник бик нык үкенгән, үртәлгән тавыш белән.

—Ватан хисе җаныңда бер дә юкмыни?

—Башта булгандыр инде ул, аннары бетте. Армиядә мине бик каты рәнҗеттеләр...

—Син настроение кешесе икән. Алай ярамый. Суккан өчен анага рәнҗемиләр!

—Минем атам-анам юк.

—Үлделәрмени?

Мин детдомда үстем. Паспорт алгач, заводка эшкә урнаштым. Заводтан армиягә...

—Беләсеңме, безнең разведка үзенең бурычын үтәде. Кызганыч, Шумба белән Назыйров һәлак булды. Дюжев авыр хәлдә. Безнең барыбызны да III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләделәр,—дип мин аны «сөендерергә» теләдем.

—Булмас, ышанмыйм,—диде ул башын як-якка чайкап.

—Указ армийский газетада басылды. Мина госпитальдә ятканда бирделәр. Син часть номерын онытмагансың, яз, таптыр. Бәлки, язмышыңны җиңеләйтергә ярдәм итәр.

—Немец ягында булдым, шул барысын сызып ташлый. Юк,—дип өметсез кулын селки.

—Синең хәлдә кеше саламга да тотына.

—Безнең особистлар саламга тотындырмый, беләбез.—Ул бөтенләй өметен өзгән кыяфәткә керде. Минем күңелгә авыр төер булып таш ятты.

Тагын килергә сүз биреп мин киттем. Ләкин безгә башка очрашырга язмаган икән. Эш шунда ки, немецлар чигенгәндә Советтан риза булмаган җирле кешеләрдән бандалар оештырып калдырган. Аларның милли хисләрендә уйнап, руслаштыруга каршы сылтавы белән отрядлар төзелгән. Аларны националистлар дип атыйлар иде. Бер төнне безнең частька шулар һөҗүм итте. Исне җыеп коралларны худка җибәргәнче, бандитлар ике атны алып караңгыда юкка чыктылар. Мин тагы каты яраландым. Бу юлы туры Мәскәүгә озаттылар. Ике моторлы самолет салоны киң генә. Шунда носилкаларда яралы генерал, полковниклар һәм ниндидер секретный чиннар икән. Янәшәдәге носилкада ятучыга карап-карап алам. Ничектер йөз чалымнары таныш сыман тоела. Саргылт салам чәчле, түгәрәк битле, кырынган, матур чырайлы. Ул арада сестра безгә уколлар кадый башлады. Укол кадаганда теге йөзе белән миңа таба борылды һәм мин аны таныдым. Теге әсирләрдән сорау алганда тәрҗемә итеп торучы чибәр немец лейтенанты Зинкель ич бу! Уколдан соң ул икенче якка борылды. Ә мин исә ничектер җанланып киттем, зиһенем эшли башлады. Тегенең Зинкель булуына тәмам үзем ышандым. Бераз тын алып тордым да:

—Лейтенант Зинкель?—дип дәшкәнемне сизми дә калдым. Теге ишетте, әкрен генә башын минем якка борып карап торды да, мине кем дип тә белмичә, үз ягына борылып ятты. Бер сүз дә әйтмәде. Уйланып ята иде шикелле. Әмма дару үзенекен итә иде, ул йоклап китте, минем дә керфекләремә герләр тагылгандай йомылдылар.

Һава шартлары начарлану сәбәпле, самолет Смоленск янындагы аэродромга төшеп утырды. Безгә бик яхшы әбәт бирделәр. Майлы зур ипи телеменә кызыл икра ягылган, шуның янына какао...

Ризыклангач, адәм баласының күңеле күтәрелеп китә. Теге чибәр лейтенант минем якка борылып яткан. Шуннан соң гына мин аңарда ышаныч тудырганмын.

—Сез мине каян беләсез?—дип кызыксынды.

Мин сөйләп бирдем. Отто Гитлер турында әйткәч, андагы хәлләрне исенә төшерде. Әмма сине хәтерләмим, диде. Бер-ике сүз белән үзенең разведчик булуын, Ригада немец колониясендә үсүен әйтте. Немецлар Риганы бик тиз алалар. Шул чакта Зинкель немец армиясенә «внедрять» ителгән булган икән. Дүрт ел немецларның оккупация частьларында хезмәт иткән...

—Пычак йөзеннән йөргәнсез икән,—дидем мин.

—Әйе, пычак йөзеннән,—диде ул гади генә итеп.

—Сез бит мине үлемнән коткардыгыз,—дидем,—әсирләрдән сорау алганда хыянәтчене, үз иптәшләрен сатучыны фаш иттегез?

—Мондый хәлләр күп булды, алтмышлап кызыл армия командирын коткара алдым,—дип, ул уйланып торды. Аннары дәвам итте. Һәр җайны файдалана идем. Кечкенә әмәлне дә әсир файдасына эшләдем. Мин коткарган кешеләрнең моны сизмәүләре-белмәүләре дә мөмкин. Сине кем сатканын, кем хыянәт иткәнен белү гаять читен. Барысы бер йомгакка төйнәлеп, чуалып беткән була. Мисалга шуны әйтәм. Полк командиры майор һәм аның комиссары капитан чолганышта калалар. Әсир төшкәннәр. Командир яралы, муен тамырына пуля эләккән. Комиссар җиңел яралы иде. Допрос вакытында шул беленде: командир да, комиссар да иң соңгы пуляны үзләренә атарга тиешләр. Тере килеш дошманга бирелмәскә бурычлылар. Уставта шулай

куелган. «Ни шагу назад!»—дигән приказ чыккан вакыт. Полкның барча сугышчылары әсирлеккә алына. Командир белән комиссар урман эчендәге яшерен блиндажда бары икесе кала. Комиссар әйтә командирга:

—Әнә, немецлар янда гына, әйдә, атыл, аннары—мин, ди. Командир әйтә:

—Әйдә, башта син, аннары—мин!—Комиссарның эчке заданиесе бар: кискен очракта командирны немец кулына калдырырга ярамый. Күп стратегик серләрне белә. Немец кулына күп хәрби данныйлар төшүе ихтимал. Шуңа командирны үз-үзен хәл итүне үзеннән эшләтү ягын кара! Әгәр шуңа йөрәге житми икән, үзең аның эшен бетер! Аннары үзенә расчет ясарсың!.. Комиссар моны шәхсән үзе генә белә. Командирны атыл дип кыса. Тегенең йөрәге житми. Юк, комиссар, миннән булмый, лутчы син мине үзең ат! Бетте-китте, бер шаһит юк. Давай, эшлә, мин сиңа приказ бирәм, ди... Комиссар башын селки, юк, нәрсә син мине ычкынган дип белдеңме әллә?.. Шулай тарткалашалар болар блиндажда. Ә якында немецлар кычкырып сөйләшә-сөйләшә йөриләр. Тавышлары аермачык булып ишетелә.

Комиссар командирны блиндаж ишеге төбенә алып килә һәм әнә немец автоматын безгә төбәгән дип сөйләнә-сөйләнә, арттан жинел яраланырлык итеп аның муенына ата. Командир егыла. Комиссар үзенең йөрәгенә пистолетын төби, ләкин тәтене басканда терсәге белән нәрсәгәдер бәрелә, пуля йөрәккә эләкми, кулбашына тия. Исен жуеп ава... Нинди фидакарь батыр йөрәклеләр, ә? Ватанга үзләрен беткәнче багышлаган кешеләр! Идеягә нинди ихлас тугрылыклылык! Газиз гомерләре белән санашмыйлар!

Ул чырае-кашы жыерылып, тынды. Ярасы бик нык кисеп авыртканы беленеп тора иде. Тизрәк сестраны дәште... Укол ясагач, битендәге жыерчыклар ябылды, йөзендәге газап эзләре бетте. Тәмле итеп иснәде дә авыр кабаклары күзен томалады.

Сестра миңа да морфей уколы кадады. Шунда ук яраларымның чәнчеп сызлавы басылды. Тәнемә жиңеллек, рәхәтлек жәелде. Зинкель ягына башымны бордым: ул немецлардан ничек ычкына алды икән? Ләкин Зинкель тирән йокыда. Үземнең йокы мамыгына төшеп китүемне сизмәгәнмен.

Мин биш сәгатьләп йоклаганмын. Кичке ашка уяттылар. Карасам, янәшәмдәге носилка юк. Аны ашыгыч рәвештә каядыр озатканнар икән. Теге сорауга жавапны үзем таптым. Немецлар барча нәрсәләрен ташлап чигенгәндә ычкыну әллә ни кыен булмагандыр. Бәлки, шул чагында яралангандыр да...Аңа үзебезнекеләр дә атуы мөмкин бит.

Мин Мәскәүдә «престижный» госпитальдә дәваландым. Әлбәттә, инде жай чыккан саен майор, полковниклардан Зинкель турында сораштырмый калмый идем. Ләкин берни дә белә алмадым. Чөнки Зинкель аның чын фамилиясе дә булмагандыр әле, бәлки...

Ватан сугышында нинди генә батырлыклар, үз-үзеңне аямыйча нинди генә фидакарьлекләр эшләнмәде! Нинди генә кан, жан, тир, хәләл көч түгелмәде! Очы-кырые юк андыйларның! Ни кызганыч, барысы да вакыт туфрагы астында күмелеп калды, югалды.



Ренат
Харис

# СОНЕТЛАР

## Шикләнүләр сонеты

**Көчле микән рухым? Үзем белмим.**
**Сынамады бугай беркем дә..**
**Мин үземне һич тә эзләмимен**
**баһадирлар йөргән төркемдә.**

**Ымсынулар, көнләшүләр көче**
**кайларгадыр тартып карады.**
**Сынау булды микән бу рух өчен?**
**Тарткан якка никтер бармадым.**

**Бәлки, курку гына булгандыр ул—**
**рух дигәннең боламыклыгы...**
**Ә, шик салып, җанны уйландыру**
**күрсәтмиме рухның ныклыгын?..**

**Шикләнергә гаҗәп яратам,**
**җиңәм аны чөнки, таратам...**

## Йомшак тәртип сонеты

**Без әле урлап туймадык,**
**гәрчә карак булмасак та.**
**Тыштан канун, әдәп саклап,**
**нәфесебезне тыймадык.**

**Бай ил—ул бай кешеләр дип,**
**без халыкны ышандырдык.**
**Һәм баюга план кордык,**
**урнаштырдык йомшак тәртип.**

**Кыйпылчык алырга таштан**
**чокчынасың тирләп-тирләп...**

Ренат ХАРИС (1941)—*Татарстанның халык шагыйре; Г. Тукай исемендәге һәм Россия Дәүләт премияләре лауреаты. Күпсанлы китаплар, шул исәптән 7 томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Казанда яши.*

Мамыктан була җеп эрләп—
чеметкәләп бертоташтан...

Урлап булмый үзеңнекен...
Безнең илебез кемнеке?

## Пушкин сере сонеты

*Пушкин умер в полном развитии своих сил и бесспорно унёс с собою в гроб некоторую великую тайну. И вот мы теперь без него эту тайну разгадываем.*

Ф.М.Достоевский

Син нинди сер алып киттең анда—
агач тамырлары арасына?..
Шушы сорау, Пушкин, яна канда...
Синең кургаш миндә эри сыман.

Һәр шагыйрьнең, әлбәт, була сере,
йә нәфрәтләре зуррак, йә сөюе,
йәки үкенечле бер көенү...
Серле шагыйрь гомер бакый тере!..

Ачылган сер—ачык сандык кебек—
теләгәнчә актар, тикшер төбен.
Күз туйдымы—күңел гамьсезләнә...

Синең кургаш белән минем каләм
арасына сыйган чиксез галәм
уртасында ул сер... Мин эзләнәм...

## Аваз сонеты

Бер-беренә берегергә әзер торган
авазларга нинди серле җилем кирәк?!
Аны җанда буранлаган хаос-буран,
канга сеңгән хәтер эретмәсе бирә!

Оеша Сүз! Туу—Үлем аралыгын
тәгәл дөнья итеп туплый, оештыра
һәм аңлата бу дөньяның яралуын,
һәр яңага милли исем биреп тора.

Бер-беренә сискәнешеп берегергә
әзер сүзләр ялганалар нәрсә аша?
Андый җилем җанны милли итеп үргән
язмышыбыз каны дымында укмаша.

Канның дымын халык тынына тоташтыр!
Һәрбер аваз халык тыны өчен аштыр!

## Ихласлык сонеты

Мәкерле бәхәскә тартма—
ачтырма ачу ишеген,

анда керпе сырт кабарткан—
сөңге урманы ише гел!

Нужарма баллы телләнеп,
мин балга да, җилемгә дә
кунакларга һич теләмим
хәтта ахыр чигемдә дә.

Ләкин кирәк икән нидер,
әйт турысын—ихлас бул син,
намусыңа җаның тидер.

Ихласлык иң бөек тылсым—
ул илаһи көчкә тиңдер.
Шул тылсым юлдашың булсын!

## Җәлил каны турында сонет

Һәр августның мин егерме бише көнне,
хәтер кошы булып очып җыр артыннан,
җан сәгате суккан чакта уникене,
Җәлилнең баш каны тамган ташка кунам...

Һәр февральнең унбишенче якты таңы
илһам дәрте өстәр әле диеп, юрап,
канатланып, мин Мусаның кендек каны
тамган изге тарафларны кайтам урап...

Һәм горурлык хисе миндә чиктән аша—
ул шагыйрьнең шәһит канына тоташа,
батырлыкка матурлык кушылган кебек;

ул ялгана Мусаның кендек канына—
йөрәгемдә мәхәббәт булып кабына!
Һәм яшимен халкымның мин күзен үбеп!

## Аның күзләре турында сонет

Кем ул безгә кояш-күзе белән
карап тора икән көндезен?
Җаным аны, ахры, яхшы белә...
Беләм микән аны мин үзем?

Мин чамалыйм гына... Ләкин чамам
мин белмәгән Аңнан туена...
Ә төннәрен яңа утта янам,
салкын суда гүя коенам—

Ай-күз нуры җанга сихәт яга,
пакьлек иңә сүзем, кулыма...
Ай батмаган, кояш калыкмаган
чиктә күп чак гөнаһ кылына...

Һәр төштә бар ул күзләрнең нуры.
Барлык почмак нурлар өчен туры!

## Ак кәгазь сонеты

Ак кәгазьнең эчке чиксезлеген
кем ишетә, ә кем күрә дә...
Әллә кая барып юк эзлисе—
кәгазь эчендә ул, тирәндә...

Булдыралсаң—көй-җыр тартып чыгар,
булдыралсаң—төсләр саркыт син.
Тышкарысы нәрсәгә дә чыдар,
эчкәресен ләкин ярсыт син—

шигырь, рәсем, көй нотасы итеп
ак битенә беркет барысын—
һәр кемсәнең, исе-һушы китеп,
ишетәсе килсен, карыйсы...

Кәгазь чиксезлеге—тылсымчы...
Ә син—шагыйрь, җырчы һәм сынчы!

## Казма тираты сонеты

Уйга батып, зират буйлап атлыйм...
Җан башларым монда күмелгән.
Пакьләнергә башка чара тапмыйм—
эчкәрегә аккан яшь белән.

Әни киткән чакта яз кояшы
төшкән иде салкын гүренә ...
Һаман җылы аның кабер ташы—
чыкка яки бәскә төренә.

Әти киткән чакта көзге болыт
кабер диварларын чылатты.
Шул дым, тыштан күзләремә тулып,
йөрәгемә таба юл тапты.

Җанны юа бары күз яше.
Һәм җиһанда бу су—тиңдәшсез...

## Кёнигсберг сонеты

Мин сагынып бардым, килеп бастым,
Шиллер, синең һәйкәл төбенә.
Чәнчеп-чәнчеп алды күкрәк асты...—
сизәм—анда шигырь тибенә...

Яза алмый тордым аны никтер,
кәгазь-каләм кулда булса да...
Акылымда, белмим, нинди биктер,
тоткарлыйдыр нинди бусага.

Юк, каләмем минем күзекмәгән,
ләкин җаным ят бер калыпта—
туфрагыңны безгә үз итмәгән
Фатих Кәрим каны тамып та...

Өйгә кайткач туды бу шигырь,
туган туфрак җаны булышып...

## Аралык сонеты

Озынайды кебек метрлар...
Кыскардылар кебек минутлар...
Шуңа микән әллә мин утта?
Ә җаныма бозлар утырган...

Юллар белән керфек арасы
якынайды... Ә юл томанда...
Гомер! Кая алып барасың?
Көтеп тора мине кем анда?

Җәннәт сакчысымы?.. Әлләме?..
Кайсы ачкан миңа ишеген?
Мин үкенмим, берни җәлләмим,

мин курыкмыйм, чөнки бар шигем...
Җәннәт—Тәмуг аралыгында
тукталырга разый кеше мин...

## Тиле сорау сонеты

Мин үземә үзем яшьтәшме соң?
Нинди сорау? Нинди авыздан?
Гомеремне уйларымда кысып,
елларымның маен агызам.

Исем җисемемнән аерылмады,
адымыма адым ялганды.
Җиңел җиңүләргә ябрылмадым,
күтәралмас данга алданып.

Булганыннан акыллырак булып
мин тиештер, бәлки, яшәргә?!
Ә йөрәгем тилелекләр тулы,
һәм уйларым минем шәп-шәрә...

Бәхеттерме, бәхетсезлектерме—
мин үземә тиле сорау бирдем!

## Дога турында сонет

Үз-үземә әйттем инде ничә:
нигә бер дә дога кылмыйсың—
кылган саен, диләр, җанга күчә
догаларның сихәт-тылсымы?!

Күңелемне тыңлыйм, йомып күзем:
нинди җавап аннан яңгырар!
Ә җавап юк... Әллә инде үзем,
әллә инде күңел саңгырау?!.

Әллә инде шулай ерагайган
үзем белән күңел арасы?!.
Кыска юл барында, әллә кайдан,
бәхеткә ник урап барасы?..

Җанда безнең дәвер ярасы!
Дәваларга бармы чарасы?..

## Яшь саны сонеты

Кем булганмын яралганга чаклы
бу галәмдә, нинди күзәнәк?
Шушы сорау белән мин кайчакны
иң илаһи сергә кизәнәм.

Бер нәрсә дә бар булмаган юктан...
Чиксез үзгәрешләр чылбырын
башлаган соң кайда нинди нокта?
Һәм ул нокта матди-чындырмы?

Һәр атылган саен күктә яшен,
сорыйм тизрәк кешелекнең яшен...
Тик җавап юк Бөек Сердәштән...

Мин чамалыйм бугай яши-яши:
Идея һәм матдә берләшкән—
галәм белән кеше бер яшьтә!

## Елау турында сонет

Елау күңелне чистарта...
Елыйсылар килгән саен
җан дәрьясында су арта,
җилкәнен күтәрә каек.

Керле дөнья артта кала,
син—сафлыкта һәм иректә!..
Син гүя ки—сабый бала,
сине хыялың йөртә.

Күз яшеңдәге каектан
тизрәк чыгу ягын кара—
күздә дә дәрья саега—

ташлар өскә калка бара,
сине хыялыңа илткән
каегыңның төбен яра...

## Вак-төяклек сонеты

Нидер тота кош буласы килгәндә...
Җир тартуы гына түгел, әлбәттә.
Мин—МИН түгел, ахры, һаман, ә бәндә—
үз-үземне җигә алмыйм һәйбәтләп...

Акыл көчем күтәрелгән үрләрнең
мин, асылда, итәгендә казынам,
һәм җанымның канатларын күрәлмим—
бата барам вак-төяклек базына.

Ә югыйсә, атом-аң реакторы,
буш куәткә җанымда кайнап торып,
үземне үк эчемнән харап итә...

Ә гомерләр, сиздереп, сискәндереп,
юаткычлы рәхәт җилләргә төреп,
күзләремә, битәрләп, карап үтә...

## Караңгылык сонеты

Яктылыкның үзәгендә кояш тора!
Караңгылык үзәгендә нинди җисем?
Кайчакларда күңелемне шушы сорау,
бик хәвефле хәнҗәр булып, китә кисеп.

Һәм мин эзлим караңгылык чыганагын.
Нигә эзлим? Ниемә ул минем кирәк?
Һәм кайдадыр үзәгемдә чыга янгын,
һәм сулкылдап үрсәләнә башлый йөрәк.

Мин кояшны күк йөзеннән сөртеп алам,
йолдыз, Айны офык артларына салам,
ә яктылык һаман-һаман күзгә керә.

Мин аптыраш чоңгылына тәмам чумам,
каш җыерам, теш кимерәм, күзем йомам
һәм... караңгылык үзәген шунда күрәм...

## Ялгыш тыңлау сонеты

Лалә-гөлгә тиңли сине кемдер...
Лалә-гөлләр көнгә ачыла.
Кояш нурларына, әнә, сеңде
төн серләрен җыйган тамчылар.

Син ачыла торган вакыт—төндер.
Төндә—тышаусызлык тылсымы!
Бәлки, җәннәт назларына тиңдер
шул тылсымга бергә буйсыну?!.

Каршымыни мондый тиңләүгә мин?
Бу тиңләүдә—минем теләгем:
дәрт ялкыны дигән ут аша

синең көнең минем төнем белән,
минем көнем синең төнең белән,
һич югында, уйда тоташа...

Рабит Батулла

# АПУШ—ТУКАЙ

КЫЙССА

## Тынгысыз җан

Камил мәхдүм Җаекта Мотыйгулла хәзрәт курасында 1883 елның 25 февралендә дөньяга килде. Камил сабый чагыннан ук зиһенле, тиктормас бер бала иде. Мәдрәсә программасыннан тыш, атасының бай китапханәсендәге төрле телләрдәге китапларны ул су кебек эчте. Мәдрәсәдә ун ел эчендә тулы программа үтеп чыкканнан соң, ул бушанып калды. Җаек мохитенә генә ул сыеша алмый иде, аның читтә укыйсы килә иде. Атасы-анасы киңәш иттеләр дә уларын Казанга җибәрергә булдылар. Камил мәхдүм Казанга барып, Касыйм мулла мәдрәсәсенә укырга керде. Тиктормас Камилгә мәдрәсә гел ошамады. Чынлыкта ул үзе Касыймия хәлфәләрен укытыр дәрәҗәдә белемле иде. Бер ел укуга ук ул кире Җаекка, атасы йортына кайтып китте.

Җаекта озак тормастан, тынгысыз Камил ата-анасының фатихасын алып, Төркия, Мисыр илләренә сәяхәткә китеп барды. Бу илләрнең мәгариф системасын өйрәнде, аларның әдәбияты белән кызыксынып һәм Мисырдагы атаклы университет Әл-Әзһәрдә ике ел укып, белемен арттырды.

Җаекка кайтуга ук атасы аны югары сыйныфлар мөгаллиме итеп куйды. Төркиядә, Мисырда алган белемен ул шәкертләренә тапшыра башлады. Элеккеге тәкәббер мәхдүм шәкертләр белән бик теләп аралашырга сусап кайткан иде.

Камилнең гайрәте хәттин ашкан иде, ул мәдрәсәдә мантыйк, хәдис, тәфсир, фикъһ дәресләре биреп, шулар өстенә дивар гәзитләре, кульязма журналлар чыгаруны башлап җибәрде, аннан соң мәдрәсә каршында «Гыйльми мәҗлес» түгәрәген оештырды. Җаектагы татар тормышына яңалык артыннан яңалык алып килә торды. Бу мәҗлесләрдә татары, башкорты, казагы катнашып, үзләре язган шигырьләрне сөйләп, халык җырларын җырлап, шау-гөр килә башладылар. Камил мәхдүм бу фәгалияте белән шәкертләрен, Җаектагы татар халкын уятырга, азатлыкка өнди иде. «Могыйгыя»дагы бу үзгәрешләр, бу яңалыклар мәдрәсә диварлары эчендә генә калмыйча, башкаларга да үрнәк булды. Башка мәдрәсәләрдәге алдынгы шәкертләр «Мотыйгыя»га җыела, кичәләрдә актив катнаша башладылар. Мәҗлесләрне «Ракыйбия» шәкерте Миннулла Хәйруллин алып бара, ул соңра Габдулла Кариев булып, татар театрының башында

*Дәвамы. Башы узган санда.*

йөрер, Габдуллаҗан шигырьләр сөйли, халык җырларын башкара. Озак та узмас, Апуш Тукай булып китәр. Камил әфәнде үзе язган хикәяләрне күтәртмәгә басып укый, соңра ул атаклы журналист һәм татар халкының профессиональ җырчысы булып китәр.

Мотыйгулла хәзрәт корган мәдрәсә «Мотыйгыя» ул татар халкының бөек кешеләрен тәрбия кылган, аларга киң юл ачкан мәдәният учагы булып тарихта калыр, иншалла.

Камил Мотыйгый шул вакытта язучы буларак, бик күп әсәрләр иҗат итте. Хикәяләр, пьесалар, роман. Чыннан да бу истигъдатлы егет бары тик мәдрәсәдә күп фәннәр буенча белем биреп кенә яшәсә дә татар халкының олуг мәгърифәтчеләреннән саналган булыр иде. Камил Мотыйгый язучылык белән генә шөгыльләнгән булса, һичшиксез, олы әдип булып китәр иде. Юк бит, ходавәндә! Бу кешегә Аллаһ тарафыннан күп сәләт бирелгән, ул бер төпләнеп, бер урында гына эшли алмый, ары сугыла, бире чәчелә, аны эчке куәсе шулай куып йөртә. Чак кына бушаган арада ул манарага йөгереп менеп, җомга намазына азан әйтә. Аның азан әйтүен көтеп торалар. Мисыр мәкаме белән азан әйтүче бер Камил әфәнде генә иде.

Камил Мотыйгый Мисырдан кайткач, Җаек каласының мөселман хәяте астына ут керде. Кульязма гәзит-журналлар сәләтлеләр мәйданына әверелде.

Камил әфәнденең уй-хыяллары чын гәзит, чын журнал ачып, татар халкына хезмәт итү иде. Ничә тапкыр мөрәҗәгать итеп караса да, аңа җандармерия рөхсәт итми, киресенчә, Камил Мотыйгыйны шикле кешеләр исемлегенә кертеп, аңа дело ачалар.

Камилнең бөек хыялы бары тик 1905 елда гына тормышка ашты. Мотыйгыйның хыяллары белән бергә Габдуллаҗанның да теләге бәйдән ычкынды кебек.

Соңгы елларда Мотыйгулла хәзрәттән гыйльме гаруз, Чулпаныйдан көрәш дәрте, Әмрулладан мәхәббәтнамә дәресләре алгач, Габдулла үзендә дә нииндидер бер дәрт, билгесез куә барын сизә башлады. Ул дәрт, ул куәт һичшиксез бәреп чыгарга тиеш иде. Дивар гәзитләрендә каләм тибрәтеп караган Апушны ул гына канәгатьләндерә алмый иде. Аңа мәйдан кирәк, аңа укучы кирәк.

Һәм, ниһаять, аңа мәйдан ачылды!

Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

1905 елның 26 ноябрендә Камил Мотыйгый җитәкчелегендә «Фикер» исемле гәзит чыга башлады.

Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

1906 елның 15 гыйнварендә Камил Мотыйгый җитәкчелегендә «Әлгасрел-җәдит» журналы чыга башлады.

Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

1906 елның 7 июнендә Камил Мотыйгый җитәкчелегендә «Уклар» журналы чыга башлады.

Бер-бер артлы бер типографиядә бер кеше, Камил Мотыйгый химаясында ачылган өч басма Апуштан Тукай ясады. Еллар буе читлектә, тоткынлыкта яткан бөркетләр падишасы шоңкарны богаулардан азат иттеләр: Габдулла Тукай «матбугат» дип аталган давыллы дингезгә ташланды. Йөзә белмәсәң— бет, тончык, йөзә белсәң—йөзеп чык.

Шушы «матбугат» дип атала торган гуҗны туйдырыр өчен журналистлар булмау сәбәпле, Габдулла Тукай өчесе өчен дә редактор, өчесе өчен дә шагыйрь, өчесе өчен дә корректор, өчесе өчен дә журналист булып китте.

Гәзит-журналларны алдыралар, алардан акча килә, Тукайның да матди яклары шәбәеп китте.

«Уклар» журналын Тукай тулысы белән үз әсәрләреннән чыгара иде. Бу сатирик журнал шулкадәр тиз танылып китте ки, аннан күрмәкче Оренбурда «Карчыга», «Чүкеч», Казанда «Яшен» журналлары калкып чыкты. Жаектагы татар матбугатының чәчәк атуы барча төбәкләргә дә уңай тәэсир итте, газета-журналлар күбәйгәннән-күбәя барды.

Тукайның мәшһүрлеге көн белән түгел, сәгатьләп, минутлап арта иде.

Ләкин Тукайның һәр шигыре, һәр мәкаләсе саен аның дошманнары да күбәя иде. Дошманнарның да ниндие әле, Тукайның чыбыркысына Дума депутатлары да, мулла-мунтагайлар да, гаделсез байлар да, әхлаксыз түрәләр дә, шовинистлар белән карагруһчылар да, татарның татарга зыян салучы бәндәләре дә эләгә тора.

«Таркатучы милләтне ишан икән, белмәдем, ул ишаннар милләткә дошман икән, белмәдем»; «Пәйгамбәрдән калган дин урынына килгән чегәннәрдән үзенә башка бер дин, кайдадыр исламымыз, һай-һай», «Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак; тотып ярсак боларны без заман үткәрми, картаймай», дигән сүзләрне халык арасында ятлап алып, сөйләүчеләр артты. Жыелышларда, мәжлесләрдә Тукайдан өзекләр, гыйбарәләр күрсәтеп, исбат-дәлилләр китерә башладылар.

Жандармериянең Өченче бүлеге дә тик ятмый иде шул. Газета-журналның һәр саны, һәр сүзе агентлар өстәленә килеп ята иде. Мотыйгыйга күптән теш кайрап йөргән оешмалар, Тукайны да Мотыйгый белән рәттән куя башладылар.

1906 елның азагында баш калкыткан революционерларны кайсын атып, кайсын асып, кайсын зинданнарга яба башлагач, Жаектагы кыюларның да кикриге тиз шинде. Социал-демократлар оешмасы тар-мар китерелде. Өченче бүлек Мотыйгый матбугатына каршы кара эшләр башлап жибәрде. Дума, жандармерия, депутатлар, пуришкевичлар турындагы мәкаләләре шовинистларның жен ачуын чыгарса, дин исеменнән кеше талаучы муллалар, шәригать исеменнән халыкны каралтучы ишаннар турында әче әсәрләре кадимчеләрне, кирегә сукалый торганнарның хәтәр үченә дучар иде. Шовинистлар татар кадимчеләрен сөя түгел, алар бер-берсенә нәфрәтле ике як. Менә Мотыйгый белән Тукайны юк итәргә дигәндә шушы ике нәфрәтле як дуслаша, берләшә ала.

Урал төбәгенең хәрби губернаторы генерал-лейтенант Родзянко Камил Мотыйгыйга уңай карый торган түрә булса да, өч матбага иясе Мотыйгыйга карата фикерен үзгәртте. Чөнки Мотыйгый белән Тукай өстеннән әләк артыннан әләк, донос артыннан донос килеп тора иде.

Өченче бүлек татарлар арасыннан ышанычлы шымчылар әзерләп өлгергән иде инде. Карагруһчылар белән мөселман кадимчеләре берләшеп, татарның активларына каршы погромнар оештырырга, аларны бетерергә, кайсыларын зинданга ябарга планнар кора иде.

Бу шымчыларга, әләкчеләргә Өченче бүлек шактый гына акча түли, аларга кайбер ташламалар ясый, әйтик, жир алырга, сәүдә оештырып жибәрергә аларга властьлар тарафыннан тоткарлык юк. Әйтик, шундый шымчыларның башында торучы кәвеш тегүче вак һөнәрче Шәрәфетдингә, Өченче бүлек белән хезмәттәшлек иткәне өчен, «Лично-почетный потомственный гражданин» дигән кәгазь кисәге биреп, үсендерделәр. Әнә шул «потомственный» шымчы Шәрәфетдиннең өендә яшерен оешма әгъзалары жыелды.

Бу 1906 елның 5 июле иде. Жыелышта иң актив әгъза «Лично-почетный потомственный гражданин» Хәйрулла Гаделшин хәзрәтләре дә бар иде. Сәхип Пиргин, Гайнижамал хәзрәтләр соңгарак калып килде. Жыелышны Хәйрулла Гаделшин ачты.

—Җәмәгать! Сезләр эшләрне яхшы ук аңлыйсыз булыр, майор Сафронов барыгызга да ирештергәндер шәт... Берсекөнгә, киләсе чәршәмбегә мин үзем кырык кеше әзерлимен. Аларга үзем командир буламын. «Фикер» гәзитәсенең идарәханәсендәге машиналарны, хәреф кассаларын, һәммәсен ватамыз. Камилнең үзен, бала-чагасын кыйныймыз, изәмез. Нинди тәкъдимнәр бар?

Гайниҗамал хәзрәт тамак кырды.

—Әйдә, хәзрәт, фикере касыйрыгызны җиткерегез!

—Минем тарафтан егерме гаярь егет булыр! —диде хәзрәт.—Минекеләр Тукай дигән мәлгуньне тукмаячаклар.

Шушы җыелышта ни-нәрсә сөйләнсә, барысы да Тукайга килеп ирешә, кем аңа килеп бәйнә-бәйнә сөйләгән, шунда утыручыларның берәрсеме, әллә аларны күрше бүлмәдә тынлап утырган хатыннарыннан берәрсеме, белгән юк, икенче көнне үк «Фикер»дә шул җыелышның беркетмәсе басылып чыкты. Ду килде халык. Җиденче июль көнне һәр якын урамнарга каравыллар куелды. Әгәр дә погромчыларның берәрсе генә күренсә дә халык аларны ботарлап ташлаган булыр иде. Погром булмый калды, шымчылар, кадимчеләр хурлыклы җинелде. Шуннан соң «Фикер» погромчыларның һәрберсенең исемнәрен атап, кат-кат мәкаләләр бастырды. Погромчыларны тәнкыйть итеп, Оренбур, Уфа, Казан газеталары да, Җаекның «Уральский дневник» исемле урыс гәзитәсе дә Тукайны, Мотыйгыйны яклап мәкаләләр бастырды.

Ләкин Өченче бүлек тик ятмый, бу ике куркыныч «элемент»: Тукай белән Мотыйгыйның авызын ябарга кирәк иде. 1907 елда февраль аенда губернатор фәрманы белән Камил Мотыйгыйдан каширлек һәм мөхәррирлек хокуклары алынып, аның үзен дә, атасы Мотыйгулланы да суд җаваплылыгына тарттылар.

Шулай итеп, 1906 елның 15 гыйнварында ачылган «Әл-гасрел-җәдит» журналы унҗиде сан чыгып, 1907 елның 27 маенда юкка чыгарылды.

«Уклар» гәзите 1906 елның ноябрендә ябылды.

«Фикер» гәзите 1907 маенда яшәүдән туктады.

Бу Мотыйгыйга да, Тукайга да авыр тәэсир итте.

Судта Мотыйгый белән хәзрәтне тагын шул ук адвокат Рудольф яклап чыкты. Төрмәдән котылу шатлыгыннан Мотыйгый тагын «Яңа тормыш» исемле гәзитә чыгарырга йөри башлады. Ләкин аңа матбугат тотарга рөхсәт итмәделәр. Тиктормас Камил гәзитәне бай сәүдәгәр Мусин җитәкчелегендә чыгарырга рөхсәт алды.

Ләкин аның гомере дә озын булмый. 1909 елда февраль аенда губернатор фәрманы белән «Яңа тормыш»ның да гомере өзелде.

Тукай шушы кыйналышларны кичергәнгәме, өч редакциядә җигелеп, тузан арасында, кургаш хәрефләрне җыя-җыя, дымлы подвалда яшәп, шунда еш кына куна калганына күрәме, авырый башлады. Ул йөткерә, туна, аның тәне кызыша торган булып китте. Гәзитләрне-журналларны ябып бетергәч, ул шактый төшенкелектә яши, бу аның рәнҗүле рухын изә иде. Җаектагы дусларын, шәрикташләрен, остазы Мотыйгулла хәзрәтне, Камил әфәндене калдырып, ул хәрби хезмәткә каралырга дип, Казан ягына, туган авылына кайтып китте.

## Хаста

Казан өстендә азан тавышы:

—Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр...

Мәчетләр манзарасы. Мәһабәт манаралар, айлар балкый... Җигүле атка утырган бер мөселман мәчеткә бара... Җәяүле агайлар намазга ашыга... Мәчет капкасы төбендә берничә теләнче хәер көтеп утыра.

—Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр...
Әшһәдү әллә иләһә иллаллаһ,
Әшһәдү әллә иләһә иллаллаһ...
Бер теләнче:
—Ишеттегезме әле, Тукай үлем хәлендә ята икән бит!—ди.
—Ишеттегезме әле, Тукай үлеп ята икән.
—Әстәгъфирулла, ни булган?—ди бер ир.
—Кырау суккан, кырау,—ди икенчесе.
—Чихүтке, чихүткесе азган...
Баягы теләнче:
—Духтыр багып караган, өч көн үмере калган, тубирклиз ачылган дип атькән...

Казан өстендә чиркәү чаны гизә. Чиркәүләр манзарасы... Яңа туган айны сытып кергән хачлар күренә... Христианнар чиркәүгә җыела... Чиркәү эчендә поп, кандил белән төтен таратып, кешеләр өстенә «изге су» бөркеп йөри:
—Господи помилуй сущего раба твое-го-о...
Чиркәү ишеге төбендәге хәерчеләр сөйләшә:
—Слышали, татарский поэт Абдулла Тукаев при смерти, говорят!
—Ты что милай, он же ишшо молодой был...
—Молодой-то молодой, но в сурьез болен был...
—Ну фиг с нем, одного гололобого меньше будет на свете...
Поезд алга ыргый.
Бер ир-җегет тәрәзәгә карап утыра. Ул бик хәвефле күренә. Чибәр чырайлы бер татар зыялысы, ул Ауропача киенгән, тирән уйда, аның колагында бер сүз:
—Тукай үлем хәлендә! Тукай үлем хәлендә!
Эче пошуга түзәлмичә, кеше купедан чыга, ул коридор тәрәзәсенә карый. Агачлар, урманнар, болыннар артта кала, тәгәрмәчләр тыкылдый:
—Тукай үлем хәлендә! Тукай үлем хәлендә!
Поезд зур вокзалга туктый. Перронда халык кайнаша. Бер ир, алъяпкыч бәйләгән йөкче, тартмалар, капчыклар күтәреп поездга ашыга.
Бер городовой читтәрәк басып тора. Күзгә курсисткалар чалынып китә. Бер мөселман агае таягына төенчек аскан. Кешеләрне ырып-ерып бер шымчы килә. Ул туктап җитмәгән поезд тәрәзәләренә бага, кемнедер эзли, күзәтә.
Баягы теләнче дә шушында чуала. Вагон тәрәзәсендә баягы пошамандагы чибәр җегет чырае күренә, ул перрондагы шымчыны күреп ала, сагая. Тиз генә икенче вагонга китә. Ул дамаларга, офицерларга бәрелә:
—Пардон, мадам! Извините! Простите!—дип йөгерә.
Шымчы да аның башка вагонга күчкәнен шәйләп, кемгәдер ым кага. Теләнче перрон буйлатып, җегет йөгергән якка таба чаба.

Язгы көпшәк кар каплаган кыр буйлап чана юлы сузылган.
Таякларга эленгән салам учмалары—маяклар—юлның ике ягында чайкала. Атлар чаба, кыңгыраулар зеңгелди. Атлар пошкыра. Бер олауда чибәр йөзле бер татар кызы, олаучыга аркасы белән утырган. Бу туташ та бик борчулы күренә. Атлар чаба, шөлдерләр, кыңгыраулар зеңгелди.
—Һәйдә, бахбай!—диеп кычкыра олаучы.
Кызның йөзе, йөзендә авыр уйларның чаткысы:
—Тукай авыр хәлдә! Тукай авыр хәлдә!

Бер кеше читлек эчендә бәргәләнә. Кара киемле кешеләр сөңгеләрен әлеге затка төзәп, әкрен генә урап кысалар, адәмнең баш очында ике башлы кара бөркет талпына.

—Нигә мине читлеккә яптыгыз? Ни өчен мин төрмәдә?—дип кычкыра кеше.

Артта бер тавыш янгырый:

—Тукай!

Бәргәләнгән кеше—Тукай уяна, ләкин әле өнме бу, төшме икәнен анламый.

—Ачыгыз зиндан ишекләрен! Минем ни гаебем бар! Ачыгыз!

Сөнгеле шәүләләр, кара бөркет юкка чыга, поездда килгән кеше, алак-ялак каранып алганнан сон, тагын дәшә:

—Тукай! Сиңа ни булды?

—Ә? Кем бар?—диде Тукай.

Әлеге кеше Тукай янына ук килеп:

—Бу мин, Хөсәен!—диде.

Тукай инде айнып бетте шикелле, ул:

—Хөсәен әфәнде, хөрмәтле дустым!—диде.—Сине күрер көннәрем дә бар икән.

—Салкын тидергәнсең, ахрысы,—диде Хөсәен.—Даруын...—дип өстәл өстендәге күп кенә шешәчек, тартмачыкларны актарырга алынды.

—Куйсанчы, Хөсәен,—диде Тукай.—Даруга гына калгач, булмый инде ул.

—Ни сөйлисең син, дустым?—диде кунак.—Димәк, телеграммалар дөрес сөйли?

Тукай, гаҗәпсенеп, кунакка бакты:

—Нинди телеграмма ул?

—Редакцияләргә телеграмма килде. Имеш, Тукай каты авырый. Имеш, Тукайны хастаханәгә салырга җыеналар икән,—диде Хөсәен.

Тукай инде куркыныч төшеннән айнып бетте, әмма икенче бер шом аны биләп алды:

—Мин беркемгә дә телеграмма сукмадым, Хөсәен дустым. Кем эше икән ул? Дөрес, өченче көн минем янда доктор булып китте. Ләкин ул һични әйтмәде. Гап-гади бер бизгәк авыруы, үтәр, диде.

Хөсәен иркен сулап куйды, аннан соң:

—Шулай була күрсен,—диде.—Юкса, котны алдылар.

Икесе дә тынып калды. Бераз шулай утырганнан соң, Тукай:

—Төш күрдем бугай мин, Хөсәен,—диде.—Имеш, урамда мин, нәмаешта. Халык белән бергә каядыр барабыз. Шатланабыз, кычкырабыз. Кинәт күктән зур каракош атылды. Ике башлы зур каракош кешеләрнең башларын, күзләрен чукырга тотынды. Мин кычкырам, каракошка ташлар атам. Аннан кинәт кенә үземне читлектә күрдем... Читлектә, төрмәдә...

—Төш түгел ул,—диде Хөсәен.—Өн ул. Без барыбыз да төрмәдә. Без барыбыз да читлектә. Кемнендер читлеге таррак, кемнекедер кинрәк. Аерма бары шунда гына. Царизм—халыклар төрмәсе.

Тукай өстәп куйды:

—Бигрәк тә мөселман халыклары өчен, бигрәк тә татарлар өчен, төрмә генә түгел—җәһәннәм ул Русия.

—Дөрес,—диде Хөсәен.—Җәһәннәм булды. Әмма җәһәннәм булып калмаячак. Хөррият, азатлык, тигезлек, туганлык киләчәк Русиягә, Габдуллаҗан. Аның өчен тагын бер революция кирәк.

—Шулай, булды бит инде бер революция!—диде шагыйрь.—Кан белән сугарылды җир. Революцияне асарга агачлар житмәде. Каберләр өч аршын түгел, менәр сажин чокыр хәлендә казылды.

—Тагын кан коелачак, тагын дарларда мәетләр чайкалып торачак!—диде Ямаш.

Тукай, авыр уйларын куарга теләгәндәй, кинәт:

—Ташла, Хөсәен дус,—диде.—Кил бер көрешик үзебезчә...

Хөсәен Тукайга ике кулын сузды. Көрештеләр.

—Исән-саумыни син, Хөсәен, хөрмәтле Ямашыбыз!—диде Тукай.

—Үзен исән-амансынмы, Габдуллажан!—диде кунак. Тукай:

—Мин исән, ә менә син югалдың, Ямаш,—диде.

Хөсәен янәшәдәге урындыкка утырды да:

—Безнең эш сезнекенә караганда яманрак, Габдуллажан,—диде.—Исем үзгәртәбез. Ике көнгә бер фатир алмаштырабыз. Розыск игълан ителгән мина. Эзлиләр. Минем баш хәзер бик кыйбат тора, дустым... Әле менә—Уфадан...

Тукай җанланып алды:

—Уфадан?.. Гафури ни хәлдә анда, Уфада?

—Гафури да, синең сыман, борын салындырып утыра,—диде Хөсәен.— «Баш алып бу җирдә тормый, бер тараф качмак булам»,—ди. Качып кая бармак була? Япония мөселманнарынамы? Әллә төрек солтанынамы, олтан булырга? Барыгыз, бар. Анда сезнең ерак әбиегез кияү коймагы пешереп, мунча ягып көтә, ди.

Тукай елмайды, аннан соң кычкырып көлә башлады. Бүлмәгә нур инде, Хөсәен Ямашка да җинел булып китте. Тукай әйтте:

—Мунча үзебездә дә бар, Аллаһка шөкер. Өченче отделениенең ләүкәсе бик шәп кыздыра, ди анда.

Ямаш Тукайга сокланып карады, аннары әйтә куйды:

—Беләсенме, Тукай, сина көлү килешә. Валлаһи, килешә. Көл син, Габдуллажан. Синең асылында көлү ята.

Тукай кинәт көлүеннән туктады да, үпкәләгән кыяфәттә:

—Син, Хөсәен, комплиментларынны барышняларына калдыр!—диде.

Ямаш, эчкәрәк кергәнен аңлап, эшне җайлау ягына кереште:

—Үпкәләмә, җан дус. Турсайма бала кебек,—диде.

—Көл әйдә, көл,—диде Тукай.—Көлү сина да килешә.

—Иҗатында көл син, сатираң шәп бит синең, чукынмыш. Хәзер татарга Тукай көлүе кирәк.

Тукай бик яхшы белә лә сатира язарга кирәк икәнен. Мәскәүләр көн саен «якадан тота». Хуҗалар урынында монда ишәкләр утыра: килмешәк урыслар белән килмешәк татарлар, күсәкләр. Күрәсең монда, көн саен бер гәзитәнә арест салсалар. Театрлар ябыла тора. Артистлар мескен хәлдә. Көләрсең, көлә-көлә үләрсең.

—Революция җиңелде,—диде Ямаш.—Бусы әле баласы гына. Олы революция алда. Киләчәк революция синең сатираңны сорарга килде, Габдуллажан. Илдә кап-кара реакция хөкем сөрә. Революция попутчиклары чери, таркала. Интеллигенция үләргә йөз тоткан. Кемдер авылга качты. Кемдер жандармериягә сатылды. Халык шомлы тынлык эчендә яши. Халык көтә. Сатира-юмор көтә. Шушы шомлы мохит эчендә дә шаяра-көлә белә торган лидер кирәк. Күрсәт, Тукай, татар зыялыларының үлмәгәнлеген, курыкмаганлыгын. Самодержавиенең дарлары, зинданнары, канлы якшәмбеләре генә баса-сыта алмаган рух барлыгын аңласын халык. Көл син, Габдуллажан. Көлү сина бик килешә, синең тешләрең тигез, матур. Анда, Уфада Гафури җылап утыра. Монда, Казанда Тукай пыскый. Кая керер урын юк, кругом юеш. Татар халкына суык тигән, ул ютәлли. Татарны кыерсытканнар—ул җылый. Татар ютәленә дәва юк. Җылак татарны юатучы булмаячак. Татар халкы хәзер ажгырып торган дәрьяга ташланган сабый хәлендә. Йөзә белсә—чыгар, белмәсә—тончыгыр...

Ямаш туктады, тынлык эчендә Тукай үзалдына:

—Йөзә белсә—чыгар... Белмәсә—тончыгыр...—ул тагын көләргә тотынды, көлеп туктагач, әйтте:—Шигырь ич бу, Хөсәен дустым. Усал. Чыннан да усал, рәхимсез сүз әйттең, Ямаш. Йөзеп чыгарлык булмаса, халыкның яшәве нигә кирәк? Бетсен ул халык! Син чибәр җегет кенә түгел, син революционер гына түгел, син куәтле тәрбияче-өндәр дә икәнсең. Рәхмәт!

—Рәхмәтуллаһи галәйһи,—диде Ямаш.—Анысын Аллаңа әйтерсең. Минем өчен рәхмәт—ул син язган шигырь!

Хөсәен Ямаш кинәт сагаеп калды, ул, колакларын торгызып, ишек ягына башын кыегайтты да, пышылдап:

—Анда коридорда кемдер бар. Кайсы яктан китеп була?—диде.

Тукайга да шөбһә иңде кебек, ул каушап калды, алак-ялак карангалады да:

—Менә моннан кит!—диде. Ямаш ашыгу аша:

—Яз син, Габдуллаҗан, яз! Синең котылышың—язуда!—дип, Тукай күрсәткән ишеккә сикерде. Тукай язарга утырган булды.

## Теләнче

Шулчак ишек шакыдылар һәм, рөхсәт тавышы ишетелгәнче үк, бүлмәгә теләнче керде.

—Кем ул? Нигә болай тәкәллефсез?—диде Тукай.

Теләнче, исе китмәенчә генә:

—Бу мин әле, базар хәерчесе,—диде.

Тукай, башын күтәрмичә генә:

—Уз, әйдә, уз, Печән базарының кәләпүш карагы, Карамалай, синме?—диде.—Ыштан төшә, каеш юк. Каеш буыр идең, каеш алырга акча юкмы? Әнә, өстәлдә бер сум! Уз, нәрсә карап каттың анда?

—Уздым!—диде теләнче.—Узма, дисәң дә узам. Уз, дисәң дә узам.

Ишек катында әвәләнүче килмешәккә Тукай, текәлебрәк караганнан соң:

—Карамалай, синме соң бу?—диде.

Чакырылмаган кунак, бер дә исе китмәенчә генә:

—Малай дисәң дә ярый. Бабай дисәң дә, үпкәләмәм. Мин үпкәле белмим. Артыма типсәң дә үпкәләмәм. Кабахәт дип сүксәң дә зарланмам. Үпкәли башласаң, бу дөньяда үпкә җитмәс. Шулаймы, Габдуллаҗан әфәнде?—диде.

Тукай җиңелчә генә ютәлләп алды, ул нидер әйтмәкче иде, ютәле аның теләгән бүлдерде, аның каруы, теге мөштәри сүзен җәтрәк әйтеп куйды:

—Үпкә сиңа да бик кирәкле нәрсә!

Хәерченең төрттереп әйткәне Тукайның ачуына барып кадалды, ул:

—Яп авызыңны!—дип кычкырды.—Ишекне дә яп, җил кертәсең.

Бәндә көлә башлады:

—Хи-хи-хи, шигырь белән сөйләшүчеләрне тыңлавы кызык та соң. Авызымны да ябам, ишекне дә ябам,—дип, ишекне тыгызлабрак япты.

—Кем син?—диде Тукай.

—Хәерче!—диде кергән кеше.—Менә... Тукай үлем хәлендә дигәннәр иде дә... хәл белергә килдем.

Тукай сагаеп калды:

—Кем үлем хәлендә?—диде кырыс кына.—Каян алдың син бу сүзне?

—Бөтен базар сөйли, бөтен мәчет әһелләре әйтә: сине бик чирле, диләр.

Сөйләшергә сүз бетте, чыгып кит, дигәндәй, Тукай катгыян әйтте:

—Йә, хәзер әйт, сиңа монда ни кирәк?—диде.

Хәерче әрсезрәк булып чыкты, ул Тукайның шелтәсен шаяруга борып җибәрмәкче булды:

—Эндәшә батыр утынчы: сиңа миннән ни кирәк?

Сәер хәерче бу, сүзенә җавап табып булмый, шактый укымышлы, ахрысы, бу теләнче дигән нәмәстәкәй, туктале, моның белән сүз куертып багыйм дип, Тукай:

—Син Шүрәлемени?—диде. Теләнче тагын көлде:

—Тапкыр әйттең, Тукай. Логика! Батыр утынчы сүзләрен әйткәч, әлбәттә, мин Шүрәле булам инде. Ләкин әз генә хаталанасың, шагыйрь, мин Шүрәле түгел, мин—Шәүлә!

—Шәүлә!—дип кызыксынды Тукай.—Кушаматыңмы?

—Юк!—диде теләнче.—Кушаматым түгел, үзем Шәүлә.

—Кемнән төшкән күләгә соң син?—диде Тукай.

—Күләгә түгел, шагыйрь, шәүлә!—диде теләнче кистереп.

—Күләгә белән шәүләнең аермасы бармыни аның?—диде Тукай.

«Шәүлә» ишек катыннан түргәрәк узды һәм укучысына дәрес аңлата торган мөгаллим кебек, ишекле-түрле йөренә башлады:

—Агачның күләгәсе була. Койманың күләгәсе була. Кешенең дә була күләгәсе. Күләгә ул хуҗасына ияреп йөри. Яки хуҗасы янында тик тора. Шәүлә күләгә булалмый, шагыйрьҗан. Шәүлә—ул җисемнең үзе. Кояш баеп беткәч, офыкта агачларның күләгәсе түгел, шәүләсе кала. Шул мохиткә, ягъни Кояш баешка берәр кеше килеп керсә, кешенең күләгәсе түгел, шәүләсе күренәчәк. Күләгә куркыныч түгел. Күләгә Кояш яктысында гына була ала. Көндез. Ә шәүлә шомлы, шәүлә куркыныч, чөнки шәүлә, кеше шәүләсе һәрвакыт куркыныч җинаятьләр тирәсендә йөри.

Кеше туктады да, йә, ни әйтерсең дигәндәй, Тукайга сораулы бакты.

—Кызык фәлсәфә!—диде хуҗа.—Чыннан да, шәүлә—башка, күләгә башка булып чыга икән шул. Тукайга җинеллек өстәде бу килмешәк теләнче. Ул башка хәерчеләргә бер дә охшамаган. Баш бар бу бәндәдә, дип уйлады шагыйрь, үзе кычкырып әйтте:

—Моңарчы бу турыда уйламаганмын да. Кызык кеше син, Шәүлә!—диде.

Соңгы сүзләр ихлас әйтелде һәм алар мактау сүзләре вә ышаныч белгертү булып ишетелде: Шәүлә кыюрак түргә узды да сөйләр өчен янә тын алды, як-ягына карангалап:

—Син шагыйрь, Тукай,—диде, бүлмәгә хуҗа булгандай.—Син күп нәрсәне матур хыял аша күрәсең. Хыялларның барысы да тормышка аша алмый. Тормыш катлаулы, бай нәрсә. Тормыш ул парадокслар белән бизәлгән... Әйтик, синең тирәдә шикле кешеләр йөри. Алар сиңа дус булып күренә. Синең тирәдә сиңа каршы фикер йөртүчеләр дә күп, син аларны үзеңә дошман санныйсың. Төче телләре синең дошманың булуы ихтимал. Тегеләре чын дусларың булуы да бик мөмкин. Дошманнарыңны син иркәлисең, дусларыңа каршы таш атасың булып чыга. Чөнки синең холкың шундый, Тукай... Шулай итеп, син холкың аркасында үзеңә дә, халкыңа да, әдәбиятка да зур зыян эшлисең.

Шәүлә туктады. Сүзе беткәннән түгел, аның сүзе бетәргә бер дә охшамаган, ул Тукайны сынар өчен туктады булса кирәк, һәм ялгышмады: Тукай уйда иде. Чакырылмаган бу хәерченең мантыйкый фикер йөртүе Тукайны нишдидер, моңа кадәр аңа таныш булмаган фикерләүгә этәрә кебек иде.

—Син шактый оста сөйлисең, Шәүлә,—диде Тукай.—Әмма әдәбиятка... халыкка... зыян эшләүче мин түгел.

Кунак көлемсерәде:

—Тукай үзенә зыян эшли икән, халыкка да зыян эшли, чөнки Тукай—халык шагыйре.

Тукай кинәт хәерчегә күтәрелеп, туры карады:

—Кем син?—диде ул ярым кызыксыну вә ярым ачу белән.

—Шәүлә, дидем ич инде!

—Кем шәүләсе?

Тукай кыза бара иде, аның кызганын күреп, Шәүлә дә куркып калмады, киресенчә, кыланган сымаграк итеп:

—Бөек держиморда, патша самодержавиесенең ике башлы каракошы һәм дә урыс шовинизмы Шәүләсе мин!—диде.

Тукай аптырашта иде, Шәүлә бу сүзләрне артык җитди һәм, шул ук вакытта, ачуланырга урын калдырмаслык итеп, кыланып әйтте кебек. Шәүлә көлә башлады. Янәсе, ул шаяра.

«Мондый сүзләр өчен бүген—каторга!»—дип уйлады Тукай.

Шәүлә Тукайның уйларын укыгандай:

—Безгә, хәерчеләргә каторга ни дә, катыргы ни, барыбер катасы!—диде.—Ярлы янудан курыкмый. Хәерче хөрriяттән шүрләми.

Бу кеше Тукайга ошый иде.

—Кызык кеше син!—диде хуҗа.—Ни белән тамак туйдырасың?

—Күрәзәче мин, Абдуллаҗан,—диде кунак.

—Чегәнмени?

—Сорашма, Тукай, чегән дә, черт та түгел мин, күрәзәче!

Ул Тукайга якын ук килеп, аның кулын алды:

—Багыйммы?

—Яле, әйтеп бир, минем турыда ниләр беләсең?—диде Тукай.

Шәүлә инде Тукайның уч төбен бирелеп тикшерә, ләкин үзе хуҗа сүзләренә колак сала иде:

—О-о, Апуш хәзрәт,—дип сөйләнә-сөйләнә ул уч төбендәге сызыкларны карый.—Мин синең турыда күп нәрсә беләм... Ләкин әүлиялек өчен түләргә кирәк, хуҗам.

—Әнә, өстәлдәге бер сум көмеш синеке!—диде Тукай.

—Юмарт кеше син, Тукай,—диде Шәүлә кулдан аерылмыйча гына.—Алай икән. Ярый... Юмарт булсаң, юмарт бул, тагын ни бирәсең инде?

—Әле син киләчәгемне әйтмәдең бит, һаман мин бир!—диде Тукай шаткөр тавыш белән.

Шәүлә өстәлдәге бер сум көмешне барып алды да, бер дә исе китмичә генә янә Габдулланың учына текәлде һәм, үзалдына сөйләнгәндәй, салмак, мыңгырдык тавыш илә әйтте:

—Базардагылар әйтә, имеш, син сорап кергәнгә соңгы тиенеңне биреп чыгарасың. Имеш, синең бүлмәң тулы кеше була икән. Бүген мин беренче булып килгәнмендер әле... Шулай бит...

—Ялгыштың, Шәүлә, мин һәрвакыт ялгыз,—диде Тукай.

—Син алдаштың, Тукай... Ярый, шулай да булсын ди... Һу-у, сызыклар... юллар... үзгәрешләр... Һу-у, Габдулла Тукай, сине алда яңалыклар көтә...—күрәзәче серле итеп елмайды, кеткелдәп алды һәм әллә ниләр вәгъдә итә торган тавыш белән:—Мәхәббәт!—диде.—Кара чәчле, кара кашлы, кара күзле, чибәр кыз. Ул сиңа гашыйк. Син дә аны чит күрмисең шикелле...—Күрәзәче уч төбендә ырымлый-сихерле янә әйтте:—Зур гына байлык синең кесәгә менә керәм, менә керәм дип кымырҗып тора. Тик ачык кына әйтә алмыйм, ул байлык байлыкмы, әллә теге кызмы? Ә-ә, минемчә, алар икесе берьюлы керә. Син бер бай кызына өйләнәчәксең!

Тукай дөньясын онытып күрәзәче сөйләгәннәрне тыңлый, үзе ышанып та куя кебек, шул ышануы аңа шатлык китерде, әллә бу йолкышның

кыланмышлары аның күңелен күтәрдеме—Тукай көлә башлады:

—Шактый остаргансың син, күрәзәче. Мәхәббәте кирәк түгел, акчасы булса ярый,—диде ул.

Аңа кушылып чакырылмаган кунак та көләргә тотынды:

—Мин сине яратам, Абдуллаҗан,—диде ул.—Шаянлыгыңны, шигъри усаллыгыңны, тугрылыгыңны... «Ошбу милләт ертыгының җөен җөйлим. Җебем—кара, инәм каләм булыр имди. Көн-төн донос ясыйсың, вөҗдансызсың тидия». Надо же бит, әй! Шулай әйтергә кирәк бит, әй. Суга печ иткән җүләр син, Иблискә юлдашчысың!

Шәүлә тыйлыгып көлә дә көлә. Аның көлүе дә кызык иде, ул җиңе белән авызын каплаган, черек-чалыш тешләрен күрсәтергә теләмиме, авызыннан сасы ис бөркелмәсен дипме, шулай авыз каплап көлә, аның үз гариплеген капларга тырышуы ул гариплекне тагын да арттыра иде.

Тукай кинәт туктады, ютәлләп алды да кырыс кына әйтте:

—Ярый, булды, Шәүлә, мин эшкә утырам! Бар!—диде.

Шәүлә, рөхсәт-ни сорап тормастан, өстәлдәге казыны алып сындырды, сыныкларны үлчәп карады да зуррак өлешен ашый башлады:

—Тәшәккүр, Тукай, ләббәйкә, Тукай!—дип, иелә-бөгелә, артка чигә-чигә чыгып китте.

## Зәңгәрсу чәчәк

Ишектә ул Фатих Әмирхан арбасына килеп бәрелә язды. Арбаны тәгәрәтеп йөртүче Мәхмүт олан аны тотып калмаган булса, хәерче мотлак Фатих әфәнде өстенә утыра иде.

—Пардун, гафу итәрсегез!—дип Шәүлә юк булды.

Тукай инде өстәле янына килеп, кәгазьләр актара башлаган иде, Фатих ишек яныннан ук:

—Җыен әтрәк-әләм хәерчене син җыеп ятасың!—дип кычкырды.—Аннан, теге әйбер югала, бу әйберне табып булмый, дисең.

Тукай ачуланмыйча гына, үз эше белән мәшгуль буларак:

—Хәерче түгел ул, әфәндем, философ! Күрәзәче!—диде.—Беләсеңме, Фатих дустым, ул миңа күрәзә ачты. Уч төбемә карап, дөп-дөресен әйтте дә бирде. Син дустыңа ук атасың, ди. Дошманнарыңны иркәлисең, ди. Хак бит, Сәгыйть Рәмине ничә тапкыр рәнҗеттем. Мотыйгыйны ничә чәнечтем. Сүнчәләйнең бәгыренә ук аттым. Бичара Бикчурага миннән көн юк. Ә бит алар дус. Чын дуслар. Дөрес әйтә бит бу йолкыш күрәзәче.

Фатих Әмирханның арбасы Тукайга шактый якын килеп туктады. Мәхмүт, бер кырыйга китеп, китаплар караштыра башлады.

—Йолкышларың күбәеп китте әле синең бу арада,—диде Фатих Әмирхан.

Ләкин Тукай аны тыңламый иде, аның башында нинди дер бер хафалы уй пәйда булды кебек.

—Фатих дустым,—диде ул.—Минем авыруым турында редакцияләргә син телеграмм суктыңмы? Уфада да шул турыда телеграмм алганнар.

Фатих бу хәбәрне ишеткәч, кинәт Тукайга туры карады:

—Мин дә шуны ишетеп аптырадым, синең үзеңнән сорамакчы булып килдем,—диде.

Тукай, кәгазьләрен ташлап:

—Кем таратты икән бу ялганны? Доктор түгелдер бит?—дип куйды. Фатих дәшмәде.—Кемгә кирәк булды икән соң бу нәрсә? Хөсәен Ямаш атылып кайткан. Аңа Казанда күренергә ярамый бит. Ул розысктагы кеше.

—Димәк, кемгәдер кирәк!—диде Фатих.—Кемгәдер синең авыру булуың кирәк.

—Ә мин авыру түгел!—диде Тукай. Икесе дә тынып калды. Икесе дә авыр уйда иде. Тынлыкны тагын Тукай бозды:

—Күрәзәче әйтә, менә-менә синең кесәгә байлык керергә тора, ди. Кара кашлы, кара күзле бер гүзәл алдында тора, ди.

Тукай көләргә тотынды.

—Ни булды сиңа?—диде Фатих Әмирхан.

—Бәйрәм булды! Бүген иртүк күңел күтәрүчеләр генә керә минем янга. Мин көч сизәм, Фатих әфәнде. Миндә куәт бар. Язам әле мин, Аллаһы боерса, язам. Сатира язам, көлке язам!

Ул кара савытын ачып, кәгазь өстенә иелде. Фатих, кулына гәзитә алып, үзалдына сөйләнгәндәй:

—«Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен. Кирәк түгел, мәгънәсе юк көлке уен», дип кем әйткән?—диде.

Тукай дәшмәде. Агабәк Мәхмүткә ишарә ясады, тегесе, кесәсеннән чыгарып, Фатихка кәгазь кисәге сузды. Кәгазьне алып, Фатих:

—Күрәзәчең дөрес әйткән!—диде. Тукай язуыннан аерылмыйча гына:

—Нәрсәне, Фатих?—диде.—Ә-ә, дус-дошман турындамы? Дөрес шул!

—Юк,—диде Фатих.—Акча мәсьәләсендә, дим. Күрәзәчең аста синең исемгә Сиражидан килгән йөз сумлык извещениене укыган. Мә!

Фатих кәгазьне Тукай алдына ташлады. Тукай, кәгазьне алып, андагы саннарны укыгач, балаларча шатланып:

—Рәхмәт, дускай!—диде.—Сыйланабыз икән бүген. Теге күрәзәче Шәүлә соңгы казымны алып чыгып киткән иде.

Фатих хәйләкәр көлемсерәп, Тукайга карап янә әйтте:

—Мәхәббәт турында да төгәл әйткән. Монда кергәндә күрәзәчең залда утыручы туташны да күргән, Зәйтүнә туташ анда син бушаганны көтеп утыра.

Тукай акча кәгазен ташлап, кинәт үзгәрде, каушап, кабалана башлады:

—Ничек? Кем? Кайда?—диде ул.—Әйт, өйдә юк, диген.

—Тиле!—диде Фатих Әмирхан.—Ул синең өйдә икәнеңне белә бит.

—Әллә ничек бит әле бу, Фатих, бүлмә җыештырылмаган,—дип Тукай әйберләрен күчерештергәли башлады, ләкин өйне рәтлисе урында, тагын да ныграк туздырып ыргытты.

—Каушама,—диде Фатих.—Әнә, борының тирләп чыкты. Нәрсә шашасың ул кадәр? Тирләгән борын белән гүзәл туташлар кабул итә алмассың, тынычлан.

Тукай нишләргә белмәгәннән сөлгесен алып битен сөртә башлады.

—Юк, Фатих, бар, чыгып әйт: авырый, диң, хәйлә тап инде, син оста бит. Һич югында, әнә, Мәхмүт төшеп әйтсен.

—Үзең әйткәндәй, син җүләр балык, Тукай!—диде Фатих Әмирхан.—Ни ара җир узып килгән. Сине күрү аның өчен бәхет. Бөтен иҗатыңны яттан белгән туташны кире бору ахмаклык булыр иде, әфәндем. Высший кругларда «мужиклык, мокытлык» дип атала ул.

Тукай малай кебек турсайды:

—Без синең кебек высший кругларда әйләнмәгән шул...

—Кызганыч!—диде Фатих. Высший кругларда капкорсаклы байлар гына түгел. Анда Пушкин да, Лермонтов та, Дәрдемәнд тә бар.

—Ни сөйләшим мин ул туташ белән?—диде Тукай.—Үзе һаман сөлгесен йомарлап йөренә дә йөренә.—Вәт, җүләр балык, әйләнәм дә тулганам.

—Җүләрен җүләр инде син, Тукай,—диде Фатих Әмирхан.—Ләкин балык түгел. Җүләр гашыйк син!

Тукай йөрүеннән туктап:

—Анысы нәрсә тагын?—диде.

—Мәҗнүн син бүген!—диде Фатих, Мәхмүткә китәргә ишарә ясады.

Мәхмүт арбаны чыгу ягына таба борды. Тукай үзен ташлап китүләреннән куркып, арбага каршы төште:

—Ни турында сөйләшим соң аның белән? Син бит үзең затлы туташлар белән күп мөзакәрә кылган кеше, өйрәт!

—Утызга җитеп килгәндә дә хатын-кыз белән нишләргә кирәклеген белмәгәч, ник тудың, ә?—диде Фатих.

—Утызда түгел, егерме җидедә генә әле, картайтма!

Моңарчы тыны чыкмаган Мәхмүт пырхылдап көлә башлады. Фатих Әмирхан да елмая иде. Тукай гына шөбһәдә.

—Шигырь сөйлә!—диде Фатих.—Мәзәкләр сөйлә. Бер күрер өчен ни җир килгән бит бичара кыз.

—Тәсмәгы бин Мөгайди хәйрен мин ән тәраһе!—диде Тукай.—Мөгайдинең үзен күреп белгәнгә караганда ишетеп кенә белүе яхшырак.

—Алайса, үзе килеп кочаклаганын көтеп тик утыр, җүләр балык сыман,—диде Фатих. Аннан соң җитди итеп өстәп куйды:—Туташны озак көттерү килешми! Сөйләшергә сүз табалмасаң, сораштыр. Мичегезгә ничә ипи сыя, туташ, диген. Аяк калыпларын белеш. Йә үзең белгәннәрне сөйлә. Чистайда мишәрләр, Алабугада керәшеннәр яши, диген. Французлар французча, урыслар урысча сөйләшәләр икән, диген. Бетте!

Фатих кулы белән ишарәләде, Мәхмүт арбаны чыгышка таба этте. Ишеккә килеп җиткәч, Фатих:

—Узыгыз, туташ!—дип кычкырды. Ишектә кыюсыз гына бер кыз күренде.

Фатих Әмирхан, Тукай да ишетерлек итеп, туташка пышылдаган булды:

—Шигырьләрен мактамагыз, җене сөйми мактаганны. Шигырьләрен хурламагыз, хурлаганны да яратмый... Кичерегез, мине бүлмәмдә кешеләр көтә!

Туташ арбага юл сапты. Мәхмүт арбаны алып чыгып китте дә ишекне япты. Бүлмәдә Тукай белән туташ икәвесе калды. Сүзне кем башлаячак? Әлбәттә, туташ башлар һәм шулай булды да.

—Исән-амансызмы!—диде кыз.

—Узыгыз, утырыгыз!—диде Тукай.

—Сезне хастаханәгә салганнар икән, дигәннәр иде...

—Мин сау-сәламәт.

—Сөендем, рәхмәт.

—Ни өчен?

—Сез сәламәт булган өчен...

Шунда сүз өзелде. Икесе дә сөйләшер өчен сүз эзли иде, ахрысы. Бу юлы да туташ өлгеррәк булып чыкты. Ул:

—Мин бөтен хастаханәләрне йөреп чыктым. Юк, диләр. Ә сез бүлмәгездә, сау-сәламәт. Шөкер.

Туташ, кулындагы чәчәк бәйләмен кая куярга белмичә, күзе белән эзләнә иде:

—Хөрмәтле Тукай әфәнде, бу чәчәкләр сезгә,—диде ул бераздан.—Бу чәчәкләр сулмыйча озак тора. Шулай да, суга утыртып куйсак, яхшырак булыр иде.

Тукай савыт эзли башлады һәм тәрәз төбендә торган буш пыяла савытны өрә-кага:

—Менә бу банка...—диде.

Туташ җәт кенә аның янына килеп, банканы тотты да:

—Үзем!—диде.—Зинһар, борчылмагыз, Тукай әфәнде. Бу эшләрне мин үзем эшләргә яратам...

Тукай банканы ычкындырды, туташ өстәлдәге артык нәрсәләрне алып, чәчәк савытына урын әзерләде дә, юынгыч янына барып, банкага яртылаш су салды. Банканы өстәл уртасына утыртып куйды. Шулчак аның карашы өстәл өстендәге яңа языла башлаган кәгазьгә төште.

—Кичерегез,—диде туташ.—Мин сезне эшегездән аердым бугай.

—Борчылмагыз, туташ,—диде хуҗа.—Зарар булмас.

Туташ бая Тукай күрсәткән урындыкка утырды, Тукай да нишләргә белмичә, каршы урындыкка яңы белән урнашты. Уңайсыз бер мохит барлыкка килде. Икесе дә сүз башларга форсат көтә. Икесе берьюлы тын алып, сүз башламакчылар иде, бер-берсенә комачаулаганнарын сизенеп, шып туктадылар.

—Э-э...

—Беләсезме, Тукай әфәнде,—дип башлады кунак кыз.—Мин сезне күптәннән күреп йөрим.

—Ие-ие,—диде шагыйрь.—Мәдәният йортында безне таныштырганнар иде...

—Ана кадәр дә мин сезне күп мәртәбәләр күрдем,—диде кыз.

Сүз тагын өзелде. Тагын форсат көтәргә, сүз табарга кирәк.

—Беләсезме, Тукай әфәнде,—диде туташ.—Ни өчен матурлык билгесе булып чәчәк санала?

Ярый әле чәчәкләр бар бүлмәдә, хәзергә сүз гел чәчәк тирәсендә әйләнә, яшьләрне кыен хәлдән чәчәк коткарды шикелле. Тукай:

—Уйлаганым булмады,—диде. Сука тагын ташка терәлде, Тукай матур теманы дәвам итәргә теләмәдеме, кисте дә куйды. Ләкин туташның болай гына чигенергә исәбе юк иде, ахрысы, ул янә сүз тапты:

—Җегет кызга, кыз җегеткә ни өчен чәчәк бәйләме бүләк итә? Тантана вакытларында кешеләр бер-беренә чәчәк бирә. Мәшһүр шәхесләрне чәчәккә күмә халык. Карабодай, ясмык белән рәттән адәмнәр гөлбакча үстерә. Ни өчен?

Тукай кыска гына:

—Чәчәк үзе матурлык бит,—диде, үзе, туташ китергән чәчәк бәйләменә үрелеп, сабы кыска бер чәчәкне алды, алды да шул чәчәккә текәлде. Тукай өчен бу котылыш иде, чөнки карарга чәчәк бар, тотарга чәчәк бар.

—Гаҗәеп матур!—диде Тукай.—Нәкъ мин яраткан төс.

Туташ, ирексездән, елмайды. Ул канәгать иде, шат иде. Син китергән чәчәк кешегә ошый икән, син биргән бүләк дөрес сайланган икән, шул куаныч китерә дә инде. Җитмәсә, Тукай зәңгәрсу чәчәккә карап, нәкъ мин яраткан төс, диде. Туташның өстендә дә нәкъ шундый, фирүзә төсендәге күлмәк иде. Туташ, чәчәккә карап әйтелгән бу сүзләрне үзенең күлмәгенә багышланган, дип уйлады. Күлмәккә карата әйтелгән сүзнең күлмәк иясенә атап әйтелгән булуы бик мөмкин бит?.. Туташ куануын яшерә алмый иде инде. Ул арада Тукай карашын чәчәктән аермыйча, сүзен дәвам итте:

—Зәңгәр төс. Зәңгәр чәчәк. Зәңгәрнең дә иң нәфисе—зәңгәрсу төслесе. Бәгыремә, каныма якын иң матур чәчәк бу, туташ. Бу чәчәккә карасам, авыру чагым булса, савыгам мин. Кайгылы чагым булса, күнелем күтәрелә. Илһамсыз каңгырап йөргәндә, иҗат дәртем уяна. Рәхмәт сиңа, Зәңгәрсу Чәчәк!

Тукай чәчәкне туташның күлмәк якасына кадарга уйлаган иде дә, тыелып калды. Туташ аның бу теләген күрде, аңлады. Туташ чәчәк аша әйтелгән бөтен сүзләрнең дә үзенә аталганын сизенде. Бәлки, ул хаклы түгелдер? Тукай аңа түгел, туры мәгънәсендә чәчәккә сөйләгәндер бу сүзләрне.

Шуна күрә ул да ачык мәгънәле сүз әйтергә кыймады, үрелеп, савыттан ак чәчәк алды; алды да, нәкъ Тукай кебек, чәчәктән карашын аермыйча гына сөйләнә башлады:

—Гаҗәп бер гүзәллек! Ак чәчәк—минем сөйгән чәчәгем. Аклык ул пакьлек галәмәте. Ак чәчәк—иң нәфис, иң саф чәчәк. Чәчәкле җәйне сөйсәм дә, мин ап-ак карлы кышны яратам. Күзләрне камаштырырлык ап-ак кар өстенә карасаң, эреп югаласың. Бернинди башка төс юк кебек тоела башлый. Ап-ак кар яуган кыр өстенә карасаң, вакыт югала, дөньяның матдилеге онытыла. Син хыял дөньясында эреп юк буласың... Бу ак чәчәк мина шул ап-ак кышны хәтерләтә. Кышларын ап-ак карга багып, мин шушы ап-ак чәчәкне искә алам. Бу чәчәк—минем иманым, бу чәчәк—минем саф хисләремнең билгесе, Габдуллаҗан әфәнде,—дигәч, туташ ак чәчәкне Тукайның күкрәк кесәсенә кадап куйды. Чәчәкнең сабагы кесәдә булып, таҗлары-касәләре өстә калды.

Тукай туташның бу эшенә карышмады, киресенчә, ак чәчәк янына зәңгәрсу чәчәкне дә кесәсенә тыкты. Ике чәчәк янәшә балкый башлады.

Туташ күзеннән Тукайның бу хәрәкәтләре читтә калмады. Алар икесе дә хисләнгән иде.

—Хисләр билгесе итеп адәмнәр сүзләр уйлап чыгарган,—диде туташ, урынына утыргач.—Хисләр билгесе итеп, музыка, җыр чыгарганнар. Хисләр билгесе итеп кешеләр чәчәк бүләк итүне уйлап тапканнар. Япуниядә чәчәкләр теле бар икән. Нәфрәтләрен дә, кайгыларын да, мәхәббәтләрен дә алар чәчәк аша әйтәләр икән. Шулай дигәч, минем бер дус кызым: «Нәрсәкәй, әллә япуннарның теле юкмы?»—диде.

Тукай баядан бирле инде кыз сөйләгән дөнья мохитендә утыра иде: ул инде тарсынмый, ул туташ белән теләктәш, фикердәш иде.

—Телсез түгел алар!—диде Тукай туташ фикерен дәвам иткәндәй:—Телсез түгел. Мәхәббәт телдән калдырган аларны.

—Сез мине аңладыгыз, Тукай әфәнде,—диде туташ.—Гыйшык аларны мәҗнүн ясаган.

—Табигатькә гашыйк алар,—дип дәвам итте Тукай.—Күк йөзенә, диңгезгә, таш-тауларга гашыйк алар. Ә гашыйк кеше күп сөйләшми. Артыгы белән гашыйк кеше гыйшкы утыннан янып көлгә әверелә. Телдән кала. Сүзе бетә. Хәтта үлеп гашыйк булган кайберәүләр, янып үлмәс өчен, үз мәхәббәтеннән качып йөри. Гади мәхәббәт ул куркыныч түгел. Ә бөек мәхәббәтнең һәр ике якны да яндырып, көйдереп ташлавы ихтимал. Ике шырпы бер-берсенә үлеп гашыйк булганнар, ди. Ниһаять, алар кавышканнар. Кавышып, башларын башка тидерүгә гөлт итеп ут чыккан. Ике шырпы икесе дә янып көлгә әверелгән, ди.

—Чи усак утынындай чыш-пыш пыскып ятканчы, олуг ялкында янып бетүең мең кәррә артык,—диде туташ.

Кызның бу кинаяле җавабыннан Тукай бик тә канәгать иде.

—Ә сез, туташ, олуг мәхәббәт барына инанасызмы? Нәрсә ул мәхәббәт? Күпме шагыйрь гомерен баглаган шуңа җавап эзләп! Аңлы кешелек әле дә булса мәхәббәтнең ни-нәрсә икәнен төп-төгәл генә әйтә алмый.

—Бәлки, төгәл җавап кирәк түгелдер дә, Тукай әфәнде? Төгәл җавап әйтелсә, мәхәббәтнең, гыйшык утының калыбын коручылар табылыр иде. Бөтен кеше үз хисләрен шул калыпка куып кертергә тырышыр иде. Аның мәхәббәте бер төрле. Минем мәхәббәтем гел икенче төрле. Әлбәттә, һич шөбһә юк ки, олуг мәхәббәт бар. Мин инанам. Менә сезне, Тукай әфәнде, яратучылар аз түгел!

Сөйләшү агышы кинәт үзгәрде дә куйды. Матур гына барган бу әңгәмәгә, шигъри сөйләмгә гади, анык тема килеп керде. Туташ ялгышты бугай.

Тукайны ул куркыта язды кебек. Тукай да бу сүзне ишеткәч, кинәт үзгәрде һәм канәгатьсез генә:

—Туташ!—диде.

Шушы бер сүздә, сез ни сөйлисез, тузга язмаганны дөрес булса да сөйләмәгез, кем миңа гашыйк булсын, кебегрәк мәгънә ята иде.

Ләкин әйткән сүз, аткан ук, кире чигәргә урын тар иде, туташ искәрмәстән башланган сүзне басым ясап дәвам итәргә булды:

—Сезне яшертен генә сөюче ханымнар, туташлар бихисап, Тукай әфәнде!—диде кыз бәхәскә урын калдырмастай итеп.

Тукай бу катгыян белдерүгә каршы көлемсерәде дә:

—Рәхмәт инде, туташ,—диде.

—Сез уенга алмагыз, Габдуллаҗан әфәнде,—диде туташ.—Мин дөресен әйтәм һәм төгәл белгән кешеләрне күз алдында тотып сөйлим.

—Ни өчендер, моңа кадәр берәүсенең дә телдән әйткәне булмады.

—Гашыйк икәнеңне әйткәч, гыйшык кача икән бит, Тукай әфәнде. Сүз мәхәббәтне үтерә... Әнә шул сезгә гашыйк булучылар һәммәсе дә сезне аерым, үзенчә сөя. Шөһрәтегез өчен. Сезне бай дип уйлаучылар бар. Байлыгыгыз өчен. Сезне күреп белмәгәннәр баһадир гәүдәле дип уйлый, каһарман булганыгыз өчен. Яшертен гашыйк булганнарның кайберәүләре... сезнең вөҗүдегез, иҗатыгыз, иҗтимагый хәлегезне белеп, сезне саклар өчен, үзе өчен түгел, бичара татар халкының бердәнбер җаны булган туры Тукайны саклар өчен җанын фида кылырга әзер. Көймә бата, йота торган балык өчен фида булган мөрәүвәтле бер җан кирәк.

Тукайга бу сөйләшү авыр бер ләззәт бирә. Һәр әйтелгән сүз ишарәле, мәгънәле, астарлы иде. Бу туташ ун иреңә, йөз суфиеңа торырлык акыллы фикерле. Ул Тукайны үз сүзләренә ышандыра ала иде. Тукайны куркытканы да әнә шул тәэсир көче. Тукай шушы туташ зиһенендә туган ихтыяр куәтенә кол булудан курка. Шуңа күрә ул тизрәк бу сөйләшүгә чик куярга теләде бугай:

—Туташ!—диде ул.—Хөрмәтле Зәйтүнә туташ, минем вөҗүдемне, хәлләтемне берәү дә белми. Ихлас әйтәм, хәтта күрше бүлмәдәге дустым Фатих Әмирхан да белми...

Тукай тын алыр өчен туктады, ләкин тын алгач та тиз генә сүзгә күчмәде. Бүлмәдә тынлык. Бу тынлык авыр түгел. Икесе өчен дә сөйләшмичә утыру рәхәт иде. Бу тынлык сүздән дә яхшырак аңлашыла иде булса кирәк.

—Туташ,—диде Тукай.—Мин үземнең хәләтемне һичничек тә сезгә аңлатып бирә алмам. Зинһар, минем тупас, гади сүзләрем сезне рәнҗетмәсен... Сүз кирәк түгел... Кешеләр дәшмичә дә бер-берсен яхшы аңларга тиеш... Сез дә мине аңларсыз...

Тукай тагын туктады. Мәгънәле озын тынлыктан соң туташ сак-салмак тавышы белән сүз башлады:

—Сабый чакта мин каз бәбкәләре сакларга ярата идем. Күзем гел күктә була торган иде. Оныгым тилгән күзле, дип уйлагандыр инде әби. Мин тилгәннән битәр болытларга карыйм. Ап-ак болытлар. Күпереп торган болыт таулары. Шул таулар күз алдында әкрен генә үзгәрә. Кайбер болытлар арысланга охшап кала. Ике өркәчле дөя, мәһабәт чал сакаллы Алып бабай күктә йөри. Ап-ак болытларга карап йөри торгач, ялгыш бер бәбкәмнең аягына басканмын. Аягы имгәнде шул бәбкәмнең. Үкереп җыладым. Төнлә саташып уяна торган идем. Әти-әни куркуга калды. Соңыннан сөйләделәр. Баланың зиһененә көч килмәгәе, дип курыкканнар. Интекмәсен дип, барыбер мал булмас, дип әткәй Заһир абыйга бәбкәмне чалырга кушкан. Заһир абыйның кулына ябышканымны белештермәдем дә. Җыладым, сугыштым, тәки чалдырмадым бәбкәмне. Аягын бәйләдем, чыралар белән

як-яктан ныгыттым. Көннәр, атналар буе тәрбия кылдым. Кулдан ашаттым, эчерттем—барыбер терелттем. Шуннан бирле ярдәмгә мохтажларны карарга, тәрбия итәргә күнегеп киттем...

Туташ туктады. Тукай ул сөйләгәннәр тәэсирендә иде. Гарип бәбкә күтәреп йөрүче кызны ул аермачык күрә иде кебек. Сабый кыз янында тагын бер күләгә пәйда булды—сабый бер ир бала. Монысы Тукайның бала чагы иде. Тукай елмайды да әкрен генә сүз башлады:

—Кырлай урманында еш була идем мин. Урманга баргач, җиләк җыючы малайлардан юри читтә йөри идем. Адашмасын дип, малайлар: «Габдуллаау»,—дип кычкыралар. Мин бер урында сәгатьләр буе утырам. Кояш төшеп өлгермәгән аланчыкларда абага, балтырган үсә. Үләннәрдә, пәрәвезләрдә, чәчәк касәләрендә бихисап сәйләннәр, аллы-гөлле тамчылар тирбәлә. Тәгәрәп төшмәсеннәр, дип, селкенергә дә куркып тик утырам. Күзем шул сихри сәйләннәрдә. Озак карап утырганда шундый халәт барлыкка килә. Шул матур сәйләннәрне җыясы килә башлый. Алар чын сәйлән кебек тоела.

Бервакыт түзмәдем, җыярга дип үрелдем. Бөтен асылташлар җиргә коелды. Чәчәк, кыйммәтле бизәкләрдән арынган патша хатыны кебек, шыр ялангач калды. Якында гына миллионлаган асылташлар. Шунда мин аңладым: ул асылташлар мәңге дә минеке булмаячак. Шуны аңлагач, олыгаеп киткәндәй булдым...

Туташ та Тукай сөйләгәннәрне терелтә күз алдына китереп утыра иде, ул Тукай хыялындагы, шагыйрь хәтерендәге сабый Апушны да, сихри урманны да ачык күрә, ул хыял дөньясында. Шул сихри-серле мохитта янә Тукайның моңлы тавышы ишетелде:

—Икенче бервакыт, сабын күбеге кабартып уйнаганда, тагын нәүмиз калдым. Сабын күбеге һавада очканда гаҗәеп матур шар була. Могҗизалы шарда салават күпере төсле йортлар, тәрәзә шәүләләре күренә. Шул шарны тотып карыйсы килә. Матурлыкны озакка саклыйсы килә. Тотасын—матурлык та, тылсымлы дөнья да шундук юкка чыга... Төшемдә әллә ничә тапкыр чык тамчылары җыйдым. Төшемдә әле дә сабын күбеген тотам. Шул матур шарны тотам да рәхәтләнеп капшап карыйм. Ни кызганыч, менә, ниһаять, сәйләнем дә, матур шарым да булды, дип сөенечемнән кычкырам да уянып китәм...

Тукай сөйләгән саен җитдиләнә, сагышлырак була бара, хәтта, аның сөйләнүе фаҗигале бер сурәт барлыкка китерә иде сыман, туташ әнә шул сагышны, шул фаҗигане күрә кебек. Тукай иркен сулап куйды, ул әйтәселәрен әйтеп бетерде кебек, хәзер инде йомгак кына ясыйсы калды:

—Бар шундый кул җитмәс, кеше акылы җитмәс нәрсәләр... Бая сез әйткәнчә, мәхәббәтне аңлатырга кирәк түгелдер, ихтимал. Салават күперен тотарга тырышу ахмаклыктыр, ихтимал. Ана карап сөенергә генә, сокланырга гына кирәктер? Бәлки ак болытлар да, ак кардагы бушлык та, аландагы сәйләннәр дә бары хыял гынадыр? Шулай хыял килеш алар яхшырактадыр. Ихтимал...

Ул кинәт туктап, туташка карады: туташ җылый иде. Тукай аптырадыйөдәде. Нигә җылый туташ? Аны ничек юатырга?

—Туташ сезгә ни булды? Сезнең күзегездә яшь!—диде Тукай; ул урыныннан торып туташ янына килде, ләкин, нишләргә белмәгәннән, янә аптыраашта туктап калды, аннан соң ишекле-түрле йөренә башлады.

—Болай гына...—диде туташ.—Сез бик тәэсирле сөйлисез. Гап-гади нәрсәләрне дә ничектер сагышлы итеп әйтәсез.

—Кичерегез, туташ,—диде шагыйрь. Туташ дәшмәде. Зәйтүнә туташ чынлыкта бу сәяси-кинаяле сөйләшүне үзе башлады. Тукай аның тел төбен

шундук анлап алды. Һәм алар бер-берсенә булган чиксез мәхәббәтләрен анлаттылар, ләкин ул мәхәббәт кояш кыйпылчыклары төшкән сәйлән тамчылары вә сабын күбегендәге сихри дөнья кебек әрвахи мохит иде сыман. Туташ үзен кулга алды. Төзәтенде, елмайгандай итте, ул инде җыламый иде.

Кыз урыныннан торды.

—Мин бик озак утырдым,—диде.—Зинһар, миңа тагын килергә рөхсәт итегез, Тукай әфәнде...

—Ихтыярыгыз, туташ,—диде хуҗа.

—Тәшәккүрдән гаҗизмен!—диде дә туташ бүлмәдән чыкты.

Тукай япа-ялгыз бүлмә уртасында тырпаеп калды. Ул йөгереп чыкмак булды, ләкин эчке бер куәт аны тотып калды. Ул ишек катына килеп, туташ тоткан җиз тоткычны сыпырып:

—Хуш, гүзәлем!—диде.—Хуш, ак чәчәккәй!

Шагыйрь әкрен генә тәрәзәгә килде, ян диварга сыенып урамга, аскы якка карады. Ул ераклаша барган туташ гәүдәсен йотлыгып күзәтә иде. Сонра салмак атлап өстәл янына килде, ак чәчәкне үпте дә язарга утырды. Шулчак ишек ачылып китте, ишек ачыклыгында арбалы Фатих Әмирхан күренде. Мәхмүт арбаны тәгәрәтеп эчкә алып керде, ишекне япты.

—Җә!—диде көр тавышлы Фатих.—Булдымы?

Тукай ризасыз вә игътибарсыз калды, ул кәгазеннән аерылмыйча:

—Нәрсә «булдымы»?—диде, «булдымы» сүзенә аеруча басым ясады.

—Анлашу булдымы, дим?

—Булды.

—Димәк, эш пешә?

—Нинди «эш»?

—Димәк, шуңа өйләнәсен?

Тукай бу юлы түзмәде, каләмен ташлап, Фатихка гаҗәпсенеп карады:

—Ни сөйлисен син, Фатих туган? Нинди өйләнү? Кемгә?—диде.

—Атаң башына!—диде Фатих.—Туташның кәефенә караганда сез матур сөйләшкәнсез.

Тукай сабырланды, ул Фатих Әмирханга житди карап:

—Сөйләштек лә без, Фатих, ләкин аңлашмадык шикелле,—диде.

—Ничек анлашмадыгыз?—диде Фатих.—Шул гомер буенамы?

Тукай янә хыял дөньясына аяк атлады:

—Анлашырга вакыт тимәде... Мин авызымны ачтым да калдым. Ул бит мәхәббәт алиһәсе, Фатих. Мин әле монарчы мондый зәүкый ләззәт кичергәнем булмады. Бу—хыял. Бу—шигырьнең үзе. Жыр бу, музыка!

Фатих Әмирхан куанычын яшерә алмыйча, урынында кымырҗып куйды:

—Котлыйм! Ниһаять, Тукай күнелен яулардай туташ та табылыр икән,—диде ул.

Дөресен генә әйткәндә, беренче тапкыр Зәйтүнә туташны күргәч тә, Тукай аңа гашыйк булган иде. Аңа аталган шигырь шул кичне үк атылып кәгазьгә төшкән иде. Бу үзгәреш Фатих Әмирхан күзеннән читтә калмаган иде. Тукайның лирик шигырьләренең илһамчысы нәкъ менә шушы Зәйтүнә туташ кебек тоелган иде ана. Тукай ул заманны бәхетле иде. Шундый бәхетле иде, хәтта ул үз бәхетеннән шүрләп куйган иде. Бу кадәр олы бәхеткәме соң ул фәкыйрь лаек? Сәрхуш бер йолкышны зур акча куркыткан кеби, ул да мәхәббәтеннән куркып калган иде.

Фатих Әмирхан Тукай уйларын дәвам иткән кебек:

—Олы шәхеснең гыйшкы да олы булырга лазем, дустым,—диде.

Тукай дәртле итеп:

—Төнлә саташып уяндым. Куркыныч төшләр күрдем. Уянсам, мине шатлык, бәхет көтә икән...—диде.—Тик шунысы эчне пошыра, кем телеграммалар сукты да, кем таратты икән яман хәбәрне?

—Игътибар итмә!—диде Фатих, ләкин аның күнелендә дә ниндидер шом, шик бар иде, әмма ул шикләрен дустына сөйләмәскә булды, шат-көр тавыш белән:—Эшлә син, Тукай! Күмеп ташла шундый телеграммаларны!—дип бүлмәдән чыкты.

Чыннан да, бу очрашудан соң Тукай икеләтә күп эшли башлады. Озак яңгырлардан соң ерылган буа кебек, шагыйрьнең куәте ургым-ташкын булып мәйданга чыкты. Язып кына өлгер, укып кына өлгер. Ни-нәрсә Тукайны шулай яскандыра, алгысыта? Туташ белән булган шигъри-кинаяле сөйләшүме, Хөсәен Ямашның үгетләвеме, әллә Фатих Әмирханның ана ышаныч, көч биреп торуымы? Бәлки ул Зәйтүнә белән очрашкан саен аннан көч-рух, илһам ала торгандыр.

Печән базары гадәттәгечә кайный, кайчандыр кечкенә Апушны арбага утыртып Гыйльфан абзый: асрамага бала бирә-әм, асрамага ир олан баар, дип кычкырып йөргән урыннарда хәзер шул кечкенә Апуш хәтле малай-шалай гәзит сата. Әнә башына беләүләнеп каткан түбәтәй кигәне кычкыра:

—«Әл-Исла-ах»!.. «Әл-Исла-ах» гәзитәсе... Габдулла Тукайның яңа шигырьләре! «Сорыкортларга!» «Эзе дә калмаган диннең, басып киткән мәҗүсиләр; моны сизгән мөселманга чыдау мөмкинме җан җанмай?

Яланбашлысы аннан да каты тавыш белән:

—«Яшен»! «Яшен» журналы... Тукай шигырьләре, «Тотса мәскәүләр якаң?» «Яшьләр өстеннән донос илткәндә яхшы «дустларын», бел, үзеңнүк яптырырлар, тотса мәскәүләр якаң!»

—Урыслар эш күрәләр, мөселманнар төш күрә, ди Тукай!

Сатуларын ташлап кешеләр гәзиткә чиратка тезелде:

—Миңа «Әл-ислах», миңа «Яшен»не бир.

Малайлар гәзитләрне алучыларга сонып, алардан акча алып, тиеннәр кайтарырга өлгерми, этешәләр, төртешәләр.

Балык базарында да шул ук хәл.

Бер үсмер кычкыра:

—Абдулла Тукай! Печән базары, яхут Яңа кисекбаш! Трамвай юлы буйлап киселгән мөселман картының башы тәгәри, укымый калмагыз!

Үсмер бер кочак гәзитен шундук сатып бетерде дә, йөгереп китеп барды.

Ташаяк базарында да сәүдә гөрли:

—Сенсация! Гадәттән тыш хәл!.. Габдулла Тукайның Думага атаган яңа шигыре... Их, Дума, Дума, эшең бума! Дума үзен-үзе буып үтерде! ди Тукай.

*Ахыры киләсе санда*



Шәмсия
Җиһангирова

# АЧАМ ҺАМАН БЕР ҮК ФАЛ

* * *

Айның бүген җиденче кичәсе.
Ай нурында кырда атлар йөри үлән утлап.
Дөнья талган тын йокыга,
Гүя яшәү калган туктап.
Күзен ачар иртән кояш белән
Яңа көнгә куәт-егәр туплап.
...Ә мин ятам күз яшь түгеп,
Китә алмый йоклап.
Йөрәгемдә леп-леп итеп сөю ята сутлап.
Кемдер: «Шәп бит инде, сөйгәч!»—диеп,
Куяр мине хуплап.
Кызыкмагыз, көнләмәгез!
Җанымда сутлаган ул сөюнең
Җавапчысы юк ла!..

* * *

Апрельдә мин гел башкача янам—
Апрельдә мин янам Тукайча.
Гомер исәбемне саный башлыйм
Янган уттан сүнгән уткача.

Апрельдә мин гел башкача сөйлим—
Туган телнең тәмен мең татып.—
Тукай үзе тыңлап торыр кебек,
Шыпырт кына «тегеннән» кайтып.

Апрельдә мин гел башкача ярсыйм—
Апрельдә мин ярсыйм Тукайча!
Гел Тукайча көләм, елыйм, яшим,—
Күргән булмасам да һичкайчан.

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА — *шагыйрә; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Төсле моң», «Яшел гармун», «Жирсу» h. б. китаплар, күп популяр җырлар авторы. Казанда яши.*

Апрельдә мин гел Тукайча язам...—
Бу сүземне Ходам кичерсен!—
Мине дә бит «Шагыйрь» дип йөртәләр—
Тукай юклыктандыр... Нишлисең!..

* * *

Ач күзеңне—дөнья бу!
Синең белән миңа бу!
Рәхәтләрен татый белсәң,
Искитмәле дөнья бу!

Ач күзеңне—дөнья бу!
Кучә кулдан-кулга бу!
Синнән-миннән калыр өчен
Яратылган дөнья бу!

Ач күзеңне—дөнья бу!
Елатып та сынар бу,
Көлдереп тә сынар бу!
Байлыгыңны пыран-заран
Бөлдереп тә сынар бу!
Бөгелдереп, сыгылдырып,
Сындырып та сынар бу!
«Эһ»дигәнче узар бу!
...Газиз әнә шуңар бу!

## Ачам һаман бер үк фал

Ничәмә-ничә мәртәбә
Ачам һаман бер үк фал:
Кадерләрең бар чагыңның
Кадерләрен белеп кал!
Үтә икән, китә икән
Гомер дигәнең агып...
Җитә икән яшәү чоры
Кадерсезләргә калып.
Беркем килми, беркем китми,
Һичкем белми хәлеңне.
Берьялгызың үткәрәсең
Шулай картлык мәлеңне.
Телефон да телсез калган,
Йоклый никтер кыңгырау...
Җанны гел кимереп тора
Җавапсыз мең-мең сорау.
Ул сораулар барысы да
«Нигә?» белән башлана...
Һәр нәрсәнең чарасы бар,
Картлыкка юк ник чара?!
Бик ямьсез микәнни соң ул
Читтән карап торырга?—
Нигә аңа бөтен кеше
Арты белән борыла?
Артка борылып, картлыгыңнан
Качып булмый лабаса!—
Беркөн килеп нәкъ каршыңа
Ул үзе килеп баса.

Кеше картлыгын буладыр
Күрмәмешкә сабышып.
Төшенерсең: үзеңә беркөн
Картлык куйгач ябышып.
Яшьләр, яшьләр! Тыңлагызчы
Сезгә әйтер сүзем бар:
Өлкәннәргә—игътибар!
Өлкәннәргә—игътибар!!!

* * *

Башкаемда уйларым күп,
Уемның бар төрлесе,
Шул уйларым арасыннан
Синең турыда бересе.

Шул бер уем иртә уйлыйм,
Уйлыйм көндез, кичен дә...
Сине генә уйлап тормыйм,
Уйлыйм синең өчен дә.

Синең турындагы уем
Иң асылы, татлысы.
Уйлаган саен шул уйны,
Җанга иңә яктысы.

Уйларга чумдым, уйларга—
Алларына, гөленә...
Уйламас идем берни дә,
Янда булсаң гел генә!

## Җилләр дә генә исә...

Җилләр дә генә исә, җилләр исә,
Иртәләрен исә, кич исә...
Искән җилгә аркаларын куеп,
Ниләр булыр иде ул килсә.

Җилләр дә генә исә, җилләр исә,
Тынар иде микән кич җитсә?
Тынар иде йөрәк ярсуларым
Җилләр диеп тормый ул килсә.

Җилләр дә генә исә, җилләр исә,
Нигә исә икән тынмыйча?!
Тынмас инде, тынмас йөрәккәем
Күкрәгенә башым куймыйча...

* * *

Мин бер гөлдәй бу җиһанга күзем ачтым.
Торып бастым.
Уңга бактым.
Сулга бактым...
Дөрләп торган уттан гайре һични таптым.
Мин шул уттан йөрәгемә учак яктым.
Язда яндым.
Җәйдә яндым.
Дөрләп яндым!..

Беркем күмер өстәмәде. Үз күмерем.
Яна-яна уза бардым бер гомерем.
Күзгә кердем...
Әле һаман йөрәгемдә утым дөрли ничә заман.
Һаман янам.
Һаман янам.
Сүндермәккә, салкын диеп, сиптем суын.
Шул салкыннан пеште җаным, янды уем...
«Янмыйм!» дигән уемны мин читкә кудым.
Янә киттем.
Кышка җиттем...
Җавап учак кабынырын өмет иттем.
Барам,барам...
Кая табан?!.
Бу җиһанда уттан башка, йә, ни таптым?!—
Утта яндым.
Утлар яктым...—
Һични таптым!..

* * *

Таң алдыннан сандугачлар
Җанымны салды моңга.
Алай моңлы түгел идем,
Әллә ни булды миңа!?

Чык бөртеге, таждан күчеп,
Керфек очыма кунды...
Мөлдерәп елап җибәрдем—
Миңа соң ниләр булды?!

Тезләнеп торам каршыңда,
Сәер карама миңа!
Үзең мине моңга салдың,—
Күңелемне ач, дөнья!

Син дә кил, тезлән каршыма,
Тотыныйк кулны кулга.
Куеныңа салып кына
Юатчы мине, дөнья!

## Татар барда...

Аптырама, татар җырдан гына,
Бары моңнан гына тора, дисәм.—
Җыр булганга татар теле исән,
Моң булганга татар үзе исән!

Гаҗәп түгел, әгәр һәр татарга
Тиеп киткән саен моң түгелсә,—
Моң белән сугарып җырлар сипсәң,
Җирдә аллы-гөлле гөлләр үсә.

Татар туган саен гөлләр җетә!—
Матурлыклар күрсәң, гаҗәпләнмә.
Татар барда—дөнья гүзәл булыр!
Ышан гына бары мин әйткәнгә!

Яши бирә татар тыйнак кына,
Өмет итми генә мөнбәр-тәхет.
Гөлләр үскән илдә җырлап яшәү,
Моң илендә яшәү үзе бәхет!

Нурислам Хәсәнов

# ЗОЛЫМ

РОМАН

## Казна күле

Сәрия пароходтан төшкән ирен ачык чырай белән каршыламады, аны эчтән көнчелек корты кимерде. Нәфис артык сүз куертмады, хатынын сабыр гына тынычландырырга тырышты. Шулай да үзара аңлашу булмады. Ике арада туган каршылык, гүя өй эчен тискәре энергияләр белән биләп, Нәфисне ниндидер киеренкелектә тотты, тынычлыгын качырды. Ул, теләсә дә, кирәкле эшенә тотына алмады, вакытын бушка уздырды. Шушы ялыктыргыч халәте иртән торгач та бетмәде. Аннары ул Байтирәккә кайтасы итте. Җиенып автовокзалга төшкәч, планнарын үзгәртеп, юл уңаеннан туган авылы Акъярга сугылырга булды...

Автобус аны Акъяр урманы буендагы Кабык күпердә төшереп калдырды. Туган җиргә аяк басуга, бераз тынычлангандай, саф һаваны иркенләп сулады, аңа монда барысы да якын. Ул кайчандыр бу юллардан яланаяк чабып узды, урман җиләкләре, чикләвекләр җыеп кайтты. Үсә төшкәч, урман печәннәрен чабарга килде, ачлы-туклы «уф алла» арбасына җигелеп кайтты... Төрлесен күрде, әтисе тарткан «уф алла» артыннан этеп барган яланаяклы малайның ертык чалбар балакларына тузан сарды, аны кызганучы булмады, чоры шундый иде. Юлда очраган председатель Һашим абыең «уф алла» арбаңны исән калдырса, аңа бик сөенә иде... Инде хәзер бу юлларда тәртә арасына кереп, тирләп-пешеп арба тартучы әтисе дә, аңа йөк артыннан этеп булышкан, тирләгән битенә чигә чәчләре төшеп ябышкан ак яулыклы әнисе дә күренми. Үрләрне менгәндә, сөекле Ярулласының: «Тау менәбез, Сәрвәр, катырак эт!»—дип әйткән тавышы да ишетелми... Әй гомерләр, сиздерми генә узган да киткән. Ә туган җир, туып-үскән йорт һаман да үзенә тарта.

Менә ул истән чыкмас Казна күле! Аның урман чишмәләреннән агып чыккан сулары күл булып җыелган да кояшта җемелди-җемелди җәйрәп ята. Саф суында балыклар йөзә, авылдашлары кармак сала, су коена. Ул күлне узган-барганнар да читләтеп узмый, әлеге урын Нәфисне дә кайткан-барган саен үзенә тарта. Ниләр генә ишетмәде ул Казна күле турында. Имеш, кайчандыр шушы камышлы күл өсләрендә җен-пәриләр биешкән, урманга баручыларны, юлларыннан адаштырып, ерак-еракларга алып киткән... Иң элек җил-давыллар да шушы күл өстендә куерып, кара болытлар хасил иткән, хәвефле яңгырлар яудырган. Зур, юан имәннәрне яшеннәр суккан, күмергә әйләндергән. Ә бервакыт Казна күленең кыл уртасыннан бер зур Аждаһа калкып чыккан да, иген-басуларын яндырырга

*Дәвамы. Башы 3 санда*

телəгəндəй, авызыннан ут-ялкын сипкəн, аннары аны əллə кайдан гына чыгып пəйда булган кара болытлар суырып алган да ерак-еракларга—Каф таулары артына илтеп ташлаган. Шуннан соң гына кешелəр күл ягыннан тыныч кына үтеп йөри башлаганнар.

Күлгə якыная төшкəч, яр читендə кемнендер ак «Жигули» машинасы ялтырап күренде. Су коенырга килүче микəн? Юк, анда берəү кармак салып утыра. Кем икəн ул? Һашим абый ич. Шул, гомере буе колхоз председателе булып эшлəгəн, балык тотарга яраткан Һашим.

—Исəнмесез, Һашим абый!—диде Нəфис, аның янына килеп.

—Исəнмесез!..—Һашим, ябык яңакларын тартыштырып, Нəфискə карап алды.—Кунакка кайтып килəсеңме?

—Əйе. Авылны да күреп китим дигəн идем.

—Ярый, ярый...

—Балык элəгəме соң?

—Бераз бар...—Ул ярда, су эчендəге тимер сеткада чупырдашкан балыкларына ишарəлəде.—Бер-ике табалык булды.

—Болай элəккəч ярыйсы инде.

—Булганы житə.—Һашим, күтəрелеп, Нəфискə карады.—Газетада эшлəп буламы соң?

—Була...

—Байтирəкне мактый-мактый алга чыгарасыз инде.

—Кем белə инде... Мактасаң, тимилəр, тəнкыйтьлəсəң, сугəлəр...

Һашим «һе-һе» дип артка чиккəн мангаен ялтыратып көлемсерəде һəм ялт кына бер кəрəкə балыгын тартып чыгарды. Кармакка элəккəн балык, көзге су өстендə ялтырап, яшел чирəм өстенə килеп төште, Һашимның сөякчел бармакларына элəгергə телəми, оялчан кыздай тыпырчынды, учка кергəч тə, тимер сеткадагы балыклар янына илтеп салганчы, талпынды. Балыкның энжедəй балкып чəбəлəнүе Нəфис күнелен күтəреп жибəрде. Ул кармагына яңа суалчан кигерткəн Һашимнан сорады:

—Һашим абый! Хəзерге көндə уңыш күрсəткечлəрен арттырып күрсəтүлəр бар, сез шушы «приписка»га ничек карыйсыз?

—Бик начар карыйм.—Ул кармагын күлгə ыргытты.—Элек без һəр гектардан бер-ике центнер уңышны киметеп күрсəтергə тырыша идек. Дөресен күрсəтсəк, бездəн ул ипине дəүлəткə саттыралар иде, мəжбүри итеп. Бу очракта арттырып күрсəтү түгел, дөресен күрсəтү дə файдалы түгел иде.

—Ə хəзер югары күрсəткеч ялган дан, премия алыр өчен дə кирəк...

—Шулай инде...—Ул телəмичə генə килеште.—Арттырып бирəлəр анысы. Менə узган ел Байтирəк районында гектарыннан утыз биш центнер уңыш алганнар, дилелəр. Шулкадəр уңыш булгач, нигə соң читкə чыгарга? Үзебезнеке артып калырга тиеш лəбаса. Бу минем башка сыймый... Гажəплəнерлек бит, алтышар ай хезмəт хакы бирмилəр, ə алдынгыларны машина, мотоцикл биреп бүлəклибез, ничə меңнəргə төшереп...—Ул дулкынлана төште.—Тагын икенче нəрсə бар. Кайбер председательлəрнең юбилеена, туган көннəренə машина бирəбез. Биш еллык зарплатасын тот та бер көндə бүлəк ит. Бу бит колхозның ярты айлык хезмəт хакы... Машина алган председатель биш ай хезмəт хакы түлəмəгəн, моның өчен аны судить итəргə кирəк. Мин белми торган гажəп хəллəр инде бу. Ни өчен алай? Үзеңне ярлы дип əйтə аласыңмы беренче урынга чыккан жырчыга, көрəшчегə машина биргəндə? Кайчан бирелергə тиешле, аңламассың? Шунысы гажəп: без ярлыланабыз, бүлəклəр арта... Түрə үз-үзенə хезмəт хакы билгели.

—Əйтмə. Сабан туйларына вертолет чакыртабыз, парашютчыларны

очыртабыз, түләп җырчылар китертәбез... Янәсе, акчаны спонсорлар түли. Бу кадәресе дә зурдан кубып кылану тыйнаклыкны бозу түгелме?

—Әгәр район житәкчесе алай итеп акча таба ала икән, кайсыдыр ки хуҗалыкны торгызырга, нинди дә булса предприятие ачып җибәрергә була. Акчасын шунда бирсен. Байтирәк районы оешканга инде ничә ел, район администрациясе бинасын да корып кερә алмый, дәүләттән төзелешкә дип ничә тапкыр акча ала. Эшсез калган кешесе Казанга йөгерә...

—Мәчетләрне шактый төзедек анысы,—диде Нәфис.

Һашим янә авыр сулап көрсенде.

—Ул мәчетләрнең күпме файда китергәнлеген санап карарга кирәктер инде,—диде.—Ярар, мәчетләрне төзегәннән соң, кешеләр арасында күпме әдәплек, тыйнаклык артты соң? Җинаятьчелек күпмегә кимеде? Эчүчелек, наркомания беттеме? Дин юлыннан китүчеләребез арттымы? Алар ничек итеп гаделлек, намуслык хакында пропаганда алып бара? Хәзер боларны белергә, нәтиҗә ясап карарга вакыттыр инде. Мәчетләр дә кирәк, ләкин алар үз эшен эшләргә тиеш, тик тормаска...

Нәфис офтану кичерде: «Кая җинаятьчелек кимесен?! Арта гына ул, аны арттыралар... Наркомания, игромания чәчәк ата. Әле шуннан бизнес ясап арттыралар. Чөнки түрәләрне акча боза, шашындыра. Болганчык күлдә балык тоту шәбрәк ич. Чуртаннарга—ирек, ашасыннар тотып вак балыкларны, симерсеннәр үзләре генә... Әле шушы күленнән дә колак какмасаң ярый».

—Һашим абый!—диде Нәфис, сүзне икенчегә борып.—Менә сез ничек уйлыйсыз, теге илленче елларда Байтирәк районын бетерү дөрес булдымы?

—Дөрес иде,—диде Һашим, икеләнмичә.—Административ команда системасын киметергә кирәк иде. Нәрсәгә безгә ул кадәр чиновниклар, әрәмтамаклар?.. Патша вакытында Лаеш өязе булган. Ул моннан туксан чакрым радиустагы район. Без, хәзергесен әйтсәк, барабыз капитализмга, тагын районнарны эреләндерергә кирәк. Ә без ваклыйбыз. Ни өчен?

—Бер оешкан районны бетерү килешерме соң?—диде Нәфис.

—Мин районны бетерергә кирәк дип әйтмим. Ул үзеннән-үзе бетәчәк, әгәр дә без колхозларны таратып, фермерларга бирәбез икән. Ул вакытта фермерларга, арендаторларга, корпорация вәкилләренә берниндн чикләү булмаячак... Менә эш кая бара! Ярар, районның роле нәрсәдә соң? Толкач булуда. Ул кем артта калганны карап торырга, аңа ярдәм итәргә тиеш. Начар эшлиләр икән, аларны кыздыру һәм башкалар. Ә инде җир башка милеккә—фермерларга күчкәч, ул аңа әйтә: «Слушай, синең ни эшең бар мində?—ди.—Күл минеке, чишмә, урман минеке. Мин—хуҗа, мин теләсә нишләрмен, монда килеп нәрсәгә тыгыласың?» Хәзер районның роле кими. Аннары җир хуҗалары депутатлыкка да үз кандидатурасын гына куя, өстән кушып сайланган курчак депутатлар белән исәпләшми. Ул: «Миңа үз мәнфәгатьләремне яклый ала торган юрист, экономист депутат кирәк»,—ди. Менә сез аңлатып бирегез миңа, районны бүлү нәрсәгә кирәк иде?

Һашим карт Нәфискә текәлеп карады. Аның карашы: «Сез журналист, редактор кеше, бу хакта нәрсә булса да чамалыйсызмы? Районның киләчәген күрә аласызмы?»—дип сыный иде сымак. Сорауларга җавап эзләгәндәй, Нәфиснең башыннан ГКЧП дан соң эшсез калган кайбер партократлар, Байтирәк районын оештырырга кирәк дип, ду килеп, республика җитәкчеләренә хатлар язып мөрәҗәгать итеп йөргән көннәр узды һәм ул шундый нәтиҗәгә килде:

—Кемнәргәдер район оештыру, форсаттан файдаланып власть алу, баеп

калу өчен кирәк булгандыр,—диде.

Һашим, аның сүзен ишетмәгәндәй, игътибарын калкавычка юнәлтте. Нидәндер ризасызлыгы кулында дерелдәгән кармак сабына күчкәндәй булды, сүзен болай дип дәвам итте:

—Социализм, Совет власте вакытында кирәк иде ул толкач—өреп торучы. Партия кушканны гына эшләргә! Аны тормышка ашыру өчен тагын нәрсә кирәк иде? Райком. Хәзер фермерларны, аерым хуҗалыкларны колхоздан аерып чыгаргач, аларга толкачлар кирәкми. Ярар, район хуҗасы монда килде ди. Мин—аерым хуҗалык. Ул миңа нәрсә дип әйтә ала инде? Аның минем бакчамда ни эше бар? Димәк, без моңа кереп китәбез икән, район үзеннән-үзе бетә. Аны бетермәс өчен бу чиновниклар хуҗалыкларны сакларга тырышачаклар. Чөнки аларга төшемле эш калмый. Әйтик, авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигының нәрсәгә кирәге кала? Анда бер кеше житә. Элекке земство, өяз күләмендәге белгечләр авыл халкына ярдәм иткәннәр. Районнарның вазифасы житәкче түгел, ярдәмче генә булып калачак... Мәсәлән, губерна земствосында тору өчен кимендә аның ун мең акчасы, байлыгы булырга тиеш булган. Акчалыны сайлаганнар, сине, мине түгел...

Нәфис елмаеп куйды.

## Урам эте Сарбай

Сарбай ияләнгән гадәте буенча койрыгын болгый-болгый тәрәзә артына килде дә, үз хәбәрен салып, өрер-өрмәс шыңшып алды. Мәкалә язарга утырган Нәфис, эт шыңшуын ишетеп, тәрәзәгә килде. Урам хуҗасына әйләнеп калган Сарбайның кара-кучкыл, дымлы күзләре ашарга сорап ялвара, өмет чаткылары белән яна, нишлим, мин иясез, ни чарадан бичара хәлендә калдым, дия сыман. Барганда-кайтканда артыннан ияргән, инде шактый ияләшкән Сарбайны Нәфис кызгана төште, тәрәзәне ачып сүз катты:

—Нәрсә, ачыктыңмы? Хәйт, сине...—Эт таныш тавышка янә дә жанлана төште, телен ялап-ялап алды.—Шулай ул, Сарбай, ачлык һәркемне биетә, бер өйдән икенче өйгә дә чаптыра. Сөяк, ит калдыгы да тама жан иясен кызгана белгәннәрдән. Ә сараннарның ишегалдына керә калсаң, алар сине таш атып куып чыгарырга да мөмкиннәр. Аннары син, дөньясына карганып, тагын ары чабасың, бире чабасың... Ходаем, мондый эт тормышына калырга язмасын инде!.. Син дә, Сарбай, кайчандыр болай урамда калырмын дип уйламагансыңдыр инде. Байтирәккә сине бик ерактан, Австралиядән үк игезәк туганың Барс белән икегезне Тукбаев алып кайткан. Нәселле эт буларак, Барсны үзендә калдырган, сине урынбасары Ишкәевкә бүләк иткән. Нигәдер син аларда яшәп китә алмагансың. Күрәмсең, ул сине чын күңелдән кабул итмәгән... Әллә бик рәнжеттеләрме үзеңне? Нидер булган инде, булган... Булмаса, болай ачлыктан интегеп йөрмәс иден... Ярар, үрсәләнмә, Сарбай, хәзер ни булса да табарбыз...

Нәфис, кухняга узып, аннан колбаса кисәге алып килде. Ризык исен сизенгән эт, куаныч кичереп, арт аякларына ук торып басты, ал тәпиләрен сузып биеде, түземсезлек белән ашарына бирәсен көтте. Нәфис сардельканы ваклап, бер кисәген һавага чөйде. Аны Сарбай, жиргә төшерми, хап итеп эләктереп алды, чәйнәп тә тормый, голт-голт йотты һәм кабат Нәфискә карап тора башлады.

—Тагын кирәкме?—диде Нәфис һәм янә бер кисәк колбасаны һавага чөйде.—Мә, тот! Туганың Барс Тукбаевларда ничек кенә сыйланмыйдыр... Аңа райпо каравылчысы Кәрим абый ярты ашханә ризыгын алып кайта.

Ул аны туйдырмый гына карасын, Чуртан Әхәт кирәген бирәчәк. Юкса Тукбаевның җилле тукмагы аңа да эләгәчәк. Ул аның да ипи шүрлегенә менеп төшәргә күп сорамас... Син, Сарбай, Барс янында кечерәеп, кәрлә булып калгансың. Игезәк туганың бозау кадәр булып үскән. Аңа хәтта Кәрим абый да якын килергә курка. Ит калҗаларын тимер рәшәткә аша гына ыргыта. Усаллыгына чыдар әмәл юк, ди. Артык симергәнгәме, әллә хуҗасына охшап шулай булганмы, белмәссең? Ул синең кебек урам этләрен бер селтәнүдә ботарлап ата. Үз ризыгын бүтәннәр белән һич бүлешми... Әй, ярлы хәлен бай беләмени хәзер... Брат братның көтү көткәненә рад, дип тикмәгә генә әйтмиләрдер инде. Сине, Сарбай, хәзер Барс танымый да торгандыр инде. Бер кан бит, иснәп тә сизәргә тиеш югыйсә. Нишлисең, дөнья иркен дисәк тә, ул кемнәргәдер тар булып тоела. Комсызлар туймастан хөсетләнәләр. Янәсе, миңа гына булсын, минем өлешкә кермә!.. Нишлисең? Шагыйрь Фәнис абыең әйтмешли:

Хәйләкәрләр һәм көчлеләр җинә,
Көчсезләргә тими итле кисәк!
Көчле этләр калҗа кимергәндә,
Көчсезләре тора исен иснәп.

Менә шулай, тук ач хәлен белми. Хет тәгәрәп ела, тәпиеңне суз... Юк, син, Сарбай, алай тәпиеңне сузарга ашыкма...—Нәфис эткә тагын бер кисәк колбаса ыргытты. Сарбай анысын да җиргә төшермәде.—Менә шулай, тәмле ризыкны җиргә төшерми генә ашыйлар, кадерен белеп. Хәер, ризык кадерен белмәсәң, син болай өтәләнмәс тә идең. Карлы бураннарда, җан өшеткеч салкыннарда, калтырана-калтырана, ачтан төн уздырулар бер дә җиңел түгелдер сиңа, Сарбай. Хуҗаң Ишкәев бу хәлдә йөрүеңне аңласа, ул сине капкасыннан куып та чыгармаган булыр иде. Юктыр, ул акыллыларны үз яныннан тизрәк куарга тырыша... Эх, Сарбай, Сарбай, бәлки, синең шушы аяныч тормышың Ишкәевнең Тукбаевны эчтән өнәп җиткермәве сәбәпче булгандыр. Ничек инде ул яратмаган кешесе бүләк иткән этне асрасын? Тукбаев тәкъдим иткәч арусынмаган инде. Башта куштанланып, Тукбаев ышанычына керәсе, тамыр җәеп үсәсе бар ич. Инде күралмау тышка бәреп чыгып, сөйкемсезлек чуаны эчтән тишелгәч, үчне эттән алмый кемнән алсын ул?.. Ишкәев корбаны булырга гына язмасын... Ул глава була калса, үч алуын иң элек миннән башлаячак, калганнарын да читкә тибәреп, үз иярченнәрен янына җыячак. Хәер, минем кендегем Байтирәккә бөрешмәгән...—Мә, Сарбай, аша!..

Нәфис эткә колбасаның соңгы кисәген атты. Эт тагын күтәп карап тора башлады.

—Юк шул, бетте инде, бетте, туганкай!—диде Нәфис, башын чайкап.

Аннары Сарбай, Нәфис уйларына төшенгәндәй, башын читкә борды һәм, өметен өзгәндәй, капкага таба китеп барды...

Нәфис, шимбә көн булуга карамастан, чуалган фикерләрен туплап, язасы мәкаләсен дәвам итәргә утырды...

## Сөяркә

Тукбаев сүзендә торды, Нәфис «Нива» машинасында утырып йөри башлады.

Аңа авыл хуҗалыгы идарәсенә кыр эшләре мәгълүматларын алырга килгәч, башлыкка кереп чыгарга куштылар. Ал бүлмәдә, сәркәтип кыздан

тыш, купшы гына кыяфәттә кырык яшьләр чамасындагы озын буйлы бер таныш булмаган ханым утырып тора иде. Ул ирennәрен кызарткан, керфекләренә сөрмә тарткан. Кыяфәте, мин кем дигәндәй, байларча, колагындагы алтын алкалары биеп-биеп ала, махсус игътибар сорый. Ана сүз катсаң, ул шунда ук ясалма елмаеп җавап бирер кебек. Күзләр үткен, карашлар ялт та йолт. Кем ул? Каян килгән? Нәфис аңышмыйча көтүен белде. Каршы яктагы бүлмәдә утыручы аппарат житәкчесе Мәхмүт Тәкәевнең ишеге ярым ачык калган, ул каядыр чыккан булса кирәк. Сәркәтип кыз Ләйсән Нәфискә күтәрелеп карады да, бердәнбер алтын тешен ялтыратып, башлык бүлмәсенә таба ишарәләде:

—Сезгә керергә мөмкин…—диде.

—Анда кемнәр бар соң?.

—Кергәч күрерсең…

Нәфис Тукбаев бүлмәсенә үтте. Исәнләште. Телефоннан сөйләшкән килеш Рәсим Юлаевич аңа утырырга тәкъдим ясады. Тәрәзә кырыендарак, кабартмадай түгәрәк битен кызартып, түшен күркәдәй киергән мәшгульлек үзәге башлыгы Алия Тутаевна утыра. Аның янәшәсендә сөмсере коела төшкән, районның элекке милиция башлыгы хатыны Фирая урын билгән. Нәфис эшнең нәрсәдә икәнлеген төшенде: исәпләре иреннән аерылган Фираяны редакция штатына эшкә алдырту. Аның гозерен Нәфис бер кире каккан иде инде. Фирая Абага районында урыс газетасында эшләгән булган. Әмма татарча яза белми. Нәфис бер карауга гаугалы, тәкәббер кешегә ошаткач, өнәп бетермәде. Тагын кем өчендер мәкалә язып утырасы килмәде. Аңа әзер корреспондент кирәк иде. Фирая бу юлы үзе белән яклаучысын—Алия Тутаевнаны ияртkән.

Тукбаев трубкасын куюга, Фираяга таба ишарәләде:

—Нәфис абый! Менә бу кеше ничә тапкыр килә инде,—диде.—Үзе, редакциядә эшләдем, дип тә әйтә, аны эшкә ал инде.

—Ул урыс редакциясендә эшләгән бит,—диде Нәфис.—Миңа татарча яза белә торган кеше кирәк.

Алия Тутаевна кабарынып алды да яклауга күчте.

—Өйрәнер, татарча сөйләшә белә бит ул.

—Татарча сөйләшә белү татарча яза ала дигән сүз түгел әле ул…

Рәсим Юлаевичның сытылган йөзе, бу кеше мине туйдырды инде, бу соң минем эшмени, дигән мәгънәне аңлатты һәм үз тәкъдимен әйтте.

—Нәфис абый, синең штатыңда юкмы соң берәр чуртым-муртымы анда, корреспондентмы, җаваплы секретарьмы? Кара инде, ярты ставкага булса да…

Колагын үрә торгызган Алия Тутаевна бу мизгелне ычкындырырга теләмәде.

—Әйе, ярты ставкага булса да, Нәфис абый, алып тор инде,—диде.—Аның хәзер кыен чагы, ире белән дә аерылышкан. Кешегә булышмый булмый бит. Мин дә аңа, эш юклыгы сәбәпле, учетка алып ярдәм итәрмен…

Тукбаев Нәфискә текәлде.

—Хәл итеп бетер инде, Нәфис абый!

Нәфис шулчак, ничектер йомшаклык күрсәтеп:

—Ярты корректор штатына алып торсаң гына инде,—дип әйткәнен сизми дә калды. Һәм ул бу минутта төзәтә алмаслык ялгышлык эшләгәнлеген аңлап та җиткермәде. Бу фикерне әйтергә яхшатлы булып кыланган Алия Тутаевна да «булышты». Баксаң, Фираяның тору урыны Абага районында теркәлгән икән. Аны Байтирәк районындагы эшсезләр исемлегенә берничек тә кертеп булмый икән ләбаса. Нәфис Алия Тутаевна тарафыннан да алдануын соңыннан гына аңлады.

Бүлмәдән чыгып барганда, Тукбаев Нәфискә ашыкмаска кушты. Аннары ул кабул итү бүлмәсендә көтеп утырган озын буйлы ханымны чакыртты.

Ул керә-керешкә як-ягына каранып алды да:

—Исәнмесез, Рәсим Юлаевич!—диде, алтын алкаларын чайкалдырып һәм үзенә таныш булмаган Нәфискә шикле караш ташлагандай өстәде:—Менә без, ни, килеп тә життек. Теге вопросны решать итәргә дип инде...

Анын «теге вопрос» дигәнен Тукбаев яхшы анлады һәм үзенчә төшендерергә тырышты:

—Луара Сабировна! Менә безнең мөхәррир каршыгызда утыра,—диде ул, Нәфискә ишарәләп.—Без ирегез Әхәт Хәбирович йортын редакция итәргә булдык. Сез, Нәфис абый белән бергәләп, кирәкле кәгазьләрен тәртипкә салып бетерерсез. Хәзер иске мәктәп бинасына урнашкан авыл советына барыгыз да оформить итә башлагыз...—Ул беразга тынып калды һәм өстәде:—Калган «ский»ларын аннары сөйләшербез, тоткарланмагыз, эшне «пешереп» бетерегез...

Администрация бинасыннан чыкканда, Луара ханым Нәфистән:

—Сез машина беләнме?—дип сорады.

—Әйе.

—Без дә машинада килдек, малай белән...—Ул сүзләрен тәтелдәп сипте.—Әнә безнең машина, зәңгәр «девятка»...

—Безнеке ак «Нива»,—диде Нәфис, уйга калып. «Димәк, Чуртан хатыны бай түти шушы булып чыга...»

Ханым машинасына таба атлаган Нәфистән сорап куйды:

—Хәзер кайсы якка барабыз соң?

—Үзәккә төшәбез.

—Мин әллә сезнең машинага гына утырыйммы?

—Утырыгыз соң.

Луара ханым, «девятка» руле артында утырган малае янына барып, ана «Нива» артыннан калмаска кушты.

Кузгалып киткәч, Луара, руль артында утырган Нәфискә кырын-кырын карап алды да:

—Сезнең исем-фамилиягез ничек була соң?—диде.

—Нәфис, Ярулла улы Хаков. Нәфис кенә дисәгез дә ярый.

—Мин Луара Сабировна булам.

Берара сүзсез баргач, Нәфис сорады.

—Әхәт Хәбирович кайда соң? Йортын сатарга нигә килмәде?

—Кем белгән аны, кая тайгандыр...—Ул кытыгы килгәндәй кеткелдәп көлде.—Бәлки, кайда да булса сөяркәсе белән чукынып ятадыр.

—Сөяркәсе?—диде Нәфис, гажәпләнеп.—Сез бергә яшисездер бит?

—Кайткалап китә...

Нәфис дәшмәде. Луара өйгә карата ачыклык кертергә теләп сүз башлады.

—Без Байтирәк йорты мәсьәләсендә сөйләштек,—диде.

—Кем белән?

—Рәсим Юлаевич белән!..—Ул башлык исемен якынлык сиздереп атады.

—Сез Рәсим Юлаевичны яхшы беләсезмени?

—Ул безнең гаилә дустыбыз... Хатыны Иркә белән дә телефоннан еш кына сөйләшеп торабыз.

Нәфис, Иркә исеме чыккач, бертын, телен тешләгәндәй, сүзсез калды һәм тал төбе хатирәләрен исенә төшерде. Аннары ул:

—Йортны купмегә сатарга килештегез соң?—диде.

—Сигез йөз меңгә!..

—Ул йортны хәзер карап чыгарга мөмкин булыр микән?—диде Нәфис.—Ачкычыгыз бармы?

—Ачкыч миндә...

Алар, күперне чыгуга, ак силикат кирпечтән салынган зур йорт янында туктап калдылар. Луара кара сумкасы эченнән ачкычын эзләп тапты да алга таба узды. Ишекне ачып керүгә, экскурсия житәкчесе сыман, бүлмәләр белән таныштыра башлады.

—Менә монысы веранда булачак иде,—диде ул.—Монысы кухня, монда кунак бүлмәсе, зал, болары дүртесе дә йокы бүлмәләре. Бу якта котельный, юыну бүлмәләре...

Нәфис, үз күзләренә ышанмый, хәйран калып, Луара артыннан йөрде. Бүлмә стеналары фасонлы такталар белән кадакланган, өйдә чыршы-нарат исләре аңкып тора. Киров өлкәсенең ярты урман агачы монда күчкән диярсең. Ничек итеп Тукбаев Чуртан йортын тулысы белән редакциягә генә бирер икән? Синең алты-жиде бөртек кешенә өч бүлмәсе дә житеп торыр, димәсме? Ни булса, шул, аңа иске мәктәпнең тәрәүле бинасыннан гына котылырга кирәк.

Йортны карап чыккач, алар Байтирәк авыл советына килде. Авыл советы рәисе Егор Юрьевич, эшнең нидә икәнен төшенүгә, сәркәтибеннән документларны сорартып алды. Симергәнлеге аркасында сулышын көчкә алды.

—Тәк-тәк,—диде ул, кәгазьләрне актарып.—Жир участогы ун сутый икән, гаражы унга—унбиш метр, йорты егерме метрга егерме биш, була биш йөз квадрат...—Ул йорт хужасы фамилиясенә төртелеп калды да Луарага карады.—Сез Әхәт Хәбирович хатынымы?

—Әйе,—диде Луара, чат итеп.

—Паспортыгызны мөмкинме?

—Рәхим итегез...

—Юк, кирәкми, ышанам инде...—Һәм ул уйга калды.—Хикмәт менә нәрсәдә... Йорт ирегез исемендә, ул язган гаризага карап, жир бүлеп бирелгән, барысы да аңа карый...

—Ә нишләргә кирәк?—диде Луара.

—Белмим... Йортны сату-алу эшләрен Әхәт Хәбирович кына башкара ала. Нигездә, законлы рәвештә йорт рәсмиләштереп тә бетерелмәгән әле...

Аптырап калган Луара эшлекле кыяфәттә коридорга чыкты да кесә телефоныннан Рәсим Юлаевичка шалтыратты. Аңа бу хәлне аңлатып биргәч, кире бүлмәгә әйләнеп керде. Шунда ук Егор Юрьевич өстәлендә телефон шалтырады.

—Тыңлыйм, Рәсим Юлаевич,—диде рәис, хужа тавышын ишетүгә өтәләнеп.—Тәк, тәк, аңлашыла, аңлашыла. Да, да. Будет сделано!..

Луара түземсезлек белән Егор Юрьевичның трубканы куюын һәм нәрсә әйтерен көтте.

—Монда эш күп булачак әле,—диде Егор Юрьевич.—Башта ирегез язган гаризаны юкка чыгарып, малаегыз исеменнән гариза язарга, һәммәсен малаегыз исеменә рәсмиләштереп язарга кирәк. Аннары нотариус аша уздырганда...—Һәм ул Нәфискә болай дип ишарәләде:—Нәфис Яруллович! Без монда аңлашып бетерербез, сезгә чыгып торсагыз да була. Аннары бу ханым сезне эзләп табар...

—Аңлашылды,—диде Нәфис үзенең артык күз икәнен чамалап һәм комачауламаска дип редакциясенә чыгып китте.

Редакциядә Нәфисне эш сорап килгән Фирая көтеп утыра иде инде. Ул аны, Тукбаев бүлмәсендә сөйләшенгәнчә, килешү төзеп, алты айга дип,

ярты корректор ставкасына эшкә алды... Фираяны озаткач, ул өстәленә өелгән газета мәгълүматларын җентекләп укырга кереште...

Луара Сабировна, кәгазь эшләрен янадан рәтлисе булгач, Нәфис янына керми генә кайтып китте.

## Һәрнәрсәнең җае бар...

Тукбаев тиктомалдан куанды. Елмаеп-елмаеп алганда, кабартмадай бите ялтырап-ялтырап китте, авыз кырыйлары тырпайган колакларына сузылды. Авыр гәүдәсеннән утырган кәнәфие шыгырдап куйды. Киң җилкәләре бер киерелде, бер язылды. Ул эчке куанычыннан учын учка уды: әйтерсең бүген алтын кош тоткан, кәеф шәп! Булган егет син дигәндәй, ул үз-үзен хуплады. Янәсе, бүтәннәр аның кебек эшләп карасын әле. Йә, кемнең районга бер көндә унбер миллионлаган акча алып кайтканы бар? Кем юктан акча ясый ала? Моның өчен теләк кенә җитми, җелегең суырылганчы тырышырга да кирәк. Әрсезлән, тасма телләреңне чыгарып, бар сәләтеңне эшкә җик, кабинетларга кереп аяк терәп сорый да бел, гозереңне әйт, ышандыр. Түрәләрнең җаен тап, яраклаша бел!.. Бу заманда эшләп кенә баеп булмый, тормыш һаман да шул җайлау-майлау белән дәвам итә. Акчаң гына булсын, акча үз эшен эшли, эшләячәк... Барысын да «господин рубль!» хәл итә. Ана табыналар, ул кемнәрне генә кем итми, кемнәрне генә бәла-казалардан коткармый. Түрәлек кәнәфиенә дә утырта. Утырдым бит...

Тукбаев күчәрле кәнәфиендә боргаланды. Аны күтәренке кәефе үсендерде: «Унбер миллион акча кечкенә генә районның эчен тишми ул һәм беркемнең кесәсеннән дә төшеп калмый. Һәр эшне үз вакытында «пешерә» белергә кирәк. Ә ул пешерә белә... Нинди генә кабинетларга кермәде, имзалар җыеп, бөтен каланы айкап чыкты. Мәгариф, сәламәтлек, матбугат-мәдәният министрлыгында, спорт комитетында булды. Хәтта ике метрлы матбугат министры Сәет Әскәровичны да «сындырды». Биш миллион акчаны кысып калырга тарткалашкан иде дә...

Кәнәфиендә уйга чумган Тукбаев, бер карарга килеп, телефон трубкасына үрелде, урынбасары Ишкәевкә шалтыратты.

—Алло! Динар Хамаевич! Миңа кереп чык әле...

Район күрсәткечләрен арттырып күрсәтү әмәле белән баш ватып утырган Ишкәев ялт кына башлык бүлмәсенә ашыкты.

—Тыңлыйм сезне, Рәсим Юлаевич,—диде ул, ишектән керүгә.

—Утыр әле...

Үзен түрәләрчә иркен тоткан Тукбаев, бераз тынлыкны күтәп алып, куанычын җиткерергә ашыкты.

—Динар Хамаевич!—диде ул.—Мин бүген районга шактый гына акча алуга ирештем. Добился—унбер миллион!.. Бу эшләрне ничек майтарып чыкканымны берүзем генә беләм. Мин менә болай уйлыйм: ул акчаларны кырып-себереп район оешмаларына таратып бирүдән файда күрмим. Биреп-биреп карадык бит инде...—Ул җитдиләнә төште һәм бер бармагын бөкте.—Йә, кинофикациягә акча бирүдән ни файда? Ул ике миллионны исерек Хәмзә үз кирәгенә тотып рәхәтләнәчәк. Ярар, яңа машина алыр, фәлән-төгән иткән булыр. Хәзер клубка киногә йөрүче юк. Кешене телевизор яныннан кузгатып булмый. Дөрес бит?—Ул икенче бармагын бөкте.—Йә, спорт комитетын алыйк. Хәлим дә ни эш кырыр? Өч тиенлек хоккей таягын биш тиенгә алдым дип, икенче йортын корып сатар. Көрәштә беренче урынга чыкмадылар. Спорт заллары бар, ни җитмәгән?—Тукбаев өченче бармагын бөкте.—Редакциягә ни булган?! Яңа бинага күчтеләрме?! Күчтеләр. Артлары җылыдамы? Җылыда. Яза бирсеннәр. Ул газетаны калада

да чыгарып була. Акчасын күчерербез. Мин болай уйлыйм: безгә ничу типография төзеп торырга. Менә син, Динар Хамаевич, ничек карыйсың? Мәсәлән, мин шундыйрак фикердә.

—Сезненчә дөрес, Рәсим Юлаевич,—диде Ишкәев, төлке хәйләлеге белән керфекләрен кагып.—Ул Абага районы типографиясендә басылган газетаның сыйфатын әйтер идем инде, карага тапланып беткән була, укырлык түгел.

—Сон, шулай булгач, әллә, мәйтәм, ул акчаларны башка максатларга файдаланабызмы?—Ул Ишкәевнең ни әйтерен көтеп карап алды. Ишкәев җавап бирергә ашыкмагач, сүзен дәвам итте:—Сезгә бер «Джип»мы, «Мерседес»мы алырбыз. Минем үземә дә машинаны алыштырырга кирәк. Әле йортның җиһазлары да алынып бетмәгән…—Ул янә тынып калды һәм башын күтәрә төште:—Дөнья хәлен белеп булмый, без бу урынга гомергә килмәгән, калада да торак-мазар алып кую мешать итмәс… Бушка килгән мондый акчалар кысылыр. Власть та үзгәреп китәргә мөмкин.

—Белеп булмый…

—Шулай булгач, безне гел канат астына алырга теләмәсләр. Тимерне кызган чагында сугарга кирәк. Без моны уртак фикергә килеп эшләргә тиеш…

—Сез дөресен сөйлисез, Рәсим Юлаевич,—диде Ишкәев, хуҗасын хуплап.—Мин ике куллап килешәм. Һәммәсе сезнең карамакта, ничек әйтәсез, шулай була…

Тукбаев, сер саклау кирәклегенә төшендергәндәй, тавышын әкренәйтә төште.

—Акчалар кая китте дигәндә, аның формаль якларын эшләп бетерергә, документлаштырырга кирәк булыр инде.

Ишарәне Ишкәев тиз аңлап алды.

—Җаен табарбыз,—диде ул, ышандырып.—Без ул акчаларны, Рәсим Юлаевич, хуҗалыклар бурычын капларга биреп тордык дип, вакытлыча оформить итеп торыйк. Кире кайтарып бирү шарты белән килешүләр төзик… Кая китте дигәндә, җавабы әзер булыр. Аннары…

Тукбаев Ишкәев тәкъдименнән разый калды.

—Алайса,—диде ул,—иртәгә үк колхоз-совхоз җитәкчеләре белән сөйләшергә, бухгалтерлары печатьләрен ала килсеннәр. Акчалар бирелгән оешма җитәкчеләре белән ике арада килешүләр төзергә. Кайсы хуҗалыкка күпме акча «бүлеп» бирү исемлеген үзең хәл итеп бетер…

—Аңлашылды, Рәсим Юлаевич, аңлашылды.—Ишкәев, тыңлыйм һәм буйсынам дигәндәй, китәргә торып басты.—Эшләрбез…

Бүлмәдә ялгызы гына калган Тукбаев янә үз-үзенә куанып елмайды, кош тоткандай учын учка угалады һәм яраткан сүзләрен кабатлады:

—Һәрнәрсәнең җае бар, яшь нәрсәнең мае бар…

*Ахыры киләсе санда*



Ленар
Шәех

## ӘЙТЕЛӘ СҮЗЛӘР, ӘЙТЕЛӘ

* * *

**Соң да түгел, түгел иртә дә,
Вакыты да түгел...
Тик өзелерлек булып
Тартыла күңел.
Күңел—тартылган кыл,
Ул кыл тимер кебек каты,
Кылыч кебек үткен...
Бер ишекне шакы,
Меңне шакы. Табылырмы
Сине аңлаучылар?..
Сәләтеңне, белемеңне,
Талантыңны санлаучылар?..
Юк. Мин ышанмыйм.
Өметемне кисәм аркылы.
Өметнең дә бар бит,
Бар кылы...
Соңгы кылы—соңгы ышанычым
Бу дөньяның һәр адәменә.
Көтә-көтә, чираттагы шәмем
Сеңеп бетте еллар шәмдәленә.**

**Соң да түгел, түгел иртә дә,
Вакыты да түгел...
Күпме теләнә аласың,
Әйт, әй күңел?!
Аңлыйм, синдә юк бит
Бер тамчы да кер һәм начарлык...
Күңелләрдә бөреләнә гайрәт
Ишекләрне тибеп ачарлык!..**

Ленар ШӘЕХ (1982) — *шагыйрь; «Авылдан килгән мендәр», «Дүртенче кат... Бишенче кат...» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Бу телефон мәңге шалтырар инде,
Еллар үтәр, һава алмашыр.
Кемдер анда, үткәннәрен эзләп,
Хатирәләрендә адашыр.

Блокнотын алыр кулларына
Һәм җыяр ул шушы номерны.
(Киләчәкне ялгый вакыт җебе,
Ә үткәннәр барыбер кадерле!)

Телефонны, белмим, кемдер алыр,
Таныш тавыш, әллә ят тавыш.
Күңелләрне биләр якты бәхет,
Әллә җанны басар ят сагыш?..

Бәлкем, телефонны беркем алмас,
Җавап килмәс ерак тарафтан.
Узган мизгелләрне вакыт җиле
Бер мизгелдә куып тараткан.

Бу телефон мәңге шалтырар инде,
Еллар үтәр, һава алмашыр.
Блокнотын алып кулларына,
Үткәннәрдә кемдер адашыр...

* * *

И Ходаем, мәңге бакый
Иман бир Син.
Күңелләрдә ышаныч һәм
Иман йөрсен.

Яшәешне тыңлап була
Гөлчәчәккә...
Шул ышаныч алып барсын
Киләчәккә.

Яманлыкка каршы көчне
Иман бирсен.
Иман белән бергә җанга
Шәфкать иңсен.

Кешеләрнең күңелләре
Якты булсын.
Авызлары һәм телләре
Татлы булсын.

Күзләрендә очкын булсын
Иман нуры.
Һәрберсенең юлы булсын
Дөрес, туры.

Йөрәкләрдә һәрчак йөрсен
Изге хисләр.
Бу дөньяда хөкем сөрсен
Якты төсләр...

И Ходаем, терәк бул Син
Һәммәсенә,
Фанилекнең һәрбер мохтаҗ
Бәндәсенә!

Яшәешне тиңләп була
Бер мизгелгә.
Калдырма Син колларыңны
Эзсез көлгә.

Без беләбез ялган һәм чын
Аермасын.
Иман белән ышанычтан
Аерма Син!

* * *

Исәнме, кояшым, исәнме!
Бик күптән көтәбез, чыкмыйсың.
Ай буе болытлар артында
Йоклыйсың ахры син, йоклыйсың.

Халыкка син кирәк, бик кирәк,
Кояшсыз көннәрдә боегам.
Гел болыт эчендә яшәүдән
Җәмгыять, кешелек оеган.

Күкләргә карасаң—сорылык
Җаннарны суыра үзенә...
Кояшлы киләчәк каршына
Сыгылмый бар гына, туз генә...

«Исәнме, кояшым, исәнме!»—
Диярмен. Син бары чык кына.
Күземдә өметтән яралган,
Җаныма таралган чык кына...

## Әйтелә сүзләр, әйтелә...

Әйтелә сүзләр, әйтелә
Кайчак дуламыйча да.
Үзләре телгә киләләр
Кайчак уйламыйча да.

Бу сүзләр туры һәм дөрес,
Кырыс та, аяусыз да.
Дошманнарны бәреп ега
Чирүсез дә, яусыз да.

Дусларны да үпкәләтә,
Хәтта сөйгән ярны да.
Туры сүзләр туры бәрә
Иң оста татарны да.

Туры әйткән туганына
Ярамаган диләр дә...
Нишләтәсең, шагыйрь җаны
Ауный алмый идәндә.

**Әйтелә шул, ни хәл итим,**
**Авыр суламыйча да.**
**Авыздан чыгып китәләр**
**Кайчак уйламыйча да.**

* * *

**Кызыл куртка кигән бер кыз,**
**Кызыл шарф бәйләгән.—**
**Кызыл машинасы белән**
**Бүген шәһәр әйләнә.**

**Ул сөйгәнен эзли микән?**
**Әллә болай гынамы**
**Машинасына утырып,**
**Кич шәһәргә чыгамы?..**

**Тыз-быз чаба машиналар,**
**Кызыллары күренә...**
**Гүя кызыл карлар ява**
**Кызның күңел түренә...**

**Явар да шул, сөйгәнеңне**
**Машинада эзләсәң,**
**Тирә-юньне караланган**
**Тәрәзәңнән күзләсәң...**

**Кызыл куртка кигән бер кыз,**
**Кызыл шарф бәйләгән...—**
**Чү! Кызыбыз җәяү генә**
**Бүген шәһәр әйләнә...**

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, жинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

Әхәт
Мушинский

# ҺАВАЛАРДА—АК КҮГӘРЧЕН...

РОМАН

## ТУГЫЗЫНЧЫ БҮЛЕК

### Ә шмайсер кирәк түгелме?

Гайнан абыйның үги малае белән беренче бәрелеше туйдан соң бер атна узгач ук булды.

Дүшәмбе көн. Иртә. Гайнан абый йокысыннан артык күп эчүдән башы чатнап уянып китте. Буфетларында актарынып алды, бүлмә буенча йөренде, тегендә-монда тыгылып карады, ләкин башын төзәтерлек берни дә таба алмады. Шунда үги малае килеп чыкты. Аның белән ышанычлы гына итеп, ир-ат ир-ат белән сөйләшкән шикелле сөйләшеп китте. Үзенең менә хәзерге кызыксыз хәле белән уртаклашты, ә тегесе аңа бүре (әйе, бүре баласы кебек түгел), нәкъ бүре сыман карап тора. Күпме генә күндерергә тырышмасын, барыбер бер шешә аракы артыннан кибеткә барып килмәде үги малае. Бу зур хезмәте өчен аңа акча да вәгъдә итеп караган иде дә, юк, тегесе акчадан да баш тартты, хаҗәте юк, диде. Аһ, нинди миллионер табылган! Син акчаның нәрсә икәнен беләсеңме соң, Казан ятиме, аларны бер мәртәбә булса да күргәнең бармы синең, ананны саткыры нәрсә! Ә менә ул, Гайнан Фазлыгалләмович, әле күптән түгел генә аны көрәк белән көрәп алды, мунчада башын сыра белән юды, кемнәрдер ачтан аяк сузганда икмәкне тәгәрмәчләре юкка зырылдап пычракка батып яткан машина асларына капчыклап ташлады. Аллага шөкер, Гайнан Фазлыгалләмович хәзер дә теләнеп йөрми. Циркта эшләре бик яхшы бара. Менә бүген эшкә чыкмады, алай да аңа беркем берни дә әйтмәү түгел, тынын да чыгармас, чөнки, беренчедән, әлбәттә, циркта дүшәмбе авыр көн түгел, ә икенчедән һәм иң мөһименнән, чөнки анда, склады, ите дигәндәй... бар нәрсә дә анын кулында. Һәм шулар аркылы—калган бөтен нәрсәләр дә. Килеп чыккан узгынчы гастролер-өйрәтүче дә, сыер итен юлбарыстан ким ашамаган цирк директоры үзе дә һәм цирк биләмәсендәге тагын башка кемсәләр дә. Яши белергә кирәк! Һәм бу гади нәрсә түгел, чөнки яши белү ул, беләсең килсә, балеттан чистарак сәнгать! Бер грамм да брак жибәрмәс өчен, ай-яй, ничек бөтерелергә һәм шундый «па» хәрәкәтләре ясарга туры килә... Башкача булмый да, ярамый да—сызгырып мәсхәрә итәрләр дә Колымада уянып китәрсең.

---

*Дәвамы. Башы узган елның 12нче санында*

Һәм, кирәк бит, бер университетта да ишетеп булмаган бай эчтәлекле фәлсәфи дәресе өчен дә рәхмәте нинди аның: «Мин сине фаш итәчәкмен!» имеш. Бу бит аны уллыкка алганнан соң, әнисе белән икесен дә ярлылыктан һәм фәкыйрьлектән күтәргәннән соң!! Әйтерең дә юк, яхшы түләү! Яхшы. Ә бит бу арка кимерүче аны чыннан да сатарга мөмкин. Бер дә юкка... Кырык бишенче елда алып барып житкерә алмаган (Абаканда поездан калып качкан иде) кояш чыгышы якларына таба сузылган рельслар тоташкан урыннарда шалтыр-шолтыр килерсең, дыңгырдарсың аннары. Жину хөрмәтенә атып үтерү хөкемен Себердәге унбишьеллык хезмәт эшчәнлегенә алыштырганнары өчен аның күңелендә совет властена карата рәхмәт хисе тумады һәм гуманлы закон алдында баш ию хисе дә барлыкка килмәде. Һәм аңа ул кырык бишенченең шатлыклы маенда эшләгән эшен тормышка ашыруы бер дә авыр булмады. Ул чакта, әлбәттә, башында бераз гына акылы булган һәркем кача ала иде, әлбәттә. Ә менә бернинди документсыз, акчасыз, рәтле киемсез, азык-төлексез, инде сине Европа юлындагы барлык станцияләрдә дә почет каравылы каршы алырга торганда, үзенне иректә саклый алу—икенче эш. Юк, күзен акайтып көнбатышка таба жилдерергә сарык түгел, ул Енисей буенча көньякка таба китте. Кызыл шәһәренә кереп чумды да анда ярты ел буе рус телендә ике сүздән артыгын белмәгән кысык күзле аш-су пешерүче бер хатында яши бирде. Аннары Кемеров өлкәсендәге Таштаголда яшәп алды, казакъ шәһәрчеге Карсаклайда, Сызраньда яшәде, һәм илле жиденче елда Сталин репрессиясенең акланган корбаны флагы астында Г. Ф. Субаев дип йөртелгән документлары белән магнит шикелле тарткан Казанга кайтты.

Уйсулыкның иркен кырларында Гайнан абый бәрәңге казыды һәм шунда аның Сократныкы сыман маңгаен төрле уйлар чолгап алды. Бәрәңге кемнеке булгандыр, ләкин ул законсыз рәвештә—жирле «шәхсиләр» тарафыннан, ташландык жирдә булса да, барыбер дәүләт территориясендә утыртылган булганлыктан, аны закон нигезендә жаваплылыкка тарта алмыйлар иде. Шуңа күрә ул курыкмыйча, башы белән үз уйларына чумган халәттә казуын дәвам итте.

«Ит тә ашамаган була бит әле, ач бет, акча да алмый. Акылдан язган диярсең. Ничек кулга ияләштерә алмадым икән соң мин аны?! Акылдан язган ул, менә шуңа да ияләштерә алмадым. Йә ярар, ярар, тормыш—көрәш ул, ә без көрәшә беләбез».

Ләкин барыннан да бигрәк Гайнан абыйны Шәехнең аның сугышчан узган юлына, аның «хәрби» майор булуына ышанмавы борчый һәм ачуын китерә иде. Син аның белән нинди дә гомуми, башка нәрсә турында сөйләшә генә башлыйсың, ә ул сине күзләре белән бораулый, әйтерсең эчендәге бөтен яшерен серләреңне алдан ук белеп тора. Сугыш турында гадәти сөйләшү вакытында жибәрелгән бер-ике ялгыштан да шул кечкенә генә малай фактларсыз, махсус белемсез, тәжрибәсез нинди дә төгәл нәтижә ясый-ясый чын дөреслеккә барып житә аламы? Харап булган, исерек баштан журнал картинасындагы танкны самоход белән бутаганмын. Ә бер мәртәбә бер үк көндә үземнең сөйләмемдә иртән үзем турында —артиллерист, ә кичен, исерек баштан, разведчик дигәнмен. Ярый әле, ырып-ерып чыктым аннары, янәсе, күзлексез күрмим. Монысы—журнал турында, ә артиллерист һәм разведчик мәсьәләсендә, бер дә гажәп түгел, әйе, артполкта разведчик та булдым, дидем.

Гайнан абый үз-үзен, моңарчы ул үзенең иң беренче дошманы булган теле китереп чыгарган төрле кыен хәлләрдән дә жинел котыла иде әле, дип юатты. Мондый гына пинкертоннарның миләрен сәмихләмәде ул. Әмма нинди дә эчке кабахәт тавыш юк-юк та, ләкин кайчак колагына: «Ә бит

ул сине шул вак-төякләр буенча түгел, ә синең бөтен яшәеш-көнкүрешең, синең һәр адымың, урлаган итең, алдый торган итеп куелган фасонлы үлчәвеңнән чыгып фикер йөртә...»—дип пышылдый башлады. Үзе дә инде... Кирәк бит аңа шушы нәрсәләр белән дә мактанырга! Салган баштан инде, әлбәттә, салган баштан. Артыгын эчәсең, сөеклем, артыгын. Ә тагын (монысы да начар, әлбәттә) җәзасызлыгыңа бик артык ышанасың, үзеңне гайре табигый шәхескә, артык акыллыга саныйсың, янәсе, аның башы баш түгел, ә Берләшкән Милләтләр Оешмасы! Шуны аңлый алмыйсың, әлегә сиңа моңарчы җай гына чыгып тора, хәлләр уңай килә, җил уңай исә, сугыш вакытында синдә эшләре булмады, чыннан да, гадәти эшләпә һәм пинжәк астында сигезаяк яши дип кемнең башына килер!? Сиңа кемнең дикъкать белән караганы бар? Беркемнең дә. Һәм сиңа игътибар белән караган беренче кеше үк, хәтта кеше түгел, малай да, синең нинди фрукт икәнеңне шундук аңлап алды.

Гайнан абыйның күңелсез уйларын ерактан килгән, чак кына ишетелгән ике шартлау тавышы бүлде, әйтерсең кемдер көтүче чыбыркысын шартлатты. Ул тыңлап тын калды. Шуннан, ерым артындагы күл ягыннан каргаларның куркып каркылдашуы белән бергә, җил тагын шундый ук аерым-аерым ике «шарт» иткән тавыш алып килде. Юк, бу атулар көтүче чыбыркысыныкы түгел, болар нindидер башка, инде күптәннән ишетергә туры килмәгән нәрсә.

Гайнан абый тулып җитмәгән чиләген ызандагы коры тигәнәкләр куаклыгы астындагы канауга куйды да, көрәгеннән җирне кагып, аны штык сыман алга каратып тотты һәм, туктап тыңлый-тыңлый, күлгә таба атлады.

Ул үзенең чамалавында ялгышмаган булып чыкты. Пистолеттан аталар иде. Инде ул күл янына килеп җиткән чакта гына тагын бер ату тавышы яңгырады. Тик атучыларны саргаймаган, куе аю баланы чытырманлыгы артыннан күреп булмый иде. Көрәген калдырып, ул мәргәннәр адымы белән сак кына куаклар арасына керде, ботакларны аерып куйды һәм ялтыравыклы пәрәвез аша, прицельдәге шикелле, Жбан белән Киләлене күреп алды. Алар өстенә консерва банкасы куелган ташлардан өелгән пирамида янында тыныч кына сөйләшәләр иде. Жбан кулында—пистолет.

Гайнан абыйны аларның ваемсыз эшлекле кыяфәтләре гаҗәпләндерде. Ял көне уртасында атыш оештырганнар да исләре дә китми, әй! Болай тыныч урынны сайлаганнар үзләре. Мондый пычракта һәм юештә күл янындагы бу тупикка кемне һәм нинди эш алып килсен!

Ул күзәтеп торды. Тегеләр тагын биш мәртәбә атып җибәрделәр. Кызык, тагын да атарлармы икән?

Шулчак нindидер исләнгән азык белән аю баланы янында торган мичкәгә бер карга килеп кунды. Барысы да тын һәм тыныч. Гайнан абый яшеренгән урыныннан чыкмакчы гына иде, кинәт Жбан, бераз борыла төшеп, төзәмичә генә диярлек, шул каргага ике мәртәбә атып җибәрде. Тегесе, очып китәм дигәндә, һавада тузган каурый фейерверклары калдырып, сай суга килеп төште.

—Күз түгел, ә ватерпас!—дип җырлап җибәрде Киләле һәм карга янына йөгерде.

Жбан исә, пистолетын бармагында әйләндереп, ковбойлар эшләгән шикелле, көпшәсенә өреп алды да илтифатсыз гына әйтеп куйды:

—Бездән дә булмагач!

Гайнан абый куркуыннан куаклыкта багана сыман катып калды. Каргасы да бит аның белән Жбан арасына килеп кунды һәм ул Жбан аю баланы артында посып утырган Гайнанга атты дияргә була. Мондый көтелмәгән

курку өянәгеп аның беркайчан да кичергәне юк иде бугай әле. Очраклы рәвештә аңгыра, аның шәхесе көченнән бәйле булмаган Жбанның каргага җибәрелгән беренче пулясы сыйфатындагы үлем аның башыннан ике генә карыш өстән сызгырып үтте ич. Менә сиңа мә, сугышта исән кал, ә монда ниндидер бер җитлекмәгән бәндә кулыннан тояк ташларга язганмы? Шунда Гайнан абый, ауган агачлар арасыннан шатыр-шотыр чапкан кабан дуңгызы сыман, куаклыктан атылып килеп чыкты.

—Сез нәстә монда?!

Киләленең кулыннан каргасы төшеп китте. Жбан, бармагында әйләнеп торучы пистолеты турында онытып, күзләрен акайтты һәм көпшә авызын тагын Гайнан абыйга таба төбәде.

—Төшер пушкаңны, тинтәк!—дип акырды «отставкадагы хәрби майор». Һәм тагын кабатлады:—Сез нәстә монда?

—Нәстә-нәстә... Без бернәстә дә түгел,—дип мыгырданып алды Жбан, кинәт кайсыдыр вакыттан бирле шактый еш аралашкан Гайнан абыйның исемен онытып. Киләле таныштырган иде аларны, җәй көне үк инде.—Сез үзегез нәстә-ә?

—Нәстә-ә?—дип кабатлады Киләле дусты артыннан тутый кош шикелле.

—Тәмам нәстәләнеп беткән сез монда!—дип Гайнан абый кырыйдан Жбан янына килде дә, аның пистолеты көпшәсеннән тотып алды.—Төшер, дим.

Жбан буйсынды.

Хәзер алар икесе дә—үсмер белән ир, пистолетка тотынган килеш басып торалар иде. Жбан—тоткасыннан, Гайнан—көпшәсеннән.

—Бир әле карарга, курыкма—ашамам,—диде Гайнан абый, пистолетны каерып алырга тырышып. Ләкин Жбанның кулы инде күптән үсмернеке түгел иде. Алай гынамы, бу үсмер шактый гына хөрмәтсез рәвештә учы белән пистолет көпшәсеннән тоткан яңа ревизорның кулына китереп сукты да, коралын азат итте, аннары, аны саклагычка куеп, куенына яшерде.

Ачуыннан Гайнан абыйның чигәләре сулкылдап куйды, йөзендәге һәр тамыры кан белән тулышты.

—Тиешле җиргә җиткерермен менә!

—Ә мин сезне аударам аннары,—диде Жбан тоныкк тавыш белән һәм, моны исбат итәргә теләгән шикелле, куенындагы пистолетын рәтләбрәк куйды.

—Эчәгең юка,—дип елмаюын сыгып чыгарды Гайнан абый һәм, бераз үзен кулга алып, аталарча мактап куйган булды:—Ләкин синең әйткәнең ошый миңа. Ул батырлык турында сөйли. Йә, эшләр ничек соң, Рәшит?— дип дәште ул аннары Киләлегә.

—Уртача эш башыннан, Гайнан абый,—дип шаяртып алды тегесе.

—Ә әниең ничек?

—Безнең бетте, дип әйтергә кушты...

—Менә иртәгә яңа суйганны алып кайтам, керсен,—дип Гайнан абый кесәсеннән «Казбек» кабы чыгарды да, папиросны дусларча башта Жбанга, аннары шундук Киләлегә сузды. Тартып җибәрделәр.

—Мин инде,—дип төтен бәҗрасы чыгарды Киләле,—беттек, тотылдык, опергруппа килде дип уйлаган идем.

Әкренләп Жбан да тынычланды, һаман үсә барган аппетиты белән авызының әле бер, әле икенче кырыена йөртә-йөртә, папиросын чәйнәвен дәвам итте.

—Нинди пушка бу?—дип сорады Гайнан абый.

—«Вальтер»,— диде Жбан һәм бик гадәти генә итеп аны куеныннан

чыгарды. Гайнан абый үз кеше иде, тик андый очракларда мондый кисәк хәрәкәтләр ясарга ярамый, ә ул көтмәгәндә килеп чыкты һәм алай кургаш порциясен эләктерүең дә бар бит.—Яхшы машина, күрдегезме, карганы ничек, ә?

—Кая, карыйм әле.

Жбан, әйләндереп, пистолетын имән бармагына элде дә аңа сузды:

— Мәгез.

—Яхшы уенчык.

—Шулай булмыйча соң!

—Кайдан алдың?

—Таптым.

—Анда мондыйлар тагын юкмы соң?

—Юк.

—Ә шмайсер кирәк түгелме?—дип көлеп куйды Киләле.—Тәкъдим итә алам. Тик магазины гына юк.

—Андый байлыкны!..—дип Гайнан иреннәрен чалшайтты.—Калдыклар белән бала-чагалар уйнасын.

Алтмышынчы еллар башында безнең ишегалларында малайлар чын корал белән дә уйныйлар иде әле. Казан сугыш вакытында тыл шәһәре булса да, трофей алам-саламы монда да җитәрлек, хәтта—муеннан иде. Станция тупикларында да, шәһәрнең башка төрле почмакларында да танк-туплар эшелоны-эшелоны белән өелешеп торалар иде. Ватык техника бигрәк тә тимер юл вокзалы артындагы Иделнең су баса торган болыннарында күпләп җыелды. Бронялы коточкыч аждаһаларның кырыйларында тәреләр, свастикалар, баш сөякләре агарып тора... Минем абый—кырыгынчы еллар сукбайлары вәкиле, анда корылган пистолетлар гына түгел, хәтта сугышчан комплектлы пулеметлар да табып була дип сөйли иде. Безгә бу байлык тәтемәде, ләкин алай да кайбер нәрсәләр эләкте. Илленче елларда минем, хәтерлим, ярылган немец каскасы, парабеллум һәм шул ук шмайсер да бар иде. Әлбәттә, инде алар корал түгел, ә бары тик аларның ярым тутык скелетлары гына, ләкин барыбер «Балалар дөньясы»ндагы пластмасс кин куллану товарлары да түгел иде инде. Часовой уены уйнаган чаклар истә калды. Касканы киеп алам, күкрәккә шмайсерны асам һәм утын өемнәре буенча йөренәм. Димәк, стратегик мөһим объектны саклыйм. Ә дусларның разведчик булып куелганы арттан сиздермичә генә килә дә утын агачы белән каскага китереп тә ора. Шунда мин егылам, янәсе, һуштан язамын. Ә үземнең күз алдындагы түгәрәкләр бөтенләй уендагыча түгел. Малайлар соңыннан, авырттымы, дип сорыйлар. Һич тә авыртмады, дип җавап биргән булам. Янәсе, миндә каска ич!

Ике обойма патроннары булган «Вальтер»ны Жбан белән Киләле бер атна элек Жбанның мичен чистартканда төтен юлында кирпеч астыннан таптылар. Яңгырлы, пычрак көн иде ул, егетләр, эш юклыктан нишләргә белмичә, өйдә утыралар. Урамга чыгарга уйлаганнар иде дә, әнисе чыгармады, үзе эшкә китәр алдыннан гына ягып җибәргән мичләрен карарга кушты. Җәйдән соң әле бу мичне беренче генә тапкыр ягулары иде. Малайлар утын агачлары алып керделәр дә аның чуен ишеге янына килеп утырдылар, шулай итеп, мичне ашатырга җыендылар. Алар өчен бу барыбер ниндидер эш иде. Хуҗабикә өйдән чыгып кына китте һәм утыннар шарт-шорт килеп янарга гына тотынды, шунда мичнең барлык тишек-ярыкларыннан да төтен чыга башлады. Жбан әрле-бирле йөренде, капкачка сузылды, аны тартып ачты һәм ул «ите» белән диярлек суырылып чыкты һәм шулчак аның астыннан коры мич балчыгы коелды, оясыннан

бер кирпеч килеп төште. Аллага шөкер, әле ярый, Киләленең башына килеп кунмады. Аннары дуслар мичтән яна торган агач пүләннәрен алып таска ташладылар һәм ишегалдына алып чыгып сүндерделәр... Бүлмәне җиллләттеләр, төтен аркасында ыгы-зыгы килә башлаган фатир күршеләрен тынычландырдылар... Бераз сулу алгач, төтен юлындагы каһәр суккан капкач-шиберны тикшерергә керештеләр, һәм шунда кирпечләр артында берничә кат асбест тукымага һәм чүпрәкләргә төрелгән бер төргәккә тап булдылар. Кем яшергән аны? Кайчан? Алар өчен ярамаган кызулыкка карамастан, мичтә патроннар да бик яхшы яши биргәннәр иде. Ләкин бар нәрсә дә вакыт хөкеме астында бит. Сугышчан коралга да эшсезлектән җылынып яту туйдырган, күрәсең, ирекккә чыгасы килгән һәм шуңа күрә төтен юлын каплаган да.

Жбан белән Киләле, «вальтер» хакында бернинди шик һәм төрле имеш-мимешләр тумасын өчен, бу хәл турында Гайнан абыйга бик тәфсилләп җиткерделәр.

Гайнан абый пистолетны Жбанга кире кайтарды.

—Карагыз аны, малайлар, әгәр дә болай ачыктан-ачык кылансагыз, чөмерәсез сез...

—Бүтән алай эшләмибез,—диде Жбан, үкенү белән,—патроннар аз.

—Барыбер... Сезгә бу пушкадан котылырга кирәк. Беләсезме, утлы коралны саклаган өчен күпме тиешле? Юкмы? Шуңа күрә көн уртасында каргаларга атасыз да сез.

Шул ук көнне кич белән Гайнан абый, зур булмаган «тет-а-тет» сөйләшү өчен, өенә кайтып баручы Жбанны туктатты. Ул аңа теге пистолетны үзе теләгән суммага аңа сатарга тәкъдим ясады.

—Сат, бәладән башаяк, гөнаһлы булып куюың бар,—диде ул.

—Ә сезгә нинди гөнаһ өчен соң ул?

—Минем гөнаһым, дускай, шунда: мин шундый ук «вальтер»ымны ашыгыч эвакуация вакытында югалткан идем. Ә ул миңа бик кадерле, чөнки аны миңа һәлак буласы төн алдыннан фронтташ дустым бүләк иткән иде. Шылдымы?

—Ничек шылмасын?—Жбаннан шәраб исе килә иде. Ул елмая. Мондый «сөйләшү» аңа ошый иде.—Патроннары да кирәкме?

—Патроннары да.

—Тагын бер обойма бар алар миндә.

—Йә нәстә, кыскача гына әйткәндә?

Сатулаша башладылар. Инде кулны кулга сугабыз дигәндә генә Жбан, ни әйтергә дә белмичә, туктап калды һәм аңа бу эшне тагын уйларга кирәклеген белдерде.

—Берәрсе белән киңәшергә уйламагансыңдыр бит?—дип Гайнан абый сагаеп калды.

—Ю-у-к,—дип тынычланырлык итеп кулын селтәп алды Жбан,—бу турыда Киләледән башка беркем дә белми.

—Кара аны, башкача а-ля-мафо, фанфар тавышлары астында дөбердәрбез. Икебез дә... Бер аяктан.

—Борчылмагыз, хөрмәтле Гайнан Га-лям-фазлы-евич, фу, син! Фазлы... Фазлы-ляга-мович...

—Фазлыгалләмович,—дип төзәтте аны Гайнан абый.

—Шулай дим ич... Сез мине беләсез бит, барысы да бик шәп булыр. Ярты йөз сум һәм плюс циркка контрамарка, ә? Ха-ха!—Ни әйтсәң дә, егет шактый ук исерек иде.

Уйсулыкта, бүген көндез күрешкән күл буенда очрашырга килештеләр. Шуның белән аерылыштылар.

## Ау коллыктан яхшырак

Гайнан абыйга пистолет бик кирәк иде. Андый коралның аңа ни өчен кирәк икәнен ул үзе дә төгәл генә белми, ләкин аның бик тә кирәклегендә шиге юк иде. Жбан белән ачыктан-ачык сөйләшүнең дөреслегенә дә шикләнмәде ул. Нигә куркырга? Үзе шаһит булган Уйсулыктагы атыштан һәм Жбан белән Киләлене сүзләр белән беренче мәртәбә капшап караганнан соң, аны бөтен аңлы тормышы буена эзәрлекләп килгән дияргә мөмкин булган утлы коралга хуҗа булу теләге тормышка ашкан очракта алда моның нинди нәтиҗә белән бетәсе турында уйланып карады һәм аннары үз-үзенә: «Юк нәрсә! Нинди нәтиҗә? Алай да гражданкада нинди куянга әйләнеп калырга мөмкин икән!»—диде.

Анатолий Жбановны ул бик күптәннән белми, әмма аның намуслы кеше булуына шикләнмәде. «Намуслы» сүзен Гайнан абый үзенчә аңлый иде. Намуслы—димәк, Гайнан абый шикелле үк «тәртип» яклы кеше. Ягъни бер үк бакча җиләге. Мәктәп ишегалдында бу егет белән бер-ике тапкыр эчәргә дә туры килгәне бар. Акча—Гайнан абыйныкы, аяк—Жбанныкы иде. Кәрт тә суккаладылар, футболга да баргаладылар... Карасаң, болар барысы да вак-төяк шикелле, ләкин Гайнан абыйга үз кешене белеп алу өчен кыска гына очрашу да җитә иде. Гайнан абый үзен зур психолог дип саный. Аның, мәсәлән, колаклары буенча кешенең холкы турында белә алуы турында әйткәне бар. Ябышып торганы—үз акылындагы иптәш, башка карата перпендикуляр рәвештә басып торганы—бик тә үзсүзле, үҗәт, зурлары һәм колак йомшагы филнеке сыман асылынып торганы—рәхимле, андыйларда су ташырга мөмкин, очлары нәселсез этләрнеке шикелле төшеп торганы—алтылы, йомышчы малай... Жбанның колаклары салпы, ләкин алай зур түгел һәм башына карата почмагы туры түгел. Димәк, үҗәт, ләкин өйрәтүгә бирешә торган зат. Тик менә үзенең үги малае гына аның универсаль схемасына һич тә туры килми. Аның колаклары ачык булмаган конфигурациядә— салынкы түгел, ябышмаган, зур да түгел, шул ук вакытта кечкенә дип тә әйтеп булмый. Бер сүз белән әйткәндә, үзенең холкы шикелле үк, аңлаешсыз иде.

«Карале, монда да шул шайтан үги малай башка керә!»—дип, уйлары белән Жбанга, аның белән очрашуга әйләнеп кайтып, Гайнан абый авызындагы тәмәке төпчеген шадраланган күл өстенә төкерде. Күл янына ул килешкәннән бер сәгать алдан килде, бернинди шикләнер нәрсә дә тапмыйча, күлне әйләнеп чыкты. Юк, Жбан җанын ментларга закладка сала торган камырдан түгел. Аңа гына түгел, үзендә корал саклаган һәм аннан файдаланган һәркемгә милициягә баруда мәгънә юк.

Жбан бераз соңарып килде.

—Гүзәл кыз вакытында килә алмый инде ул,—дип ачусыз гына мыгырданып куйды Гайнан абый сәламләү урынына. Ул шундук аның курткасының корсагы тирәсендә кабарып торуына игътибар итте. Өстәвенә Жбан корсагын кулы белән дә тотып тора иде.

Берәр «Казбек» тартып җибәрделәр.

—Уйладынмы?—Гайнан абый сорамады, ә ничектер сүз арасында гына әйтеп куйгандай булды.

—Ес-с,—дип Жбан да шулай сүз арасында гына кыстыргандай җавап бирде.

—Әгәр дә «ес-с» икән,—чыгар.—Гайнан абыйга резинаны тарту туйдырды. Сонарып та килде, кабахәт, җитмәсә, бушлай аның папиросын да тарта.—Нәстә уйга калдың?

Шунда Жбан сатты. Һәм кирәген бирде, гаҗәпләндерде мәгънәсендә

дә, һәм серне ачты, сатты мәгънәсендә дә. Пушка өчен илле сум гына аз, диде ул.

—Ләкин без килештек бит инде,—диде Гайнан абый ачу белән.—Син килешкән идең бит.

— Ике көн элек иде бит ул. Ә чамалап карадым да... Азрак икән бит бу.

—Ярты йөз суммы? Искечә—биш йөз... Биш йөзлек!

—Сезгә тагын керенкага күчереп санап карарга иде,—диде Жбан, көлемсерәп.

—Монда керенканың ни катнашы бар? Реформа әле кичә генә йөзлекне ун сумга әйләндерде түгелме? Чагыштырып карарга да ярамыймыни? Син күпме телисең соң?

—Борчылмагыз, Гайнан Фазлы-галямович. Миңа акчаның килешкәннән артыгы кирәкми.

—Ә нәстә кирәк соң сиңа?

—Акча түгел, ә... Аңлыйсызмы, четерекле мәсьәлә монда...

—Четерекләнеп беттең. Йә, йә?

Менә шунда Жбан пистолетын сату турындагы килешү буенча кинәш сораган дустын сатуын үзе дә абайламыйча калды. Ул килешенгән түләүгә артык ун сум өстәүне түгел, ә беркайчан бернигә дә гаҗәпләнмәгән Гайнан абыйны гаҗәпләндереп, Николай Сергеевич Новиковның өстәл астында тузан җыеп яткан сары саквояжын сорады. Гайнан сызгырып куйды, ләкин шунда Жбан артында кем торганын һәм аның планының кисәк кенә шуна үзгәрүен—саквояжны урлау мөмкинлеге булуы аркасында түгел, ә турыдын-туры Новиков открыткаларын алырга сусаган кешегә чыгу мөмкинлеге булуын һәм, шулай итеп, Жбанның арадашчысыннан һәм аның йөзендә артык шаһиттан котылу, шулай ук илле, искечә биш йөз сумны да саклап калырга мөмкин икәнлеген аңлап алуын сиздермәскә тырышты.

—Юк, Субаев беркайчан да вак карак булып эшләмәде,—диде Гайнан абый абруйлы гына.—Андый артык мәшәкатьләрдән коткар инде син мине, дускай. Йә безнең элеккеге килешү үз көчендә кала, йә без дингездәге кораблар шикелле аерылышабыз.

Гайнан абый күз алдына китергәнчә, Жбан, килешкән чакта катнашмаган үзенең өлкән иптәше киңәшен тотмыйча, товарын бары тик акчага гына бирергә кыймады. Саламга тотынып карарга тырышты, пистолетны саквояжны аннан соң, киләчәктә кулга төшерергә бирелгән вәгъдә бәрабәренә алырга кушты, ләкин Гайнан абый катгый рәвештә баш тартты. Вариант ачык: куендагы кара көпшәле дәлил белән кемнеңдер кармагына утыртырга исәпләре. Тапканнар юләрне, борын аслары юеш бала-чагалар.

—Гуд бай, Анатолий!

Алай да Гайнан абый бу сөйләшүдән канәгать калды. «Вальтер» беркая да китмәячәк. Ул хәзергә Жбанда. Ә бу егет Пичуга сыбызгысына бии. Ә коллекционер Пичугинга открыткалар белән саквояж бик кирәк. Ә саквояж Новиковның язу өстәле астында. Әкияттәге шикелле килеп чыга монда: онык—әбигә, әби—бабайга... һәм, шулай итеп, шалканны тартып чыгармакчы булалар.

Александр Пичугинның коллекцияләр белән мавыгуы турында Гайнан абый Николай Сергеевичтан белгән иде. Профессор малае Йолдызчы янына бу елның август аеннан бирле кергәли башлаган икән һәм сары саквояждагы открыткалар белән бик кызыксынган, хәтта аларны сатуын яисә кайберләрен алмаштыруын да сораган. Ләкин Йолдызчы аның бу тәкъдимен катгый рәвештә кире каккан, чөнки ул открыткалар аңа, аларда

тасвирланган нәрсәләрнең кыйммәтенә һәм кайчан чыгарылган даталарына карамастан, үзләреннән-үзләре, барысы да бер үк дәрәҗәдә кадерле.

Таркау Йолдызчыдан саквояжын алу Гайнан абыйга берни дә тормый иде. Бүлмәсеннән йомышы белән ишегалдына чыккан чакларда бу күршесе ишеген беркайчан да бикләми... Ләкин башта Пичуга турындагы фаразының дөресме,түгелме икәненә ышанырга һәм аның белән очрашырга кирәк иде.

Гайнан абыйны Пичуга белән «Хезмәт резервлары» стадионында шәһәр беренчелегенә узган футбол матчыннан соң Киләле белән Жбан таныштырды. Кыр хуҗалары «Буревестник» белән очрашты. Гайнан абыйга каршы як капкасына ике туп керткән студентлар «унлыгы» ошады, ә Жбан белән Киләле бертуктаусыз, «унлык» ул—Сашка Пичугин, безнең яхшы дустыбыз, дип мактанды. «Телисезме, таныштырабыз?»—дип кабатлады дус-җанатарлар әледән-әле.

Яңа танышлар, бигрәк тә яшьләр белән танышлыктан Гайнан абый һич тә тартынмый иде. Ул аларны тиз арада үзенең дусларына, булышчыларына, йомышка йөрүче малайларга, кайчак хәтта бергә җинаять кылучыларга да әйләндерә ала. Аның инде күптән ул яшь, көчле, бер үк вакытта шундый эшләрне ерып чыгуы ансатрак та, катлаулы да, дөресрәге, куркыныч та булган хәтәр кырыгынчы еллардагы кебек саллы эшләр әйләндереп чыгарганы юк. Ләкин, инде сугыштан соң егерме ел узса да, аның табигате, холкы шундыйрак эшләр таләп итә һәм әле ул кайбер нәрсә белән шөгыльләнә дә бирде, үзенең тынычсыз канына тик торырга ирек куймады. Клептоман сыман, шунсыз яши алмый иде бугай инде ул. Куллары кычыта, җаны сызлана. Ә булышчылар, дип санады ул, эшкә караганда, күбрәк әнә шул җаны сызлануын, сагышын басу өчен кирәк. Мөгаен, яше дә сиздерә торгандыр, анда кемнәрнедер акылга керту-өйрәтү, үгет-нәсихәт бирү ихтыяҗы да барлыкка килде шикелле. Кул астына Жбан белән Киләле эләкте. Ләкин эш әлегә Киләлене ит сатып җибәрүгә тартудан ары узмады. Анда да бу эш белән ул үзе түгел, күбрәк аның әнисе шөгыльләнде. Ул үзе болай вак-төяк йомышларга гына тартылды. Моны тапшыр, тегене житкер... Жбан—Киләленең капма-каршысы, перпендикуляр-салпы колаклы, кабахәт кеше, аңгырарак. Ләкин андыйлар да кирәк бит. Менә ич яхшылык эшләргә—бер обойма сугышчан патроннары белән «пушка»сын бүләк итәргә теләде. Бүләкне кабул итеп аласы гына калды.

Матчтан соң Гайнан абый үзен «профессор малае, кичә мәктәпнең алтын медальле укучысы, ә бүген студент булып алган, ләкин барыбер үзебезнең егет булып калган» Пичуга белән танышырга кыстауларына бирелергә булды.

Александр Пичугин, якты нур сыман балкып, чистарып, душтан соң юеш чәчләрендәге җеп сыман нечкә аерымы белән ярым караңгы чишенү бүлмәсе ягыннан килеп чыкты. «Иртәнге трамвай сыман!»—дип сокланды Киләле, аңа карап.

Гүзәл үсмернең беренче сүзләреннән үк Гайнан абыйга аның алдында кем басып торуы ачык иде инде. Тиеннеке шикелле тырпаеп торган колакларына да карарга кирәкмәс иде: шөһрәт яратучы, нәркәс кеше. Бу—беренче нәтиҗә, мөһим нәтиҗә, ләкин бу өчлек белән ярты сәгать аралашу вакытында Гайнан абый ясаган икенче нәтиҗә шикелле түгел иде. Болар икесе дә—Жбан да, Киләле дә—менә шушы форвард тезгенендә. Ләкин нишләп, ни сәбәпле? Киләле—бер хәл, шуңа күрә ул Киләле дә, ул кушаматына туры килергә тиеш, ә менә Жбан нигә эләккән аның кармагына? Бу сөрхәнтәйне аның мәктәптәге алтын медале һәм футбол тубы тибеп йөрүе генә буйсындырмагандыр бит инде?..

Ул җәйге көндә Гайнан абый форвардка аның «Хезмәт резервлары»ндагы

уены һәм ул бик оста итеп манчыган ике тубы турында бик күп мактау сүзләре яудырды. Ул мактау сүзләре белән кешенен күнеленә ничек үтеп керергә һәм аның җанын ничек яуларга кирәген белә иде. Ана профессор малаенын нигә кирәк икәнен Гайнан абый әле ачык кына күз алдына китерә алмый, ләкин шулай да кирәк булачагы көн кебек ачык иде.

Күл буендагы унышсыз килешүдән соң уйга калган Жбан белән саубуллашкач, Гайнан абый, очраклы гына булса да анда Пичуга юкмы икән, дип карарга мәктәп ишегалдына юнәлде.

Мәктәп артында уралучы малай-шалайлар, гадәттәгечә, бик күп иде. Арлы-бирле йөренәләр, гитара дыңгырдаталар, мәзәкләр сөйлиләр... Ә Пичуга күренми иде. Ул йөдәтмичә генә, берәрсенен Пичуганы күрү-күрмәве белән кызыксынып алды, һәм аңа: «Граф Пичугин хәзер мәктәп ишегалдына килми, ул өйләнде»,—диделәр.

—Өйләнде?

—Өйләнде.

Бер атна үтте. Пичуга күренмәде. Гайнан абый тынычсызлана башлады, чөнки вакыт катламы астында «вальтер»нын эреп юкка чыгуы да мөмкин иде бит. Ул Жбан белән яңа сөйләшүләр алып бару, аның бөтен шартларына да күнү (харап булган, ярты йөз сум акча нәрсә инде ул!) турында уйлана башлады. Ләкин шунда ерткыч аучыга үзе килеп чыкты.

Алдан күрүчәнлеге буенча диярсең, ул Гайнан абый Йолдызчы белән сөйләшеп утырганда галим бүлмәсенә үзе килеп керде. Килеп керде дә, гаҗәпләнүдән авызын ачты: монда аны күрергә уйламаган иде. Ләкин үзен бик тиз кулга алды һәм йомшак, иркен генә, барган килеш иске трамвайга утырган шикелле, өлкәннәр белән әңгәмәгә кушылып китте.

Николай Сергеевич ни турындадыр сөйли иде. Ул, күктәге ятагында утырган килеш, хәзер алар барысы да чын тарихи җепшеклек, хәзерге сәяси, икътисадый, иҗтимагый, фәнни фикерләүнең тулы сулы җепшеклек чорында яши, диде.

—Бу—очып күтәрелеш, богаулардан азат булу. Һәм Гагаринның космоска менүе, валлаһи, яхшы фал! Бу объектив та, символик та, шигъри дә... Гагарин башка берниндн алдагы елда да оча алмаган булыр иде. Нәкъ менә шушы, безнең мең дә тугыз йөз алтмыш беренче елда гына! Минем сүзләремне хәтерләп калыгыз, Бөек Вакыт, Бөек Эпоха чоры килә.

—Бөек вакыт?—дип Гайнан абый калын иреннәрен чалшайтып куйды.—Һәрвакыт телдә булган, исеме белән үлемгә барган сугыш һәм безнең барлык җинүләребез каһарманын башыннан аягына хәтле шакшыга коендырдылар да—менә сезгә Бөек! Ә чит илләрдә ниләр булып ята тагын? Патрис Лумумбаны шапылдаттылар әнә...

*Ахыры киләсе санда*

# *«Казан утлары» архивыннан*



*Фронтовик язучылардан бер төркем. Сулдан уңга беренче рәттә: Риза Ишморат, Зәйни Шәһиморат, Мирсәй Әмир, Габдрахман Минский; өстәге рәттә: Сәет Шәкүров, Баян Гыйззәт, Хәй Вахит. 70нче еллар.*



*60нчы елларда Тукай премиясенә лаек булган шәхесләр. Сулдан уңга—композитор Александр Ключарев, композитор Заһид Хәбибуллин, шагыйрь Хәсән Туфан, актриса Шаһсәнәм Әсфәндиярова, композитор Җәүдәт Фәйзи. 1970 ел.*



*"Казан утлары" редакциясендә язучы Ибраһим Салахов белән очрашу.*
*Беренче рәттә (сулдан уңга): Л. Бадыйкшан, Л. Хәмидуллин, И. Салахов, Р. Фәйзуллин;*
*икенче рәттә: Р. Гаташ, Н. Гамбәр, Г. Бәйрәмова, Р. Бикчуров, М. Вәлиев-Барҗылы,*
*Р. Камалова, М. Әгъләмов. 1994 ел.*



*Шагыйрь Әнвәр Давыдовның (уртада) укытучы булып эшләгән вакытта туганнары белән төшкән рәсеме. Мордва Республикасы, Ләмбрә районы, Алтар авылы. 1940 ел.*



*Язучы Радик Фәизов (1931-2011).*

Печән базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Туфан
Миңнуллин

# МИНҺАҖ МАҖАРАЛАРЫ

***

*Минһаҗ абзый тагын каядыр китеп югалды. Җомабикә җиңгидән сораган идек:*

*—Ишетмәдегезмени, бизнес булды бит ул,—диде.*

*—Ничек?*

*—Каян белим ничек икәнен. Казанга чакырып алдылар. Министр үзе бугай. Кайтышлый өйгә генә кагылып китте. «Эзләмә, мин әллә кайда түгел, бизнес булып эшләп алырга китәм. Эшләр көйләнгәч, кайтып алырмын, диде. Вәлиәхмәтләр, Садретдиннар сораса, әйт, эзләмәсеннәр, кирәк булса үзем чакырып алырмын», диде.*

*Без нишләргә дип баш ватканда үзе кайтып төште Минһаҗ абзабыз. Безне җыеп алды.*

*—Егетләр, күп сөйләшеп торырга вакыт юк, җыеныгыз, китәбез. Үзегезгә тагын биш-алты кеше ияртегез. Бик сериуз эшкә алындым. Эш юк авылда дип елаган идегез, туйганчы эшләрсез,—диде.*

*—Нәрсә булды, ни-нәрсә эшләргә җыенасың?—дидек.*

### Министр кушты

—Җыенасың, дисезме? Мин җыенмый идем, җыендырдылар. Шул инде—өстәгеләр рәхәтләнеп картаерга да вакыт калдырмыйлар. Бладимир Илич Ленинннан башланган иде, һаман шул тирәдән җибәрмиләр. Бу юлы үзебезнен министр чакыртып алды. Авыллар белән камандалык итүче министр.

—Килеп чык әле, Минһаҗ абзый, сөйләшәсе сүзләр бар иде,—дип шалтырата.

Бардым инде. Шулай матур итеп чакыргач, нишлисең. Хан сарае шикелле двариста утыра икән. Бик матур итеп елмаеп күреште, хәлләрне сорашты.

—Садретдин абый эчүен ташладымы әле?—ди.

Менә күрәсенме, Казанда юкса эт тә белми Садретдинның кем икәнен, ә бу белә. Авылда туып-үскән егет шул. Онытма, Садретдин, мин сине хурламадым, ташлады, сөттән башка нәрсә эчми хәзер, дидем.

—Менә, менә, шул сөт мәсьәләсендә чакырдым әле сине,—ди министр,—Әйдә, чәйләп алыйк та, бер жирне карап кайтырбыз синең белән, ди.

Сөтләп чәй эчкәч, киттек машинасына утырып. Барып життек «Метро» дигән бер кибеткә.

—Син, Минһаж абзый, чүпрәк-чапрак ягына барма, әйдә, азык-төлек ягын карыйбыз,—ди министр. Киттек шул якка. Министр аңлатып бара.

—Менә күзенне сал, Минһаж абзый, күрәсеңме монда ничаклы ризык, шуның нихәтлесе Рәсәйдә эшләнгән, ди. Лимонны, әфлисунны әйтеп тормыйм, алары бездә үсми, боларын кара, болары бездә үсә бит, ди. Кара кишерне, укы, кайдан килгән? Израел дигән жирдән, ди. Израел кайда? Жир читендә. Кишере кишер инде, бәрәңгене күр, анысы да Израелдан. Без нәрсә, бәрәңге белән кишер үстерә белмибезмени, ди. Сөт ризыкларын кара, кайдан китерелгән, нәрсә, без инде сыер да сава белмәс халыкка әйләндекме, ди.

Ул сөйли, мин тыңлап йөрим. Нәрсә әйтергә чамалаганын сизмим. Кемнедер гаепләргә маташкан кебек тә тоела, үзенең дә гаебе барлыгы сизелә.

—Әйдә, минем кабинетка кайтыйк, калганын шунда сөйләшеп бетерербез, ди.

Кайттык. Тагын сөтле чәй эчтек. Ул сөйли дә сөйли. Сөйләве сөтле чәеннән дә тәмле. Татарча шундый таслап сөйли, куян койрыгы белән кызлар битенә пудыр яга диярсең. Ара-тирә телефоннан урысча да сөйләшеп ала. Анысын да инде урысның үзеннән дә уздыра. Хәер, мин үзем дә урысча үзебезнең райондагы урыслардан остарак сөйләшәм. Аларның яртысүзе мат та мат, ә минеке корып куйган автомат.

Ярый, анысы шулай, тик менә нигә чакырганын әйтми бит әле бу. Бик ерактан алдырырга чамалый, ахрысы. Тәки әйтте:

—Менә, Минһаж абзый, карадык, күрдең, сөйләштек. Инде болай—коткар син безне. Рәсәйне үк дип әйтмим, аны син генә коткара алмыйсың, Татарстанга ярдәм ит, ди. Милләт, милләт дип күп сөйлибез—тел дибез, фәлән дибез. Милләткә бит тел генә түгел, ашарга ризык та кирәк. Ач кешедә милләт кайгысы булмый, ди. Без зур эш башларга жыенабыз, алын шул эшкә, ди. Без сиңа акча бирәбез, син төзе кечкенә генә сыер фермасы. Тора-бара фермаларың күбәер. Миллиардир Хәйруллин, адашың Минһажев белән ярыша башларсың. Аларның ун фермасы булса, синеке мең булыр. Татарстанга гына сыймасаң, Рәсәйдә жир күп, анда да жәелерсен,—ди.

Менә шулай әйтте дә салды министр. Аннан инде кайдан ничегрәк акча табарга, тегесен-монысын сөйләштек. Риза булдым инде алынырга. Илне коткарырга кирәк бит. Мин тотынмасам, кем тотыныр. Израел белән Кытайга карап ятып булмый бит. Хурлыгы ни тора. Кытай миллиард кешене ашата, без 140 милиунны рәтле-жүнле ашата алмыйбыз. Менә шул, егетләр, жыенygыз, тотынабыз. Мин жирне үзебезнең районнан алмадым, читтәрәк булсын дидем. Үзебезнең жир үзебезнеке инде ул, читләр жирен дә үзебезнеке итик, дидем.

## Тотындык, ләкин...

Минһаж абзый анда чаба, монда чаба, төзү материаллары ташый, без эшлибез. Ферма күзгә күренеп үсә. Безнең эшләгәнне карап китүчеләр дә күбәйде. Арада берсе бик жентекләп сораштыра. Кем икәнен дә әйтми. Кыяфәте дә безнең якныкы түгел, Жириновскийга охшаган.

Шулай әйбәт кенә эшләп йөргәндә Минһаж абзыебыз югалды. Ятабыз эшсез. Эчүен ташлаган Садретдин абый да кайдандыр самогон табып эчкән. Пошаманга төштек.

Берзаман Минһаж абзый кайтып төште. Кәефе кырылган. Дәшми дә, сөйләшми дә.

—Нәрсә булды, шеф?—дибез.
Озак дәшми торды да:
—Сез авылга кайтып торыгыз, кирәк булсагыз, кайтып алырмын,—диде.
Безнең беләсебез килә.
—Шулай да әйт инде, кайларда булдың, ниләр күрдең-ишеттең?—дибез.
—Күрдем, егетләр. Күрсәттеләр миңа дөньяның түгәрәк икәнен,—дип сүз башлады Минһаҗ абзый.—Бер шома гына адәм килеп карап йөргән иде бит безнең эшне. Көннәрдән бер көнне шул адәми зат мине юлда тотып алды да матур гына исәнләште.
—Без сезне күптәннән беләбез, Мингаз Габсаматович, ди. Линин белән бергә эшләгәнеңне дә, Лэнит Илич Брежневка роман язып биргәнеңне дә, Хруччув белән хат алышканыңны да, Гарбачув белән чәй эчкәнеңне дә беләбез, ди. Син безне белмисең, шунысы жәлке, ди. Сезне үзебез белән таныштырасыбыз килә, ди. Утырыгыз әле минем машинага. Курыкмагыз, исән-сау килеш Җомабикәгез куенына кайтарып салырбыз, ди. Шундый итеп сөйләшә—хөрмәт тә иткән кебек, киңәш биргән дә кебек, куркыткан да кебек. Мин бит инде төрлесен күргән—утырдым машинасына.
Мәскәү ягына чаптырды бу машинасын. Мәскәүгә җитәрәк самалютка күчереп утыртты. Киттек очып. Аска карап барам. Астагы галәмәт: җире дисеңме, елгасы-күле дисеңме, урманы дисеңме. Уйлыйм инде—шул тамаша байлык белән нигә болай ярлы яшибез, дим. Министр искә төште. Ул да минем сыман уйлаганга мине фермер булырга кыстаган инде. Мине алып баручы адәм дә аска карап бара, ул да мин уйлаганны уйлыйдыр сыман.
—Шушы Жир шарын сиңа бирсәләр, нишләр идең, Мингаз Габсаматович?—ди.
—Каян белим, мин бит Ходай Тәгалә түгел,—дим.
Көлде бу рәхәтләнеп.
—Бигрәк хитрый халык сез татарлар, ди. Әйтәсе сүзегезне әйтеп бетермичә сөйләшәсез, ди. Бер сүзне сөйлисез, икенчене уйлыйсыз, ди. Менә мин Сезне безнеңчә уйлатыр өчен алып барам, ди.
Шуннан ары сөйләшмичә генә очтык. Самалют җиргә төшәргә җыенгач кына телгә килде адәм.
—Аста Әмрикә,—диде.
Самалюттан төшеп машинага утырдык. Барып життек фабрика ише бер җиргә, кердек эчкә. Ә анда, егетләр!.. Кубамитырлап өелгән тавык боты. Киткән ыскылад буйлап тезелеп—очы-кырые юк.
Шунда мине алып килүче адәм кемнедер чакырып китерде.
—Ни өчен бу тавык ботлары болай күп?—ди.
—Алучы юк,—ди Әмрикә кешесе.—Без тавыкларны суя торабыз, канатлары белән түшләрен ашыйбыз, ботларны алучы юк, ди. Рәсәй аладыр иде, нигәдер туктатып тордылар, тагын ала башлыйбыз диделәр, озакламый котылырбыз, ди.
Минем белән килгән адәм:
—Акәй!—диде дә без чыгып киттек. Самалют янына барып, самалютка утырдык та тагын очтык. Оча-оча шактый җир киткәч, минем адәм:
—Аста Израел,—диде. Тагын машинага утырып киттек. Бара-бара зур гына бакчага килеп чыктык. Андагы байлык!.. Иге-чиге юк. Тау-тау кыяр кибәннәре, кишер тавы, бәрәңгене әйткән дә юк—Каф тавыннан биегрәк итеп өеп куйганнар.
Мине алып килгән адәм монда да берәүне чакырып китерде.
—Нигә болар болай өелеп торалар?—ди.
Яшелчәләрнең хуҗасы әйтә:
—Кая куйыйк без аларны,—ди. Алучылар юк, ди.

—Чериләр бит болай булгач,—ди «минем адәм».

—Нишләтәсең инде,—ди хуҗа.—Рәсәй ала да, әмма дә ләкин әз ала, ди. Монда да:

—Акәй!—дип китеп бардык. Машинадан самалютка, самалюттан машинага күчә-күчә әллә ничә илгә кереп чыктык. Мин ишеткәнчә, бөтен җирдә зарланалар: берсендә сарык итен кая куярга белмиләр, икенчесендә—сөтне...

Бер атна йөргәч, кайттык Мәскәүгә. Мәскәү кырыендагы бер ресторанга кереп утырдык.

—Күрденме?—дип сорый мине йөртеп кайтучы.

—Нәрсәне?—дим.

—Барган илләрдәге пыраблималарны,—ди.

—Күрдем,—мин әйтәм.

—Шуннан ни әйтәсең инде?—ди.

—Безгә дә шулар кебек булырга кирәк,—дим.

—Күргәнсең, бер нәрсә дә аңламагансың,—ди адәмем.—Сез татарлар гел үзегез турында гына уйлыйсыз. Бүтәннәр турында да уйларга кирәк. Нифтедән безгә нигә аз өлеш тия, дип кычкырынасыз. Гел без дә без... Әмрикә тавык ботын кая куярга белми изалана, сезнең гамегездә дә юк. Израелдә яшелчә чери, ә сез кыяр үстереп интегәсез, үзегез ферма салып ит-сөт булдырырга маташасыз, бүтәннәр турында кайгыртмыйсыз. Интырнатсиянал дигән хис юк сездә. Ташлагыз бу гадәтегезне. Үстереп интеккәнче сатып алыгыз,—ди. Менә син ни пычагыма дип ферма салырга тотындың? Кемгә кирәк синең ферманң?

—Безгә кирәк,—мин әйтәм,—министрга кирәк, халыкка кирәк.

—Син халык дип маташтырма. Халык ул ни бирсәң, шуны ашый,—ди адәм.

Сүздән сүз чыгып бәхәсләшергә тотындым. Ул үзенекен әйтә, мин үземнекен. Шунда мин бер нәрсәне анлаган сыман булдым: без үстергәндә бу адәмгә берни дә тәтеми икән, сатып алганда моңа да өлеш чыга икән. Шуны сизеп алдым да:

—Үгетләмә, төзеп бетерәм ферманы, сөт чишмә булып агачак, ит түшкә-түшкә булып эленеп торачак,—дидем.

Теге адәм кычкырып көлде.

—Линин белән эшләсән дә дурак икәнсең,—ди.—Нәрсә, мин сиңа ферма төзергә ирек бирә дип уйлыйсыңмы, ди. Тот капчыгыңны. Төзеп бетергәч тә банкрут итәчәкбез без син ахмакны,—диде.

—Папрубуй,—дидем.

—Папрубуем,—ди бу.—Шуны бел, кайтканыңа электр-газ бәяләре арткан булыр. Бензинның бәясе синең сөтеннән өч-дүрт тапкыр кыйбат булыр. Тагын да үҗәтләнсәң, тагын арттырырбыз.

—Арттыра алмассың, Дума бар,—дим монарга.

—Дума ул думать итәр өчен. Алар уйлаганчы без эшләп куярбыз,—ди. Әйт анда типлитса тотучыларга, тавык үрчетүчеләргә, аларның да башына җитәчәкбез. Чаллы дигән калада берәү ипи пешереп маташа. Аны да туктатабыз. Электрсыз, газсыз ипи пешереп карасын. Ә пешкән ипине кайсы илдән кайтартырга икәнен без беләбез. Үзең турында гына түгел, дөнья турында уйларга өйрәтәбез сезне,—диде дә бу китеп барды. Мин ристаранда ул ашаган өчен дә түләп, менә кайттым. Инде нишлибез. Мин үзем курыктым. Әллә төзеп маташмыйбызмы ферманы? Барыбер бөлдерерләр.

Минһаж абзый сүзләреннән соң без дә уйга калдык. Дөрес килеп чыга кебек бит теге адәмнең сүзләре. Ярый инде без түзәргә күнеккән, Минһаж абзыйга да шөгыль бетмәс, министрыбыз кызганыч, тырыша бит...

***

*Минһаҗ абзыйны больницага салдык. Кермәскә бик тырышты. Миннән котылу өчен шулай эшлисез дип киреләнде. Кирәргә теләмәвенең сәбәбен соңрак ачыкладык—бик күпне белүче Вәлиәхмәт абый больницаны хастаханә дип әйткән дә, Минһаҗ абзый, мин хаста түгел, дип кырт кискән, бик кыстасагыз бүлнис дигәнендә бераз ял итеп чыгармын, дигән. Авыл белән җыелып үзебезнең Президентка хат яздык.*

*—Килсен, теләсә кайсы бүлнискә ишек ачык,—дигән хөрмәтле Президентыбыз.*

*—Кергәләп-чыккалап йөрергә бик яхшы урын,—дип Минһаҗ абзый базар янындагы больницага керергә ризалык биргән.*

*Ун көн яшәп кайтты ул аннан. Яшәргән, егетләр кыяфәте кергән үзенә.*

*—Нишләттегез ул карт җүләрне,—дип зарланып йөрде Җомабикә җиңги,—төн озыны йоклатмады,—ди.*

*Без инде, билгеле, хәл белергә җыелыштык.*

*—Йә, ничек, Минһаҗ абзый,—дип сорадык.*

*—Күреп торасыз,—диде бөек авылдашыбыз.*

*—Бик әйбәт күренәсең, югыйсә көне-төне дәүләт эшләре белән мәш килеп йончыган идең,—дидек. Ун көнгә китеп торган арада да илдә нинди галәмәтләр булып алды,—дидек.—Газга, электрга бәяләр һаман күтәрелә. Бөек державаның гына бәясе төшә,—дидек.*

*—Нәрсә, ниләр булганны, ниләр күргәннәремне сөйләтер өчен килгәнсездер. Әллә ниләр булмады болай. Бәя күтәрелә инде ул. Рәсәйдә яшибез ич, нигә исегез китте. Искә алып сөйләрлек ике нәрсә генә булды. Беренчесе—минем аркада прописырлар яңа ачыш ясадылар. Яңа авыру барлыгы беленде.*

## Феминит

...дип атала торган чир. Әллә нәрсәсе дә юк инде аның, шулай да чир, авыру, ягъни мәсәлән. Үлем-мазар белән бетми ул чирнең ахыры, ну мәгънәсе зур. Болайрак булудан башланды чирнең тарихы. Килеп урнаштым шулай бер кешелек палатага. Дуктыр керде, кыяфәте белән Каратун урысына охшаган. Танып алды мине.

—А-а, Мингаз Габсаматович, зимләк, сам пажаловал к нам,—ди,—какой витер бросал вас к нам,—ди.

—Вот, мин әйтәм, послали свои деревенские,—дим,—Больнуй говорят.

—Сейчас посмотрим,—дип чишенергә кушты.

Без бит кушканны үти торган халык, чишен дисәләр, соңгы ыштанны салып бирәбез, чишендем. Бастырып та тыңлады бу мине, яткырып та тыңлады йөрәкне, кан басымын үлчәде.

—Сто двадцат на восемдисят,—ди,—как у маладува жеребса,—ди.—Но чарауна провирять будем,—дип чыгып китте.

Сузылып яттым караватка. Палата минем медсестралар җыелып утыра торган урын каршысында икән. Сөйләшкәннәре, көлешкәннәре ишетелә. Яшьләр, ахрысы, тавышлары кенәри чыпчыкларыныкы шикелле. Оҗмах бакчасында яткан кебек. Татарча сөйләшәләр. Без яшь чакта систралар марҗа иде, хәзер татар кызыйлары кереп тулган. Сөйләшәләр болар, мин тыңлап ятам—кайсы яклардан җыелганнар икән дим. Мишәр кызлары күбрәк. Араларында чыкылдый торганнары да, цыкылдый торганнары

да бар. Болар йә Чистай, йә Чүпрәле ягыннан инде, дим. Минзәлә ягыныкы да бар шикелле: берсе «Ярай, кыздар, мин кайтаем инде», дип ычкындырды.

Кереп чыга башладылар болар палатага, карап ятам боларга картайганыма ачуым килеп. Шунда берсе кан басымын үлчәргә дип беләгемә орынган иде, күз алларым караңгыланып китте. Минем күз алларым караңгыланды, кызыемның күзләре акаеп маңгаена менде. Шул көенчә чыгып чапты бу. Теге врачны ияртеп янадан керде. Ах-ух килә. Врач аптырап мина карап тора.

—Мин караганда нормальный иде,—ди.

Кыз кан басымын үлчәргә дип янадан беләккә орынды. Бу юлы күз аллары караңгыланмады, йөрәк тыпырчынырга тотынды. Врач кан басымын күрсәтә торган машинага карады да:

—Ышту такуй!—дип кычкырып җибәрде.—Ни мужыт быйт,—ди.—Такого ни бывает,—ди. Чөнки дә кан басымын үлчи торган машина 350гә 200не күрсәтә иде. Болай булганда кешенен йөрәге шартларга тиеш икән. Ә мин исән. Шуннан врач үзенең машинасы белән үлчи башлады. Үлчәде дә тагын миңа карап тора. Үзе һаман:

—Ышту такуй!—ди. Чөнки дә аның машинасы 120гә 80не күрсәтә икән. Шуннан бу теге хур кызына үлчәргә кушты. Үлчәде кызыкаем—350гә 200. Врач һаман:

—Ни мужыт быйт,—ди.

Тагын үзе үлчәде—120гә 80. Кызның машинасы белән үлчәде—120гә 80. Үз машинасын кызга биреп үлчәттерде—350гә 200.

—Нимужыт быйт!—дип систра кызны ияртеп чыгып китте врач.

Шуннан мин зоопарктагы маймылга әйләндем. Систралар керәләр дә карыйлар, керәләр дә карыйлар. Аннары берәм-берәм кан басымын үлчиләр—350гә 200. Кызларның чыркылдаганын-цыркылдаганын ишетеп Җомабикә яшендәгерәк бер хатын керде.

—Ни бар, нигә ыржаясыз?—ди. Бу зур врач икән. Аңлаттылар мона. Ул үз машинасы белән кан басымын үлчәде—120гә 80. Кызлар үлчи 350гә 200, карчык үлчи 120гә 80. Өелешеп чыгып киттеләр. Прописыр чакырткannar. Кәҗә сакаллы, шома битле минем яшьләрдәге адәм. Бу да үлчәде—120гә 80. Кызлардан үлчәттерде—350гә 200. Шулай итеп Минһаж абзагыз бөтен Казанны аякка бастырды. Мәскәүгә шалтыраткannar. Анда да:

—Ни мужыт быйт!—дигәннәр.

Быйт или не быйт,—дигән ди безнең авылның Гамлит дигән бер малай. Моның серен беләсезме кем ачты? Уборчитса. Фәйрүзә исемле сөйкемле генә бер карчык. Юеш чүпрәк белән тәрәзә төпләрен сөртеп йөри.

—Булмый ни, булыр да,—дип сөйләнә үзе.—Күзеннән күренеп тора мутлыгы,—ди. Кызлар кулы тигәч күтәрелә инде ул,—ди.

Шунда инде, кем әйтмешли, мәсьәлә ачыкланды. Кызлар кулы тисә минем тәнгә, кан басымы күтәрелеп китә икән, ирләр белән карчыклар тисә, чурт та булмый икән. Менә шундый авыру таптылар врачлар. Кемнәрдер хәтта ки орден да алды бугай. Чиргә феминит дип исем дә кушканнар бугай. Шундый чир табарга ярдәм иткән өчен миңа рәхмәт тә әйттеләр. Рәхмәтен рәхмәт тә, начар ягы да булды шул. Кызлар кулын тидерми башладылар беләгемә. Теге прописыр әйткән бугай:

—Берәр систрагыз кочаклап ятып карасын әле шул Габсаматовны, ни булыр икән,—дигән.

Яткырмадылар. Шундый да кыйммәтле кешене үтереп куюыбыз бар, дигәннәр.

Минем икенче чирем билгеле чир булып чыкты.

## Аллергия

...дип атала икән ул. Берәр ярамаган ризык капсаң, яки дә ярамаган дару каптырсалар, йә булмаса иснәргә ярамый торган ис иснәсәң, бөтен тәнгә кызыл-кызыл нәрсәләр чыга икән. Минем дә чыкты бит шул тимгелләр. Бөтен тәнне басты. Ашауны солы боткасына калдырдылар, дару бирмиләр, палатаны сәгать саен юып-сөртеп торалар, чир китми.

—Шту такуй?—ди минем врач. Бу юлы «шту такуй»ның нинди чир икәнен үзем чамаладым. Ник дисәң, Гәптрәхимнең оныгы авылга кайткан саен шешенә, тәннәре тимгелләнә, борыны пышкылдый башлый иде. Нигә алай икәнен ишеткәч, исебез китте: сыер терлеге яңа гына салып киткән белен исе ярамый булып чыкты. Мина да нәрсәдер ярамаган инде. Нәрсә ярамады икәнен уйлап ятам. Ниләр булды, ниләр ашадым икән дим. Ашауга бәйләнерлек түгел—гел солы боткасы ашаттылар. Чуртым да булмады моңа чаклы. Тә-ә-әк, дип уйлыйм. Кайчан башланды соң әле, дим. Үзем генә ятканда нармальны иде, палатадагы икенче караватка бер кешене керттеләр. Шул көннән башланды түгелме? Ничек, ничек булды дип уйлыйм. Әһә, керттеләр тегене. Исәнләштем. Здрастуйте дип сәламемне алды. Танышырга кирәк бит инде яңа күрше белән. Сорыйм монардан: «татаринмы, урыскиймы?»—дим. «Татарин» ди. Алайса, үзебезчә сөйләшәбез икән дип монарга татарча дәштем. «Я предпочитаю говорить по урыски»,—ди. «Әһе, дип уйлыйм, мин яратып бетермәгән нәселдән икән бу. Ярар, түзәрбез, дип уйлыйм, бер кичкә кер пичкә, өч-дүрт көннән чыгасы», дим. Син, Вәлиәхмәт, минем кесә тилифунына татарча «Әпипә»не көйләп куйган идең бит. Тотынды берзаман «Әпипә»гә сиптерергә тилифун. Садретдин шалтырата икән. Сөйләштек Садретдин белән рәхәтләнеп. Хәтерлисендер, Садретдин... Бераздан тагын шалтырый «Әпипә», монысы Вәлиәхмәт икән. Сөйләштек бит инде. Шуннан придпачитаю урыски дигән адәми зат әйтә: «Гаварите каридорда ди, я ни намирен слушать ваши каля-баля», ди. «Как, мин әйтәм, кәлә-бәлә? Бу бабаңнар теле», дим. «Ни имеет значиние», ди. Шуннан, күрәм, тәнгә кызыл-кызыл тимгелләр чыга башлады. Шуннан китте инде паника врачта. «Шту такуй да, шту такуй». Миндә тимгел кайгысы түгел. Ачу килә. Бладимир Илич белән эшләгәндә аның әйткәне искә төште. «Синең, Габсаматов, урыска исең китмәсен, урысның яхшысы да начары да урыс инде. Син урыс булырга маташкан татардан саклан», дигән иде. Әйе, әйе, урысчалап «берегис», диде. Бу күрше урыс булырга азапланган татар булып чыкты бит инде. Шуннан әйттем врачка, «Мине бүтән палатага, чын урыслар янына күчер, дидем, ни лүблү урыски татаринны», дидем. Көлде бу. Ләкин дә күчерде. Рәхәтләндем чын урыслар белән урысча сөйләшеп. Тимгелләр бетте. Шунда әйтте инде врач, «Синдә, Мингаз Габсаматович, урыски татарларга аллергия икән», ди. «Сак бул, астма дигән чиргә әйләнмәсен, урыски татариннарданерактарак йөр», диде.

## Дошман

Дошманны әллә кайдан эзләмәскә кирәк. Дошман ул һәрчак янында йөри. Дусны эзләп табарга кирәк, дошман үзе табыла. Менә әйтегез, Вәлиәхмәт әйткән хастаханәдә нинди дошманым булсын инде минем. Теге татар урысын әйтмәгез, ул дошман да түгел, чурт та түгел. Ул минем кебекләргә авыру таратучы ни генә... Ничек әле авыру таратучы җәнлекнең исеме? Юк, юк, вирус түгел... Шул, шул—дөрес сукалыйсың, Садретдин, микроп ул авыру таратучы. Теге минем янга кертелгән бәндә микроп кына ул, дошман түгел. Дошман ул башка. Менә шул табылды хастаханәдә.

Сез беләсез бит инде, минем дәфтәрне. Анда мин төрле нәрсәләр язып барам. Күнелгә ятышлы җырларны да күчереп куям. Менә шул дәфтәрем төшеп калган каридурда йөргәндә. Шуны бер татар табып алган. Миңа

бирде бу моны. Чөнки анда исем-фамилиям язылган. Бирүен бирде дә үзе хәйләкәр генә итеп миңа карап тора. «Ә бит мин сине, теләсәм, утыртып куя алам», ди. «Кая?» мин әйтәм. «Тиешле жиргә, ди, чөнки дә син Бөек Россия дигән державаның дошманы, ди, син яшертен генә Бөек державага каршы көрәшәсең, коткы таратасың», ди. Аңламый торам. Ул төшендерә: «Син бу дәфтәреңә нәрсәләр язып куйдың?» ди. «Жыен юк-бар», дим. «Ю-у-ук, юк-бар түгел, иптәш, ди, әйт әле бу жыр нәрсә аңлата?

Әй икегез, икегез—
Икегезнең битегез.
Икегез дә шулай яшәп
Тигез гомер итегез.

Нәрсә аңлата?..» «Нәрсә аңлатсын, туйда жырлыйлар аны», дим. «Ю-у-ук, ди, туй жыры язып куярга син кияү түгел, ди. Кемнәр алар икәү? Кемнәрне күздә тоттың? Нәрсә син алардан кияү белән кәләш ясадың?» ди. Аларны, нәрсә, нетрадиционныйлар дип атыйсыңмы? Син кемнәргә селтәнәсең?» ди. Чуртым да аңламыйм. Аңлап алгач, тотындым көләргә. Ә бу әйтә: «Ашыкма көләргә», ди. Аннары, «икегез» дигәннең кемнәр икәнен төшенгәч, әйттем моңарга дурак дип. Ул нәрсә ди? «Минем кебек дураклар теге елларда млиун кешенең башына життеләр. Кирәк булса, минем ише дураклар эшкә жигелергә гатавый тора, ди. Ә менә бу жырың өчен суд ясамыйча да атарбыз», ди.

Дулкынланып сулар керә
Парахут идәненә.
Мондый рәхәт, матур тормыш
Тик безнең илдә генә.

Син бит Бөек державадан көләсең. Мактаган булып мыскыл итәсең. Идәненә су кергән парахут нинди була инде ул? Батып барган парахутмы? Нәрсә, безнең ил батып барамыни? Шундый илдә яшәү рәхәт буламыни?»

Тыңлап торам моны, чынлап та шулай килеп чыга икән бит. Юкса мин аны Габбасов дигән жырчының жырыннан күчереп куйган идем. Ул аны жырлаганда безнең ил СССР иде әле. Чыннан да батты бит ул парахут. Бәйләнергә урын бар икән бит. Шүрләп куйдым. Ә теге адәм бәйләнепме бәйләнә. «Монысы тагын нәрсә? ди.

Сулар итеп йотыймммы?
Чәчәк итеп тотыймммы?
Әллә инде шашып китеп
Кочагымда сытыймммы?

Монысын кемнән күчердең?» «Анысына ни булган тагын?», дим моңарга. «Ни булганмы? «йотыйммы», «тотыйммы», «сытыйммы» кем фамилиясе белән рифмалаша? Шуны сытарга жыенасыңмы?» Монда инде, егетләр, агарып каттым. Чөнки дә ул шигырьне яшьләрнеке кебегрәк булсын диеп үзем язган идем. Вәлиәхмәт әйтмешли, жыеп әйткәндә, бетерде бу мине. Бетерде дә, «Син дошманым минем», дип укол кадатырга кереп китте. Ярый әле дәфтәрне үзенә калдырмады. Бетерә иде башны. Мин ул каһәр төшкән дәфтәрне ертып аттым.

Бу Минһаж абзыйның шулай куркып калуыннан көлештек. «Үтте бит инде андый заманнар», дидек. «Бәлки үткәндер дә, ләкин дә ул дәфтәргә минем «Рәсәйдә беркайчан да бернәрсә дә үзгәрми», дип язып куелган сүзләр бар иде бит», диде Минһаж абзабыз.

Асия
Хәмзина

# АТАКЛЫ РАЗВЕДЧИК ИБРАҺИМ АГАНИН

Бу сугышта аңа катлаулы йөкләмә эләкте. Ул немец офицеры—зондерфюрер формасында гестапоның өнендә махсус бурычлар башкарды.

Совет разведчигы паспортта Ибраһим Хатәм улы Аганин булса, сугыштан соң СССРда һәм чит илдә дөнья күргән китапларда, матбугатта ул Игорь Харитонович Аганин яки Агапов яисә Миронов дип аталды. Ибраһим ага минем әниемә туганнан туган иде. Ул вакытта аңа унсигез яшь булган...

Утызынчы еллар уртасында халыкта интернациональ хис-тойгылар көчле иде. Балалар «испан башлыклары»н киеп йөрделәр. Поездларда Мадридны яклар өчен өйләреннән качкан малайларны ауладылар. Мәскәү урамнарында Испаниянең зур карталары эленде һәм олылар, ерак илдәге вакыйгалар, соңгы яңалыклар белән уртаклашып, озак кына шулар яныннан аерыла алмадылар.

Шул чорда Мәскәү үсмере Ибраһим Аганин да телләр өйрәнергә ашыга. Индусларга ярдәм кирәксә дип—һинд телен, Германия халыкларын фашизмнан коткарыр өчен—немец телен өйрәнә малай.

Инде 14 яшендә ул немец сәясәтчеләренең һәм икътисадчыларының хәрби хезмәтләрен төп нөсхәдән укый. Бу уңышында әнисенең бертуган абыйсы—аның язмышына зур йогынты ясаган кадрлар чекисты Алексей Николаевич Агишевнең роле зур була. Энекәшенең башкалардан аерылып торган талантын күреп, ул күп балалы сеңлесеннән малайны үзенә тәрбиягә бирүен сорый.

Абыйсы гаиләсендә тәрбия кырыс була: һәр көнне әтәчләр белән уяна, спорт белән шөгыльләнә, мәктәпкә барганчы һәм кайткач чит телләр өйрәнә, сәяси эмигрант Эльзадан немец теле дәресләре ала.

Унҗиде яшьләргә Ибраһим Аганин немец телен камил дәрәҗәдә үзләштереп бетерә. Германиядә бер тапкыр да булмавына карамастан, илнең дәүләт төзелешен, икътисади географиясен бик яхшы белә. Ул кайсы шәһәрнең кайда урнашканын, анда күпме кеше яшәгәнен һәм аларның нәрсә белән шөгыльләнгәнен төгәл әйтеп бирә ала. Шулай ук немец лидерларының биографиясеннән, язучыларыннан, шагыйрьләре һәм композиторларыннан хәбәрдар була. Ә Кант, Гегель, Шопенгауэр кебек немец фәлсәфәчеләренең фикерләрен, гыйбарәләрен күпме кирәк—шулкадәр мисалга китерә ала. Шушы сәләтләре өчен аңа сыйныфташлары «профессор» дип кушамат та тага. Ибраһим мәктәпне бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый. Бауман исемендәге Мәскәү югары техник училищесына укырга керә. Әмма анда бер курс кына укып кала. 1941 елның 22 июнь иртәсендә ул район хәрби комиссариатына килә һәм фронтка җибәрүләрен сорый.

---

Асия ХӘМЗИНА—*журналист; Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре. Чиләбе өлкәсендә яши.*

...И. Х. Аганинның хәрби биографиясен ике өлешкә бүләргә мөмкин: 1943 елга кадәр һәм аннан соң. Беренчесе, ин кыскасы, сугышның башлануын үз эченә алса, икенчесе—аның калган барлык тормышын.

Иң элек җәяүле гаскәргә эләгеп, унҗиде яшьлек Аганин кул сугышларында, «тел» алып кайтуларда катнаша. Бик тиздән аның немец телен белүе кирәк булып чыга. Бервакыт тылга ташланган дошман десанты тар-мар ителә һәм парашютчыларның бер өлеше әсирлеккә эләгә. Батальонның политругы күрше-тирә бүлекчәләрдән немец телен белүчене эзли. Аганин немец әсирләре сөйләгәннәрне тиз арада тәрҗемә итеп бирә. Һәм шуннан башлана. «Тел» алалар—Аганинны чакыралар. Немец гаскәрен чолгап алгач, алар белән «сәяси әңгәмә» үткәрергә кирәк була—Аганин солдатлар белән рупор аша «хәбәрләшә». Шундый әңгәмәләрдән соң еш кына немец солдатлары әсирлеккә бирелә. Аганин белән полкның разведка бүлегендә дә кызыксына башлыйлар. Алга таба барысы да кино тасмасындагы кебек тиз һәм борылгысыз була.



Аны хәрби тәрҗемәчеләр курсына укырга җибәрәләр. Ул мондагылар арасында иң яше, әмма хәзерлек буенча иң алдынгысы булып чыга. Аннары, чит телләрнен хәрби институтын тәмамлый һәм фронтка ыргыла. Бу вакытта аның өлкән абыйсы, апалары һәм әнисенең абыйсы А.Н.Агишев сугыш эчендә була.

Ул тәрҗемәче һәм полкның разведка җитәкчесе буларак, Мәскәү һәм Воронеж янындагы сугышларда катнаша, аннары Сталинградтагы хәрби бәрелешләргә җибәрелә... 1943 елның гыйнвар башында аларның дивизиясе Дон тирәсендә дошманны чигендерә башлый. Чир бистәсен немецләрдән азат иткән вакытта Аганин блиндажга үтеп керә һәм анда ГФП штампы сугылган язулы кәгазьләрне күреп ала. Ул әлеге хәрефләрнен ни-нәрсә аңлатканын яхшы аңлый: «гехайме-фельдполицей»—яшерен кыр полициясе. Ләкин икенче нәрсәне—бу вакытта армия штабында кыр гестапосына җибәрердәй тәҗрибәле разведчик эзләүләрен белми. Әлбәттә, Аганин моңа иң лаеклы кеше була. Билгеле булганча, ГФПнең җәза бирү бүлекләре вермахт тарафыннан яулап алынган җирләрдә—Кырымда, Мариупольдә, Таганрогта, Ростовта, Краснодарда, Ейскида, Новороссийскида... таралып урнашкан була. Алар шул җирләрдә фашистларга каршы булган көчләрне бастыруны максат итеп куйган Гиммлернең сайланма офицерларыннан тупланган.

Аганинның генерал белән сөйләшүе озак дәвам итә. Махсус йөкләмә үз эченә бик күп бурычларны ала: фельдполициянең немец армиясендәге урынын ачыкларга, аның көрәш ысулларын, куркынычсызлык хезмәте һәм фашистларның башка яшерен җәза бирү хезмәтләре белән мөнәсәбәтен өйрәнергә кирәк була. Шулай ук йөкләмәдә шымчыларны, сатлык җаннарны, совет тылына җибәрү өчен кемнәрне әзерләүләрен, дошманның разведка белән шөгыльләнгән рәсми һәм рәсми булмаган хезмәткәрләренең фамилияләрен белү дә күздә тотыла.

Аганинны «игезәген»—аңа охшаган кешене табу максатыннан хәрби әсирләрнең лагерена урнаштыралар. Тиздән андый кеше табыла. Ул—Чир бистәсендә кулга төшерелгән зондерфюрер Георг Бауэр булып чыга. Хәрби җинаятьче булганлыктан, суд каршында җавап тотарга тиешле Бауэрны лагерьдан төрмәгә күчерәләр. Ибраһим Аганин да аның белән бер камерага «эләгә».

Бауэр белән бергә үткән атналар разведчик өчен киләчәктә бик зур әһәмияткә ия булачак. Ул төрле вазифадагы гаскәриләрнең исем һәм фамилияләрен, зондеркомандаларның төзелешен, югары хәрби дәрәҗәдәге кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен белүдән тыш, немецларның тормыш-көнкүрешләренә дә яхшылап

төшенә. Бигрәк тә Георг Бауэрның истәлекләре аңа нык ярдәм итәчәк.

1938 елда Нюрнбергта, соңрак сәясәтчеләр «аншлюс», ягъни бер ядрәсез яулап алу, дип атаган бер вакыйга була. Ул вакытта Гитлер үзенең психологик йогынтысы алымнарын яшьләрдә сынап карый.

Бәреп яуган янгыр астында яшьләр Нюрнбергның зур стадионына митингка җыела. Германиянең төрле төбәкләреннән 60 мең үсмер егет һәм кыз Гитлерны күрү, тыңлау һәм аңа тугрылыклы булуларын исбатлау өчен килә. Ул чакта унбиш яшендә булган Бауэрга байрак йөртүне ышанып тапшыралар. Лев Гинзбургның «Упкын» исемле китабында әлеге вакыйга түбәндәгечә тасвирлана: «Фюрер трибунага күтәрелеп, яшьләргә: «Мин сезгә җаным-тәнем белән һәм сукырларча ышанам»,—дип мөрәҗәгать итүгә, җыелучылар үзләренең пычакларын тартып чыгарып, кыныларына туктаусыз бәргәләделәр. Яшьләрнең мондый халәте берничә сәгать дәвам итте. Георг Бауэр байракны үпте. Аны калтырау биләп алды. Янакларыннан яшь тамчылары тәгәрәде».

Фронт сызыгын кичү 1943 елның 23 февраленә билгеләнелә. Барысы да уйланылганча бара. Ахырдан Аганин (документлар буенча—Георг Бауэр) елганың су катмаган ачык урынына эләгеп, юешләнгән һәм тунган килеш, көч-хәл белән Донбасстагы Амвросиевка шәһәренә килеп житә. Немец штабында аны сагаеп каршы алалар. Ниһаять, бетмәс-төкәнмәстәй тоелган кәгазь эшләреннән соң, аны контрразведка җитәкчесе, комиссар Майснерга җибәрәләр.

...Разведчик дулкынлану белән гестапо урнашкан ике катлы бинага килә. Үзенә кирәкле ишекне ачуга, сискәнеп китә. Пычкы чүбе һәм боз салынган тартмада кеше ята. Аның арка тиресе салдырып алынган. Гестапочы аны резина таяк белән кыйный, тегесе исә авыртуга чыдый алмыйча каты итеп кычкыра.

Аганинның башыннан яшен тизлеге белән төрле фикерләр үтеп китә: ни әйтергә, нәрсә эшләргә? Шул минутта артында тыныч кына:

—Безгә яңа хезмәткәр килдеме?—дигән тавыш ишетелә.

Комиссар Майснер аңа диванга утырырга куша һәм Бауэр белән әңгәмәне башлап җибәрә. Кайчакта сөйләшү тукталып тора, чөнки җәзалanучының ачыргаланып кычкырган тавышы комиссарныкын басып китә.

Аганинга инде ничәнче кабат аның, ягъни зондерфюрер Георг Бауэрның, полк тар-мар ителгәч, урыс танкы астыннан бу якка качып чыгу турындагы уйдырманы кабатларга туры килә. Янәсе, әнисе аңа «абыйсын», 6 нчы армия штабы полковнигы Паулюсны эзләргә кушкан. Ул аңа гаскәргә урнашып, бөек Германиягә файда китерергә ярдәм итәчәк, имеш.

Вакыйганың бар нечкәлекләренә төшенү өчен, комиссар Бауэрга ял итеп алырга тәкъдим итә. Аны аерым бүлмәгә кертәләр һәм кыска тун белән ябылган тимер койкага ташлыйлар. Әмма ул йоклый алмый. Бертуктаусыз әле бу, әле тегe гестапочы килә һәм һаман да бер үк сорауларны яудыра. Төнге уникеләр тирәсендә, инде күзләрне йокы тәмам баскач, кизү торучының ярдәмчесе йөгереп килә һәм Бауэрны йолыккалый башлый: «Каян килдең? Частьнең исеме? Фамилия?».

Иртә берникадәр ачыклык алып килә. Штабта аның абыйсы белән хезмәт итүчеләр табыла. Алар полковникның Георг исемле энесе булуын һәм әниләре урыс кешесендә кияүдә икәнлеген, шунлыктан малайның урыс телен яхшы белүен һәм «абыйсы»ның аны күптән эзләгәнлеген, озак вакытлар энесеннән хат алмавына борчылганлыгын раслыйлар.

Әлеге очраклылык Георгның биографиясен ачыкларга ярдәм итә. Аны «1-С» (разведка һәм контрразведка) бүлегенә тәрҗемәче итеп билгелиләр. Мондый бәхетле очраклылык разведчик хезмәтендә аз булмый...

Сугыштан соң Ибраһим Аганин бик нык үзгәрә. Туганнарының, дусларының сорауларына бертөсле итеп җавап бирә: «Башкалар кебек үк сугыштым». Туганнары унсигез яшьлек егеткә җиңел булмаганлыгын аңлыйлар. «Ә кемгә рәхәт иде?»—ди аларга үсмер. Әйе, ул чакта сугышта катнашкан һәркемнең дә яше бер булды—Ватанны саклаучы яше.

Әмма ана йөрәге нәрсәдер сизенә. Улы төннәрен бөтенләй йоклый алмый башлый. Табиблар сугышны онытырга киңәш итә. Яшь лейтенант өчен оныту—

үзенең сугыштагы дусларыннан, разведчик өлешенә тигән сынаулардан баш тарту кебек була. Ул Бауман исемендәге Мәскәү югары техник училищеда укуын дәвам иттерә. Аны тәмамлаганнан соң, кандидатлык диссертациясен яклый. Тормышы үз эзенә кайткан кебек тоела.

Әмма бу вакытта үзебездә һәм чит ил матбугатында кинәт кенә Аганин фамилияле яшь разведчик турындагы мәкаләләр басылып чыга башлый. Сонрак беленә, ул очраклылык булмый. «Комсомольская правда» гәжитенең хәбәрчесе Людмила Овчинникова үзенең 1994 елда дөнья күргән «Разведчикның яшерен хәбәрләре гестаподан килде» исемле очеркында: «Игорь Харитонович белән әңгәмәбез минем архивымда берничә ел сакланды. Мин ул мәкаләне озак еллар бастыра алмадым. Һәрчак юлымда цензура пәйда булды. Хәзер тоткарлык юк. Ләкин исәннәр арасында минем әңгәмәдәшем дә юк инде»,—дип язды.

Журналистларны һәм язучыларны кулларына каләм алудан тотып торган тагын бер сәбәп була. Сугыштан соң Халыкара Нюрнберг трибуналы үзенең хөкем карарында: «ГФП, ягъни яшерен кыр полициясе, хәрби һәм кешелеккә каршы зур җинаятьләр кылды»,—дип белдерәчәк. Дөньяның күп илләрендә нацистларга һәм аларга ярдәм иткән җинаятьчеләргә каршы хәрби чаралар күрелә башлаячак. Алар Россиядә дә, Мәскәүдә, Краснодарда, Ростовта, Сәмаркандта...да булачак. Бу трибуналларның һәммәсендә дә диярлек ГФПнең Кырымдагы һәм Донбасстагы җанварларча җинаятьләренең соңгы шаһите булган И. Х. Аганин катнашачак. Бу хакта Лев Гинзбург үзенең «Упкын» китабында, М. Кореневский һәм А. Згибнев разведчиклар турындагы «Батырлык мәңге яшь» исемле хикәяләр җыентыгында язачак. Әйдәгез, 1943 елгы вакыйгаларга әйләнеп кайтыйк.

... Бауэр-Аганин тәрҗемәче итеп җибәрелгән ГФП-312 Донецкта урнашкан. Кыр гестапосындагы эш тәртибе катгый тәртипкә салынган. Теләсә нинди шартларда һәм гадәттән тыш хәлләрдә дә ул төп-төгәл 17.00 сәгатьтә төгәлләнә.

10 июльдә Совет гаскәрләрендәге бер «кешедән», парашютчылар ыргыту белән башланган яңа һөҗүм көтегез, дигән хәбәр алына. Десантны каршылау (юнәлеш—аландагы учаклар) җирле яшерен оешмадагыларга йөкләнелә.

Шундук шәһәрдән һәм аның тирәсендәге авыллардан чыгу юллары сак күзәтүе астына алына. Десант төшәсе урынга юнәлгән һәр кеше кулга алына. Шымчылар хезмәтен, кыр жандармериясен, гаскәри частьләрне һәм шәһәр полициясен дә кузгаталар.

Бу кичтә Георг Бауэр гестапо бинасыннан чыгып, Елизавета урамына юнәлә. Юлда ул каршыга килгән танк йөртүчене—ефрейторны туктата һәм аннан озата баруын таләп итә. Бер йортка килеп, зондерфюрер ишекне шакый. Аннан унсигез яшьлек егет чыга. Аны кулга алалар һәм шәһәр полициясенә илтәләр. Шактый кадәр ул шул егет белән «сөйләшә» һәм аңа әзерләнә торган операциянең билгеле булуын әйтә, рейх файдасына эшләргә тәкъдим итә. Ә иртә белән егетне: «Бер атнадан тагын килерсең»,—дигән сүзләр белән чыгарып җибәрә.

Бер атнадан немец гаскәренең югары житәкчелегенә десант ташланырга тиешле урында беркемнең дә булмавы, совет самолетларының ул урында күренмәве турында хәбәр ителә. Бер көннән совет гаскәрләренең башка фронтта һөҗүмгә күчүләре билгеле була.

Л. Гинзбургның «Упкын» китабындагы разведчик Мироновның прототибы Ибраһим Аганин була. Сугыш тәмамланып унике ел узгач, автор Ибраһим Хатәм улы белән очраша һәм таң кала. «Разведчик миңа үзенең ничек Бауэр булып яшәвен сөйләде,—дип яза Гинзбург.—Кырык яшьлек ир минем күзалдымда яшь немец егетенә, тәкәббер һәм үз дигәнен итүчән кояз гестапочыга әверелде. Мина ул минутта аның тавышы, йөзе генә түгел, хәтта колагы һәм борыны да үзгәргән кебек тоелды. Немецча ул гаҗәп дәрәҗәдә яхшы сөйләште».

—Мин яшерен оешмадагылар белән беркайчан да турыдан-туры аралашмадым. Алар белән җир аркылы гына элемтәгә кердем,—дип сөйләде Аганин.—Ә теге вакыттагы операцияне җимерү эшен ике юнәлештә билгеләдем: фронт линиясе аркылы хәбәрчене мәгълүмат белән җибәрдем һәм җирле яшерен оешмадагыларны кулга алынган теге егет аркылы кисәттем...

Монда охшашлы вакыйгалар аз булмый. 1943 елның апрель—маенда гына да ул Үзәккә унике хәбәр җибәрә. Ул шифровкаларда ГФП шымчылары турындагы мәгълүматлар, рәсми һәм рәсми булмаган разведка һәм контрразведка хезмәткәрләренең исем-фамилияләре була.

Сүз унаеннан, мин Россиянең ФСБ хезмәтенә Аганинның гестапо бүлекчәләрендәге хезмәте турында сорау җибәрдем. Җавапта мондый сүзләр бар иде: «Ибраһим Хатәм улы Аганин фашистларның разведка оешмаларындагы йөкләмәләрен үтәде».

Дошман тылында разведчикнын бер генә ялгыш җибәрергә дә хакы булмый. Шуңа да ул мөһим адымга барганчы җиде кат кына түгел, ә житмеш җиде тапкыр уйлый һәм шулардан иң нәтиҗәлесен, дөресен сайлап ала.

Әлбәттә, мәгълүматның төп чыганагы документлар була. Гестапочылар үзләренең гамәлләрен күпсанлы кәгазьләрдә күрсәтә. Шулардан безнекеләр унышлы файдалана.

Икенче чыганак булып гестапочылар белән эчкерсез сөйләшүләр тора. Бервакыт, эш көне ахырында Бауэр-Аганин кизү торучылар бүлмәсенә сугылып чыга. Тикшерүчеләрнең барысы да өйләренә таралышкан, кулга алынучылар үз бүлмәләренә куып кертелгән. Телефон янында кизү торучы берьялгызы гына күңелсезләнеп утыра. Бауэр үз бүлмәсеннән ярты шешә шәраб алып килә һәм аны чәркәләргә тигез итеп бүлеп сала. Аһ, шәрабтан Ватан, Рейн исе килә! Сүз гаилә тормышына, өйдәге матур бәйрәмнәргә күчә. Алар якыннары янына кайчан кайтачак? Шуннан әңгәмә һөнәрләренең үзгәрүчәнлегенә күчә. Әлбәттә, аларның эше Германия өчен кирәкле. Ләкин яшь гестапочы рейхта эшләү турында хыяллана. Бар бит бәхетлеләр: алар Дахаудагы яки Заксенхаузендагы концлагерьларга урнашканнар. Монда исә йөз ел хезмәт итәргә мөмкин. Юк, Бауэрга разведка күбрәк ошый: их, большевикларның тылына ук үтеп керәсе иде! Кизүдә торучы башын селки: бу бик куркыныч! Әле күптән түгел генә ул «1-С» бүлегендә булган. Ә анда аның якташын—полковник Модерзонны совет ягына җибәрергә әзерлиләр икән. Ике «фикердәш» Модерзонның уңышлары өчен эчәләр... Берничә көннән совет ягында немец шымчысын «җылы» итеп каршы алалар. Беркем дә, хәтта теге кизүдә торучы да Модерзонның бик тиз фаш булуының серенә төшенә алмый.

Ибраһим Аганин һәркөнне 19.45-20.00 сәгать аралыгында җирле радиодан доктор Геббельснең чыгышларын тыңлый. Һәр кичне каләм һәм көндәлек дәфтәре алып, радиоалгыч янына килеп утыра. Бу вакытта ул гүя яшәми. Бер генә хезмәттәше дә аны ул вакытта бүлдерергә җөрьәт итми. Ә икенче көнне Бауэр Геббельснең җөмләләрен яттан китерә, аның акыллы булуына шакката, Геббельс биографиясеннән өзекләр сөйли.

Гестапочылар Бауэрның җирле радиодан Моцарт операларын мөкиббән китеп тыңлавын да күреп алалар. Икенче көнне Бауэр композитор көйләреннән өзекләрне җырлап йөри башлый. Шулай итеп разведчикның бер генә хезмәттәше дә янына килергә кыймаган буш вакыты пәйда була. Нәкъ менә шул чакларда ул элемтәчеләр белән очраша һәм Ватанга яшерен хәбәрләр җибәрә.

...Әмма тиздән Берлиннан ГФП-312гә хәбәр килә: «Сезнең соравыгыз нигезендә зондерфюрер Георг Брауэрның шәхси эшенең күчермәсе җибәрелә». Һәм Аганинга Үзәктән күрсәтмә килә: «Яңа документларны кулга төшерергә».

...Поезд көньякка таба чаба. Георг Бауэр юлда ялга—Кырымдагы санаторийга китеп барган немец лейтенанты Рудольф Клюгер белән таныша. Немец формасын кигән күрше купедагы партизаннар Бауэрга Клюгергә «әверелергә» ярдәм итә. Тегесе исә поезд тәгәрмәчләре астында кала.

ГФП-312дә тупланган тәҗрибә Кырымда тиз арада ярдәмгә килә. Барысы да тагын кино тасмасындагы сыман тиз бара. Санаторийда ял иткән майор Бреннер белән дуслашып, Рудольф Клюгер аның ышанычын яулый. Тегесе исә яна дустын Керчь районындагы штабка урнаштыра. Аганин шулай итеп кабаттан кыр гестапосына эләгә. Бу юлы—ГФП-712гә.

Бик тиздән тәрҗемәче Клюгер-Аганинның хезмәт урыны буенча дәрәҗәсен күтәрәләр. Ул полицей-комиссар Отто Каушның адъюданты була. Яна шеф белән

мөнәсәбәтләр бик яхшы башланып китә. Төгәллек, житәкчесенең уйларын алдан ук белеп тору, хәтта аның яшерен фикерләрен сизү ике арадагы рәсмилекне юкка чыгара һәм дуслаштыра. Ул иң мөһименә ирешә: шефының күрсәтмәсе нигезендә, комиссар портфеле аның кулына күчә.

Үзәккә гестаподан хәбәрләр агыла башлый, чөнки хәзер барлык яшерен документлар да Клюгер-Аганин аша үтә. Дөрес, безнең гаскәрләр һөҗүмгә күчкәннән соң, гестапода хәлләр катлаулана. Тыныч Кауш та тамак ярып кычкыра башлый, адъюдантыннан биш минут эчендә аның барлык әйберләрен, документларын җыюны һәм машина алып килүен таләп итә...

Бервакыт разведчик күзенә бер шымчының комиссар Каушка җибәрелгән хаты ташлана. Анда румын капитаны Ион Кожухаруның ышанычны югалтуы хакында хәбәр ителә. Шикаятьтә румын капитанының нинди дер сөйләшүләр алып барганлыгы һәм аның гаскәрдәге хәрбиләргә тискәре йогынты ясавы турында да сүз була. Отто Кауш шикаять белән танышуга, гадәттәгечә, ана тәре һәм ядрә рәсеме ясый.

Икенче көнне үк Клюгер румыннар урнашкан урынга килеп җитә. Ион Кожухару анда унай тәэсир калдыра. Разведчик үлемгә тиң карар кыла. Ул капитанга шикаятьне, Отто Каушның хөкем карарын күрсәтә һәм ахырдан өстәп куя: «Комиссар үз сүзләрен җилгә очырмый». Бу очрашуның нәтиҗәсе шул була: румын капитаны фронт линиясе аша үтеп, совет армиясенең разведка штабына урнаша...

Кауш үз адъюдантына хөрмәт белән карый. Россияне белүче буларак, аның белән ул якка шымчы итеп кемне җибәрү турында да киңәшләшә. Нәкъ менә шул көннәрдә Кырымнан безнекеләргә Кубань һәм Ставрополь якларына җибәрелгән фашист шымчыларының фамилияләрен күрсәткән хәбәрләр китә. Тиздән Кауш аны совет җирендә шымчы итеп калдыру теләге барлыгын җиткерә: «Сез яшь әле, Руди, ризалашыгыз. Яхшы эшләсәгез, Германия сезне онытмас». Әгәр бер вакыйга килеп чыкмаса, шулай булыр да иде. Беркөнне Кауш Клюгерне үзенә чакыра һәм борчылу белән яңа хәбәрен җиткерә:

—Ашыгыч рәвештә Брашовка кузгалабыз. Анда кыр гестапосының иң каймагы җыела. Киңәшмәнең төп мәсьәләсе—СССРга шымчылар җибәрү. Сүз уңаеннан, сезне анда элеккеге дустыгыз белән очрашу көтә. Ул үзенең исемен атамавымны үтенде. Аның сезне күрәсе килә...

Бу мәгълүмат Клюгер-Аганинның ниятләренә үзгәреш кертә. ГФП-721 полиция-комиссары Отто Каушның документлар тулы портфелен урлап, ул үзебезнекеләр ягына чыгарга мәҗбүр була.

...Күпләр өчен сугыш 1945 елда тәмамлана, әмма Ибраһим Аганин өчен ул әле озак еллар дәвам итә. Фашист палачлары белән исәп-хисабын ул сугыштан соңгы суд эшләрендә дәвам итә. Җәзачылар хезмәттәшләре—Донецктагы ГФП-312 һәм Кырымдагы ГФП-721 яшерен гестапоның тәрҗемәчесе—үзләренә тиешле җәзаны Гамбургта бирер дип башларына да китерә алмаслар иде, мөгаен. Ростовтагы, Мәскәүдәге, Берлиндагы суд барышында Аганин тарафыннан ачыкланган җәзачылар шундук үзләренең гестаполарындагы кыр тәрҗемәчесе Рудины-Рудольф Клюгерне яки Георг Бауэрны танымыйлар. Баштарак алар аның судта катнашу максатына төшенмиләр. Өстәвенә, элеккеге зондерфюрер ярдәмендә үзләренең гаепсез булуларын дәлилләргә омтылалар. Бауэр-Клюгерның үзенә, әнә, бу мөмкин булган бит, дип уйлый алар. Әмма аның кемлеге билгеле булуга, фашист палачлары шок халәте кичерә. Аның күрсәтмәләре башкаларныкына караганда куркынычрак, төгәлрәк була.

Сугыштан соң Ибраһим Аганин әнә шундый уңлаган шымчыны ачыкларга ярдәм итә. Әмма дөреслеккә ирешү юлы кыен була.

...Сугыш вакытында Кырымда чекистларның яшерен оешмасы эшләп килә. Аларның Үзәккә никадәр кыйммәтле мәгълүматлар җиткерүе бер тарихка гына билгеле. Менә шул батыр сиксән егет сатлыкҗанлыкта гаепләнде. Сиксән гаилә үзләренең уллары, абый-энеләре һәм ирләренең хәбәрсез югалуы турында кәгазь алды. Әмма И.Аганин киресен дәлилли: юк, алар хәбәрсез югалмадылар. Аларның

фаҗигасендә җитәкчеләре Гисак Арабаджаев гаепле. Ибраһим Хатәм улы әлеге сатлыкҗанны фашистларның документларыннан табып ачыклый. Сиксән гаилә үзләренең туганнары турында яңа хәбәр ала: барлык чекистлар да гестапочылар тарафыннан атып үтерелгән.

Сатлыкҗанлык өлкәннәргә генә кагылмый. Станислав Наконечный үзенең «Яшерен полициянең тәрҗемәчесе» очеркында җаннарны өшетерлек хәл турында яза. «Ал җилкән», «Дулкыннар буйлап йөгерүче» китапларын язган балаларның яраткан язучысы Александр Грин вафат булгач, аның хатыны Нина сугыш вакытында Кырымда—яшерен оешмада кала. Әмма бөтенләй башка эшләр белән шөгыльләнә. Ул фашистлар кулына 10-13 яшьлек пионерларны тапшыра. Балаларның һәммәсен дә куркыныч дошман санап, атып үтерәләр. Нина Грин аларга үлгәннән соң да яла ягу өчен кулыннан килгәннең барын да эшли. Яшь ватанпәрвәрләрнең әниләрен Себергә озаталар. Аннан исә аларның бик күбесе кире әйләнеп кайта алмый. Ибраһим Аганин шул балаларга кагылышлы дөреслекне кире кайтару өчен күпме көч куйганын үзе генә белә. Язучы Иван Мельников «Әле йөрәк типкәндә» китабын яшь геройларның батырлыгына багышлады.

И. Х. Аганинның шаһитлек күрсәтмәләре илнең күп кенә язучыларының, журналистларының, тарихчыларының һәм галимнәренең игътибарын үзенә җәлеп итте. Хәрби юрист һәм генерал С. Синельковның хәрби тарихчы С.Асановка язган хатыннан өзек моны раслый: «Кызыл йолдыз» гәҗитеннән И.Аганинның ГФП-312 нче контрразведка бүлегендәге эшчәнлеге турындагы сезнең язманы зур канәгатьлек белән укыдым. Мактау һәм дан аңа! Аның Краснодардагы суд барышында Ватанга хыянәт итүчеләр—Михельсон, Шепф, Потемин һәм башкалар турындагы күрсәтмәләрен беркайчан да онытмаячакмын. Безнең алда сугышның күпләргә билгеле булмаган сәхифәләре ачылды».

Потемин фамилиясе безне кабаттан 1943 елга әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә.

Мартның беренче көннәрендә гитлерчылар фюрер һәм бөек Германия өчен гомерләрен биргән солдатларны искә алуны оештыра. Үзенең кул астындагылар алдында ГФП-312нең полицей-комиссары Майснер чыгыш ясый. Әйе, Георг Бауэр-Аганинны үз кабинетында каршы алган Майснер.

—Без Потемин белән бер сафта басып тордык,—дип сөйли Мәскәү хәрби округы трибуналында И.Аганин,—чөнки без бер буйда идек. Тантана уңаеннан безнең өстә яна гына энә-җептән төшкән хәрби форма иде.

Кыр гестапосы сейфында сакланган документлардан, Бауэр-Аганин Потеминның Майснер алдында яхшы исәптә йөрүен белеп ала. «Актив, тырыш. Рәхмәткә һәм империягә сәяхәткә бару хокукы белән ялга лаек». Фельдполицей-комиссарның боерыгында әнә шул сүзләр язылган була. Әмма андый биографияне бары тик шикаятьләр, кеше үтерүләр белән эшләргә кирәк була, Потемин гитлер Германиясендә яңа тормыш башлап җибәрү өмете белән тырышып эшли.

Ә безнең якка күчү белән, Потемин биографиясен яңадан яза. Анда ул дошман ягына разведка төркемен алып чыккан һәм совет ягына эшләү өчен гестапода калган лейтенант булып тора. Ул үз төркеменә фашистлар күптән атып үтергән кешеләрне кертә.

Тыныч вакытта әлеге «чиста» биография Потеминны саклап кала. Ул тарих фәннәре кандидаты була, Мәскәү югары уку йортларының берсендә кафедра җитәкли. Мәскәү обком партиясенә якын булган генералның киявенә әйләнә...

Әмма Потемин сугыш елларындагы җинаятьләре белән кыр гестапосының тәрҗемәчесе Георг Бауэр-Аганинның хәбәрдар булуын гына күзалдына китерә алмый. Суд эшендә И.Аганин кире каккысыз дәлилләр китерә. «Шаһит Аганинны чакыруыгызны үтенәм» исемле очеркта М.Кореневский һәм А.Сгибнев: «Аганин тумышы белән нечкә психолог, аналитик иде һәм үзенә хас төгәллек белән хыянәтчеләрне хисаплап чыгарды»,—дип язды.

Фәнни һәм укыту эшчәнлегеннән тыш, Ибраһим Аганин хәрби-ватанпәрвәрлек һәм әзтабарлык эшчәнлеге белән дә шөгыльләнде. Һәр җәй саен диярлек ул үзенең студентлары белән хәрби бәрелешләр булган урыннарга сәяхәткә кузгалды.

Элеккеге разведчикның бер бүлмәле фатирына туктаусыз хатлар агылды.

«Сезгә әтием өстеннән күләгәне алып ташларга ярдәм иткәнегез өчен зур рәхмәтемне җиткерәсем килә. Хәзер безнең шәһәрдә аның Ватанга ахыргы минутына кадәр тугрылыклы булып калуы турында рәсми белдерү ясалды».

«Без 1943 елның кышында Керчь ярымутравында гестапо тарафыннан камап алынган якташларыбызның соңгы көннәре турындагы дөреслекне беләчәгебезгә ышанычыбызны югалткан идек инде. Алар турында төрлечә сөйләделәр... Һәм кинәт кенә СССР Югары Советы Президиумының геройларны бүләкләү турындагы Карарын укыйбыз...»

Мондый рәхмәт хатларының исәбенә чыга торган түгел. Минем Ибраһим Аганин холкының тагын бер үзенчәлеген атыйсым килә. Ул дошман тылындагы үзенең ярдәмчеләрен беркайчан онытмады. Совет солдатлары булмасалар да, алар фашистлардан алынган материалларны фронт линиясе аша тапшыра килделәр. Алар арасында безгә таныш румын Ион Кожухару, немец антифашистлары Рудольф Грамши һәм Ганс Угнаде бар.

Ибраһим Хатәм улы үзен җәлләмичә яшәде һәм эшләде. Аның алдагы елларга ниятләгән күп эшләре бар иде әле. Әмма аның йөрәге чыдамады. Бер инфаркт, аннан икенчесе...

Мәскәү зиратларының берсендә һәйкәл-ташына биш почмаклы йолдыз куелган кабер бар. 1987 елның көзендә аның янында генералның саубуллашу сүзләре яңгырады: «Ибраһим Хатәм улы Аганин дошман тылындагы иң атаклы ун разведчикның берсе иде...»

---

# КЫРЫК ДҮРТНЕҢ ИЮЛЕНДӘ

*Бөек Ватан сугышы елларында да туган телләрендә дәрес биргән укытучыларның белемен күтәрү эше туктатылмаган, планлы рәвештә алып барылган. Шул исәптән татар телендә дә. Иң мөһиме шунда: Татарстаннан читтә урнашкан татар мәктәпләре өчен югары белемле укытучылар әзерләү дә дәүләт планына кертелгән була.*

*Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсенә дә мондый план-йөкләмә бирелә, аның бер өлешен безнең Камышлы районы мәгариф бүлеге үтәргә тиеш була. Кайда үгетләп, кайда куркытып дигәндәй тиешле сандагы укытучылар төркеме җыялар һәм Казанга җибәрәләр. Алар арасында минем әнкәй дә була.*

*Шул елларның бер истәлеге әнкәйдән калган кәгазьләр арасында сакланган. Ул татар язучылары белән очрашу турында.*

**Альберт НАРБЕКОВ**

8 июль көнне татар язучылары белән очрашу булачакны безгә алдан ук белдереп куйдылар. Татар әдәбиятын яратып укыганга күрә, татар язучылары белән очрашу теләге миндә күптән бар иде инде. Шуңа күрә бу көнне мин түземсезлек белән көтә башладым. Язучылар булгач, алар үзләрен эре тоталардыр, гомумән, культурадан бик үк алда булмаган авыл укытучыларына ул кадәр игътибар биреп тормаслар, бик өстән генә үзләрен танытырлар да шуның белән бетәр дип уйлаган идем мин. Ләкин мин уйлаганның бөтенләй киресе булып чыкты.

8нче июль килеп җитте. Без (Казан педогогия институтының тел, әдәбият бүлеге заочниклары) күрсәтелгән вакытка Казанның Бауман урамындагы Тукай клубына киттек. Барып җитү белән безгә 5нче этажга менәргә кирәклекне әйттеләр.

5нче катка мену белән, очрашу өчен билгеләнгән зур залга кердек. Анда тел укытучылары өчен китап сату оештырганнар иде. Барыбыз да матур әдәбият китаплары һәм 1944 ел январь, февраль, март айларында чыгарылган «Совет әдәбияты» журналлары алдык. Озак та үтмәде зал укытучылар белән тулды. Сәхнәнең бер читендә гади генә сөйләшеп, көлешеп утырган кешеләр күрдем мин. Без барыбыз да урыннарга урнаштык һәм түземсезлек белән язучыларның безнең каршыга чыгуларын көтә башладык. Менә шул сәхнәдә утыручылар арасыннан берәү килеп сәхнәдә безнең каршыга килеп басты һәм кичәнең көн тәртибен игълан итте. Шул ук кеше хәзер безнең каршыга Г. Кутуй чыгып үзенең шигырьләрен укыячагын белдерде. Г. Кутуй иптәшне без көчле кул чабулар белән каршы алдык. Ул безгә үзенең берничә шигырен укыды һәм сүз арасында гына үзеннән алда сәхнәгә чыккан кешенең Мирсәй Әмир иптәш булуын белдерде. Залда күңелле көлгән тавышлар яңгырады. Шулай бер-бер артлы язучылар сәхнәгә чыгып, безгә үзләренең шигырь, хикәя, очерк һ. б. укыдылар.

Т. Гыйззәт үзенең «Юл истәлекләре»н, К. Нәҗми «Фәридә» поэмасын, Мирсәй Әмир «Мөстәкыйм карт йокысы»н, Сәрвәр Әдһәмова «Песи белән чыпчык», «Минем апалар» дигән хикәяләрен, Әхмәт Юныс «Әтигә хат», «Милли моңнар» дигән шигырьләрен, Д. Аппакова «Минем атым»ны, Әсгать Айдар «Дөресме эшләдем мин»не, Фатих Хөсни «Йөзек кашы» повестеннан өзек һәм иптәш Ш. Сарымсаков Шәрәф Мөдәрриснең кайбер шигырьләрын укыды.

Моннан соң татарның атаклы гармунчысы Ф. Туишев гармунда берничә татар көе уйнады. Бу вакытта зал шул кадәр тын, хәтта чебен очкан тавыш та ишетелерлек иде. Монда гүя үзенне әллә кайларда еракта-еракта ялгыз гына моңаеп йөргән төсле сизәсең. Йөрәк ярсый.

Аннары сәхнәгә Әхмәт Фәйзи чыгып «Борын», «Фәйзиләр» дигән шигырьләр, Хәдичә Шәрипова «Бабай фәлсәфәсе», «Хәят апа», «Фатыйма белән сандугач» дигән шигырьләр сөйләде һәм берничә татар көе җырлады.

Кичәдән без бөтенебез хуш-канәгать калдык. Чөнки язучыларның якын иптәшләрчә очрашулары, бөтенесен дә уртаклашырга әзер булулары безне бик шатландырды. Безнең алар турында башта уйлаганнарыбыз киресенчә булып чыкты. Әнә шул сәхнәдә утырган кешеләр язучылар иде инде. Без кичәдән сөенешеп таралдык һәм торакка кайткач та озак сөйләшеп ятканнан соң гына йокыга киттек.

**Һаҗәр НАРБЕКОВА.**
*Казан, 1944 ел, 8 июль.*

Тәлгат
Галиуллин

# АКЫЛ ҺӘМ ХИС БЕРЛЕГЕ ШАГЫЙРЕ

РЕНАТ ХАРИСКА 70 ЯШЬ

*Мәгърур итә татар дөньясының*
*Тукай тоткан рухи әләме,*
*Муса Җәлилләрнең шәһит каны*
*Исхакыйның милли каләме.*

Р. Харис. «Кан һәм каләм»

Хәзерге татар шигъриятен Р. Харисның тыгыз эчтәлекле, җыйнак формалы, шәхеснең иң нәзберек хисләрен үзәккә алган, житди һәм ироник элитар шигъриятеннән башка күз алдына китерүе кыен. Ул—халкыбызның фаҗигале тарихын тирәнтен инләп, бүгенге хәлен яхшы аңлаган, киләчәген ихластан кайгырткан фикерләрен салган кырыктан артык шигырь җыентыгы, дистәләгән поэма, шигъри роман, йөз иллеләп җыр, романс, оратория, кантата, тәнкыйть мәкаләләре, тәрҗемәләр, публицистик чыгышлар авторы, Р. Харисның XX гасырда туып-үскән үзенчәлекле шәхесләрнең берсе булуы турында М. Кәрим, С.Хәким, Н. Дәүли, Г. Ахунов, Н. Хисамов, Р. Фәйзуллин, Р. Мөхәммәдиев, Ф. Хәсәнова, В. Дементьев кебек күренекле шәхесләр, әдәбият галимнәре язып чыктылар, шагыйрьнең фикерләү сәләтен, шигырь калыбын баетуын, киң эрудициясен, традицияләргә таянса да, берәүне дә кабатламаган шигъри өслүб, мәктәп тудыруын ассызыкладылар.

## I

Шагыйрь, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе, үзешчән рәссам, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1997), Татарстан республикасының халык шагыйре (2004), Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе иясе (2005) Ренат Харис (Харисов Ренат Мәгъсүм улы) 1941 елның 6 маенда Ульянов өлкәсенең Цильна (Чынлы) районы Кәшә (Зирекле күл—Елховое озеро) авылында укытучылар гаиләсендә туа. Балалык һәм мәктәп еллары Татарстанның Буа төбәге авылларында уза. А. В. Луначарский исемендәге Буа урта мәктәбен (1958), Казан дәүләт педагогия институтының филология факультетын тәмамлагач (1963) Арча педагогия көллиятендә рус телен һәм әдәбиятын укыта (1963—1964), ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында инструктор (1964—1965), «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркәтип (1965—1971) вазифаларын башкара. Әдәбиятка мәхәббәте мәктәп елларында уяна, шигърияткә студент елларында килә, 1968 елда «Җир һәм Кеше» исемле тәүге китабы «Беренче карлыгачлар» сериясендә дөнья күрә. «Кайтаваз» (1969) җыентыгы сүзгә игътибарлы,

үз өслүбен эзләүче яшь шагыйрь иҗатына җәмәгатьчелекнең игътибарын уята. «Ак сөлге» (1971), «Яна көн» (1972), «Бизәк» (1974), «Баскычлар» (1976), шигырь белгече Н. Юзиевнең кереш сүзе белән дөнья күргән «Замана эзләре» (1981) шигырь китаплары аны интеллектуаль-фәлсәфи юнәлешкә өстенлек бирүче, тасвирлау алымнарын туктаусыз төрләндереп торучы, ритм-рифма чараларына, шигырь техникасына яңалык алып килүче житлеккән сүз остасы буларак таныталар.

«Кайтаваз» китабы күренекле шагыйрь Сибгат Хәкимнең фатихасы, иҗат алымнарын хуплавы белән чыга. Кереш сүзендә поэзия метры Р. Харис шигъриятенең төп бер хасиятен—тар мәйданда тәгалләнгән фикер әйтә белүен, метафорик тыгызлыкка омтылуын калкытып куя. «Шагыйрьләр шигырьләрен озынрак язган саен, кыска формаларга ныграк сусадым,—дип яза С. Хәким «Һәр талант үзенчә килсен» исемле мәкаләсендә... «Ни өчен кыска формалар сагындыра? Шигырь ул—хисләр, фикер концентрациясе, фикернең, хиснең кристаллашкан формасы... Шигырь формасы шагыйрьнең дөньяны ничек күрү формасы»[1].

Р. Харисның остазлары турында уйланып, С. Хәким болай ди: «Мин яшь шагыйрьнең фикерләвен, шигырьдә эзләнүләрен Дәрдемәндчә—үзенчә дияр идем». Өлкән шагыйрьнең XX йөз башы татар поэзиясенең күренекле вәкиле Дәрдемәндне искә алуы очраклы хәл түгел. Озак еллар дәвамында тыелып, шигырь китаплары күптән түгел генә кин таныла башлаган Дәрдемәнд алтмышынчы елларда иҗатка килгән шагыйрьләрнең сурәтле фикерләвенә, шул исәптән Р. Харис иҗатына, тирән тәэсир ясый. 1968 елда ул Дәрдемәнд шигъриятенең мотив-символларына, шигъри ачышларына таянып, «Дәрдемәндкә нәзыйрә» исемле 14 шигырьне эченә алган цикл иҗат итә. Р. Харис бер очракта Дәрдемәнд әсәрләренең исемнәрен үк саклаclass («Сыгылдырып күл камышын...», «Табып ләззәт»), күпчелек шигырьләрендә остазының сурәтлелек байлыгына, аң төпкеленә үтеп керү алымнарына, шигырь төзелеше үзенчәлекләренә таяна. Әмма ике чор шагыйрьләре арасында тышкы, шәкли охшашлык саклана да, 60 нчы еллар сүз остасы «кувшинга» замана алып килгән яңа эчтәлек, үзгәрәк әхлак кануны сала. «Табып ләззәт» шигырендә Дәрдемәнд лирик затның матурлыкка сусавын, пакълек эзләвен үзәккә алса, Р. Харис гомерен заяга сарыф итүченең киләчәк фаҗигасенә искәртә.

*Табып ләззәт уенда һәм куенда,*
*Калды ул гомер елгасы буенда.*
*Тарих ансыз китте.*

(Р. Харис. «Табып ләззәт»)

Дәрдемәндтән шигъри осталык дәресләре алса, Р. Харис шул чорда ук үзе өчен икенче әхлакый, мәгънәви сыену үзәге таба. Анысы ислам динен тотучыларның изге китабы—Коръән. «Коръән сүрәләренә нәзыйрә» дип аталган, берничә шигырьгә «Хәбәр» сүрәсеннән юллама-эпиграфлар алынган бу бәйләмдә автор ирләр («Ирләр»), хатыннар («Хатыннар»), аларның җир йөзендәге нәсел калдыру, тынычлык саклау кебек вазифалары турында уйлана. «Пакьләнү» нәзерендә кешеләргә күңелне тазарту, чистарыну юлларын күрсәтә.

*Кулны, битне су белән юып була...*
*Ә күңелне—*
*туфрак белән генә...*

*«Кардай ак, сөттәй пакь...»*—дибез.
Бәлки:
*«Сөттәй ак, туфрактай пакь»,—дип әйтсәк, дөресрәк булыр?..*

(«Пакьләнү»)

Шигъри мәктәп, элгәргеләрдән үрнәк-өлге алу, туган тел матурлыгына өйрәнү

[1] Хәким Сибгат. Халык язмышы—шагыйрь язмышы. Казан: Татар.кит.нәшр.,1979. 352-353б.

турында сүз чыкканда, ул «Тукайдан өйрәнде, аңа ияреп иҗатка килде» кебек гомуми бәягә шулчаклы күнегеп беткәнбез, бу гыйбарәнең эчтәлеге турында уйлап та карамыйбыз. Р. Харисны исә өслүбеннән чыгып, фольклор һәм Тукай мәктәбенә якын шагыйрь дип булмый. Фикерләү рәвеше буенча ул Дәрдемәнд, яшь Туфан, Ә. Фәйзи, Ә. Давыдов, Ш. Анак кебек сүз осталарына якынрак тора, әмма аңа Тукайның гражданлык позициясе, иҗтимагый-фәлсәфи эзләнүләре, тел байлыгы, иронияcе якын. Тукайдан алган «Китмибез без, безгә анда...» эпиграфы белән башланган «Китмибез!» шигыре шуның ачык бер үрнәге. Тукайның шул ук исемдәге шигыре 1907 елда кайбер татар милләтчеләре һәм Дума депутатлары арасында «татарларны Төркиягә күчерергә кирәк» дигән мәкергә җавап рәвешендә язылган. Р. Харис шигыренә нигез-өлге итеп Тукай фикерен ала һәм туган илнең, туган җирнең изгелеген, мәңгелеген раслап чыга. Ул, Тукай кебек үк, үз халкының тарихы белән горурлану хисен калкытып куеп, кичерешне фикерне ачуга буйсындыра. Милли аһән шәхси бәхет, халык мәнфәгатьләре турында уйлану белән кушылып китә.

Яңа чор татар шигъриятенә нигез салучы Тукай образы—Р. Харис өчен якты маяк, юл күрсәтүче фидаи җан, көрәшче шәхес. «Тукайның мәхәббәт төшләре» драматик поэмасына ул «Тукай таптап тузан иткән ташлар», «Тукай соравы», «Тукай туган көнне һәр ел кояш» кебек күп санлы шигырьләре аша килә. Төшендә курай уйнаган шагыйрьгә багышланган әсәренең беренче юллары Русиядә алып барылган сәясәткә мөнәсәбәтне ача да куя:

*Татар Тукайга сыена*
*язмышы юл көткән саен.*

Сәясәткә баш бирмәгән, үз фикерле шагыйрьләр тормышы, язмышы турында Р. Харис «Каурый каләм» исемле шигырьләр бәйләмендә уйлана. Күз алдыннан Кол Гали, Рудаки, Пушкин, Тукай, Дәрдемәнд, Гарсиа Лорка, Н. Хикмәт кебек һәркайсы тирән һәм мәгънәле иҗат һәм тормыш юлы узган бөек сүз осталары образлары уза. һәркайсы дәвамчыларына гыйбрәтле шигъри мирас калдырган шәхесләр.

## II

Р. Харис—шартлаулы, көтелмәгән чагыштырулар, кыю метафоралар, шашкын вә салмак ритмнар, кабатланмас рифмалар шагыйре. Мәхәббәте алдында «сыгылып» төшкәләсә дә, аның лирик герое көчле, нык ихтыярлы шәхес. Рухи дөньяны сурәтләүгә дә шагыйрь элегик моң, сагыш аша үтеп керүдән бигрәк, «ихтыярлы» аһән, «мускуллы» сынландыру, көтелмәгән борылышларга өстенлек биреп килә. Аналитик фикер, тынгысыз хис шагыйрьгә көнкүрешнең, эчке дөньяның төрле кыйтгаларына үтеп керергә, төрледән-төрле чагылышларына үз шәхси мөнәсәбәтен ачыктан-ачык белдерергә мөмкинлек бирә. «Вакыт—җеп, мин—энә үтәли йөрим Җир белән Күк арасын», («Чигешем, тегешем»)—дип күләмле фикерләүгә ия шагыйрь генә яза ала.

«Кеше» ораториясендә «Кешенең иң олы байлыгы—Җир, Җирнең олы байлыгы Кеше» дип шагыйрь замандашын олы дөнья янына бастырып тасвирлый. Иҗатына дөнья сурәтен алып керү аша Р. Харис үз сиземләвен шул югарылыкка куеп карау дәрәҗәсенә күтәрелгән заманча шагыйрь. «Бөек хис» шигырендә «Мин аң чиксезлеген тойган бөек җисем» дисә, «Renayus»та үзен «Йолдызның (бәлки, йолдызстанның кирәктер.—Т. Г.) җанлы күмере» дип бәяли.

Хөкүмәт оешмаларында җаваплы урыннар биләгәндә, партия ӨКының идеология мөдире булып эшләгәндә тантаналы, «җиңүле» аһәңнәрнең иҗатында шактый булуны да исәпкә алганда, Р.Харисның сәясәткә ләббәйкә яудырып көн күрүче «сарай» шагыйре булып китү мөмкинлеге дә була. Әмма халкының аянычлы тарихын белгән, бүгенге язмышын яхшы күзаллаган шагыйрь бу «тозакны», куркыныч боҗраны әйләнеп үтү юлларын табып, үзе булып кала. Бер яктан, аңа татар һәм дөнья шигъриятенең гүзәл традицияләренә таяну, сүз сәнгатебезнең, бигрәк тә халкыбыз дәүләтчелегебезне югалтканнан соң,

әдәбиятка йөкләнгән милли горурлык хисе тәрбияләү вазифасы, «башбирмәс» юнәлеше таяныч булса, икенчедән, сурәтле фикерләвенең шигърият үрләренә күтәрелә барган саен халыкчан, милли нигезләргә сусый баруы, таяныч ноктасын шуннан эзләве коткара. Бу фикергә мисал рәвешендә «Сабантуй», «Чулпы», «Хәл-әхвәл» кебек милли нигезләре ачык беленеп торган әсәрләрен китерергә мөмкин. Халык иҗаты аның өчен төп традиция булмаса да, җыр белән мәкаль-әйтемнәргә матурлыкның мәңгелеген раслау, эзләнүләренә рухи таяныч ихтыяҗы туганда, телләп мөрәҗәгать итә. «Тәгәри китте йомгагым дәверләр, чорлар аша. Үткәннәр әкрен генә йөрәгемә тоташа» юллары Р. Харисның милли нигезләре турында уйлануларына эпиграф була ала. Шагыйрь халыкны мөстәкыйль, үзенчә яшәүче милләт булуын раслаган этнографик үзенчәлек-бизәкләргә игътибарлы. «Ак сөлге» шигырендә сабан туйларында билләргә яткан, ир-егетләрне көрәшкә озатып җилфердәгән, хәләл канны сөрткән сөлгене үзәк шигъри образ дәрәҗәсенә күтәреп, аның мәгънәви яңгырашын һәръяклап ачып, олы нәтиҗәгә килә:

*Син бит үзең дә халыкның*
*Күңеле төсле—*
*Сөттән сеңгән бер пакьлекнең*
*Бер көзгесе.*
(«Ак сөлге»).

Халкыбызга хас иң гадәти йолада да ул гасырлардан килгән бөеклек чалымнары күрә:

*Хәл-әхвәл сорашудан*
*Башлана һәр күрешү...*
*Канга сеңгән гадәтләрнең*
*Бу—иң матур өлеше.*
(«Хәл-әхвәл»).

Шагыйрь матурлыкның, инсафлылыкның серләрен милли нигезләрнең ныклыгында эзли.

Р. Харис иҗаты тәнкыйтьтә нигездә уңай бәя алса да, аның сурәтләү үзенчәлекләрен, өслүбен кабул итмәгән язучылар, галимнәр булуы да табигый. Талантлы, үзенчәлекле сүз осталарына һәрдаим иҗатларын раслау, аңлату өчен көрәшергә туры килә. Аерым алганда, Н. Фәттах белән И. Нуруллин башлангыч чор иҗаты нигезендә Р. Харис шигърияте артык коры, салкын, акыл эшчәнлегенә корылган дип чыктылар. Р. Харисны кирәгеннән артык оптимист, «кызыл», тормыш авырлыгын күрмичә, йөрәк сыкрауларын аңламыйча күтәрелгән шагыйрь дип раслаучылары да табылды. Мондый дуамал бәяләргә җавап рәвешендә әдип «Шигырьләремдә минем тимер, бетон...» сигезьюллыгында аңлатма бирә, ачыкламыш кертә.

*Тимер ләкин һәрчак ап-ак була,*
*Әллә кыза, әллә бозлана.*
*Бик беләсең килсә, шигыремә*
*Йөрәгеңне тидер, кызганма.*

«Эт уйната берәү...» шигырендә Р. Харис үзен аңламауларына, берьяклы бәяләүләренә үпкәсен, нахак сүзләргә әрнүен сагышы аңкып торган юлларга чыгара.

*Һәм язамын... Йөрәгемдә кара... рәнҗү...*
*Хисләремнән кер эзлиләр тырнап-тырнап.*
*Башымда гөрселдәшә кара уйлар*
*Җитте... куям... каләм! Син дә ялгыштырма.*

«Дару сеңгән шигырьләр» бәйләме, «Минутлык төшенкелек» шигырьләре С. Есенин тормышының иң авыр мизгелендә, «упкын» ярында язган «Черный человек» поэмасының рухын хәтерләтеп куялар. «Ничаклы каршылык яши...», «Ай, Идел суы, гүзәллекләрне уйнаткач...», «Кайбер уйлар кысыр болыт кебек...» тирән лиризм, эчкерсезлек белән сугарылган шигырьләре рухи дөньяның иң серле почмакларына үтеп керүләре белән күңелдә калалар. Олы дөнья матурлыгын кеше гүзәллеге нурландырып җибәрә. «Ак түшәктә ауный-ауный минем шигырем жылый» («Идел өстендә көмеш ай»), «ак күгәрчен булып намус очып чыга күкрәктән» («Ни чаклы каршылык яши») кебек ихласи афористик юллар кемне битараф калдырыр икән? «Йөрәк фасылы сонеты», «Тулган ай сонеты», «Язгы көн-төн тигезлеге сонеты» («Сонетлар») кебек шигъри гармония үрнәкләре булып өйрәнелергә лаеклы әсәрләре дә тиешле бәяләрен алганнары юк дип саныйм.

## III

Р. Харисның мәхәббәт хисенә багышланган әсәрләре, гомумән мәхәббәт лирикасы күләме, эчтәлеге, жанрлар һәм сурәтләү алымнары байлыгы тарафыннан могҗизаи күренеш. Шунысы үзенчәлекле: шигъриятнең иң нәзберек төренә ул олы кәнәфиләр биләгәндә, баш мөхәррир, министр урынбасары, депутат вазифаларын үтәгән чорларда мөрәҗәгать итә. Мәхәббәт хисе, Такташ әйтмешли, «үзе иске нәрсә» булса да, һәр инсанда үзенчә дулый, шырпысыз дөрләп кабына, төрле даирә кешеләрен йә дөньяда иң бәхетле яисә иң дивана ясый торган төшенчә, ди кебек шагыйрь. «Р. Харисның мәхәббәт лирикасы—әсәрләр саны һәм жанрлар төрлелеге белән дә... татар әдәбиятында аерым урын алып тора... Ренат Харисның мәхәббәт лирикасын хисләр энциклопедиясе дип тә атап булыр иде»,[2]—дип яза Ф. Хәсәнова. Чыннан да аның татар әдәбиятына алып килгән яңалыкларының берсе—мәхәббәт лирикасы булды.

«Күзгә мәхәббәт» (1991), «Хисемнең исеме» (1996) кебек мәхәббәт тойгысын үзәккә алган шигырь тупланмаларын, «Өч үбешү» (эротик поэма), «Тукайның мәхәббәт төшләре», «Сәйдәш яры», «Евнух», «Гармунчы», «Зөләйха» кебек күләмле әсәрләре тулыландыра.

Мәхәббәтне Р. Харис Блок яисә яшь Такташ кебек мистик-символик хис буларак сурәтләми, ә һәр кешегә килә торган олы бүләк дип бәяли. Җан белән Тәннең бердәмлеге, аларның язгы сулардай ташулары, күкрәүләре, яшеннәре мәхәббәт дигән бөек, тетрәндергеч хис уята. Берәрсе генә ялгышса яисә мәхәббәт акылга гына буйсынса, «Өченче фәрештә» ваклана, уала, женси тойгыга гына кайтып кала. Чын мәхәббәт—ул газап, саташу, сагыш, ләкин иң ләззәтле, татлы сагыш, ди шагыйрь.

*Чын бер көнләшү хакына*
*Мин мең газапка риза.*
(«Көнләшүләр»)

*Гашыйк чагымны күрәсегез килсә,*
*Нәфрәтем эченә кертеп җибәрәм.*
(«Беркайчан да сезгә...»)

Мәхәббәт—ул зиһен белән аңлап бетерә алмаслык күктән иңгән бәхет, сөенеч, шатлык, аны саклый белергә дә кирәк, ди шагыйрь. «Мәхәббәтсез беркем яши алмый. Мәхәббәтсез һәркем бәхетсез» («Мәхәббәтсез»). «Өченче дөнья» шигырендә «Җирдәге иң зур могҗиза—син, Мәхәббәт дөньясы!» дип тәкрарлый. Бу олы хисне «Мәхәббәт, мәхәббәт! Син—кояш» («Мәхәббәт») дип, айга, йолдызга, табигатьнең башка гонсырларына (элементларына) тиңләү, чагыштыру белән генә чикләнмичә, лирик миннең мәхәббәтенә мөнәсәбәтен гүзәл чагыштырулар, психологик анализ ярдәмендә, сәнгати жепселләр аша хәтергә сеңеп калырдай итеп сурәтләү юлларын эзли.

[2] Харис Р. Сайланма әсәрләр. Җиде томда. 1 т., Казан, татар.кит.нәшр., 2006. 116.

*Син кабат минем янымда.*
*Нигә торыйм мин чыдап?!—*
*Мин сөюемә сокланам*
*иңнәреңә ятып елап...*

(«Күпме елау елгаларым...»)

«Дөньям минем матур анда синең нурың булганда...» («Минем дөньям»), «...һәрбер зәңгәр күздә Зәңгәр чаткы булып яшим мин...» («Зәңгәр моң») дип лирик зат шатлык катыш моңая да, нечкә психологик метафора ярдәмендә сөйгәнен «кисәтеп» тә куя: «мин сукыраям, күзең суыгы күземә тисә...» («Салкын буранда...»).

Мәхәббәт лирикасы (мәхәббәт турында түгел) Р. Харисны дөнья әдәбиятының, бигрәк тә Көнчыгыш классикасының Хәйәм, Сәгъди, Хафиз, Руми, татар шигъриятенең Кандалый, Тукай, Такташ, Туфаннарның лаеклы дәвамчысы итеп бәяләргә мөмкинлек бирә. Якын кешеңне ярату фани дөнья безгә генә түгел, ахирәт ачкычы да сөйгәнең кулында икән:

*Ә җәннәт ишеген ачучы бер генә кеше*
*бар-*
*Сөйгән яр!*

(«Дантега ияреп...»)

Р. Харисның күләмле әсәрләренең нигезендә мәхәббәт һәм каһарманның бу олы хискә мөнәсәбәте ята. Аның һәр герое диярлек, кем булуына карамастан, «мәхәббәт сынавын» үтәргә тиеш була. Шул сынауны үтсә генә ул—чын кеше, матур кеше.

Хәзерге шигърияттә хатын-кыз портретын тудыруда аның кебек чагыштыру, метафораларны берсе өстенә икенчесен тыгызлап тутырып, образ тудыра алучы, хыялга бай сүз осталары күп түгел. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» әсәренә нәзыйрә, дәвам, бәхәс кебегрәк язылган «Тәүбәсез мәхәббәт» поэмасында ул Зөбәйдәне түбәндәгечә сурәтли:

*Теле бал-май, күзе чакма,*
*буй-сыны—Зөя камышы.*
*Ә йөреше—ак он иләү,*
*куллары—ак каз муены...*

Шул рәвешле, мәхәббәтне Р. Харис кешене үстерә, күтәрә торган олы, табигать матурлыгына тиң нәзакәтле, бар нәрсәдән өстен серле һәм гүзәл хис буларак сурәтли. Бу төр әсәрләрендә шигъри теленең гаҗәеп төрле яңа тасвири чараларга, метафора-чагыштыруларга, ритмик аһәңнәргә баюы күзәтелә. Р. Харисның мәхәббәт лирикасы нигезендә эшләнгән «Шашкын мәхәббәт» телевизион фильмы озак еллар экраннан төшмәде. Шагыйрьнең либреттолары буенча опералар («Идегәй». Р. Гобәйдуллин, «Тукай мәхәббәте». Р. Ахиярова) языла, «Йосыф кыйссасы» (Л. Любовский) балеты Россия Федерациясенең еллык премиясенә лаек була. Күләмле әсәрләренең нигезендә дә ахыр чиктә мәхәббәт хисе, киң мәгънәсендәге мәхәббәт сынавы ята.

## IV

Р. Харис шигъриятнең әйдәп баручы жанры—поэма үсешенә житди өлеш керткән сүз осталарының берсе. Сан ягыннан да, тематик кинлек, төрлелек җәһәтеннән дә аның тәҗрибәләре И. Юзеев белән С. Хәким эзләнүләренә якын тора. Хәзерге иҗатчылардан З. Мансуров кына беришe ноктaларда аны бәйгегә чакыра ала кебек. Р. Харис иҗатында вакыйганың эзлекле үсешенә яисә язмышлар бәрелешенә, эчтәлекнең бер юнәлештә тирәнәюенә нигезләнгән эпик яисә драматик поэма белән янәшәдә шәхеснең уй-кичерешләрен үзәккә алган, лирик монологлардан торган ирекле композицияле, лирик-фәлсәфи поэма да

үстерелә. Татар тарихында тирән эз калдырган шәхесләргә, әйтик, Ф. Кәримгә, Җәлил һәм Җәлилчеләргә багышланган әсәрләрендә героик, патетик нота өстенлек итсә, күпчелек поэмаларында аналитик башлангыч һәм психологик анализ төп гомумиләштерү чарасы булып китә.

Шагыйрь лирик төрдә үзен раслаганнан соң, җитмешенче еллар башында поэмага килә һәм бу четерекле, катлаулы жанрда эзләнүләрен, ачышларын туктаусыз дәвам итә.

1972 ел корылыгын нигез канва итеп алган «Житмеш икенче ел икмәге»поэмасы Р. Харис мөмкинлекләренең тирәнлеген раслаучы әсәр булды. Бөртекне әдәби персонаж дәрәҗәсенә күтәргән шартлылыкка корылган бу әсәрендә автор икмәкне, җир кешесен олылап, иҗтимагый нәтиҗәләргә килә.

Сәнгати югарылыкка ирешеп, үзен поэма жанрында раславы «Рәссам» һәм «Ат иярләү» әсәрләре белән бәйле. Беренчесе лирик-психологик поэма төренә караса, икенчесендә автор эпик-фәлсәфи башлангычка өстенлек бирә. Беренче поэма чынбарлыкны икеләтә «проекцияләү» алымын үзәккә куеп, рухи дөнья белән тышкы, предметлы сурәтләр арасында якынлык эзләүгә корылган поэма. Бер яктан, бер-берсен кысрыклап килгән, катлаулы мәшәкатьләр белән тулы тышкы дөнья сиземлетоемлы образлар аша реаль бөтенлегендә тасвирланса, икенче яктан, әле генә күз алдыннан үткән вакыйгалар, күренешләр яшәешне, рухи дөньяны камилләштерү, бизәү нияте белән илһамланган рәссамның сиземләве, күрүе аша сынландырыла. «Эретеп иркәли торган серле» күзләр хуҗасы гүзәл кыз һәм аның киндердәге рәсеме, рәссамның табигый сынга һәм үзенең иҗат җимешенә мөнәсәбәте, кинәт уянган мәхәббәте, сугыш һәм художникның бу афәтне күзаллавы—барысы бергә аралашып зиһенне зирәкләндерерлек, хисләрне кузгатырлык катлаулы структура һәм өслүб бердәмлеге тудыралар. Шагыйрь күпертү һом шартлылык алымына таянып, рәссамның фикерләү рәвешенә, рухи дөньясына тирән үтеп керә.

*Һәр төсне кырыкка яра белүче,*
*Һәр сызыкта җан хәрәкәте сизүче,*
*Һәр хәрәкәттә кырык мәгънә күрүче күзләр*
*Сокланудан каушап калдылар*
*Беравыкка йомылудан туктадылар.*
(Р. Харис. «Рәссам»)

«Ат иярләү» поэмасының төп персонажлары—Кәрам белән кешегә хас хискичерешләр ярдәмендә тасвирланган ат. Кәрам сугыштан читтә, тылда калу нияте белән фронтка үзе урынына атын озата. Хуҗасының хәйләсен «сизеп» алган ат ярты юлдан качып кайта. Аның да үләсе килми. Кәрам үзен мәсхәрә иткән өчен атын котырына-котырына кыйнау аша хатасын таный һәм сугышка китеп, җинүче-батыр булып кайта. Авторның унышы, әлбәттә, Кәрамны шулай тиз «төзәтүдә» түгел, ә психологик анализ тирәнлегендә, куркаклыкны, хәйләне фаш итүнең көчерелмә алымын табып, эчке дөньяның катлаулылыгын ачуның мөмкинлекләрен кинәйтүдә иде.

«Ат иярләү»дә әдәби персонаж дәрәҗәсенә күтәрелгән ат образы Р. Харисның яратып сурәтләгән объектларының берсе. «Кыздырма атның аягын», «Ат», «Ярсыган ат» шигырьләрендә ат татар кешесенең ярдәмчесе, таянычы, өмете булу өстенә миллилекнең бер билгесе буларак та сурәтләнә.

Р. Харис татар тарихында эз калдырган шәхесләр язмышына игътибарлы. Большевизмның явыз гамәлләре киң җәмәгатьчелеккә билгеле булганчы иҗат ителгән, заманында радиодан, телевидениедән унышлы яңгыраган «Мулланур», «Камил Якуб», яшь Ленинның психологик халәтен аңларга тырышкан «Борылышта» поэмалары сурәтле фикерләү үзенчәлекләре, шәкли ачышлары белән хәзер дә заманча яңгырыйлар. Автор большевикларның ялган, ялтыравык шигарьләренә ышанган Мулланур Вахитов, Камил Якубов кебек гаярь татар егетләренең тормышын иң фаҗигале мизгелләрендә үзәккә алып, табынган идеалларының тар тыкрыкка алып чыгуына басым ясый. Андый үзфикерле,

максималист шәхесләрне аклар юк итмәсә, большевикларның яшәтмәячәге көн кебек ачык иде ди автор.

«Мулланур» поэмасы композицион яктан уйланылган, «Сыктау», «Ату», «Суга батыру» дип аталган бүлек исемнәре үк фаҗига мантыйгын тудырса, аны үтерүнең котылгысызлыгына ишарә ясаса, «Камил Якуб» поэмасында солдатларның алдакчы коммунистларга булган үчләрен командирларына күчереп, аны җәзалаулары турында бара. Ошбу поэмалары сәяси җәһәттән язылган чордагы актуальлекләрен югалтсалар да, халкыбыз, ил үтәргә мәҗбүр булган тарих баскычларын искә төшерү һәм сәнгати үзенчәлекләре белән хәзер дә кызыклы әсәрләр.

Тарихи дөреслек ачыла бару белән бәйле рәвештә Р. Харис иҗатында тематика үзгәрә, каһарманнар галереясе яңара. 60-80нче елларда иҗади эзләнүләрендә Якубов, Вахитов, Ленин кебек Октябрь фетнәсен оештырган, шуна ихластан хезмәт иткән шәхесләр урын алса, акрынлап анда татар халкы тарихында мөһим роль уйнаган затларга түрдән урын бирелә. Бу юнәлештәге эзләнүләре аны әүвәл Җәлил һәм Җәлилчеләр, Ф. Кәрим кебек фаҗигале язмышлы шагыйрьләр турында уйлануларга алып килсә, ул чорда әле Р. Харис күбрәк ошбу шәхесләрнең батырлыгы белән рухланса, сонрак ул һәр вакыйганың икенче, өченче мәгънәләрендә яткан һәм күбрәк татар халкының үз язмышы белән бәйле төшенчәләр турында уйлана башлый. Әйтик, башка милләт язучылары кебек, татарның да Җәлил, Кәрим, Кутуй, Алиштай олы сүз осталары тылда калдырылырга лаеклы түгелләр идеме? Яисә аларның батырлыгы татар халкының шөһрәтенә яңа дан төсмерләре өстәсә дә, аның мөстәкыйльлеккә, бәйсезлеккә ирешүенә булыштымы? Изелгән халыклар олы җинүдән соң да шул ук хәлләрендә калмадылармы? Бу хакта киеренке уйлануларга Р. Харис соңрак, татар, аерым алганда Казан ханлыгы тарихын объектив тасвирлаган галим Худяковка багышланган шул исемдәге поэмасында килә. Тарихчылар, иҗтимагый фән белгечләре Михаил Худяковның «Очерки по истории Казанского ханства» дип тыйнак кына аталган хезмәтенә югары бәя бирсәләр дә, татар әдәбияты рус кешесе каршында бурычлы иде. Ш. Мәрҗани, Г. Гобәйдуллин, Р. Фәхреддин, Г. Исхакый, Х. Атласи кебек үз милләтебез галимнәренең Казан чорына дөрес бәя бирүләре, татарлар һәм гомумән төркиләр арасында бердәмлек булмау сәбәпле юкка чыгарылган Казан дәүләте тарихын торгызулары, аның яшәргә хакы булганлыгын раслаулары бер хәл. Башка милләт әһеленең Казан ханлыгының яшәргә тиешлегенә ышанып һәм фәнни дәлилләп язуы өчен корбан булуы, фаҗигасен сизенә торып та бу фидакарьлеккә баруы башкарак гамәл. «Худяков» поэмасында Р. Харис рус галимен олылый, аның тиңсез батырлыгы, рухи көче алдында баш ия һәм бөтен татар кавеме исеменнән аңа рәхмәтен иңдерә.

Тормышның төрле якларыннан хәбәрдар булуы, «өстә» утыручыларның идарә алымнарын, эчке серләрен белүе аның иҗатында тәнкыйди башлангычның көчәюенә, хәтта сатирик гомумиләштерү алымнарына еш мөрәҗәгать итүгә алып килә. Чорыбызның ифрат катлаулы төеннәрен үзәккә алган Г. Тукай, Ш. Бабич, Ә. Фәйзиләрнең шул рухтагы поэмалары белән янәшә куярлык, дәвамы дип кабул итәрлек сатирик һәм метафорик рухлы, дини мифологиягә яңа эчтәлек салган «Һарут» белән «Марут» поэмасы, күпчелек әсәрләре кебек үк, сискәндерә һәм үсешебезнең дөрес юлдан читкә китүен ачып тәшвишкә сала. Шул ук сатирик юнәлешне дәвам иткән «Чехов базары», «Бүре күзе» поэмалары үткен яңгырашлары, кыю күзәтүләре, төгәл метафоралары, шәкли ачышлары белән җәлеп итәләр.

Сәяси җәһәттән киеренке чорыбызда ни нәрсә турында язсаң да, халәте рухиятебезгә, киләчәкне сиземләргә омтылуыбызга бәя бирмичә булмый. Замана сейсмографы—шагыйрь йөрәге бигрәк тә. Казан шәһәренең уртасына оялаган, күбрәк түрәләрне, депутатларны, «яңа рус» белән «иске татарларны» тукландыра торган Чехов базары башка алып сату урыннарыннан аерылып тормый кебек. «Тукай базары», «Дәрвишләр базары», «Кош-корт базары» һ. б. шул ук ыгы-зыгы белән яши: бирәү алдый, икенчесе алдана, өченчесе сата, дүртенчесе ала, бишенчесе тамаша карый...

Шагыйрь сатып алучы буларак үзенә таныш базарны үзәккә алса да («Дәрдемәнд күк,

мин базарга чыгам»), аның җыелма, гомумиләштерелгән образын тудыруга ирешә:

*Мич капкачы, юшка сата Сократ,*
*Кадак сата—Хуҗа Насретдин.*

Европа белән Азия акыл ияләре янына Әфләтуннар, Наполеоннар, Чыңгыз хан һәм Батыйлар, Маэстро һәм Бисквитлар килеп өстәлә. Әлеге тарихи шәхесләр турында житди итеп сөйли автор, алар белән чәйләр-мәйләр эчә, тиз арада оешкан мәҗлесләрдә катнаша. Заманында дөнья тетрәткән, шәһәр-авылларны көлгә әйләндергән, бөтен бер халыкларны юкка чыгарган шәхесләрдән курыкмыйсын, мыскыл итү дип тә уйламыйсын, чөнки алар безнең арада яшәгән майор, биохимик, кандидат, күзен йомып юк-бар белән сату иткән доцент, рәссам булып чыгалар, һәркайсының үз кушаматы, башкалардан аерып торган «йөзе» бар. Тәхәллүсне олыдан, истә калырлык итеп бирәләр. Шагыйрь чәчәк эзли. Голландиядән килгәне ясалма чәчәк, ифрат матур, әмма иссез икән, туган як гөленә, чәчәгенә ни житә. «Тел» эзләү вакыйгасын сүз остасы сәяси дәрәҗәгә күтәрә. Мөселман кешесе суйган ризык—тел эзләү татар теленең акчалар суккан, калалар торткан бөеклеге, бүгенге матурлыгы, нәзакәтлеге турында уйлануларга алып килә. Милли телебез «Базар теле» генә булып калмасын, «базарлы тел» дәрәҗәсенә күтәрелсен иде. Сүз уйнату кебек күренгән «базар теле» һәм «базарлы тел» мәгънәви төсмерләре белән бер-берсеннән нык аерылалар. Поэманың үзәк мәгънәсе түбәндәге гыйбарәдә ачыла:

*Башка илләр—дәүләт, ә Россия,*
*Ә Россия—Чехов базары...*

Шагыйрь Россиягә бәяне, «үз өстенә» алмыйча, геройларының берсеннән әйттерә. Россиянең уртасында урнашкан Татарстан өлкән агасыннан кайсы ягы, нәрсәсе белән аерыла соң? Биредә дә акыл ияләреннән килгән хәйлә коткара:

*Татарстан нәрсә—әйтә алмыйм,*
*Мин техникум гына бетердем.*

Татарстан Дәүләт советы депутаты үзе яшәгән төбәкне хурлый алмый, ә мактанырлык нәрсәне, Россиядән кискен аерылып торган үзгәлекне табуы кыен.

«Чехов базары» поэмасын тәфсилле анализлаган профессор Н. Хисамов мондый нәтиҗәгә килә. «Шул рәвешле әлеге тәвәккәл поэмасында шагыйрь чорның иң үзенчәлекле фикер-борчуларын, үткен мәсьәләләрен бер көлтәгә туплаган. Ренат жанрның яңа серләрен ача, Ренат жигелеп эшли, Ренат эзләнә, житди уңышларга ирешә»[3]. Чыннан да, композиция төзелеше һәм сурәтле фикерләү җәһәтеннән шактый уйланылган «Чехов базары» Р. Харисның һәм хәзерге татар поэмасының казанышы саналырга лаеклы. Дөрес, мин укучы буларак, поэмага мәшһүр язучы—Чехов образы килеп керер, ул үз исемен таккан базар белән йә гарьләнер, йә мактаныр һәм һәрхәлдә гаять акыллы, реалист кеше буларак, «үз базарына» шәхси бәясен бирер дип көткән идем.

Р. Харисның «Идегәй» дастанына, татар халкының язмышы сыналган, киләчәге кыл өстендә торган көннәргә мөрәҗәгать итүе очраклы түгелдер. Чөнки халыкның сүз һәм фикер кодрәте тудырган бу әсәрнең нигезендә бер чорда да искермәс, тутыкмый торган сөземтә—хакыйкать ята. Ул—халык, туган жир язмышы һәм шул төшенчәләргә хезмәт итәргә тиеш булып та үзенең тар мәнфәгатьләре белән мавыгып, ил турында кайгыртасы урында үч алу турында гына уйлап, милләтләрен бәхетсез иткән ханнар һәм түрәкәйләр хакындагы хәбәрне думбралы карт хәтерли, серне чишә, шуның аркасында ике көчле шәхес арасында мөнәсәбәт киеренкеләнә, үзара кылыч аша «аңлашу» дәрәҗәсенә барып житә, соңыннан жырчы Субра үкенә, хаталарны «Кылыч төзәтә алмас, кылыч үзе кәкре» дип карый, мәгәр эш узган, төзәтә алмаслык хәлгә килгән була.

[3] Хәтер сагында. / Н.Хисамов. – Казан: Мәгариф,2004,436 б.

Үч алу дәрте кабынган Идегәй улы Норадын белән ил өстенә Шаһтимер гаскәрен алып килә һәм Туктамыш ханны тәхетеннән куып төшерә. Үз иленә яу чапкан кеше беркайчан бәхетле була алмый: улы белән аралары бозыла, үзен яраткан кыз Жаникәне үтерәләр, шул ук Субра ана иң хаклы сүзләрне әйтә: «Мондый чакта исән калу, Идегәй, бәхет түгел...» Иҗтимагый коллизияләр янына поэмада мәхәббәт тирәсендә барган каршылыклар килеп өстәлә. Хан кызы Идегәйгә гашыйк, әмма бу мәхәббәтнең уңышлы була алуы шикле. Жаникәне атасын үтерер дәрәҗәгә житеп, Норадын ярата, мәкер үзәге, буталчык Вәзир дә аңа гашыйк һәм үзе белән качарга өнди. Горур Жаникә мәхәббәтенә тугрылыклы кала һәм Көнчыгыш поэзиясенең романтик калыплары буенча, үлемен таба. Жаникәнең олы мәхәббәтен сурәтләү юлында Р. Харис табигать символларына мөрәҗәгать итә: кыя, таш-тау, ак бәхет, лачын, ак бүре, болыт образлары тукымага килеп керә. Жаникәнең Идегәйне очраткач әйткән монологы тоташ шундый куе төсле романтик буяуларга манчылган:

*Мин сине шундый көттем!*
*Кара дулкын арасыннан*
*ап-ак кош көткәндәй,*
*Кара таулар арасыннан*
*ак лачынны көткәндәй.*
*Килерең белеп көттем,*
*тилереп тилмереп көттем—*
*ак бәхет өмет иттем.*

Мондый олы мәхәббәт, тирә-юньне мәкер, хәйлә, явызлык чолгап алганда, бәхетле була, яши алмый. Үлеп яткан Жаникәне кулына алган Идегәй теленә кайгылы, караңгы образлар килеп керә: «Таралды алсу болыт, Каралды кара болыт, Башым кара болытта...» .

Р. Харис лирик төрнең төп таләбен—үзәктә шагыйрьнең үз шәхесе, үз мине (төрле исемнәрдә, чагылышларда) торырга тиеш дигән таләпне бер мизгелгә дә онытмый. Хәтта «Чехов базары» кебек сатирик, «һарут белән Марут»тай мифологик, «Ант суы» тарихи поэмаларында да үзәктә шагыйрь кабул итүе, бәясе тора.

*Таш ташладым мин Иделгә.*
*Һәм, табигый, таш батты.*
(«Ант суы»)

*Яшәү яме бераз тоныкланса,*
*йә коргаксып куйса язарым,*
*Дәрдеменд күк, мин базарга чыгам,*
*урап кайтам Чехов базарын.*
(«Чехов базары»)

Базардагы хәлләрне сурәтләү белән генә чикләнеп, «Наполеон», «Чыңгыз хан», «Хужа Насретдин», «Борис патша, Горбачев, Ельцин» кушаматы белән йөртелгән мескеннәрдән көлүгә кайтарып калдырса, ул Ренат Харис булмас иде. «Базар күренешләре белән аерым-аерым танышу ил тормышының мөһим яклары турында уйлану рәвешен ала»,—дип яза Н. Хисамов «Базар һәм шагыйрь жаны» исемле мәкаләсендә[4].

Р. Харис бер әсәрендә дә кабатланмаска тырышып, һәр шигыренә, поэмасына яңа композицион төзелеш, чишелеш, бетем эзли. Шул ук вакытта аның сынала килгән, әмма һәр очракта да укучы күңелен җәлеп итеп, аны әсәргә алып керә, кызыктыра торган алымы бар. Аны шартлы рәвештә беренче жөмлә эффекты дип атап булыр иде. Көй уйнауны башлап жибәргәндә уен коралына тәүге чиертүнең әһәмияте зур булган шикелле, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романының беренче жөмләсе әсәрне детектив агымга кертеп жибәргән мисле, Р. Харисның поэмаларының беренче юлларын сайлап алуга игътибар бирүе,

[4] Хисамов Н. Хәтер сагында. – 433 б.

анын бу юнәлештә туктаусыз уйлануы, эзләнүе турында сөйли. «Рәссам» поэмасының беренче җөмләсе үк укучыны «сискәндереп, әсәрнең дәвамын укырга мәҗбүр» итә:

*Сарафанын салды да ул.*
*Көтмәгәндә бөтенләй ялангач калды.*

«Ат иярләү» поэмасы түбәндәгечә башлана:

*Качып кайтты Кәрам аты...*
*Киткәннән соң ун көн узгач...*

«Бүре күзе»нең беренче җөмләсе дә гаҗәеп эффектлы:

*Көтмәгәндә килеп кадалдылар*
*Күзләремә бүре күзләре...*

Р. Харис иҗатын өйрәнүгә күп көч куйган Ф. Хәсәнова фикеренчә, «шагыйрьнең соңгы елларда язылган поэмалары гади халык тормышын кырыс реализм пыяласы аша чагылдыра, фәлсәфи тирәнлек һәм сәнгатьчә нәфислеге белән сокландыра. Шагыйрь житлеккән сүз остасы тәвәккәллеге белән кешенең тарихи барыштагы урыны турында уйлана, укучыны тәэсирләндерә, уйландыра»[5].

## V

Р. Хариснең бөтен иҗаты буйлап сузыла килгән бер мәүзугы—замана героен эзләү. «Исемсезләр» шигъри романын да ул шул хыялын калкытып куюдан башлый:

*Герой эзлим! Герой эзлим*
*күз бетереп, җир ертып—*
*әйтерсең лә татарда мин*
*Байрон, Пушкин, Лермонтов...*

Остазларының исемнәре шигырь юлларын тутыру өчен аталмый. Аларда «Дон Жуан», «Евгений Онегин», «Герой нашего времени» кебек атаклы әсәрләрендә үз чорларына хас сыйфатларны җыеп алган замана героен эзләгәннәр. Р. Харис XXI гасыр поэзиясе казанышы саналырга лаеклы «Исемсезләр» әсәренә керешкәнче үк, уңай шәхесне татар мәдәниятенең үзе яхшы белгән, аралашып яшәгән кешеләре арасыннан эзли. «Исеңдәдер...» бәйләменә кергән ике дистәгә якын шигырьнең һәркайсы берүк сүз белән («Исеңдәдер», «Исеңдәме») башланып китеп, мәгълүм шәхес белән очрашуны, күрешүне, төрле дәрәҗәләрдәге аралашуны искә төшерә.

Бу әсәрләрне аңлау, кабул итү, мәгънәләренә төшенү—укучыдан рухи һәм әхлакый әзерлек таләп итә. Безнең арабызда шундый нәзберекле, тирән тоемлы элитар шагыйрь булу татар поэзиясенең бәхете һәм, дөнья бизмәненнән килеп, үсеш дәрәҗәсен билгеләүче бер үр. Р. Харис каләме тудырган шигъри портретлардан, «җанлы сын»нардан житди күргәзмә оештырырлык. Б. Урманче, Г. Бәширов, С. Хәким, Ә. Еники, Н. Жиһанов, Р. Яхин, С. Садыкова... кебек татар мәдәниятенең сүнмәс йолдызлары турында уйлана, һәр шәхеснең кабатланмас үзенчәлекләрен эзли, очрашу-күрешү мизгелләрен яңарта. Әйтик, композитор Нәжип Жиһанов белән «терсәкләнеп ак рояльгә ике яклап» туган көнен билгеләп торганда, «татар жиле тәрәз» кага. Нәрсә ул, нинди ул татар жиле дигән сораулар туа, шуна җавап эзләгәндә, яна көй иҗат ителә һәм аңлатма да табыла:

---
[5] Харис Р. Сайланма әсәрләр 7 томда. 4 т. Казан: Татар кит.нәшр., 2006. – 76.

*—Йә, нәрсә соң татар җиле?*
*Һәм син әйттең:*
*—Кичтем еллар, кичтем илләр,*
*Бөекләрен өскә чөя башка җилләр...*

Көйченең кинаяле, төртмәле фәлсәфи җавабында дөньяны яхшы ук танып-белүе хакында хәбәр, аз-маз рәнҗү катыш үпкә дә бар. Иҗат кешесе гадәти һәм һәр нәрсәдән канәгать була алмый.

Буыннар яшәешендә рухи якынлыкны, сәнгать төрләре арасындагы керешүне, үткәндәге үрләр белән бәйләүче җанлы җепләрне искә төшерүе, олы шәхесләребезгә сүз энҗеләреннән һәйкәлләр торгызуы, ягъни «Исендәдер...» шигъри Гөләндәме өчен генә дә Р. Харис ихтирамга лаеклы шагыйрь. Исән-имин килеш арабызда яшәп иҗат иткән сәнгать әһелләреннән И. Газиев, Р. Ахиярова һәм адашлары Ренатлар гына шагыйрьнең каләм очына эләгүгә лаек булдылар. «Исендәдер...» циклыннан гайре дә Р. Харис күренекле мәдәният әһелләребезне онытмый. «Ключарев», «Сәйдәш», «Рәссам Харис Якупов», «Дирижер Фуад Мансуровка» кебек багышлаулары да югарыда каралган бәйләмгә тартылып, шагыйрьнең югары зәвыгының бер күрсәткече булып торалар.

Шигъри романын «Исемсезләр» дип атаса да, түрәләр белән беррәттән, русның С. Михалков, В. Кузнецов, Н. Старшинов, Б. Ахмадулина, Ю. Друнина, милли шагыйрьләр Мостай Кәрим, Рәсүл Гамзатов, үзебезнең Рузия Мотыйгуллина, Алсу Гайнуллина кебек артистлар исемен, җырчы Зилә Сөнгатуллинаны яратып телгә ала. Бу киң күңеллелек күрсәткеченнән бигрәк, олы исемнәрне укучы күңеленә сеңдерә бару алымы да[6].

«Мин тәрҗемәче түгел» дип язса да, җиде том «Сайланма әсәрләр»енең (2006) алтынчы китабының яртысыннан артыгын Р.Харисның тәрҗемәләре алып тора. Сүз сәнгатенең бу катлаулы төренә мөрәҗәгать итүенең сәбәбен ул «Тәрҗемә турында» исемле мәкаләсендә болай дип аңлата:

«...минем татар телендә ишетәсем килгән, башка телләрдә иҗат ителгән шигырьләрем күп. Аларны хәтта яраткан, зәвыгымны тәрбияләшкән шигырьләрем дип тә әйтергә була. Ул шигырьләр күңелем сандыгында балачактан бирле саклана»[7].

Р. Харисның тәрҗемәләре белән танышканда ике төп үзенчәлеге күзгә ташлана. Беренчедән, араларында шагыйрьнең зәвыгына, шигърияткә күзаллавына туры килмәгән очраклы әсәрләр булмаса, икенчедән, тәрҗемәче вакыт һәм милли чикләр белән «санашмый». Рус поэзиясе янәшәсендә балкар, лак кебек аз санлы халыклар поэзиясе үрнәкләре дә урын ала. Аның рухына Гавриил Державин, Федор Тютчев, Валерий Шамшурин кебек философ һәм элитар шагыйрьләр иҗаты якын. Р. Харис «Казан утлары», «Ватаным Татарстан», бигрәк тә «Мәдәни җомга» битләрендә рус, украин, белорус һ. б. элеккеге СССРга кергән халыкларның әдәби уңышлары, хәтта проза үрнәкләре белән дә таныштырып барырга тырыша. Бер дәүләт булып яшәгән халыклар белән рухи элемтәләр өзелә барган чорда Р. Харисның бу юнәлештәге эшчәнлеге аеруча әһәмияткә ия.

Р. Харисның тематик һәм хәтер киңлеге елдан-ел офыкларын җәя, тирәнәя бара. Бу даими үзгәреш аның лирикасына да, җырларына һәм либреттоларына да хас. Сыйфат үсешенә алып килгән эзләнүләр киңлеге аның поэмаларында бигрәк ачык чагыла. Тышкы үзгәрешләр аша эчке динамик, иҗтимагый һәм сәнгати яңалыкларга алып килгән эчке процесста берничә тенденция ачык күзәтелә. Заманында бәхәсләр уяткан «Рәссам», «Ат иярләү» поэмаларында тормышны ике яссылыкта күрергә һәм сурәтләргә мөмкинлек биргән психологик анализ, рухи дөньяны, чынбарлыкны кабул итүнең гаять катлаулы, һәрвакытта шәхес теләгәнчә генә булмавын сынландырган, тормышны яңадан кору өстенлек итсә, «Һарут белән Марут»та сатирик гомумиләштерү алга чыкса, «Чехов базары» поэмасында инде тормыш «төбендә» олы сәясәтнең, безне упкынга йомычкадай үзенә тартып

[6] Бу хакта кара: Галиуллин Т. Н. Әдәбият – хәтер хәзинәсе. Казан: Мәгариф. 2008. 171-189 б.
[7] Харис Р. Сайланма әсәрләр 7 томда. 6 т. Казан: Татар кит.нәшр.,2006. – 156.

алган алыш-биреш, ягъни базар мөнәсәбәтләрендә илнең реаль тормышын, хәл-әхвәле чагылышын күрү ята. «Өч үбешү» кебек әсәрләрендә Р. Харис җанын ял иттерә. Ул—кичереш белән бергә акыл, фикер эшчәнлеген ачуга, заманның әхлакый, рухи проблемаларын тарихи үткәннәр аша үзенчәлекле тел бизәкләре, кыю метафоралар ярдәмендә, тормышны фәлсәфи катлаулыклары белән ачуга омтылучы шагыйрьләрнең берсе.

Кеше—үз чорының, әйләнә-тирә мохитнең җимеше диләр. Чыннан да, яшәгән дәвереннең гадәт-әхлак тәртипләреннән, иҗтимагый кануннарыннан сикереп чыгып булмый. Һәркемгә табигать биргән акыл һәм тойгы үзен чор калыпларында раслый яисә, алар белән килешмичә, үз «минен», үз өмет-хыялларын, омтылышларын алга сөрергә тырыша. Чын иҗат үзен менә шул каршылыклар бердәмлегендә раслый.

Гаҗәеп катлаулы һәм мәгънәле Р. Харис поэзиясе. Ул теләсә кемгә эчке серләрен ачып салмаска да мөмкин. Мәгарә ишекләре җиз тупсаларга утыртылган.

Р. Харисны хис, кичереш һәм гүзәл гамь—мәхәббәт сакчысы, юлдашы дип кенә бәяләү берьяклы булыр иде. Ул татарның үткәнен, исемен, хәзергесен яклап күтәрелүче шагыйрьләрнең берсе: «Татарлар», «Татар иле», «Төрки телләр», «Татарстаным минем». Р. Харис күнегелгән, гадәти кысалар шагыйре түгел. Ул көтелмәгән, уйламаган чагыштыру метафоралары белән сискәндереп җибәрә. Яна сурәт миенә сеңгәч, аның ифрат тормышчан күзәтү, бары тик чын шагыйрь генә таба алырлык ачык, якты, вакыты белән әрнүле сынландыру икәненә инанасың. Ул—сиңа сенә, җаныңны, рухыңны баета: «Күзләремә чумасың да Күнелемне буйлыйсың» («Көнләшүләр»), «Язмышың буйлап өрәктәй утлы үкенеч йөрер» («Кисәтү»), «Мин дә җирдә бер күбәләк кенә, Нишлисең бит—язмыш ертылды» («Нишләттең?»), «Идел акчарлагы күзе аша исеп үткән җил», «Күз серле коедыр» («Өч үбешү»).

Кыскасы, бай тарихлы татар поэзиясендә Ренат Харисның берәү белән дә бутап, алыштырып булмаслык лаеклы үз урыны бар.

*—Бер аягын зуррак атлау*
*Килешә юлга чыккан иргә...*
*—Нигә?*
*—Хисләре адашканда да*
*Әйләнеп кайтыр туган җиргә!*

(«Бабам сүзе»).

Ренат Харис һәрвакыт юлда, һәр яңа шигыре белән туган җиренә, халкына якыная, аларның сихәтен, җан җылысын, олылыгын иҗатында тулырак чагылдыра бара.

❋

Рафаэль
Мостафин

# ҖАМАЛ ВӘЛИДИ ФАҖИГАСЕ

*Нәкъ 80 ел элек, 1931 елның 3 май көнне, әнием әйтүенчә, мин дөньяга килгәнмен.*

*Миңа өч көн булган төнне әдәбият белгече һәм әдәби тәнкыйтьче Җамал Вәлидине кулга алалар...*

*Беренче карашка, бу ике вакыйга арасында бернинди дә бәйләнеш юк кебек. Әмма мин, әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче буларак, Җ. Вәлиди салган юлдан атладым, аның традицияләрен дәвам иттем. Шуңа күрә дә үземә 80 яшь тулган юбилей көннәремдә икенче фаҗигале 80 еллыкны— Җ. Вәлиди фаҗигасен искә төшерәсем килә.*

## Җамал Вәлиди кызы сөйли...

Без Әминә ханым белән очрашканда аңа инде 75 яшь иде. Ул күзенең начар күрүеннән зарланды, кәефе дә бик шәптән түгел иде. Әмма шуна да карамастан, уфтанмады-сыкранмады, зиһене үткен, хәтере яхшы иде. Җамал Вәлидинен кызы Әминә Вәлитова истәлекләре минем тарафтан 1994 елның 26 маенда язып алынды.

«Әлеге төнне мин гомерем буе хәтеремдә саклыйм. Бу вакытта миңа 12 яшь иде, мин туганыбыз Садри Җәләлләрдә кунакта идем. Ул әтиебезнең туганнан туганы, әмма яшь аермалары күп булмагангамы, алар бер ата балалары кебек якын иде. Еш очрашалар, очрашсалар сөйләшеп туя алмыйлар, кыскасы, ахирәт дуслар иде. 1931 елның май башларында мин аларда кунарга калдым. Садри Җәләл ул вакытта хастаханәдә ята иде. Төн уртасында нindидер хәрбиләр килеп ишек шакыдылар. Безнең барыбызга, шул исәптән балаларга да, йөзебез белән стенага борылып басарга куштылар. Дөрес, киенергә рөхсәт иттеләр итүен. Тенти башладылар. Бөтен әйберне актардылар, нәрсәләрнедер алып төенчек итеп төйнәделәр. Мин куркуымнан дер-дер калтырап, хәзер барыбызны да кулга алалар да, аталар икән инде, диеп уйладым...

Яктырганны көчкә көтеп алып, мин бу куркыныч хәбәрне житкерер өчен өйгә чаптым. Ләкин мине анда тагын да коточыргыч хәбәр көтә иде: шушы ук төндә әтине дә кулга алганнар икән. Шундый ук хәрбиләр килгән, тентү үткәргәннәр, нindидер кәгазьләр һәм китапларны алганнар һәм әтине дә үзләре белән алып киткәннәр.»

Республиканың Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты архивында сакланган документларга караганда, Җамал Вәлидине 1931 елның 6 маенда кулга алганнар. Ә кулга алыр өчен бирелгән ордерга бары тик 7 майда гына имза куелган. Тентегәннән соң бик күп китап (25 кило чамасы), шул исәптән Л. Троцкий әсәрләрен, алып китәләр. Бу китаплар һәм кулъязмаларның язмышы белән

кызыксынуыма Татарстан Дәүләт куркынычсызлыгы комитетының өлкән тикшерүчесе, юстиция капитаны И. В. Селивановский 1988 елның декабрендә: «Вәлитов Җамалга кагылышлы бер генә документ яки шәхси язма да бүгенге көнгәчә сакланмаган»,—дип җавап бирде.

—...Мин әтиемне бик тә, бик тә ярата идем. Бөтен кызлар да шулайдыр, мөгаен. Мин аның гаепле булуына аз гына да ышанмадым. Бер мин генә түгел, барыбыз да шулай уйлый идек. Әтинең тормышы барысының күз алдында иде бит. Ул яхшы күңелле, сөйкемле кеше, чын татар зыялысы иде. Мин моны әтием булганы өчен генә әйтмим, ул чынлап та бик намуслы, гадел, ярдәмчел кеше иде. Хәер, ул елларда бу сыйфатлар кимчелек буларак кабул ителгәннәрдер. Корбан буларак, беренче чиратта, нәкъ менә шундыйлар сайланды да инде.



Тиздән ачыкланганча, әтине Черек күлгә алып килгәннәр һәм эчке төрмәдәге ялгыз камераларның берсенә ябып куйганнар. Башта аның эшен болай ярыйсы гына тоелган тикшерүче алып барган. Озак кына сорау алган, әмма кыйнамаган, түбәнсетмәгән. Туганнары, якыннары белән дә күрештергән. Мин төрмәгә, әтием белән күрешергә әнием, ике абыем белән барганымны хәтерлим. Әтинең йөзе ак, сәламәт түгеллеге күренеп тора—төрмә бераүне дә аямый шул. Әмма ул үзен нык тота иде, шаян сүзләр әйткәләп, безнең күңелебезне дә күрергә тырышты. Ул вакытта әле аңа дип биргән ризыкларны да алалар иде, шуңа күрә без аны мөмкин кадәр ашатырга тырыша идек.

Бервакытны без күрешергә килдек, ә әтиебез безнең янга чыкмады. Соңыннан гына әни сорашып белде: элеккесе урынына Бикчәнтәев фамилияле тикшерүче килгән икән... Бу кешене үлгәндә дә каргап үләрмен, мөгаен. Куллары гына корысын ул бәндәнең![1] Әтиемне шулкадәр кыйнаган ки, шул хәлдән соң әтием озак кына аягына баса алмаган.

Берәр ай үткәч, безгә тагын күрешергә рөхсәт иттеләр. Кыйналганнан соң әтием әле терелеп тә җитмәгән, хәтта утыра да алмый, шуңа күрә басып кына сөйләшә иде. Аның тикшерүче турында әйткән сүзләре бүген дә колагымда яңгырый: «Ничек аны җир йотмый! Кабахәт!» дигән иде ул. Шул кыйналудан соң әти бөтенләй йокысыз калды. Бик нык ябыкты һәм сизелерлек картайды. Яңаклары батып керде, сакалмыеклары чаларды. Берничә ай эчендә ул бетәшкән картка әйләнде. Ә бит юкса аңа ул вакытта бары тик 45 яшь кенә иде.

Ул тикшерүче әтине тагын нәрсәләр эшләткәндер, анысын белмим, әмма кыйнаулар һәм мыскыл итүләр дәвам иткән. Ә беркөнне әтинең түземлеге чигенә җиткән, ул торткан да өченче каттагы тәрәзәдән сикергән. Бөтен газапларына берьюлы чик куймакчы булгандыр инде. Бик нык имгәнеп, кул-аякларын сындырса да, исән калган. Моннан соң аны Вахитов урамындагы хастаханәгә күчерәләр. (Соңрак Галимҗан Ибраһимов та нәкъ шул хастаханәдә үлә.) Без тагын озак кына күрешә алмадык. Берничә айдан соң, ниһаять, әтине янә төрмәгә китереп, күрешергә рөхсәт иттеләр. Әти безнең янга култык таякларына таянып чыкты. Бик газапланып атлый иде. Сынган аяк-куллары бик авырткандыр, күрәсең. Аны хәтта төрмә ишегалдына да конвойсыз чыгаралар иде, барыбер кача алмас дигәннәрдер инде.

Көзге салкын көннәрнең берсе... Төнлә белән яңгыр явып үткән, ә иртәнгә суытып җибәреп, аяк асты бозланып каткан... Әтине ул көнне хастаханәгә илтергә тиешләр иде, шуңа күрә без аны төрмә янында көтеп алдык. Үзәкләргә үтәрлек әче җил исә. Өстемдәге киемем юка булганлыктан, мин бик туңдым. Шулай да түздем—әтиемне бик күрәсем килә иде.

Менә, ниһаять, ике сакчы аны өстерәп диярлек алып чыктылар. Ә әтием атлый да алмый, бөтенләй бетерешкән. Җитмәсә, аяк асты бозлавык. Ике адым гына атлый

[1] 1938елны НКВД тикшерүчесе Гәрәйшә Бикчәнтәевнең үзен кулга алалар һәм иң югары җәзага—үлемгә хөкем итәләр Р. М.

да егыла, ике адым атлый да тагын егыла. Шунда әнием түзмәде: «Нишлисез сез, ерткычлар!»—дип, әтием янына ташланды. Әмма конвоирларның берсе мылтыгын ана төбәп: «Тукта, атам!» дип кычкырды. Мин бик курыктым. Әтием нәрсәдер әйткәч кенә әнием тынычланып читкә китте. Аннары, ниһаять, сакчылар яныбыздан узып баручы олауны туктатып, әтине утырттылар да, хастаханәгә алып киттеләр. Без дә алар артыннан иярдек.

Аның көннәре санаулы гына калган иде инде. Әтинең аякларында гангрена башланды. Әлбәттә, вакытында операция ясасалар, аны коткарып калырга да мөмкин булыр иде. Әмма «халык дошманы» кемгә кирәк соң? Соңгы мәртәбә без аның белән 1932 елның 29 ноябрендә күрештек. Әтием аңында түгел иде инде, шулай итеп, без аның белән сөйләшә дә алмый калдык. Икенче көнне ул аңына килә алмыйча үлгән. Ә бәлкем, аңына килгәндер, тик янәшәсендә берәү дә булмаган.»

## Чеп-чи ялган

Гаҗәбе шул: тикшерү материалларында Җамал Вәлидинең ни үзен-үзе үтерергә омтылуы, ни үлеме чагылыш тапмаган. Бары тик тоткыннар дәвалана торган хастаханәгә «хроник плеврит белән авыру сәбәпле күчерелде» генә диелгән. Менә моннан соң документларга ышан инде син!

Ә юкса Җамал Вәлидинең тәрәзәдән сикерү вакыйгасы бөтен төрмәне шаулаткан булган. Аның үзенең дә култык таягы белән йөргәнен күпләр күргән, һәрхәлдә, бу вакыйга икеләнү тудырмый.

1932 елның 11 маенда Җамал Вәлидигә суд карары чыгарыла. Күрәсең, шуның өчен аны төрмәгә кайтарганнар да инде. Дәүләт сәяси органы карарында: «Оештыру үзәге»нең җитәкчесе булуда, «үзәк»нең легаль булмаган җыелышларын уздыруда, халык арасында һәм матбугатта буржуаз-милли идеяләр таратуда гаепләнеп, Вәлидов Ж. Д. биш елга хөкем ителә» диелгән.

Тагын бер ялган: Җамал Вәлидинең «эше»ндә бу тоткын да «башка тоткыннар белән бергә Беломорбалтлагерьга озатылды» диелгән. Шулай итеп, «Органнар» үзләренең җинаятен яшергән, күрәсең.

Болар барысы да КГБ архивында саклана торган һәм «Казанның буржуаз-милли элементларын берләштергән Солтангалиев оешмасы филиалыннан бер төркемнең контрреволюцион эшчәнлеге хакындагы» 22076нчы эштә теркәлгән. Архивтагы номеры 571768. Тикшерүчеләр Вәлидигә карата кулланылган ерткычлыкларының өскә калкып чыгуыннан курыкканнар, күрәсең. ОГПУ карары белән 1932 елның 22 декабрендә Җамал Вәлидине «шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү» турында Җамал Вәлиди эшендә сакланып калган кәгазь дә «эз яшерү» өчен кирәк булгандыр. Аның 30 ноябрьдә вафат булганлыгын белмәмешкә сабышканнар.

Бу документ турында миңа Җамал Вәлидинең кызы да сөйләгән иде. Аның әйтүенә караганда, әтисе үлеп өч атна үткәч, 1932 елның декабрь азагында, Мәскәүдән аның гаебе кичерелү турындагы кәгазь килеп төшә. Әмма бу кәгазь якыннары күңеленә хәсрәт кенә өсти, чөнки инде соң була.

## Юл башы

Җамал Вәлиди XX гасырның унынчы еллары тирәсендә, Иж-Бубый мәдрәсәсендә укыткан чагында актив яза һәм матбугатта еш басыла. Беренче фәнни һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре татар газитләре «Йолдыз»да, «Вакыт»та һәм «Шура» журналында дөнья күрә.

Аның кискен аналитик мәкалә һәм күзәтүләренә танылган язучы Галимҗан Ибраһимов игътибар итә, аларны «акыллы, эчтәлекле һәм киң колачлы» дип атый. Ә Вәлидинең үзен Ш. Мәрҗанидән соң «яңа гасырның беренче тәнкыйтьчесе» дип белдерә. Г. Ибраһимовка Ж. Вәлидинең сабыр, ышанычлы итеп язуы ошый. Язучы әле ул чагында—унынчы еллар башында—Ж. Вәлиди белән киләчәктә үзенең дә

кискен бәхәскә керәчәген күз алдына да китерми.

Икенче күренекле тәнкыйтьче—Ибраһим Нуруллин, күпкә сонрак, инде илленче елларда, Ж. Вәлидине «Беренче Тукайчы», «Тукай иҗатын тулы мәгънәсендә ин беренче булып чын тикшерүче» дип билдерә. Чыннан да, Ж. Вәлиди Г. Тукайның төп китапларын үзе исән чагында ук рецензияли. Татар әдәби җәмәгатьчелеге арасында аның фикере иң абруйлылардан санала.

Ж. Вәлиди белән Г. Ибраһимов арасындагы беренче бәхәс тә нәкъ менә шул нигездә килеп чыга. Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» повестена һәм аның татар грамматикасы китапларына унай рецензияләр язган чакта, язучы да яшь тәнкыйтьченең фикерләрен тиешле эш кебек кабул итә. Ә инде Г. Ибраһимов үзенен «Әдәбият кануннары» дигән китабында Г. Тукай иҗатына берьяклы, дөрес булмаган, кимсетүле бәя биргәч, Ж. Вәлиди аңа кискен каршы чыга һәм аның фикерләренең ялгыш булуын ышанычлы рәвештә исбатлап күрсәтә. Әмма Г. Ибраһимов бик каты үпкәли, яшь тәнкыйтьче турындагы фикерен кискен үзгәртә һәм аны «чәнчеп» алу мөмкинлеген беркайчан да ычкындырмый.

Шулай булуга да карамастан, 1918 елда Г. Ибраһимов Ж. Вәлидине янадан үз вакытының иң абруйлы тәнкыйтьчесе дип таный.

Тәнкыйтьченең иҗаты гаять дәрәҗәдә бай. Биредә борынгы татар әдәбиятына җентекле анализ да, әдәбият яналыкларын күзәтү дә, халык авыз иҗаты мәсьәләләре дә, сәясәт тә, фәлсәфә дә, тарих та бар. Аның фәнни мирасында тел белеме зур урын алып тора, бу өлкәдә байтак хезмәтләр калдыруы өстенә, лингвистиканың кайбер өлешләрендә дә ул өр-яңа ачышлар ясаган кеше. Ул, чыннан да, акыл иясе-энциклопедист. Иҗади сәләт киңлеге ягыннан Ж. Вәлиди Г. Ибраһимовка тиң.

Ж. Вәлиди иҗат юлының башында, үз чоры эшмәкәрләренең күпчелеге кебек үк, татар халкының милли бәйсезлек алуы социаль революция белән бәйле дип саный. Аның мондый эчтәлектәге чыгышлары патша сакчылары игътибарыннан да читтә калмый, билгеле. 1911 елның февралендә Ж. Вәлиди фатирында тентү үткәрәләр. «Шикле әйберләрдән» Казан шәкертләренең революцион җырлары, әдәбиятчының «Тираннарга каршы көрәш»кә чакырган үз такмаклары табыла. Шулай да эш кулга алуга кадәр барып җитми. Аны либераль фикерле цензор Н. Ф. Катанов коткарып кала. Бу очракта «тиран» сүзе патша һәм аның ялчыларын түгел, ә бәлки мәдрәсәнең реакцион карашлы мөгаллимнәрен күздә тотып язылган дип аңлата ул.

## Түнтәрелештән соңгы еллар

Ж. Вәлиди 1922-24 елларда, матбугатта «пролетар культурасы» турында бәхәсләр куера башлагач, Г. Ибраһимов белән икенче тапкыр бәрелешә. Бу вакытта большевиклар ягына күчеп беткән Г. Ибраһимов һәр милли культурада ике культура булырга тиешлеге турындагы Ленин тәгълиматын кайнар яклый. Әлеге тезиска таянып, вульгарлаштыручылар, ягъни бозып күрсәтүчеләр, революциягә кадәрге бөтен мәдәниятне «буржуаз» дип атыйлар, ә пролетариат, иске җәмгыять җимерекләрдән чистартылган өр-яңа җирдә шулай ук яңа, монарчы күрелмәгән сәнгать булдырырга тиеш дип саныйлар.

Ж. Вәлиди курыкмыйча әлеге идеологик тезиска каршы чыгучы аз санлы кыюларның берсе була. Ул әдәби әсәрләрне «пролетар» һәм «буржуаз»га, ә язучыларны «безнеке» һәм «безнеке түгел»гә бүлгәләүне кискен тәнкыйтьли. Әдәби әсәр, барыннан да элек, аның «үзгәрмәс сәнгатьчә кыйммәте» ягыннан карап бәяләнергә тиеш, ди ул. Әгәр дә әсәр шундый кыйммәткә ия икән, кем тарафыннан язылуына карамастан, ул «гомуммилли байлык» булып саналырга хаклы.

«Сыйнфый яктан ялгыш карашлары» өчен бер Вәлиди генә түгел, иҗат юлларын Октябрьгә кадәр башлаган тулы бер төркем язучылар: М. Галәү, С. Җәләл, Ф. Кәрими һ. б. да гаепләнә. Кискен мәкаләләр һәм сәяси гаепләүләр белән үзләрен «яңа сәнгать» тарафдары дип санаган К. Нәҗми, Г. Кутуй,

Ф. Мөсәгыйть андый «буржуаз» язучыларга каршы кискен чыгышлар ясый. Прозаик һәм тәнкыйтьче, «чын пролетар идеология» тарафдары һәм «сыйнфый чыгышның чисталыгы»н кайгыртучы Г. Толымбайский бу эштә аеруча зур тырышлык күрсәтә. «Октябрь», «Сулф» («Сул фронт») әдәби» төркемнәренә кергән пролеткультчылар Һ. Такташ, Ф. Бурнаш һәм башка язучылар өстеннән шау-шулы «әдәби суд»лар уздыралар. Хәзер, ул чагындагы әдәби ыгы-зыгылар күптән тынган, ерак елларда калганнан соң, «буржуаз», «оппортунистлар» исемлегенә кертелгән талантлы татар язучыларының икенче төркемендәге шундый ук талантлы язучылар тарафыннан мыскыллануын, буылуын аңлап, чын күңелдән сыкранасың. Егерменче елларда «иске» язучыларны әхлакый яктан изсәләр, утызынчы еллар башында аларны физик юкка чыгару башлана. Аннары инде, утызынчы еллар ахырында, «буржуаз» язучылар калмагач, «пролетарлар»ына да чират житә...

Менә шундый шартларда Ж. Вәлиди бәхәсләшә алу түгел, матбугатта басылу мөмкинлеген дә югалта. Шулай да 1923 елда ул Петербургта «Идел буе татарларының мәгърифәте һәм әдәбияты тарихы турында очерк» исемле монографиясен бастырып чыгара әле. Торгынлык елларында, Ж. Вәлиди аклангач, аның турындагы барлык мәкаләләрдә дә диярлек әлеге китабының В. И. Ленинның Кремльдәге шәхси китапханәсендә булуы турында әйтелә. Бу китап, чыннан да, бик акыллы һәм бай эчтәлекле, пролетариат юлбашчысы аңардан байтак кыйммәтле мәгълүмат ала алгандыр.

Шулай да Ж. Вәлидине бу китап кына коткарып кала алмый. Республикада аның турында «әдәбияттагы сыйнфый принцип»ны кире кагучы антимарксист» кушаматы ныгып өлгергән була инде.

Әдәби тәнкыйтьтән китәргә мәжбүр булган Ж. Вәлиди үзенең бөтен көчен чагыштырмача тыныч өлкәгә—лингвистикага багышлый. Грамматика мәсьәләләрен өйрәнә, татар әдәби теленең фәнни нигезләрен ачыклый, тел белеме буенча рецензияләр яза, дәреслекләр әзерли. Егерменче елларның икенче яртысында аның берничә бик саллы китабы һәм уку әсбабы басылып чыга (кайберләре берничә тапкыр янадан да басыла) һәм татар теленең ике томлык аңлатмалы сүзлеге дөнья күрә.

## Ни өчен?

Сталин елларында мондыйрак эчтәлекле мәзәк йөргән:

—Сине ни өчен утырттылар?—дип сорый ди лагерь начальнигы яна килгән тоткыннан.

—Бер гаепсезгә,—ди тегесе.

—Алдашасың! Бер гаепсезгә ун ел бирәләр. Ә сиңа бит—егерме бишне чәпегәннәр!—ди начальник.

Чынлап та, утызынчы еллардагы чынбарлык шушы монсу мәзәктәгедән әлләни аерылмый.

Егерменче еллар ахырына И. В. Сталин, үз хакимлеген гаять дәрәжәдә ныгытып, үзенең сәяси дошманнарына каршы аяусыз көрәш ачып җибәрә. «Солтангалиевчеләр»гә каршы көрәш тә әнә шул исәпкә керә.

Җамал Вәлиди, Садри Җәләл, Гали Рәхим һәм башка язучылар, нәширләр, җәмәгать эшлеклеләрен кулга алганнан соң, Казан ГПУы Мәскәүгә горурлык белән хәбәр итә: «ТАССР ГПУ органнары тарафыннан буржуаз-милләтче зыялыларның һәм сәүдә-сәнәгать буржуазиясенең контрреволюцион төркеме ачылды һәм юк ителде».

Әмма әлеге җиңү хәбәре тикшерү тәмамланганнан соң түгел (әле ул башланырга да өлгермәгән), ә бәлки кулга алу белән үк җибәрелгән. Кулга алынучылар исемлегендә, югарыда әйтелгән язучылардан тыш, корректорлар да, вак сәүдәгәрләр дә, гади совет хезмәткәрләре дә бар. Аларның гаепләре кайсысының «мулла яисә фабрикант малае» булуда, кайсыдыр «акларда писарь булган», ә кемдер моңа кадәр кулга алынучының якын кардәше. Исемлектә барлыгы 18 кеше. Тора-бара исемлек тагын да тулыландырыла.

Әлеге төркем «Вәлидов, Мохтаров, Бәдәйли, Бурундуков, Янбаев кебек күренекле солтангалиевчеләр белән 1922-25 еллардан башлап бәйләнештә торуда» гаепләнә.

## Тикшерүче белән икәүдән-икәү

«Оештыручы үзәк» (башка исем уйлап таба алмаганнар) эшен тикшерү бер елдан артыкка сузыла һәм калын-калын сигез томны били. Материалларны укыганда ук гаепләүнең күз алдында эреп тарала баруын тоясың. Беренчедән, кулга алынганнарның күбесе бер-берсен белми, танымый һәм беркайчан да очрашмаган. Үзләренең «бердәм контрреволюцион төркем» тәшкил итүләрен дә кулга алынганнан соң гына ишеткәннәр. Икенчедән, «солтангалиевчеләр» белән бәйләнешләре берничек тә ачыкланмаган. Берәүләре аларны бөтенләй күрмәгән, икенчеләре революция алды елларыннан бирле очрашмаган.

Кулга алынучылар арасында үзара якын мөнәсәбәтләрдә булган, туган көннәрне, гаилә бәйрәмнәрен бергә үткәргән кардәш-ыру, дус-иш, хезмәттәшләр дә була. Тикшерүче Бикчәнтәев үз гаепләүләрен әнә шул нигездә оештырырга тели. Бәйрәмдә җыелышып утыру татарча «мәҗлес» дип атала. Бу сүзнең икенче мәгънәсе—«җыелыш», һәм тикшерүче «яшерен мәҗлесләр»не кулга алынучыларның «контрреволюцион эшчәнлеге формасы» дип белдерә. Ж. Вәлиди юкка гына бу «мәҗлесләр»дә бернинди оештыру эшчәнлеге булмавы, аларның гадәти бәйрәм ашлары икәнлеген аңлатырга тырыша.

Сорау алулар вакытында кызыл җеп булып сузылучы икенче тема Җ. Вәлидинең сәяси карашлары һәм инанулары. Туры сүзле һәм хәйләсез кеше буларак, Ж. Вәлиди үз карашларын яшерүне кирәк дип санамый. Большевикларга каршы фикерләрен дә ачыктан-ачык белдерә.

Тикшерүче боларның барысын да сүзен сүзгә язып бару белән генә чикләнми, ә бәлки үзеннән дә куша: янәсе, «менә шуның өчен дә инде мин каләмемнең очын большевикларга каршы юнәлттем». Әмма, сорау беркетмәсен укыгач, Ж. Вәлиди боларны, артык күпертеп язылган, дип белдерә. «Уйлап карагыз, мин кайда һәм ничек большевикларга каршы чыга ала идем,—ди.—Большевик газитләре бу хактагы язмаларны басачак идеме соң?» (Әлеге сүзләр беркетмәгә аның үз кулы белән язылган.)

Тикшерүче тагын да мәкерлерәк икенче тактиканы сайлый. Ж. Вәлидигә үзенең сәяси карашларын үз кулы белән язарга тәкъдим итә. Вәлиди «эше»нә шул рәвешчә аның үз карашларын чагылдырган күләмле генә аңлатма кәгазе өстәлә. Минемчә, Вәлиди иҗатын өйрәнүчеләр аның ачык-аңлаешлы почерк белән, матур әдәби стильдәге язмасына кабат-кабат мөрәҗәгать итәрләр әле.

«82нең протесты»на ни өчен кул куюын сорагач, Ж. Вәлиди тыныч һәм аңлаешлы итеп түбәндәгечә җавап бирә: «Яңа әлифба кертү милли мәдәният өчен чын фаҗига, чөнки бу милли мәдәният традицияләренең тулысынча өзелүе дигән сүз. Бөтен халык кинәт кенә, бер мизгел эчендә наданга әверелә». Әмма тикшерүче аңарга бу мәсьәләдә барлык карашларын тулысынча ачарга мөмкинлек бирми. Аны башка нәрсә кызыксындыра: бу хатны, кул куйдырырга дип аңа кем алып килгән? «Башлап йөрүчесе», «котыртучысы» кем?

Язмалар шушы урында өзелә һәм, мөгаен, бөтенләй башка, «саллырак» аргументлар эшкә кушыла торгандыр. Сорау алулар тагын бер айдан соң гына дәвам итә, бу очракта язмаларны тикшерүче үзе алып бара. Ж. Вәлиди кулын гына куя. Аның почеркы да кискен үзгәргән, сынык, балаларча ышанычсыз булып күренә.

Тикшерүче «большевикларга каршы көрәшкә басым ясый. Әгәр дә аларның фикерләрен якламагансың икән, аларга каршы ничек көрәштең, ди? Нинди чаралар белән?

Ж. Вәлиди бернинди көрәш алып бармавы турында катгый җавап бирә. «Ни өчен?»—ди тикшерүче, Вәлиди үзенең җавабында Октябрьдән соң күп тә үтми

НЭП игълан итүләрен, иске тәртипләрнең (тикшерүче үзеннән «капиталистик» сүзен өстәп куя) яңара башлавын әйтә. Вәлиди «бернинди түнтәрелеш кирәк булмаячак, шушы рәвешчә барысы да үз урынына кайтачак» дип ышанган икән.

Тикшерү барышында Бикчәнтәев Вәлидине үзенең дуслары һәм көрәштәшләре белән дошманлаштырмакчы, алар өстеннән «компромат» сыгып алмакчы була. Аның «татар буржуазиясе идеологы Гали Рәхим» турындагы соравына Ж. Вәлиди болай ди: Гали Рәхим, белүемчә, сәясәт белән бөтенләй кызыксынмый, күптән булып үткән хәлләр турында гына яза. Галимҗан Ибраһимовка кушылып, чын күңелдән Совет властена хезмәт итә.

«Ничек алай булсын?—дип төпченә тикшерүче.—Безнең күзәтүебезчә, ул буржуаз Төркия белән элемтәдә тора, аннан күрсәтмәләр ала. Мәсәлән, «Төркилек нигезләре» китабын алган. Димәк, ул үзе дә пантюркист».

Әмма Вәлиди үз сүзеннән кире кайтмый.

Ж. Вәлиди кардәше С. Җәләлне ничек тә аклап, яклап калырга омтыла. Аны балачактан ук белүен, мәдрәсәне бергә тәмамлауларын әйтә, аннары алар Иж-Бубыйда бергә укыйлар, Татар укытучылар мәктәбен тәмамлыйлар, чөнки рус телен һәм мәдәниятен өйрәнү теләкләре көчле була. «С. Җәләлнең советка каршы эшчәнлеге турында сүз булырга да мөмкин түгел»,—ди Вәлиди. Өстәвенә ул каты авыру, паралич белән гарипләнгән һәм тулысынча сукырайган диярлек. Тикшерүче бер үк сүзне кабатлый: С. Җәләл—мулла малае, акларның чехлар корпусы офицеры, буржуаз гәзитләр хезмәткәре, милләтчелек рухындагы Хәрби шура секретаре, һәм аның гаебе тулысынча расланган, ди.

Кыскача әйткәндә, тикшерүченең куйган тырышлыгына, кыйналу һәм җәзалауларга да карамастан, «ТАССРда солтангалиевчеләр үзәге филиалы»н формалаштыру берничек тә барып чыкмый. Нindидер «Оештыручы үзәк» билгеләмәсе белән чикләнергә туры килә. Чынбарлыкта анысы да булмый. Шуңа да карамастан, кулга алынганнарның берсен дә акламыйлар. Әлеге үзәккә (исбатланмаган булса да) «кагылышлы» булганнарга бишәр ел лагерь срогы биреп, озакламый Беломорканал төзелешенә җибәрәләр. Әлеге «бөтенхалык төзелеше»ннән күпләр кайта алмый, икенчеләре гарипләнеп кайта.

«Татарстан чекистлары» исемле китапта (21 бит) шундый фикер белдерелә. Янәсе, «Совет властенең революция дошманнарына каршы көрәш формалары һәм ысуллары беренче елларда аларга күрсәтелгән гуманлы мөнәсәбәт белән гаҗәпләндерә». Чыннан да, патшаны шунда ук атмаганнар, Вакытлы хөкүмәт министрларын сак астыннан чыгарганнар. Кайбер ак офицерларны, вәгъдә сүзләренә ышанып, ирекккә җибәргәннәр.

Дистәләгән кешене, шул исәптән иҗади интеллигенциянең иң яхшы вәкилләрен—язучылар, галимнәр, нәшрият хезмәткәрләрен бер гаепсезгә бишәр елга утыртып кую да нәкъ менә шул совет судының әлеге дә баягы «гаҗәеп гуманлылыгы» белән аңлатыладыр. Соңрак моның өчен аталар, ким дигәндә ун ел бирә башлыйлар. Хәер, Ж. Вәлиди өчен боларның бер мәгънәсе дә булмый инде. Ул төрмә хастаханәсендә 1932 елның 30 ноябрендә вафат була. Күмелгән урыны бүгенге көнгәчә ачыкланмаган.

Фәнзаман Баттал

# ЮКСЫНУ

## ГАМИЛ АФЗАЛНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

*Кемнеңдер кадерен белү, аның кирәклеген аңлау өчен... ул кешене ошбу дөньяга тумаган, яшәмәгән һәм, гомумән, бөтенләй булмаган дип уйлау да кирәктер, мөгаен. Чорыбызның мәшһүр шагыйре Гамил абый Афзалны юксынып йөргән чакларымда шундый фикер килеп сискәндерә. Милли әдәбиятыбыз күпме нурдан, юмордан һәм моңнан мәхрүм калган булыр иде!.. Яшәгән гасырыбыз да салкынрак, җансызрак тоелыр иде.*

Мин Гамил абыйны беренче шигырен укыгач ук яраттым...

Ана хәтле Тукайның бөтен шигырьләрен яттан беләи идем инде.

Хәер, шушы җөмләмнән соң ук гади укучының: «Әһә, Тукайның шигырьләрен ятлап үскән икән бу!» дип нәтиҗә ясавы ихтимал. Һич тә алай түгел. Минем бер чакта да (мәктәптә мәҗбүри ятлаттырылганнарыннан башка) бер генә шагыйрьнең дә шигырьләрен ятлап утырганым булмады. Соклана-соклана, кабат-кабат, кайтып-кайтып укый торгач, үзләре хәтернең бер тукымасына әверелә иде яраткан шигырьләр...

Тукайны яттан белә башлагач, күңел... яңа Тукай сорый башлады. Егет булып та житешмәгән яшүсмер булсам да, әлбәттә инде, Тукайның кабат тумаячагын аңларлык мин ул вакытта. Ләкин, нишләмәк кирәк, нәкъ менә Тукайныкы кебек туры сүзле, юморлы, сатиралы шигырьләр укыйсы килә!.. Нәфес шулкадәр «азган»: син аңа шагыйрьнең шундыен бир—Тукай рухлы гына булмасын, хәтта Тукайга гына хас ритмлы да булсын!

Сигезенчеме, тугызынчымы сыйныфта укый идем булса кирәк, мин андый шагыйрьне таптым! «Әсмабикә жаным-ахирәт» дигән шигырьне укыгач таптым. Язучысының исеме дә гаҗәп матур тоелды: Гамил Афзал! Сусаган күңел бу шигырьне авторы-ние белән бер мизгелдә «йотты да куйды». Үзем шигырьне һәр таныш малаема укыйм, һәр строфасыннан соң эчтән генә «Гамил Афзал!» дип горурланам.

*Әсмабикә жаным-ахирәт,*
*Безнең очта сиңа ни кирәк?*
*Гөлләр сибим синең юлыңа,*
*Бу чемодан нигә кулыңда?*

Назлы да сыман, һәр сүзе мамыктай йомшак та сыман, ләкин кабатлаган саен елмайта да, рәхмәт төшкере! Тагын берничә шигырен укып куангач һәм өр-яңа Тукайның барлыгына инанып бетә язгач, мине армиягә алдылар. Ярты ел чамасы

гына эшләп өлгергән редакциямнән, берничә ай гына житәкчелек иткән әдәби түгәрәгемнән аерылып киттем. Кем анда—Украинаның аргы читенә—Татарстанда чыккан гәзит-журналларны китереп торсын да, яна китапларны ташып торсын?! Ияреп барган Тукай томнарым бар да, тагын берничә шагыйрьнең юка гына китапчыклары бар. Туган яктан сорап алдырган яңалары да булгалады. Дөресен әйтим, туя укый алмадым армиядә татар китапларын. Кая анда әдәбият яңалыклары белән танышып яшәү һәм өр-яңа әсәрләрне укып бару!.. Ләкин шуңа сөенәм, Тукай һәм Гамил Афзал шигырьләрен яттан укый белүем белән дә ике полкның (мин хезмәт иткән тупчылар полкы янында гына зенитчылар полкы да бар иде тагын) татар егетләрен карата һәм үз тирәмә туплый алдым.

Армиядән Минзәләмә кайткач, атна да үтмәгәндер, районның Тукай исемендәге үзәк китапханә директоры Мәрьям апа Сарбулатова килеп керде өйгә.

—Энем, кайткансың икән бит. Ник һаман китапханәгә кермисең? Әдәби түгәрәкнең эшен дәвам итәргә кирәк... Әле менә бүген генә Казаннан бер шагыйрь килде. Шәһәрнең китап сөючеләре белән очрашырга тели. Иртәгә үткәрербез очрашуны. Ләкин уку залының һәрвакыттагы кебек тулы булуы кирәк. Оештырыйк. Ә хәзер—киттек. Теге шагыйрьнең иң әүвәл синең белән очрашасы килә.

Әйе, бу апа әдәби түгәрәкнең кадерен белә иде. Муса Җәлил Минзәләдә укып, яшәп киткән айларда да күп әдәби кичәләр оештырып йөргән «гомерлек» директор апа Рәшит Гәрәй, Газиз Мөхәммәтшин, Габделхәй Сабитов кебек якташ шагыйрь һәм язучыларның да нәкъ менә үз йортыдай күргән китапханәсендә үсканлекләре белән горурлана иде. Һәрхәлдә, аларның язучы була алуында үз өлеше дә барлыгына шикләнми иде. Хәтта, сүз уңаенда шуны да әйтим: мин әле армиягә киткәнче үк, ни сәбәптер, түгәрәкнең бер утырышын редакциядә үткәргән идем. И рәнжеде, иллә дә хәтере калды Мәрьям апамның!.. Кулыннан төп бәхете тартып алынгандай булды. Әле дә хәтердә, ялварды да кебек, хәтеремә ныклап сеңдерергә дә теләде кебек...

—Моннан соң түгәрәкне китапханәдән аера күрмә, энем!—дип өзгәләнде ул.—Муса абыең да изге итеп санады безнең китапханәне...

Тукта! Мин бит Гамил Афзал турында яза башлап, бөтенләй читкә кереп киттем түгелме соң? Түгел икән... Чөнки боларны тасвирлап үтмәсәм, бу язмам төссез, нурсыз калыр иде. Ачылып бетмәс иде.

Киттем китапханәгә. Күргәнем булмаса да, шигырьләрен укыганым бар иде Казаннан килгән шагыйрь абзыйның. Барлык шигырьләре дә, бер калыптан чыккандай, КПССның бинаһая бөеклеге, алдында торган кыяларны да җимереп үтүче диңгез корабыдай куәтле булуы турында иде аның... Кызылдан башка төсне күрмәүче абзый инде...

Кичәне оештыру хакында сөйләшкәч-килешкәч, сорау биреп куйды бу:

—Кайсы шагыйрьне аеруча яратасың?

—Гамил Афзалны!—дидем мин. Үзем дә шундук берниичә сорау бирдем.—Кайда яши ул? Нindirәк кеше ул? Китаплары күпме? Үзен күрәсе килә... Кайда күреп була?

Кунак абзыемның кәефе тәмам кырылды. Иреннәре кипкәндәй, сүз әйтә алмый торды. Яшь башым белән дә аңладым: шагыйрь абзый нәкъ менә үз исемен ишетергә теләгән!

—Соң... Кем дип... Инвалид инде ул... Гарип... Яшьтән үк пенсиягә чыккан...—диди өзек-өзек җөмләләр тезә башлады ул боз салкынлыгы белән.—Ялгышасың... Яшь булганыңа күрә генә чын шагыйрь булып тоела ул сиңа... Аның шигырьләрен дә үзе чирле булганга күрә генә, кызганып кына бастыралар инде аның...

Шул сүзләрен ишетеп бетергәнче үк минем өчен алдымда торган абзый үлде—тере мәеткә әверелде. Әнә, аның инде минем каршымда кара шәүләсе генә торып калды. Ул минем иң кадерле, иң яраткан һәм иң авырткан «сөялемә» басты. Минем күземә директор апаның (иркенләп сөйләшсеннәр дип, ул үзе чыгып торган иде) шушы бәләкәй генә яп-якты кабинеты да гүр төбедәй карангыланды сыман. Катырак сүз дә әйткән һәм чыгып та киткән булыр идем... ләкин бу дөнья агышы минем гасабилыктан гына туктап калмаячак. Дөресрәге, калмаска тиеш...

Икенче көнне очрашу кичәсенә җыелдык. Һай ул телевизор кебек чирләр булмаган, акчага табынмаган, һәр кеше башкаларны бандит дип санамаган, төн

уртасында да шикләнми-шүрләми урамнарда йөргән, яше-карты да китаптан, әдәби кичәләрдән тәм һәм ләззәт тапкан, әдәбияттан әдәп алган заман!—киң һәм иркен уку залы шыгрым тулды. Шагыйрь абзый нәрсәләр язуы турында нотык тотканнан соң, 48 битле китабыннан (әле генә чыккан беренче китабыннан) шигырьләр укый башлады. Ул укый тора, халык сүрелә тора... Берәүләре искәнә, бәгъзеләре, урындыкларына сыя алмагандай, кыбырдаша, бер-икесе урыныннан кузгала... Ә теге укый да укый. Ниһаять, җыентыгын укып чыкты бугай бу. Аннары шул китабын өскә күтәреп:

—Кем дә кем минем бер-ике шигырьне яттан белсә, бу китабымны шуңа автограф белән бүләк итәм,—димәсенме! Мин, аның белән янәшә утыручы түгәрәк җитәкчесе, гомерем буена да ул чактагыдай кызармадым, оялмадым сыман... Ә ул, китабын тагын да өскәрәк күтәрә төшеп, халыкның күзенә карый. Табылмады моның шигырен яттан белүче кеше, табылмады... Шуны аңлап бетергәч, абзый, китабын портфеленә тыга-тыга:

—Шигъри тәрбия юк икән әле сездә... Ярый, таралыша башласак та ярыйдыр,—дип куйды.

Күңелдәге үртәлүем, бу абзыйны сөймәвем, аның әдәби җанлы якташларымны кимсетүенә чыдый алмавым җәһәт кенә аякка бастырды мине. Баскан хутка ук:

—Юк, таралмыйбыз җәмәгать!—дидем.—Бу абыйга рәхмәт әйтик тә, кичәне дәвам итик әле. Кем нинди шигырь белә, шуларны укышыйк.

Ярым кузгалган, кәефләре кырылган әдәбият сөючеләрне кире урыннарына утырту өчен, Гамил Афзал шигырен укый башладым:

*Кәҗәбезгә печән беткән,*
*Колхозныкы хәләл икән...*

Сәгать ярым буе траур кичергәндәй утырган якташларым (әдәби җанлы бәгырькәйләрем!) шигырьнең шушы ике юлыннан да дәррәү балкып китте. Инде дә «Әсмабикә»не укыганда!.. Үзләренең әйтүенә караганда, көлүдән чыдый алмыйча, арткы рәтләрдә берничә кеше идән тырмап яткан, имеш. Чын шигырь бәйрәме башланды залда. Чират торалар халык алдына чыгарга. Берәүләр Тукайдан «авыз иттерә», икенчеләр Рәшит Гәрәйне укый, Шәүкәт Галиевнең сатирик шигырьләре дә яңгырый, кайсыдыр Илдар Юзеев поэмасыннан өзек укып хисләндерергә тырыша... Көләләр, монаялар, уйга баталар, күзләрен дә сөрткәләп куялар... Урыныннан кузгалырга да өлгерә алмый калган абзам, әлеге юка китабын да салган портфелен кысыбрак тоткан хәлдә, кузгалып китәргә дә, утырып торырга да базмыйча, калкынып-калкынып куя... Кемдер Гамил Афзалның яңа чыккан шигырен укуы булды, әдәби кичәне ябып куйдым—ихластан әйтсәм, нәкъ менә шул «нотада», яраткан шагыйремне яраткан рухта түгәрәклисем килде кичәне. Кышкы төннең уртасы җитеп бара иде бит инде...

Шул ук 1961 елда мин Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга кердем. Кердем, дигәч тә, әле кереп беткән юк. Имтиханнар инде тапшырылган. Ләкин керү-кермәү хәл ителеп бетмәгән бер көн бу. Без, абитуриентлар, университетның коридорын саклыйбыз. Дөресрәге, шундагы информация тактасына кабул ителгәннәрнең исемлеген чыгарып элгәннәрен көтәбез. Көтеп-көтеп көтек булабыз да, икешәрләп-өчәрләп, дигәндәй, вакыт сату өчен шәһәр буйлап чыгып китәбез. Бу коридордан ерактарак булыйк әле, ичмасам, ди-ди, елга портына кадәр төшеп киткән дә бар. Менә, кайсыдыр яңа дус белән, Матбугат йорты астындагы китап кибетенең перронны хәтерләткән баскычына чыктык. Баш иеп кенә сөйләшеп атлыйбыз шулай, кемдер исемем белән эндәште. Борылып карасам, биек тә, арык та гәүдәле, озын чәчле, таяклы кеше басып тора. Мин инде аның кемлеген шәйләдем дә сыман. Газитләрдә мона охшаган бер-ике фоторәсем күргәнем, игътибар белән йөзенә карап утырганым бар иде. Әйе, бер дә бүтән түгел, Гамил Афзал булырга тиеш бу... Ләкин ул булуга шигем зуррак. Ни өчен дисәң, аның—мине, минем аны күргәнем юк. Бик күп булса, республика матбугатында ике-өч дистә шигырь, биш-алты хикәячек бастырган «малай-шалайны» Гамил Афзал каян белсен дә, ниләремә дип кенә эндәшеп торсын! Ул чакта

әле матбугатта юньле-башлы фоторәсемем дә чыкканы юк сыман...

—Бу дустың Фәнзаман дип эндәште сина. Бик яна исем. Минзәлә усалы түгелме син? Усалларны яратам мин.

Үзе шундый сорау бирә, үзе елмаймый да. Шулай да карашы жылы. Моңсу да...

—Аптырама, синең усаллыкны ишеттем мин. Шигырьләреңдә дә сизелә. Тешләштерәсен...

Мин инде, үземчә, әллә теге әдәби кичә хакында берәрсе сөйләде микән, дип уйлап та куйдым-куюын. Кая инде ул чак мондый шәхес белән күзгә-күз карап төпченү?! Тел дә әйләнми сыман... Ул да усаллыгымны исбатлап ләм-мим сүз әйтмәде. Ниләр майтарып йөрүем белән дә кызыксынып тормады. Таягын таягыннан да озынрак аягына сөяп куйды да Гамил абый, кыршылып беткән портфеленнән бер китапчык чыгарып, тышлыгын ачып, берничә сүз сырлады: «Минзәләнең усал егете С.Фәнзаманга истәлек булсын. Мактый-мактый, сүгә-сүгә укысын. Г.Афзал.»

«Дөнья матур» дип аталган бу китапны тотып, университет коридорына кабат кергәч, эленгән исемлеккә баккач, дөнья тагын да матураеп китте—университетка кабул иткәннәр!

Әнә шул очрашудан соң университетны тәмамлаганчы да, аннан сон да шактый еллар күрмәдем мин аны. Ләкин күңел бер генә көн дә ансыз яшәмәде. Чөнки иҗат турында уйламаган, Тукайга, Афзалга сокланмаган көн юк. Хәтта...

Әйе, хәтта Гамил Афзалнын шактый шигырьләрен яттан белүем мәгълүм шагыйрь Эдуард Мостафин белән икебезне ачлыктан, салкын тиюдән коткарды кап-кара урманда адашкан кап-кара төндә...

1968 елда Башкортстанның Калтасы районында чыга торган «Таң» гәзитенә мөхәррирлек кыла башладым. Эшли башлаганыма ай чамасы гына үткәндер, сентябрь уртасындарак Эдуард килеп керде бүлмәмә. Укуын әллә ташлаган, әллә «ташлатканнар» шунда—хәтердә калмаган, эш сорый. Миннән «югарырак» мөхәррир белән киңәштем дә (ул мөхәррир районда татарча, урысча, марича чыга торган өч гәзиткә хуҗа иде), эшкә алдык Эдуардны. Жомга көн булгандыр бу, мөгаен. Анын эшкә керүен шәпләп кенә «юдык», икенче көнне дә дәвамы булды бу «вакыйганың». Шуннан, гөнаһ шомлыгына каршы, служебный «Урал» мотоциклын кабыздым. Имеш, кайсыдыр районга, кемнедер күрергә бармакчыбыз. Бара-бара, ниндидер юл чатларында борыла-борыла, урман юлына килеп кердек. Бара торабыз, карангылык та куера бара. Ярыйсы гына киң тоелган юл да тарая, сазлыклана башлады һәм... мотоцикл да сүнде. Эчтән дә жылынган, кояш та кыздырган көн яктысында трико-мазар гына киеп юлга чыккан безләрнең тешләре тешкә тия хәзер. Жәяү китәр идек, ике мең сумлык мотоцикл мишәйт итә. Шулай да сазлыктан үләнгә чыгарып бастырдык ул имгәкне. Әйткәнемчә, кап-кара төн, тирә-як тып-тын. Яфраклар да әллә нигә бер генә шыбырдашып ала. Тамак ач. Тамак кипкән. Махмыр. Салкын. Ичмасам, мондый чакта «жылыта», юата торган сигаретларыбыз да беткән. Мотоцикл житәкләп барам, икенде күләгәседәй озын, чандыр Эдурд исә, коянтәдәй бөгелеп, этә бара... Кинәт алда тычкан утыдай яктылык күрдек. Шунда таба киттек. Барган саен зурая яктылык. Килеп житсәк, дүрт ир машина фарасы яктысына жәймә жәеп, сыйланып яталар.

Күз алларына килеп баскач, телбистәләнеп:

—Гамил Афзал әйтмешли, тәвәккәлгә Хак Тәгалә тугыз жирдән бирә икән, егетләр. Учагыгыз да яна икән. Без өшегәннәрне дә жылытырсыз, бәлки,—диюемә, берәүсе жәлт кенә калкып куйды да:

—Карагыз әле, Гамил Афзал шигырьләрен белә торган егетләр икән болар!—дип, гажәпкә калгандай итте.

—Шигырьләрен генә түгел, анын үзен дә беләбез. Тик менә тамак яна...

—Янганда ин әйбәте квас инде анын,—диде берсе, шаян елмаеп.—Мә, күтәреп жибәр.

Сузган кружкасыннан чөмерә торам, үзем аңлый торам: квас түгел, ачы бал бу, каһәр... Эдуард та чөмерде тегене. Кара төн яктырып китте, ашъяулык тулы ризык, учак кабырганы жылыта—жәннәт! Житмәсә, учактагы чиләктән ике үрдәк тартып чыгардылар. Бер читтәрәк яткан ике мылтык күзгә чалынган иде инде.

Димәк, аучылык та иткәннәр... «Акбашлар» да чыккалый табынга. «Не было ни гроша, вдруг—алтын» кебегрәк хәл монда. Минем иң үтемле «тауарым»—Гамил абый шигырьләре. Бер-ике строфасын сөйләгән саен тост әйтәләр. Тора-бара Гамил абый тегеләрнең берсенә—жизни, икенчесенә кода була башлады. Аннары инде машина фургонына тутырылган печәнгә чумып, чыбылдыкларга төренеп, йоклыйсы гына калды... Иртәнгә кырау төшкән. Учакны тергезеп, капкалап алдык. Тик менә ничек кайтасы. Алтаулап кабызырга маташсак та, мотоцикл пырлап та карамады.

—Гамил Афзал кешеләре болар, егетләр. Чурт с ним, эш качмас, кырык чакрымнан үлмәбез, илтеп куйыйк әле,—дип хәл итте дә куйды берсе. Мотоциклны үзебез йоклаган печән эченә чумдырдык та, юлга чыктык...

... Чынлап та, Гамил абый белән нибары берничә мәртәбә генә очраштым мин. Бер очрашуыбыз Әлмәттә, аның фатирында булды. Мин анда Татарстан радиосы өчен сәгать ярымлык тапшыру әзерләү өчен барган идем. Әлмәт нефтьчеләре һәм, гомумән, бөтен Әлмәт турында. Әлмәткә бар да, зоопаркка барып та филне күрми кайткан сыман, Гамил Афзалны күрми кайт, имеш. Була алмый андый нәрсә. Дилбегә буе тапшыруның һичьюгы биш-алты минутын аңа багышламасам, Фәнзаман да була алмыйм мин.

Өйдә берүзе генә. Залның тап уртасында ындыр табагыдай киң өстәл. Тәртип белән өелгән китаплар, кәгазьләр, папкалар... Биш-ун минут чәй эчкән, сөйләшкән саен, туалет бүлмәсенә кереп, аның ике ягына куелган бәләкәч кенә, тәбәнәк кенә китап хәтле генә утыргычларга утырып, маңгайны-маңгайга терәп, кара яндырып тәмәке тартабыз. Шуны да аңладым: икебез дә бик әшәке тәмәкечеләр икәнбез...

Икеме-өчме шигырен магнитофонга яздырып, кайтып киттем. Чыгар алдыннан кулга бер бит кәгазь тоттырды.

—Укыган шигырьләремнең берсен алып кит әле. Хата җибәргән булсам, үзең укырсың эфирга,—дигән булды. Әлбәттә инде, аңа гына хас шаярту бу. Бирүе дә истәлеккә иде, билгеле...Шигырь үткәнне хурлап, бүгенгене мактаучылар турында. Болай тәмамлана:

*Хәзер безнең акыл керер чаклар,*
*Сакалымны сыпырып уйланам.*
*Безнең заманны да кемдер мактар,*
*Кемдер сүгәр әле бер заман...*

Беренче яздырганда ул аның иң ахыргы юлындагы «бер заман»ын юри «Фәнзаман» дип укыган иде. Кабат яздырган идек...

Ә инде аңа 70 яше тулар алдыннан янгыраш сәгатькә якынлык махсус тапшыру әзерләдем. (Димәк, 1991 нче елның маенда булган монысы.) Тапшыру яңгырагач, шалтыратты: «Тапшыруыңнан сиздем: чынлап та зурлап карыйсың икән син мина. Яратасың икән. Рәхмәт»,—диде дә сүзен бетерде.

Көтмәгәндә-өмет итмәгәндә сәер генә хатлары килә иде аның. Яратып кына төрттерә, елмайта торган хатлары... Бервакыт ул минем турыда бик озын (75 минут телевизор өчен кыска түгел инде) тапшыруны караган да болай дип язып җибәргән:

«Мин сине яшь егет кебегрәк күз алдына китерә идем әле, ә синең инде пеләшең Ленинныкы кебек икән. Хат язарга вакытың юк, телефон шалтыратырга яратмыйсың, ә чибәр кызлар арасында акыллы сүзләр сөйләп утырырга яратасың, бирсен Ходай! Сине телевизор экраныннан ике тапкыр күрдек, пеләшеңне сыйпап, акыллы сүзләр сөйләдең...»

Шушы хатыннан соң ике-өч кенә ай үтте бугай, мине Татарстан китап нәшриятына мөхәррир итеп чакырдылар. Күп авторларның китапларын әзерләп чыгардым дөньяга. Шуларның берсе—Гамил Афзалның «Август йолдызлары» дигән җыентыгы булды. Шул китабының минем хөкемгә эләгүен ишеткәч, шалтырата:

—Бик усал кыланма минем китапка карата. Кайбер шигырьләр ошамаса, чүп кәрҗиненә ташлама. Үземә кайтарырсың.

Китапны производствога (шундый тупас термин да бар китап басу эшендә) төшерер алдыннан бер килде Гамил абый. Каләм тигергән берничә төзәтүем

белән килеште, кайсыберләрен кире какты—үзенекен «кайтартты». Икенче килүе китап басылып беткәч булды. Үзенә тиешле «авторский экземплярларны» алды, бер портфель гонорар да алып, үзе әймешли, миллионер булып кайтып китте. (Россиянең кадерсез акчалары ул чакта миллионнар белән түләнә иде бит.)

Ә инде бер портфель акча тутырып кайтып киткәннән соң, озак та үтмәде, китабының бер данәсен автограф белән җибәргән:

*Мелла Фәнзаман әфәнде Баттал, минем китапны әйбәт чыгаргансың, зур рәхмәт!*
*Үзең дә бәхетле бул, усал бул!*

*Усалларны җыеп туй ясыйлар,*
*Усал урыны мәҗлес түрендә.*
*Юашларны җигеп су ташыйлар,*
*Юаш урыны ишек төбендә.*

*Ярый, Фәнзаман, сөйгәнең белән кавыш, матур кыз ал!*

*Гамил Афзал.*
*Октябрь, 95.*

Һәр адәм баласы кебек, ул да мәңгелек кочагына китеп барды. Хәзер, үзе әйтмешли, сакалны сыпырып уйланулар безгә—исәннәргә калды: ярый әле, кеше үлгәч, аның хезмәте һәм иҗаты да юкка чыкмый. Нинди бушлык калыр иде әдәбиятыбызда!.. Хәер... бушлык сизелер әле. Шуңа охшап тора әдәбият мәйданы... Башка бик күп мәрхүм әдипләрне «алыштырырдай» шагыйрьләребез, прозаикларыбыз бар—анысына шөкер. Әмма «яңа Афзал» күренми... Куллары белән билдән түбән капшанып көлдерергә тырышучылар күп-күбен, ләкин яшендәй уйнап, кояштай балкып, акыл һәм зирәклек өстәп торырдай, яшь аралаш та көлдерә-елмайта алырдай сатира һәм юмор иясенең туганы да, үскәне дә сизелми. Горизонтта да күренми... Андый яңа шәхес әле дистә еллар буе күренми торса да гаҗәп булмастыр. Чөнки Ходай Афзалны да Тукайдан соң ярты гасыр чамасы үткәч кенә дөньяга күрсәткән. (Мин биредә иҗат гомерен күздә тотам.) Татар әдәбиятының гадел һәм күренекле тәнкыйтьчесе Мансур Вәли-Барҗылының: «Чын сатириклар сирәк туа» дигән кыска гына җөмләсе дә бөтен хаклыгы белән искә төшеп тора. Хак әйтә чөнки.

Димәк, зур өмет багълап, көтәргә туры килер... Әгәр шул көтү чорында Гамил Афзалның саллы томнарын (исән чакта ул андый бәхетне күрмәде дә) нәшер итеп яшәмәсәк, туачак һәм туган яшь буыннарны чын сатира һәм юмор үрнәгеннән мәхрүм итә-итә вакыт үткәрсәк, вакытлы матбугатта үзен дә юбилейдан-юбилейга гына искә алсак, андый ук зур шәхеснең калкып чыкмавы да ихтимал. Шунысын да истән чыгармыйк: Гамил абый егерменче гасырның соклангыч лиригы да иде бит!

Әйе, безнең чор гаҗәеп зур затның яшәп, иҗат итеп китүенә шаһит булды. Ул әле милләтне гасырлар буе елмаю, көлү аша сокландырыр:

*Бөтен халык , Алла юк, дип кычкыра,*
*Димәк, бер вакантный урын буш тора,—*

кебегрәк бихисап үткен кәлимәләре белән җан тонуларын юып алыр, Ходай биргән дөньяның матурлыгы белән рухландырыр, яшәүгә—куәт, күңелләргә дәрт өстәп торыр. Ләкин әледән-әле шул дөньяга—табигатькә каты бәрелмәскә, сак булырга да өйрәтер:

*Кош баласы, һәр агачы, һәр бөҗәге, һәр үлән*
*Мөлдерәп күзгә карыйлар моң белән, рәхмәт белән.*

Бу гасырда ата-баба гомер иткән изге җирдән йөз чөерүчеләр Афзал заманасына караганда да күбрәк булырга охшый. Инде хәзер үк: «Мин Америкада яки Төркиядә яшим! Минем ватан монда! Татарстанда ни калган?!» дип шапырынучылар очрап, шул илләрдән шалтыратып масаючылар ишәя. Алар мактана торсын, ә туган иленә

тугъры милләттәшләр аларның кем икәнен белә торсын. Анысын да зирәк һәм «мыжык, холыксыз карт» Гамил Афзал әйтеп торыр:

*Бар хаиннар лаф оралар: икенче ватан, диләр,*
*Икенче ватан җирендә типтереп ятам, диләр.*
*...Бер ватаннан бер ватанга чабып йөрисең килә,*
*Табыш алып анда-санда, акча күрисең килә.*

Замана нинди генә сәясәтләр белән үзгәреп тормасын, хак татарның хак Ватаны бер генә—Алтын Урда чикләренә җәелгән Татар иле генә!

Исән чагында ул күргән, ул бәяләгән күнел болгаткыч чынбарлыкны, ачы хакыйкатьне безнең улларыбыз һәм оныкларыбыз гына түгел, ерак торыннарыбыз да күрәчәк әле:

*Хаклык эзләүчеләр сирәк-мирәк,*
*Шөһрәт эзләүчеләр җитәрлек.*

Ул үзе берчакта да шөһрәт эзләмәде. (Җәяләр эчендә генә булса да әйтеп китәсе килә: Татарстан житәкчеләре Тукай бүләген һәм «Халык язучысы» дигән исемне кайчак лаек шәхесләргә дә биргәләделәр. Гамил абый шуларның һәр икесенә ия булды.) Аның иҗаты арзанлы шөһрәт ияләреннән биниһая югарырак иде. Ул аларны бары тик кыядагы бөркет аландагы вак-төяк кошчыкларны күзәткәндәй генә күрде. «Заман мондый, заман шундый» дип кенә иман да үзгәртмәде, кайбер каләмдәшләре кебек кырыкмаса-кырык партияләргә дә тагылмады. Аның ин зур фиркасе дә, изге кыйбласы һәм галиҗанәбе дә үз милләте иде. Хәер, үзенең кемлеген үзе дә аңлап яшәде ул:

*Заман куша, диеп ялгышмадым,*
*Намуссызлар белән ярышмадым.*
*Баш күтәрми, көн-төн эшләдем,*
*Олы кибән булды табышларым.*

Әйе, тәмле, хуш исле, тук башаклы кадерле кибәндәй олы иҗатын халкына бүләк итеп китте Афзал абыебыз. Бу «кибән» исә чын һәм ихлас иҗатка сусавы бер чакта да басылмаячак милләтебезгә гасырлар буе җан азыгы булырлык.

... Аның әлеге «Август йолдызлары» китабын әзерләп бетереп, үземнән өстәрәк утыручы наширләрдән дә «рөхсәт» кулы куйдырып, басарга дип хәл иткән көннәрдә Гамил абыйның бүлмәмә килеп керүе дә хәтердә калган. Карашы сәеррәк тә, сынаучанрак та тоелды. Түш кесәсендәге кәгазьләрен барлый торгач, шуларның берсен өстәлемә җәеп салды:

—Соң булмаса, менә бу шигырьне өстәргә иде китапка, мелла Фәнзаман. Шунын ятим булып калмавын телим.

Андый чакта, гадәттә, мөхәррирләр:

—Кычытмаган жирне кашымыйк инде. Китап төшкән—эш беткән,—диләр. Ул сүзне мин дә әйткәли идем авторларга. Ләкин аңа каршы килергә базмадым. Ул шигырьдә Гамил абыйның девизы бар кебек тоелды миңа:

*Җырла,*
*ела,*
*сөен... сүзләреңдә*
*Бер мыскал да ялган булмасын!*

Хәтта үз-үземне алдардай фикер дә килде әле башка: янәсе, миңа әйтергә теләгән сүзен язмача тоттыруы түгелме бу, алай-болай?! Юктыр... Мин андый ук мәртәбәгә лаек түгелмендер... Бу юллар—замана әдипләренең барысына да васыять булырлык. Бөтенебезгә дә житәрлек! Һәркайсыбызга кирәк!

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Азнакай

Татарстанның көньяк-көнчыгышында кайчандыр авыл булып, аннары шәһәр статусы алган торак пунктларның берсе—Азнакай шәһәре. Аның шәһәр булып формалашу чоры турыдан-туры төбәктә нефть һәм газ чыгару белән бәйле. Казаннан ул 376 чакрым ераклыкта урнашкан.

1965 елдан Азнакай эшчеләр бистәсе исәпләнә, ә 1987 елда ул республика күләмендәге шәһәр статусы алды. Мәйданы—15 кв км. Самара губернасы авыллары атамаларын исәпкә алган исемлектә (1859 ел) Азнакай авыл буларак күрсәтелгән. Мәнәвез суы ярына утырган бу авылның 213 йортында 549 ир-ат һәм 554 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән.

1900 елгы тарихи документлардагы мәгълүматларга караганда, авылда арыш, солы, карабодай, бодай һәм тары иккәннәр. Күп төрле һөнәр ияләре, аерым алганда, балта осталары, йон тетү һәм киез басучылар, тегүчеләр, тимерчеләр, ташчылар һәм чабатачылар яшәгән.

Азнакай—автомобиль юллары узелы. Анда нефть чыгару тармагыннан тыш, машина төзү һәм металл эшкәртү заводлары, шулай ук ипи пешерү һәм май эшкәртү заводлары эшли. Шәһәрдә 10 гомуми белем бирү мәктәбе һәм 5 китапханә бар.

Азнакай районы 1965 елның 12 гыйнварында оеша. Районда 79 торак пункт исәпләнә. Район жирләренең 18 процентын урманнар били.

Азнакай олылары шәһәр атамасын кеше исеме белән бәйләп аңлаталар. Авылны Азнакай баба нигезләгән дип сөйлиләр.

Азнакай янындагы күренекле тау—Чатыр тау. Аның биеклеге 334 метр. Элек һәр елны май аеның дүртенче атнасы ахырында тирә-юнь авыллардагы яшьләр Чатыр тау итәгендә жырлап-биеп күңел ачканнар, бизәнеп-ясанып бер-берсен күзләргә килгәннәр.

Азнакай янында тагын Ибрай тавы бар. Аның турында халык болай сөйли. Оренбург өлкәсенең Ибрай авылыннан килеп, гомер буе ат көтүе көткән Таһир исемле кеше тауда чишмә казып чыгарган. Хәзер ул чишмә Таһир чишмәсе дип йөртелә. Бүгенге көтүчеләр суны шушы чишмәдән алалар. Ибрай тавының түре Очлы тауга барып ялгана. Бу өлеше Караңгы кул дип тә атала, чөнки монда агачлар бик куе, кап-караңгы булып торалар.

Кыска кул тавында да чишмәләр чыга. Кыска кул тавы арткы өлешеннән Урыс кулына ялгана. Биредә урыслар хәзинә эзләп кунып-төнеп ятканнар, имеш. Әле дә алар казыган жирләрдән вак-вак зәңгәр ташлар чыга икән. Анда бүгенге көнгә кадәр чирәм дә үсмәгән. Бу хикәяттә чынбарлык чагыла булса кирәк. Ихтимал, бирегә кайчандыр бакыр эзләүчеләр килгән булгандыр.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Азнакай төбәгеннән күренекле кешеләр чыккан. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары Нәҗибә Ихсанова, Әзһәр Шакиров, язучы Марсель Галиев, Әсәй авылы кызы шагыйрә Флера Гыйззәтуллина, язучы Нур Әхмәдиев, шагыйрь Илдус Гыйлаҗев, популяр җырчы Зәйнәп Фәрхетдинова, Татарстанның халык депутаты Фәндәс Сафиуллин, галим Альберт Яхин, композитор Әнвәр Шәрәфиев, Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисткасы, Чатыр тау итәгендә туып-үскән җырчы Миңлегөл Зәкиева, балалар язучысы Әнәс Кари, Рәмзия Закирҗанова һ.б. Азнакай ягыннан.

## Акбүре

Акбүре авылы Яна Чишмә районында, район үзәге Яңа Чишмә авылыннан 21 чакрымда, Чистайдан 79 чакрымда урнашкан.

Авыл исеме 1994 елда Акбүре дип үзгәртелә. Ана кадәр ул Татар Волчье дип аталган.

XVIII йөз мәгълүматларын эченә туплаган Д.А.Корсаков белешмәсендә авыл искә алынмый әле. Бары тик Рус Волчье авылы гына теркәлгән. 1859 ел мәгълүматлары теркәлгән белешмәдә Татар Волчье авылы искә алына. Андагы 38 хуҗалыкта 113 ир-ат һәм 108 хатын-кыз теркәлгән. Мәчет эшләгән.

Рус Волчье авылына XVIII йөз ахырында нигез салына. Анын исеме шактый сәер янгырый. Авыл атамасының барлыкка килүенә карата олылар хәтерендә шундый легенда-риваятьләр сакланып калган. Имештер, бу якларда төрле ерткыч җәнлекләр яши торган калын урманнар үскән. «Волчий билет» алган кешеләр, кемнеңдер эзәрлекләвеннән качып, бу якларга килеп чыкканнар, урман кискәннәр, үзләренә нигез корганнар һәм шунда яши башлаганнар. «Волчий билет»лы кешеләр авыл атамасын да шул сүздән алганнар.

Ә икенче легендада исә, беренче нигез салынасы урында бүре оясы булган, шуна күрә булачак авылга «Волчий» дип исем кушу турында сүз бара.

Авылда татар, рус һәм чуашлар бергәләшеп яшиләр. Бер урамда татарлар гына торган, аны урыслар хәзер дә Татар урамы дип йөртә.

XIX йөз башларында татарлар: «Балаларыбыз урыс белән катыша» дип, аерылып чыгарга уйлыйлар. Урыслар болын ягын күрсәтәләр, ә татарлар урман ягын сайлыйлар. Агачларны кисеп һәм төпләп үзләренә йортлар салалар. Болар 11 татар гаиләсе, араларында мөселман диненә күчкән 1 гаилә чуаш була. Шулай итеп, яңа татар авылы барлыкка килә. Ул Рус. Волчье авылыннан аерылып чыга һәм Татар Волчье дип атала.

Рус Волчье авылы яныннан Волчанка суы ага. Елга атамасы да «волк» сүзеннән алынган, билгеле.

Югарыда әйтелгәнчә, 1994 елда, аерылып чыккан авылның Татар Волчье атамасы рәсми рәвештә Акбүре дип үзгәртелә. Акбүре исеме белән авылга багышланган җыр да чыгарылган. Халык аны яратып тыңлый, яшьләр матур итеп җырлый. Ләкин халык яңа исемгә әлегә кадәр күнегеп бетә алмый, авылны «Тат. Волчье» яисә «Булчи» дип атавын дәвам итә.

Авыл янында гына Житенле суы ага. Халык аны Житенне дип атый. Элек бу елгада халык житен батырган. Елгасы хәзер бик сай, ә ярлары тирән һәм һаман ашала бара. Бу тирәдәге кырлар да Житенне кырлары дип йөртелә. Житен тавы дип йөртелгән тау да бар. Аны менгәч, Кизләүләр өсте дип аталган урынга барып чыгасың. Элек анда чишмәләр дә аккан. Чишмә буйларында олылар һәрвакыт дога укыганнар, теләк теләгәннәр, чишмәләрне чистартып һәм карап торганнар.

Җәй көннәрендә көннәр бик корыга китсә, авыл халкы монда янгыр теләргә барган. Бу йола үзенә күрә бер зур һәм күнелле бәйрәмгә әверелгән. Йола башкарыласы көн алдан билгеләнгән. Авыл халкы 3—4 укымышлы әбигә алдан сәдака китергән. Тавык, ярма, ипи, чәй-шикәр, он, бәрәнге һ.б. азык-төлекне билгеләнгән көндә атларга төяп Кизләүләр өсте янына китергәннәр.

Якындагы урманнан утын алып төшкәннәр, учаклар ягылган, тавыклар суелган һәм янгыр боткасы пешерелгән. Карт-карчыклар, бала-чагаларга кадәр бөтен авыл халкы ботка белән сыйланган. Аннан соң олылар укыганнар, Алладан янгыр сораганнар, бала-чага, яшүсмерләр кизләүдән су алып, бер-берсенә су сибешкәннәр.

Авылда Түбән оч, Югары оч, Урта урам, Хөрти урамы бар. Яңа урамнарның берсе Котылдык дип атала. Совхоз бу урамда яңа йортлар төзи һәм аны яңа өйләнешкәннәргә бирә. Шуңа күрә шаянрак кешеләр аны мәзәк итеп Котылдык, ягъни каенана һәм каената белән торудан котылдык дип, көлеп әйткәннәр. Хәзер инде ул урам бер көлкесез Котылдык урамы дип йөртелә.

## Аккүз

Аккүз авылы Татарстанның көнчыгышында, район үзәге Актаныш эшчеләр бистәсеннән 31 чакрымда, якындагы тимер юл станциясе Нефтекамск шәһәреннән—91, Әҗәкүл пристаненнан 36 чакрым ераклыкта урнашкан. Аккүз—җирле үзидарә советы үзәге. Аңа Ахун, Яңа Кадермәт һәм татарлар белән руслар катнашып яши торган Михайловка бистәсе керә.

Элек Аккүзне Югары Ахун дип, ә күршедәге Ахун авылын Түбән Ахун дип атап йөрткәннәр.

Аккүз авылы янында археологлар бура культурасына мөнәсәбәтле торлак (стоянка) тапканнар.

1870 елгы мәгълүматларга караганда, Аккүздә 120 йорт булып, халык саны 592 кеше, шуларның 306 сы ир-ат, 286 сы хатын-кыз булган; Ахундагы 51 йортта 312 кеше, 165 ир-ат, 157 хатын-кыз яшәгән. Ике авылда да берәр мәчет, берәр мәдрәсә эшләгән. Хәзер Аккүз авылындагы 300 хуҗалыкта 800гә якын кеше яши.

Бабайлар сөйләвенә караганда, авыл халкы хәзерге Башкортостанның Җәнәй авылыннан күчеп килеп утырган. Аның элекке Ахун атамасы Ахун исемле бай кешегә бәйләнешле икән.

Элек авылда җирсез крестьяннар яшәгән, аларны типтәрләр дип йөрткәннәр. Алар байларга ялланып хезмәт иткән. Нури бай хуҗалыгында авыл хуҗалыгы машиналары булуы билгеле. Бу бай йортының аскы каты әлегә кадәр сакланып калган, элегрәк ул мәктәп хезмәтен дә үтәгән. Авыл, тулаем алганда, Алексей Дядюхин дигән рус алпавыты кулында булган. Авылда аның тегермәннәре, машиналары булган. Аның тегермән ташлары бүгенгә кадәр сакланган әле. Ул ташлар авыл халкының йорт нигезләренә салынган.

Алексей Дядюхин кызу канлы, каты куллы кеше булган дип сөйлиләр. Ул бик яхшы нәселле атлар асраган. Бер мәлне үзенә килгән бер кунак белән Актаныштан Аккүзгә атта чабып 45 минутта кайтып җитәргә бәхәсләшә бу. Әмма ат 45 минут эчендә кайтып җитә алмаган. Шуннан соң ул атыннан төшә дә, кесәсеннән револьвер алып, аны атып үтерә.

Авыл кырыеннан Сөн елгасы ага. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Сөн буенда 26 авыл утырган һәм аларда 10934 кеше яшәгән.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# М

**МАННАПОВ** Шамил Мәгыйзь улы (1.1.1938, Әлки р-ны Татар Мулла ав. туа), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Казан ун-тын тәмамлагач (1965) «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» г-талары редакцияләрендә хәбәрче булып эшли (1977-86). 1986-89 да Татарстан кит. нәшриятында, 1989 дан— «Казан утлары» ж-лының проза бүлегендә мөхәррир вазифаларын башкара. М. татар поэзиясенә 1960 еллар башында солдат хезмәтенә багышланган, студентлар тормышын, яшьләр проблемаларын күтәргән шигырь һәм поэмалары белән килеп керә. Ул «Яшьтәшләрем» (1967), «Хәят көндәлеге» (1970), «Тамырлар» (1972), «Тугрылык алиһәсе» (1976), «Кайту» (1981; русчага тәрҗемәдә «Возвращение» М., 1982), «Апрель авазы» (1987), «Жиргә сыенам» (1990), «Өндәге төшләр» (1997) «Тормыш сиратлары» (2008) исемле шигъри жыентыклар һәм «Әти урманы» (1979), «Ачы какы» (1992), «Мәңгелек елмаю» (2001) дигән хикәя жыентыклары авторы. М. үзенең әсәрләрендә тормышяшәешне замандашларының уй-кичерешләре аша чагылдырырга тырыша, алар лирик-публицистик яңгырашлы, оптимистик рухлы. Матбугатта әдәбитәнкыйть мәкаләләре еш кына басылып килә. Жыр тестлары авторы.

Әсәр.: Тормыш сиратлары. К., 2008.

Әд.: Баянов Ә. Даһилык дәгъвалامыйча гына // Казан утлары. 1997.№12; Вәли М. Янган саен өмет янара // Мирас. 1998. №1.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАНСУР** (Мансуров) Зыя Мансур улы (17.12.1916, хәзерге Башкортостан Респ-касы Дүртөйле р-ны Житембәк ав.—11.11.1965, Казан), шагыйрь.1937 елдан Дүртөйле р-нының «Ярыш» г-тасы редакциясендә корректор. 1946 дан Дүртөйле район үзәгендә радиотапшырулар дикторы, 1948 дән Илеш районы Мәдәният йортынын директоры булып эшли. 1949 дан Казанда яши: Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире (1952-53), «Чаян» ж-лында әдәби хезмәткәр (1953-55). «Язгы ташкыннар» (1950), «Ак розалар» (1963), «Этаплар китабы» (1966), «Үрләргә күнелем гашыйк» (1968) исемле шигъри жыентыклар авторы. Шигырьләренә тәэсирлелек, халыкчан гадилек һәм нечкә лиризм хас. Шагыйрь туган як табигатен, аның кешеләренен күнел дөньясын, яшьлеккә мәхәббәт романтикасын яратып тасвирлый. Юмор-сатира М. иҗатының көчле якларыннан берсе. Сатира жанрының төрле формаларына мөрәҗәгать итеп, ул карьерист, бюрократ, исерекләр кебек типларны тәнкыйтьли. «Омтылу» (1951), «Озынколак баласы Елак-Мылак» (1958) кебек поэма-әкиятләре балалар өчен язылган. Рецензияләр, әдәби-тәнкыйть һәм әдәбият белеменә караган мәкаләләре «Шигъри осталык турында» (1965) жыентыгына тупланган. Бөек Ватан сугышында катнаша. Икенче дәрәҗәдәге Ватан сугышы ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма шигырьләр. К., 1959; Сайланма әсәрләр. К., 1972; Лейсан—весенний дождь. М., 1972.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МАНСУРОВ** Зиннур Мөжип улы (15.7.1949, Мамадыш р-ны Түбән Ушмы ав. туа), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1974-83 тә «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе, 1983-86 да «Казан утлары» ж-лы редакциясендә әдәби хезмәткәр, 1986-90 да ТАССР телевидениесе һәм радиотапшырулары дәүләт к-тында баш редактор, 1990-95 тә ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, 1995тән «Мәдәни жомга» г-тасының баш мөхәррире. «Кул бирәм» дип аталган беренче шигырь жыентыгы 1979 елда басылып чыга. М.нын поэзиясе хисләренең ихласлыгы, тормыш-яшәешне фәлсәфи мәгънәдә аңлатуы белән аерылып тора. Намуска, мәхәббәткә тугры калу турында, публицистик яңгырашлы, көндәлек тормыш вәзгыятенә караган шигырьләре «Йөз суы» (1983), «Тысячелистник» (М., 1983), «Ваем» (1988), «Душицы белый запах» (1991), «Яшәү үзәне» (1998), «Күнел сәфәре» (1999), «Жәрәхәтле йөрәк жылырак» (2003) жыентыкларын тәшкил итә. «Юлын белгән арымас» (1989), «Күнелдә фидаи яшәсә» (2006) дигән публицистик мәкаләләр жыентыклары төрле буын шагыйрьләре

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

ижатына, әдәбият, сәнгатьнең гомуми мәсьәләләренә, ижтимагый-сәяси тормышның четерекле темаларын яктыртуга багышланган. Аның күп кенә шигырьләре рус, инглиз, төрек, казах телләренә тәрҗемә ителгән. ТРның Мактау грамотасы белән бүләкләнгән (1999). Г. Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2009).

Әд.: Галиуллин Т. Яшәү мәгънәсе // Гомер учагы. К., 1991; Гаташ Р. Сәфәрләргә чыксаң белерсең // Казан утлары. 2000. №4; Гафиятуллина Н. Хәтер сызлануы // Казан утлары. 2004. №1.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАНСУРОВ** Фәнил Хәбибулла улы (3.12.1931, хәзерге Башкортостан Респкасы Чакмагыш район үзәге—30.5.1995, Уфа шәһ.), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлагач (1957) Башкортостанның Бүздәк район г-тасында бүлек мөдире (1957-60), Чакмагыш р-нынын Калмашбаш сигезьеллык мәктәбендә укытучы (1960-63), «Агыйдел» (Уфа) ж-лында әдәби хезмәткәр (1963-67) булып эшли. 1968 елдан Казанда: Татарстан кит. нәшр. дә мөхәррир (1968-71), «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе (1972-76). 1983 тән кабат Уфада: «Өмет» г-тасы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире (1991-94). «Юл башы» исемле беренче повесте 1961 елда «Агыйдел» ж-лында басыла. Давыллы революция вакыйгаларын һәм Бөек Ватан сугышы елларын, сугыштан соңгы авыл тормышын сурәтләгән повесть һәм хикәяләре «Хәерле юл» (1969), «Яктытауда бүз тургайлар» (1973), «Ак буран» (1977), «Юл чатында көмеш әрем» (1978) «Агыйделкәй алкын» (1991) җыентыкларына тупланган. «Айгалаш кыйссасы» повесте гражданнар сугышы елларында шагыйрь Шамун Фидаиның тормыш юлына багышланган. Гомеренең соңгы елларында иҗат иткән «Солтан Кирамәт» романы (1993) тоталитар җәмгыять шартларында фаҗигале шәхес язмышы турында сөйли.

Әд.: Тимергалина Р. Башкортостан язусылары. Өфө. 1968.

**МАЯКОВСКИЙ** Владимир Владимирович (7.7. Грузия, Багдади а.—14.4.1930, Мәскәү), шагыйрь, драматург. «Штанлы болыт» («Облако в штанах», 1915), «Владимир Ильич Ленин» (1924), «Яхшы!» («Хорошо!», 1927), «Бөтен тавышка» («Во весь голос», 1930) һ.б. поэмалар, «Кандала» («Клоп», 1928), «Мунча» («Баня», 1929) һ.б. пьесалар, шигырьләр авторы. Казанда өч тапкыр була. Беренче килүендә 1914 нең февралендә Дворяннар җыены залында үзенең матурлыкны ничек анлавы турында лекция укый. Икенче килүендә 1927 елның гыйнварында Казан ун-тында лекция б-н чыгыш ясый, «Владимир Ильич Ленин» поэмасыннан өзекләр укый. Алган тәэсирләрен «Яңа туган башкалалар» («Рождённые столицы», 1927) мәкаләсендә чагылдыра: Казан һ.б. шәһәрләр «... революция нәтиҗәсендә башкалалар булып киткән шәһәрләр үсәләр, төзеләләр һәм, иң мөһиме, ирекқә ирешкән илнең мөскәкыйль мәдәнияте б-н сулыйлар» дип яза. «Союз шәһәрләре буйлап» («По городам Союза», 1927) шигыренең «Университет—Казанның горурлыгы» дигән фразасы канатлы сүз булып китә. 1928 елның башында М. кабат Казанга килеп китә: 20 гыйнварда «Колосс» к-т-рында язучының яңа, эшчеләр аудиториясе алдындагы җаваплылыгы турында лекция б-н чыгыш ясый, 21 ндә Казан ун-тының актлар залында «Владимир Ильич Ленин» поэмасыннан өзекләр укый, 23 ндә «Бик яхшы!» поэмасын, әдәбият турында доклад укый, «Казанское подворье» кунакханәсендә җирле шагыйрьләр б-н очраша. Бу очрашуда өч тапкыр—чуаш, татар һәм мари телләрендә М.ның «Сул марш» шигыре яңгырый (1927 дә Г.Кутуй тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә). Бу очракны М. «Казань» (1928) шигырендә искә ала: «Килеп керә татар: / Мин татарча / «Сул марш»ны / укыйм / сезгә» ди». 1923 тә Казан сәхнәләрендә аның «Мистерия Буфф» пьесасы, «150000000» поэмасы буенча инсценировка, 1967 дә «Мунча» пьесасы куела.

Әс.: Сочинения: В 2 т. М., 1987.

Әд.: Лавут П.И. Маяковский едет по Союзу. М., 1969; Бушканец Е.Г Маяковский в Казани // Литературный Татарстан. К., 1950.

*Л.Е.Бушканец.*

**МӘДХИЯ** (гарәп. мактау, ода), шәрекъ поэзиясе жанры; тантаналы мөһим вакыйгалар яки күренекле кешеләрнең эш-гамәлләрен данлау йөзеннән язылган лирик шигырь. М.нын башы борынгы чорлардан килә. Ана объектны идеаллаштыру, гиперболизация, күтәренке рух, купшы стиль хас. М.нең күбесе шигъри (бәйт, дүртъюллыклар), сирәк—кушма (проза һәм шигырь) формасында, ә кайберләре—рифмалы проза б-н (Кадыйр-Гали-бәкнең «Тәгърифе Борис»ы—«Борисны [Годуновны] мактау») язылган. Эчтәлеге һәм формасы б-н касыйдә һәм мәрсиягә якын тора.

М. татар әдәбиятында киң таралган жанр: Котбның «Хәсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Мөхәммәдъярның «Нуры содур» әсәрләренең багышлаулары, Хөсәен бине Локманның «Мәдхе Мөхәммәтҗан», Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан», Р.Фәйзуллинның «Төнге мәдхия» исемле шигырьләре мисал булып тора.

Әд.: Миннегулов Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миннегулов.*

**МӘГАРРИ** Әбүл-Галә (973, хәзерге Сүрия, Мәгаррәт ән-Нөмән ш.,—1057 яки 1058, шунда ук), гарәп шагыйре һәм фикер иясе. Тумыштан сукыр. Белемне атасыннан, Багдад һәм Хәләб дин белгечләреннән ала. Фәнни трактатлар, фәлсәфи-гуманистик эчтәлекле шигырьләр, тезмә әсәрләр авторы. Танылган шигъри җыентыклар арасында «Рисаләт әл-гофран» («Гафу итү хакында юллама»), «Сикт әз-зәнд» («Чакма таш очкыны», Каһирә, 1869), «Әл-лөзумийят-лөзум мә лә ялзам» («Мәҗбүриятлек», Каһирә, 1891 яки 1892). Аның пантеистик, материалистик һәм атеистик күзаллаулары үрелеп барган дөньяга карашының каршылыклары иҗатында чагылган. Шагыйрь яшәү һәм үлем, адәм баласы һәм Аллаһ, яшәү мәгънәсе кебек мәңгелек проблемалар хакында уйлана. Гуманист буларак, аңлау-төшенү нигезен тәшкил иткән кеше акылына дан җырлый, ләкин ш.у. вакытта хакыйкатьне танып булмый дип саный. Социаль гаделсезлекне тәнкыйтьли, ә үзе аны яшәү рәвешенә Аллаһ тарафыннан салынган хакыйкать дип саный. Һәрбер дингә карата түземле карашка өнди, руханиларның кимчелекләрен, юк-барга ышануны, абруйлы кешегә мөкиббән китүне тәнкыйтьли. Югары әхлаклы кеше буларак, яшәү мәгънәсен халыкка хезмәт итүдә күрә, һәр эштә чаманы белү һәм тыелуга чакыра. Чәчмә әсәрләренә фикер һәм хис сафлыгы хас. «Мәҗбүриятлек» әсәрендә үзен гуманист, социаль гаделсезлекне тәнкыйтьләүче буларак таныта. Теле катлаулы, ләкин ш.у. вакытта камил, аерым очракларда сүз уйнатып ала. М.нең иҗаты гарәп, фарсы һәм төрки, ш.и. татар. әдәбиятларына (Хисам Кәтиб, Сәйф Сараи, Ш.Зәки, Дәрдемәнд, Н.Думави) зур йогынты ясый. 20 йөз башында шагыйрь идеяләре аеруча популяр булып китә. Аның турында Р.Фәхретдин, Н.Думавилар яза, әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителә. 1907 дә Казанда М.Бигиевнең искәрмәле тәрҗемәсендә «Әл-лөзумийят»е басыла. 1908 дә «Әдәбият гарәбия илә гыйльме исламия» исемле китабында М.Бигиев М.нең тормышы һәм иҗаты турында мәгълүматлар бастыра.

Әсәр.: Әл-лозумийят: 2 кис. К., 1907; Стихотворения. М., 1971.

Әд.: Широян С.Г. Великий арабский поэт и мыслитель Абу-ль-Аля аль-Маарри. М., 1957; Шидфар Б.Я. Абу-ль-Аля аль-Маарри. М., 1985; Фәхретдин Р. Әбүл-Галя әл-Мәгарри. Оренбург, 1908.

*Х.Й.Миннегулов.*

**МӘҖИТОВ** Зәет Мәҗит улы (25.8.1927, Минзәлә кантоны Иске Айман а.—13.5.2000, Казан), шагыйрь, әдәбият галиме, филол. фәннәр кандидаты (1955), ТАССР нын атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). 1951 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1954-57 дә «Совет Татарстаны» г-та редакциясендә, 1957-89 да Казан ун-тында укыта. Ф.Кәрим тормышын һәм иҗатын өйрәнә. Хезмәтләре Бөек Ватан сугышы поэзиясенә карый. «Таңгы җыр» (1953), «Чәчәк бирәм сина» (1959), «Ярсу Ык» (1967), «Күңел җыры» (1972), «Рәхмәт яусын» (1977), «Теләк» (1984), «Кер бакчама» (1999) исемле шигъри җыентыклар авторы. М. лирикасына үзенә бер төрле аһәң, моң хас. Аның лирик герое—бар булганга үзенең җаваплылыгын сизеп яшәүче ватанпәрвәр. М. татар поэзиясенең лиро-эпик жанр формаларының үсешенә сизелерлек йогынты ясады, үзен сәнгати пейзаж остасы итеп танытты.

Әсәр.: Фатих Кәрим: Тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. К., 1963; Заман сулышын тоеп: Бүгенге әдәбият турында. К., 1967 (соавт.); Татар поэзиясе Бөек Ватан сугышы елларында. К., 1989.

Әд.: Гаташ Р. Ир җанында ни булмас! // Казан утлары. 1997. № 8; Харрасова Р.Ф. Заит Мазитович Мазитов (1927-2000). К., 2010.

*Р.Ф.Харрасова.*

**МӘҖЛИСИ** (15 йөз ахыры—16 йөз башы), төрки шагыйрь, татар арасында киң таралган 4 мең шигъри юлдан торган «Кыйсса-и Сәйфелмөлек» мәхәббәт дастаны авторы. Сюжеты «Мең дә бер кичә» җыентыгының шул исемдәге әкиятенә барып тоташа. Беренче тапкыр 1807 дә Казанда басыла, соңыннан да күп мәртәбә нәшер ителә. М. дастанына нигезләнеп татар шагыйре Баһави («Бүз егет»), казакъ шагыйре Йосыфбәк Шәйхелислам («Кыйсса-и Сәйфелмөлек-Бәдигыльҗамал», 1876) әсәрләрен язалар.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 том.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Индүс
Таһиров

# ТАТАР НИЧЕК БАРЛЫККА КИЛГӘН?

## Атамабыз үзебезнеке

Фәндә инде күптәннән бирле татар халкының чыгышы турында бәхәс бара. һәм беркайчан да туктамастыр. Бу хакта 1910-11 елларда «Шура» һәм «Ан» журналлары үз битләрендә махсус рәвештә фикер алышулар да оештырганнар. Шул вакытта чыккан дистәләгән татар газета һәм журналларында да бу проблемага багышланган күпләгән материаллар басылган. Мәсьәләнең асылы «без кем?» дигән сорауга кайтып кала.

Кайбер галимнәр бүгенге татарлар болгарлардан килеп чыккан, атамалары аларга читтән тагылган дип саный. Татарларны Алтын Урдадан чыккан диючеләр дә бар. Заманында күренекле тарихчыбыз Газиз Гобәйдуллин болай дип язган: «Дөньяда төрле этник элементлардан формалашмаган халык юк икәнлеге мәгълүм, һәрбер нәрсәне тик аны тәшкил иткән элементларын сүтеп тикшереп кенә анлап була. Халык та шулай. Әгәр дә без теләсә кайсы системаның элементларын өйрәнмәсәк, аны һич кенә дә аңлый алмаячакбыз. Аңлау ул—аның тормышын, культурасын, башка үзенчәлекләрен, аның тарихын белү дигән сүз». Мин шушы зур галимнең фикеренә тулысы белән кушылам һәм, беркем белән дә бәхәсләшмәстән, укучыларга үз уйлануларымны тәкъдим итәм. Фикерләрем белән ризалашучылар да, ризалашмаучылар да булыр. Мин тулы хакыйкатькә дәгъва кылмыйм, берәүгә дә үз фикеремне көчләп тагарга җыенмыйм.

Татар атамасы хакында мин Кытайда туган, андагы Өремче шәһәрендә кытай телендә университет бетергән, бүгенге көнне Алма-Атыда яшәүче милләттәшебез Мөнир Ерзинның фикердәше. Мин шушы туганыбыз кебек үк аны безгә кемдер ябыштырмаган дип саныйм. Мөнир абый, Э. Х. Паркерның 1895 елны чыккан һәм кытай теленә тәрҗемә ителгән «Тысяча лет из истории татар» исемле китабына таянып, моннан ике мең еллар элек үк һуннар белән янәшә яшәгән бер кабиләнең татар дип аталганлыгы турында яза. Паркерның исемен атаганда аның кем икәнлеге хакында белешмә кирәк булса кирәк. Чөнки милләтпәрвәр шәхес, мәшһүр дипломат һәм тарихчы Йолдыз Хәлиуллин язганча, татарларга багышланган хезмәтләре аркасында дөньякүләм шөһрәт казанган бу галимне бары татарлар үзләре генә ни өчендер өнәп бетермиләр, хәзергәчә игътибарсыз калдыра киләләр.[1] Э. Х. Паркер 1849 елда туып, 1926 елга кадәр яшәгән инглиз галиме. Күп еллар буена Кытайда дипломатик хезмәттә булып, камил рәвештә кытай телен үзләштереп, татарларга караган кытай чыганакларын ныклап өйрәнгән, милләтебезгә карата ихтирам белән сугарылган шәхес бу. Аның әнә шул инглиз телендәге китабын 2003 елда русчага АКШта яшәүче күренекле галим Вил Мирзаянов тәрҗемә иткән, һәм 2003 елда «Идел-Пресс» аны бастырып та чыгарды. Мөнир абый файдаланган кытайчага

[1] Юлдуз Халиуллин. Кто расшифрует татарский след. Древние тюрки— вдохновители создания Великой китайской стены.— Независимая газета, 2009, 10 июня.

тәрҗемәсе исә 1937 елда ук чыккан. Тәрҗемәчесе—мәшһүр галим Шан-Да аны төрле шәрехләр-аңлатмалар белән баеткан. Һәм шунлыктан аның кытайча вариантында татарларның татарлыгын исбатлаган фактлар тагын да күбрәк.

Бу китапта төркиләрнең тамыр башы татар икәнлеге исбатланган. Кытайлар «төрек» термины хасил булуга кадәр мең ел элек үк «татар» сүзен куллана торган булганнар. Китапта тупланган фактлар шушы исемдә кечкенә генә бер кабилә булып, соңрак аның исеме барлык тугандаш кабиләләрнең, шул исәптән хуннарның да, җыелма исеменә әверелгәнлеге турында сөйли. Кытай чыганаклары бу җыелма тугандаш кабиләләрне, алар төзегән дәүләтләрне «хиен-ху» дип тә атаганнар. Шул ук вакытта аларга карата «Татарстан», «татар» дигән төшенчәләрне бик еш кулланганнар.[2] Ә «төрки» сүзе тик безнең дәвернең Ү гасырында гына әйләнешкә кергән.[3] XI гасыр филологы Мәхмүд Кашгарлы татарларны 20 төрки кабилә арасында күрсәткән һәм алар бәҗәнәкләр, башкортлар, кыпчак һәм кыргызлар кебек үк төрки телдә сөйләшәләр дип язып калдырган.[4] 1160-1223 елларда яшәгән гарәп тарихчысы Ибн-Асир шулай ук татарларны төрки кабиләләр арасында күрсәтә.[5] Академик Мирфатыйх Зәкиев тә татар атамасының монгол теленә бернинди катнашы да юк дип яза. Ул борынгы төркиләр яшәгән җирләрне барлап чыгып, аларның ким дигәндә 5 мең ел элек калдырган эзләрен билгеләгән.[6] Алтай-Орхон язмаларында «тугыз татар», «утыз татар» кабиләләренең исемнәре ташка уелган. Анда Төрки каганат башында торган Истеми каган, Бумын каган исемнәреннән безгә җиткерелгән мәгълүматлар арасында шушы кабиләләргә караганнары да бар.

8-9 гасырларда Төрки каганат таркалганнан соң тугандаш кабиләләр аерыла башлыйлар. Аерылып, үз дәүләтләре белән яши башлагач, шушы шөгыльләрен һәркайсы үзләренчә үстергән. Оясында ни күрсә, очканда шуны күрер дип юкка гына әйтмиләрдер. Тик шунысы хак һәм бәхәссез, төрки халыклар уртак йортларыннан үзләре өчен бик күп нәрсә алып чыкканнар.

Татар кабиләләренең көчәеп китеп, тирә-юньдәге кабиләләр өстеннән хакимлек иткәнлеге дә чыганакларда яхшы күрсәтелгән. Бу хакимлек Чыңгыз хан күтәрелеп китүгә кадәр дәвам иткән. Рашидеддин «Татарлар борын заманнардан бирле үк башкалардан үзләренең бөеклекләре һәм куәтле булулары белән аерылып торганнар, шушы бөеклекләре һәм абруйлы булулары сәбәпле башка төркиләрне дә татарлар дип йөртә торган булганнар», дип язып калдырган. Тик XII гасырда вәзгыять үзгәрә. Татар башлыгы Моджин Солтан кытай императорына каршы чыккач, Чыңгыз хан, кираитлар кабиләсенең башлыгы Тогроил белән берләшеп, аларга һөҗүм итә. Татарлар җиңелә, Моджин Солтан һәлак була. Күпләгән татар, шул исәптән бала-чага, үтерелә. Исән калганнарның шактые көнбатышка юнәлә.

Татарларга дошман булуларына да карамастан, монголлар алардан бик күп нәрсәләргә өйрәнгәннәр. Хәтта хан, каган атамалары да аларга төркиләрдән килеп кергән. Дәүләт төзелешен, аның белән идарә итү рәвешләрен алар шулай ук татарларда күргәннәр. Төрки каганатларны монголлар барлыкка китермәгән, алар барысы төркилек җимешләре.

Кайбер авторлар хәтта Чыңгыз ханның үзен дә монгол түгел, ә затлы төрки нәселеннән дип язалар. Шунлыктан, ди аларның берсе А. Бушков, аның өчен дәүләт төзү яңалык булмаган, ул бары тик бабалары башлаган эшне генә дәвам иткән.[7] Чыңгыз хан турындагы «Сокровенное сказание»дагы мәгълүматларның берсе дә дөрес түгел, ул әсәр үзе дә Чыңгыз хан заманында түгел, 18-19 гасырда гына барлыкка килгән, аның хәтта авторы да билгесез дип саный Бушков.

Бушков сүзләре дөрес була калса, нилектән Чыңгыз хан чыннан да татар була торып татарларга каршы сугышкан икән дигән сорау туу мөмкин. Тик мона гаҗәпләнергә кирәкми. Татарлар бит берничә кабиләдән торган. Әйтик, инде

[2] Э. Х. Паркер. Тысяча лет из истории татар. Казань,«Идел-Пресс»,«Слово»,2003,с.48.
[3] Шунда ук,56 б.
[4] Divan – ay Turk. t. 1,Istanbul,p.27-28.
[5] В. Г. Тизенгаузен. Сборник материалов,относящихся к истории Золотой Орды,т.1,1884,с.4.
[6] Происхождение тюрков и татар. М.,«Инсан»,2003,с.67.
[7] А. Бушков . Чингизхан. Неизвестная Азия.М.,«ОЛМА»,2007,сс. 161-173.

телгә алынган «тугыз татар», «утыз татар» кабиләләре, тагын әле «Алчы татар», «чаган татар» кебек кабиләләрнең булганлыгы да мәгълүм. Төркиләрдә тугандаш кабиләләрнең, башкалар белән берләшеп, бер-берсенә каршы сугышу мисаллары да җитәрлек. Шул ук Паркер да аларның үзара ыгы-зыгылары турында шактый материал китерә.

Тик монысы безнең темага кермәгәнлектән, аны читтәрәк калдырып, сүзебезне дәвам итик әле.

Чыңгыз хан иң көчлеләрдән саналган Моджин Солтан кабиләсен нык зәгыйфьләндергән булса да, башка кабиләләр исән кала. Чыңгыз хан шуларның сугышчыларын үз гаскәренең удар көченә әверелдерә. Һәм татар токымы үз атамасын монгол гаскәре сафында Европага хәтле китереп җиткерә.

Татар белән монголны яхшы аера белгән көнбатыш сәяхәтчесе Вильгелм Рубрук «Чыңгыз сугышка һәрвакыт татарларны алдан җибәрә торган булган, шунлыктан, дошманнарының котлары алынып, «татарлар килә!» дип кычкыра торган булалар», дип язган. XIV гасырда гомер кичергән гарәп язучысы Әл-Гомәри болай дип язган: «Борынгы заманда бу дәүләт кыпчакныкы булып, монголлар килгәч, кыпчаклар алар астында калалар. Ләкин монголлар кыпчаклар белән бик тиз туганлашып бетеп, үзләре дә, әйтерсең лә бер нәселдән кебек, кыпчак кыяфәтенә керәләр. Шулай итеп, җир үзенең табигый һәм раса сыйфатларыннан өстенрәк икәнлеген исбатлый». Риза Фәхреддиневнең монголлар «үзләре тел һәм мәзһәб, гореф-гадәт турыларында болгар төрекләреннән җиңелделәр һәм аларга иярделәр» дигән сүзләре[8] дөреслеккә туры килә. Европа җирлегендә, килгән татарлар җирле кан-кардәшләре болгар һәм кыпчаклар белән берлектә Алтын Урда могҗизасын хасил итәләр. Мин могҗиза дим. Чөнки алар монгол ханнары барлыкка китергән дәүләтне татарлаштыралар. Монда хәтта гаскәри рәвештә килгән монголлар да бик тиз төркиләшәләр. Алай гына да түгел, бер-ике буыннан соң ханнар үзләре үк төрки-татарга әвереләләр. Үзбәк хан заманында Исламга күчү нәтиҗәсендә татарлашу процессы тагын да тизләшә. Күрәсез ки, хөрмәтле укучылар, безнең атамабызның монголлыкка бернинди катышы да юк. Ул безгә мең еллар тирәнлегеннән килгән. Ул—үзебезнеке.

## Телебез дә үзебезнеке

Ничек кенә булмасын, төрки кабиләләр төрле атамалар белән ике мең елдан күпкә артык гомер кичергәннәр. Шул дәвердә аларның уртак культуралары барлыкка килгән һәм алар уртак телдә аралашканнар. Татарлар аларның җитәкчеләре булганнар. Төрки телләрнең хәзерге, искергән, онытылган тамырлары, мәшһүр Садри Максуди исәпләп чыгарганча, 4 мең берәмлектән тора. Ә иң бай саналган немец теленең бары тик 9 йөз тамыры гына бар. Моңа һич ис китәрлек түгел, чөнки төрки телгә ким дигәндә 1200 ел.[9] Моны 19 гасырның урталарында беренче буларак Копенгаген профессоры В. Томсен исбатлаган. Сонрак Россия профессоры В. Радлов ул телне бөтен тулылыгы белән диярлек торгыза алган. Э. Х. Паркер исә скифлар, һуннар һәм төркиләрнең шушы телдә сөйләшкәнлекләрен исбатлаган.

Шушы тугандаш кабиләләр төрле һөнәрләрне, шул исәптән җир эшкәртү һөнәрен дә үзләштергәннәр. Төркиләрдә саннарның, бөртекле культураларның, яшелчәләрнең исемнәре бертөсле. Барлык төрки халыкларда да «сабан», «бодай», «тары», шуларга бәйле «урак» сүзләре, бакчачылык культуралары «кавын», «кабак», «карбыз», «алма» бертөсле яңгырый.

Алай гына да түгел, кавын, карбыз, кабак исемнәре башка телләргә, шул исәптән славян телләренә дә кергән. Димәк, төркиләр бу һөнәр белән борын-борыннан ук шөгыльләнә килгәннәр.

Һөнәр дигәннән, «алтын», «көмеш», «бакыр» сүзләре шулай ук барлык төркиләрдә дә бертөсле янгырый. Ә бу аларның алтын-көмешне таба һәм эшкәртә

[8] Ризаэддин Фәхреддинев. Болгар вә Казан төрекләре. Казан. Татарстан кит. нәшр.,1993,50 б.
[9] Э. Х. Паркер. Күрсәтелгән әсәр. Авторның кереш сүзеннән.

белгәнлекләрен раслый. Тимерчелек һөнәрен дә төркиләр беренчеләрдән булып үзләштергәннәр. Туку-тегү, орчык, энә, без, пычак, балта, пычкы кебек бик күп сүзләр барлык төркиләрдә дә бертөрле янгырый. Төркиләр алыш-биреш белән дә шөгыльләнгәннәр. «Сату» сүзе аларның барысына да таныш. Акча, тәнкә сүзләре дә шул турыда сөйли. Үлчәм—карыш, аршын, батман кебек сүзләрнең дә борынгы төрки сүзләр икәнлеген онытырга ярамый. Болары инде төркиләрнең үлчәмле тормышта яшәгәнлекләренә дәлил.

Тел—иң четерекле мәсьәләләрнең берсе. Бигрәк тә аның тугандаш, бер-берсенә якын булганнары арасындагы мөнәсәбәтләр. Хәер, болары—тел галимнәренең эше. Мин исә аларның күпләргә мәгълүм, бәхәссез булган фактларына гына таянам. Беренчедән, борынгы төрки телләр бер-берсенә якын булып, бер телдәге диалектларны гына хәтерләткәннәр. Төрле кабиләләр бер-берсен бик яхшы аңлаганнар. Бүген исә төрки халыкларның формалашкан үз телләре бар. Аларның бер-берсенә шактый ерак торганнары бар. Әйтик, чуаш яки якут телләре башка төркиләргә аңлашылмастай дәрәҗәдә. Икенчедән, күп вакыт бүген мескенрәк, ә кайчандыр шанлы булган телләр, ни кызганыч, кулэгәдәрәк кала бирә. Бу турыда сүз башлаганда уйгыр факторын искә алмасам, бу зур хата булыр иде. Чыңгыз хан дәүләт төзелешенә керешкәч, зурайганнан-зурая барган империя белән идарә итү ихтыяҗыннан чыгып, үз тирәсенә укымышлыларны җыя. Аларның күпчелеге уйгырлар булганлыктан, дәүләт документларын төзү уйгыр язмасына һәм уйгыр теленә нигезләнә торган була. Тик Урал артына күчү белән уйгыр теленә җирле төрки телләр, бигрәк тә кыпчак теле зур йогынты ясый. Уйгыр теле асылда җинелә. Ләкин ул, бигрәк тә дәүләт документларында, ярылып торган эзләр калдыра. Бу хакта яшь галим Ленар Абзаловның кандидатлык диссертациясендә ышандыргыч дәлилләр бар.[10]

Бүген инде бөтенләе белән юкка чыккан кыпчак теленә дә игътибар житми. Ә ул кайчандыр иң таралган телләрнең берсе булган. 1303 елда Алтын Урда белән сәүдә итүчеләр өчен «Codex Cumanicus» дигән кыпчак сүзлеге барлыкка килә. Бу кулланмада бүгенгәчә яшәп килгән әйтемнәр бик күп. Андагы «сабан сермәк», «сабанчы» сүзләре һәм шулай ук «арпа», «борчак» «мәк» сүзләре бүгенге татарлар өчен һич ят түгел. Шул ук Италиядә Флоренция финансисты Франческо Пеголотти үзенең Жучи олысы белән сәүдә итүчеләр өчен 1340 елны язылган «la practica della mecatura» дигән кулланмасында юкка гына үзләренә ярдәмгә төрки телне белүчеләрне ялларга киңәш итмәгәндер. Кыпчаклар үзләре башка төркиләр арасына сеңә, ә телләре төркиләрнең уртак теленә нигез булып ята. Моны төрки-татар теле диләр. Алтын Урдада ул дәүләт теленә әверелә.

Ләкин бу тел инде борынгы татар теле булмый, ул үз эченә башка төркиләрнең, бигрәк тә кыпчак, күпмедер рәвештә болгар-хәзәр телләрен сеңдергән төрки тел була.[11] Моны ачыклаганда академик Мирфатыйх Зәкиевнең болгар һәм кыпчак атамаларындагы уртаклык турындагы фикереннән чыгып эш итү кирәктер. Ул төньяк төркиләрен, шул исәптән болгарларны да, кыпчак дип тә йөрткәннәр, дип яза һәм шуның белән алар арасындагы уртаклыкны ачыклый.[12] Алтын Урда исеме белән тарихка кергән дәүләтнең күпчелек җирләре кыпчак далаларыннан гыйбарәт. Шунлыктан ул Дәште Кыпчак дип аталган. Кыпчакларның күп санлы булулары нәтиҗәсендә, күрәсең, төрле төрки диалектларның үзара мөнәсәбәтләре кыпчак диалектының өстенлеге белән тәмамлана. Шуның белән бүгенге татар теленә нигез салына. Ул болгар бабаларыбызның теленнән шактый аерылып тора булса кирәк.

Әгәр дә без бүгенге көнне телебез күбесенчә кыпчак диалекты нигезендә формалашкан дисәк, әллә ни ялгышмабыздыр. Гомумән, без нindiдер рәвештә кыпчаклар да. Казакъ, кыргыз, башкорт туганнарыбызда шулай ук нindiдер кимәлдә кыпчаклар.

[10] Абзалов Л. Ф. Официальный письменный язык и канцелярская культура Улуса Джучи. Автореферат на соискание ученой степени кандидата исторических наук. Казань,2009,с.16.
[11] Абзалов Л. Ф. Указ. Соч.,с.29.
[12] Закиев М. З. Указ. Соч.,с.50.

## Милли моңыбыз

Аны безгә борынгы бабаларыбыз васыять итеп калдырганнар. Тарихның башы булган кебек, моңның да юл башы, географик ноктасы булырга тиештер. Ул менә монда, Идел-Урал буйларында яралганмы, әллә инде Алтай, гомумән Урал арты киңлекләрендә барлыкка килгәнме? Минем бу сорауны куюымның сәбәбе шунда, кайбер галимнәребез татар эзләрен телебездән яки археологик калдыклардан гына эзләп, моң, татар милли моңының тарихын искә алмастан бер яклырак кына нәтиҗә ясыйлар кебек. Шунлыктан мондый сорау да туа: төрки моң һәм татар моңы бер тамырданмы, әллә ул тамырлар үзгәме? Әйтик, төрекләр, әзәрбайҗан, үзбәк халыкларының музыкасы һич кенә дә безнекенә охшаш түгел. Бу халыклардагы музыка фарсылашкан яки греклашкан булса кирәк.

Ә менә төрки булмаган япон, кытай һәм кайбер башка Ерак Көнчыгыш халыкларының моңы безнекенә охшаш. Бервакыт безнең тарих факультетында стажировка үтүче профессор Чян-Бин «Бездә—сезнең музыкагыз, без аны сездән алдык, без аны тик Ерак Көнчыгышка, шул исәптән Японияга дә таратучылар гына», диде. Әгәр дә безнең моңыбызның юл башы Идел-Урал булса, ул әллә шул вакытта ук Кытайга барып житкән булыр идеме дигән сорау да туа. Һәм ни рәвешле ул моң Идел-Урал татарларының моңына әверелгән? Үзенең шигырьләре моң булып яңгырый торган шагыйребез Зөлфәт моңны юкка гына әйтелмәгән сер дип бәяләмәгәндер. Ул сергә үзе милли хисләр белән сугарылган кеше генә үтеп керә аладыр. Бер милләттәшенең җырын «хәйран булып» тыңлаган Тукайның йөрәгенә җырчының «милли хисләр белән ялкынланып», күңеленнән «сызылып-сызылып чыккан» аһәңе шагыйрьнең күз алдына «Болгар һәм Агыйдел буйларын» китереп бастыра. Тукай «Халык җырлары—халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгесе», дип язган. Әйе, милли моңнарыбызга тарихыбыз сеңгән.

Профессор Марсель Бакиров шушы моңның, төрки кабиләләрдә барлыкка килгәнлеге һәм аның кытайлар арасында таралуы хакында шактый кызыклы мәгълүмат туплаган. Ул язганча, Кытай империясенең музыка палатасы булган һәм Кытай императоры аңарга һуннарның көйләрен, җыр-моңнарын язу бурычын куйган, һәм бу бурыч үтәлгән дә. Бик тиз арада төрки моң кытайларга күчкән. Гомумән, кытайлар алардан башка бик күп нәрсәләрне өйрәнгәннәр. Кытай императорлары аларның гореф-гадәтләрен үзләштерә торган булалар. Э. Х. Паркер язганча, Кытай империясенең читтәге мәмләкәтләре «татар рухы белән сугарылган була».[13] Тик шулай да борынгы бабаларыбыз үзләре дә кытайлардан бик күп нәрсә алганлыкларын әйтми үтсәм, бу хакыйкатькә хилафлык кылу булыр иде. Жир эшкәртү, яшелчә-җимеш үстерү һәм башка бик күп кәсепләр аларга кытайлардан күчкән.

Тик монысы сүз уңаеннан гына. Сүзем исә милли моңыбыз турында. Мәшһүр Зәки Вәлиди үзенең истәлекләрендә төрки моң бөтен тулылыгы белән Казан татарларында сакланган дип яза һәм моның сәбәбен заманында Казан тирәсенә Алтайдан күчеп килгән, инде телгә алынган алчы кабиләсе кебек татар кабиләләре килеп утыруында күрә. Милли моңыбызны алар алып килгән дип саный. Димәк, бүгенге татарның шушы бер рухи тамыры да Урал артына, Алтай җирлегенә барып тоташа. 1870 елда Сембер шәһәрендә чыккан бер китапта татарлар Европада бары тик физик яктан гына яшиләр, ә аларның рухлары Урал артында дип язылган. Әлбәттә, монда берьяклылык юк түгел, чөнки төрки-татарлар өчен Европа беркайчан да чит-ят булмый. Аларның шактые, әйтик, кыпчак, хәзәр, болгарлар, монда борын заманнардан бирле яшәп, хәтта дәүләтләр дә төзегән халыклар. Тик шулай да монда дөреслек тә юк түгел.

Моңыбызга багышлаган сүземне шул ук Зәки Вәлидигә таянып дәвам итәм. Ул 1920 елның җәендә Мәскәүдән качып китешли Әстерхан тирәсендә милләттәшләребез җыелган бер мәҗлестә бер татарның җырлавын хозурланып тыңлый. Шул җырлар арасыннан «Нәникәҗан» исемле җырга аеруча басым ясый. Бу җыр 1340 елны Туктамыш ханның кызы Нәникәҗанның бер караим егетенә булган бәхетсез

[13] Э. Х.. Паркер. Күрсәтелгән әсәр, 12 бит.

мәхәббәтенә багышланган. Караимнәр төрки булсалар да, иудаизм динендә булалар. Шунлыктан кызга аңа кияүгә чыгу тыела. Кыз кайгысыннан кыядан упкынга ташлана. Зәки Вәлиди бу җырның нотасын яза алмадым ди, ләкин аның бик нык Тәфтиләү көенә охшаганлыгына игътибар итә. Соңрак ул Төркиядә шушы җырның нотасын да таба. Тик менә ул хәзерге ноталарга охшамаган була.

Тукай «Тәфтиләү»не Тәфкилев фамилияле мөфтинең француз егетенә гашыйк булып, «Нәникәҗан» кебек үк бәхетсез мәхәббәткә тарган кызына багышланган җыр ди.

Инде әйткәнемчә, Тукай милли монны, көйне турыдан-туры тарихка бәйләгән. Ул татар монының татарның җинел булмаган язмышының чагылышы икәнлеген күзаллаган. Музыка белгече Земфира Сәйдәшева, үзенә кадәрге тикшеренүчеләргә таянып, юкка гына «без әле һаман да Тукай бәяләмәсе биеклегендә яшибез», дип язмагандыр.[14] Шушы галимә ханымны куәтләп шуны гына өстим, бу бәяләмәдән беркая да китеп булмый, аны тик яна фактлар белән баетырга гына мөмкин.

## Болгар һәм хәзәр тамырларыбыз хакында

Минем Урал арты проблемаларына озаклап тукталуымны шушы тамырларыбызны инкарь итү дип карау ялгыш булыр иде. Безнең өчен алар ифрат та әһәмиятле. Бервакыт минем «Кара-каршы» программасындагы кайбер тапшыруларымны караганнан соң бер милләттәшебез, монголлар безнең болгар бабаларыбызны үтергәннәр, Болгарны тар-мар иткәннәр, нигә шулай булгач сез татар-монгол тарихын шулкадәр күп яктыртасыз, дип үпкә белдергән иде. Бу сүзләрдә хаклык юк түгел. Тик бит тарихыбызның бер чоры татар-монгол мөнәсәбәтләренә бәйле булгач, нишләмәк кирәк, аны берни дә эшләтеп булмый. Булган тарихны үзгәртү мөмкин түгел. Минем максат аны бары дөрес итеп күрсәтергә тырышудан гына гыйбарәт.

Әйе, Болгар чоры тарихыбыз дәүләтчелегебезнең иң ныклы нигез ташларыннан берсе. Бу—ниндидер ят тамыр түгел. Болгарлар хәзәрләр һәм башка төркиләр белән берлектә Төрки каганатларда да шактый озын-озак гомер кичергәннәр. Тик монда монголлар Болгар җирләрен яулаганчы ук татарларга карата да вәхшилек күрсәткәнлекләрен дә онытырга ярамый. Ә инде менә болгар, кыпчак җирләренә кереп утыргач, алар үзләре төрки камалышта калалар. Әйткәнемчә, ныклап төркиләшә башлыйлар, Ислам йогынтысы аларны йота диярлек. Шунлыктан, бик зур тетрәнүләрдән соң Алтын Урда чорында Болгарстан да яна сулыш ала, аның яшәү кинлекләре арта. Гомумән, бу Болгарстанның алтын чоры дип әйтергә дә мөмкин.

Әлеге чор—халкыбызны Ислам free динена дүндергән, Ислам культурабызга нигез салган чор ул. Болгарлар Урал артыннан килгән төрки-татарларны шушы дин белән каршылап, аларны да мөселман дөньясына алып кергәннәр. Алтын Урда дәүләтендә төркиләр өр-янадан кавышалар. Иске һөнәрләрен дәвам итеп, яна һөнәрләр дә үзләштерәләр. Болгар чоры шушы дәүләткә шәһәрләр төзү һөнәрен кертә, аны шәһәрләр дәүләтенә әверелдерә. Сүз бөтен шартлары тудырылган шәһәрләр турында бара. Болгар Алтын Урданың шәһәрлек өлгесенә әверелә. Монда суүткәргечләр дә, канализация дә, мунчалар да, башка уңайлыклар да була. Сарай шәһәре дә шундыйлардан. XIV гасырда анда 70 мең кеше яшәгән. Ә бит ул заманнарда 5-10 мең кешелек шәһәрләр зурдан саналган. Үзбәк хан заманында Сарайның гүзәллеген күреп шаккаткан гарәп язучысы Ибне Баттута аны дөньяның иң зур, матур һәм гүзәл шәһәрләрнең берсе рәвешендә тасвирлый. Сокланмаслык та булмый шул ул, андагы бассейннар, фонтаннар, мунчалар, гомуми туалетлар анда килүчеләрнең барысын да таң калдырырдай булган. Ибне Баттута аның киң урамнары, матур базарлары һәрвакыт халык белән тулы булганлыгын да язарга онытмаган.

Хәер, Болгар рәвешендәге шәһәр бер Сарай гына булмый. Археологлар Алтын Урда дәүләтендә шундый затлы 190 шәһәр калдыклары табалар. Ә бит

[14] З. Сайдашева. Татарская музыка: история и современность. Казань, «Идел-Пресс,2008,с.57.

әлеге шәһәргә караганда бернечә гасыр элек барлыкка килгән Париж бу чорда пычраклык оясы булган. Урамнары тар, сасы. Пычрак су, хәтта төн чүлмәкләре дә йорт тәрәзәләреннән урамга ыргытыла торган булган. Андагы пычракка шәһәр дуңгызлары үз сасыларын өстәп йөргән. Совет фәнендә кыргыйлар дәүләте итеп күрсәтелә килгән Алтын Урда чынында шәһәрләр дәүләте булган. Болар барысы да диярлек болгар тамырыбызның игелекле шытымнары.

Бүгенге татарларда хәзәр тамгасы да юк түгел. Хәзәрләр турында мәгълүматлар шактый күп. Мәгълүм ки, Хәзәр каганаты Төрки каганатның зур бер кыйпылчыгыннан барлыкка килә. Хәзәрләр—Идел буенда беренчеләрдән булып тәнкә акча суга башлаучылар. Профессор Әзһәр Мөхәммәдиев аларның VIII—IX гасырларга туры килгән меңләгән тәнкәләрен табып, тикшергән. Аның әйтүенчә, аларга күбесендә гарәп хәлифәләренең исемнәре язылган. Бу шушы дәүләтнең югары катламы, шул исәптән каган үзе дә, иудаизм динен кабул иткән булуына да карамастан, халыкның күпчелеге Ислам диненә авышканлыгы хакында сөйли. Ибне Фазлан аларның башкаласы Итилдә ун меңләп мөселман яшәп, анда аларның утызлап мәсчедләре булган дип язган. Хәзәрләрнең телләре болгар теленә якын булганлыктан, каганатлары юкка чыккач, хәзәрләр башка төркиләр белән бергә гомумтатар милләтен тәшкил итәләр. Аңарга үз тамгаларын салып калдырганнар.

Халкыбызның килеп чыгышы турында сүз алып барганда кыпчакларның, күпмедер кимәлдә болгарларның, монгол яулары килгәнче үк славяннар белән махсус мөнәсәбәттә торганлыгын истә тотарга кирәктер. Сугышулар да, төрле рәвештәге бәрелешләр дә булмаган түгел. Булган. Ләкин тормыш күп вакыт үзара тел, лөгать, гадәт вә әхлак, хәтта тәхетләр дә алмашу рәвешендә барган.

Ләкин татар-рус мөнәсәбәтләре махсус һәм бик тә каршылыклы мәсьәлә. Шунлыктан бу язмамда мин аны бары тик билгеләп китү белән генә чикләнәм.

Бүгенге татарның канында угро-фин кушымтасы да юк түгел. Чөнки мордва, мари, удмуртлар гасырлар буе татар күршеләре булып яшәгәннәр. Алар татарлар төзегән дәүләтләрдә үзләрен иркен хис иткәннәр, аларга үзләренеке итеп караганнар. Шулай булмаса, чирмешләр /марилар/ Казан егылганнан соң да ханлыкның бәйсезлеген кайтару өчен 20-30 ел буе сугышкан булырлар идеме?

Татар дәүләтләре юкка чыккач та, угро-финнар татарларга сыенып яшәгәннәр. Аларның шактые татарлашып, милләтебезнең бүленмәс өлешенә әверелгән. Мәшһүр Риза Фәхреддиинев тә «болгарлар арасында чуаш һәм мордва мөселманнары булуы ихтимал», дип язган.[15]

Әйе, татарның үткән юлы катлаулы. Бәлки, башка халык тарих сикәлтәләрен, аның төпсез чоңгылларын үткәндә юкка да чыккан булыр иде. Ә без, Тукаебыз язганча, «татарлар һаман да татарлар булып калдык». Безнең атамабыз да, җыр-моңнарыбыз да тирән тамырлы. Алар безгә дистәләгән гасырлар аша кем икәнлегебезне искә төшереп торалар, һаман да шулай була күрсен иде!

***Редакциядән.***

*Күренекле галим, җәмәгать эшлеклесе, Казан университеты профессоры, Татарстан Фәннәр Академиясенең хакыйкый әгъзасы, күпсанлы фәнни, тарихи китаплар авторы Индус Ризакъ улы Таһиров шушы көннәрдә үзенең 75 еллык юбилеен билгеләп үтә. Журналыбызның даими авторын әлеге олы бәйрәме белән тәбрик итәбез, саулык, озын гомер телибез!*

---

[15] Ризаэддин Фәхреддинев. Күрсәтелгән әсәр, 28бит.

# ГАБДУЛЛА КАРИЕВ ФЕНОМЕНЫ

ГАБДУЛЛА КАРИЕВНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

26 майда татар театрының атасы–Габдулла Хәйрулла улы Кариевнын туына 125 *ел* тула. Бу бөек шәхеснең тормышы һәм иҗаты тулысынча өйрәнелеп, ачылып житкәне һәм тиешле бәясен алганы юк әле. Шуңа күрә, кин җәмәгатьчелек кенә түгел, хәтта махсус әзерлекле сәнгать белгечләре дә: «Габдулла Кариев турында бөтен мәгълүматларны да беләм», дип авыз тутырып әйтә алмыйлар. Аның турында дәреслекләрдә дә мәгълүмат бик аз бирелә.

Габдулла Кариевнының авыр тормыш сынауларыннан торган, әле 35 яше дә туларга өлгермәгән килеш өзелгән гомере дә бик катлаулы булган...



*Габдулла Кариев. 1914 ел.*

1886 *елда* ишле гаиләдә туган Минлебай Хәйруллин әле бала вакытында ук бик күп төрле авыр михнәтләрне башыннан үткәргән. Ул бик тырыш, эшчән, акыллы, зирәк һәм оялчан бала булуы белән башкалардан аерылып торган. Шул сәбәпле, җае чыккан саен аны кимсеткәннәр, төрлечә рәнжеткәннәр. Ул әүвәл, үзенең туган авылында, ул вакыттагы Казан губернасындагы Чистай өязенең борынгы Колбай-Мораса авылы мәдрәсәсендә, 1894 *елда* бу авылга имам-хатыйп вә мөдәррис итеп билгеләнгән Зариф мулладан ибтидаи (башлангыч) белем ала. Бередә, әле ижек тә таный белмәсә дә, остазының ярдәме һәм үзенең әрсезлеге белән Минлебай Коръәнне яттан укырга өйрәнә һәм аны «Коръән хафиз», «кари» дип йөртә башлыйлар. Мәдрәсәдә «Минлебай хафиз», «Миңлебай кари» дип әйтү артык гади булганлыктан, аның исеме «Габдулла» дип игълан ителә, аңа «Миңлебай» дип эндәшүче кешеләргә җавап бирмәскә кушыла. Шуннан соң халык аны «Габдулла» дип атый башлый.

Әтисенең фәкыйрьлеге, өендә эшнең юклыгы сәбәпле, җәйгә чыккач, Габдулла үзенең остазы Зариф муллага кымызчы малай булып яллана. Ул җәйнең озын көннәрендә караңгы төшкәнче бия сава, төне буе сөт атлый. Таннан торып, тагын эшкә тотына. Мондый ялсыз эшләүләр Габдулланы тәмам хәлдән тайдыра, ул–кайда туры килсә шунда, йөгәннәрен баш астына салып йоклый торган кызганыч ятим бала хәленә төшә. Аңа менә шундый авыр хезмәте өчен, җәйге кымыз вакыты бетеп биялар сатылгач, Зариф мулла үзенең иске җиләнен, җөббәсен, биш кат баш сапкан читеген бирә.

1899 *елда* Зариф мулланы Такталы авылына күчерәләр һәм ул Габдулланы да шул авылның мәдрәсәсенә алдыра. Такталыда да Габдулла өчен тормыш бик авыр була. Ул күп вакыт чатнама салкын көннәрдә ялан-аяк йомышка йөреп тамагын туйдыра. Ахырында, түзә алырлык хәле калмагач, 1902 *елда* мәдрәсәне ташлап, «бәхет эзләргә» чыгып китә һәм ул вакытта татарлар күп яши торган Җаек (Уральск) шәһәренә барып чыга...

1905 *елда* Җаекта Гайнеддин кари мәдрәсәсендә укып йөрүче Миңлебай шәкерт, шул мәдрәсәдә Коръән хафиз булып, дин китаплары укып һәм яшертен генә һәртөрле гәзит-журналлар белән дә танышып бара, шәһәрнең атаклы хәзрәте Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин гаиләсендә яшәүче Габдулла Тукаев белән дә



*Кәрим Тинчурин һәм Габдулла Кариев (уңда). 1914 ел.*

күрешкәли, еш кына бу өйгә килеп йөри, хәзрәтнең улы Камил белән дә танышып ала. Һәр баруында бик озаклап сөйләшеп утыралар. Киткәндә, Камил аңар төрле китаплар биреп җибәрә, шул арада, ул Камилдән берничә җыр һәм көй дә отып ала. Үзе өчен дә кызыгы булган җырлар, шигырьләр белән халык алдына чыгып, әдәбият кичәләрендә һөнәрен күрсәтә. Шулай итеп, тора-бара Габдулла җырчы да, декламатор да, мәзәкче дә булып китә.

Шул елның май аенда Миңлебай–Габдулла, мәдрәсәне ташлап чыгып, һичбер кереме булмау сәбәпле бик мохтаҗлыкка төшә башлагач, «Казан миһманханәсе» исемле кунакханә ишеге төбендә төрле китап, газит һәм журналлар сата башлый. Бу авыр вакытта аңа Камил Мотыйгый ярдәм кулын суза, арзан хаклар куеп, бурычка өч йөз сумлык китап һәм журналлар бирә. Шуларны сатып, бераз акча ясагач, июль аенда ул Мәкәрҗәгә китә. Сатылмый калган китап һәм журналларын да шунда үзе белән бергә алып китеп, анда баргач та, Җаектагы шикелле, номерлар ишеге төбендә бераз вакыт китаплар, газит һәм журналлар сатып утыра. Шул елны, Мәкәрҗәгә килеп татарча театр уйнаучы Ильяс Кудашев-Ашказарскийга барып, үзен артист итеп алуны үтенә. Ашказарский, бик теләмичә генә, аны ала. Ашказарский труппасына кергәч, кари (Коръәнне яттан белүче) сүзеннән файдаланып, фамилиясен «Кариев»ка алмаштыра. Шуннан соң Габдулланың сәхнә тормышы башлана.

...Мәскәүдә Ашказарскийдан аерылып, 1907 елның 16 декабрендә, Габдулла Кариев үзенең театр уйнаучы иптәшләре белән Җаекка килеп төшә. Бу артистлар биредә ике ай ярымлап торалар һәм алар «Мосафир артистлар җәмгыяте» дип аталалар. Җаек яшьләренең катнашлыгы белән 1908 елның гыйнвар аенда, шәһәр театрында «Бәхетсез егет», «Өч хатын белән тормыш» һәм «Алдым-бирдем» исемле өч әсәрне сәхнәгә куялар.

Җаектан киткәч, бу артистлар җәмгыяте «Сәйяр труппасы» дип атала башлый...

Хөкүмәт тарафыннан бернинди ярдәм күрсәтелмичә, өстәвенә бертуктаусыз эзәрлекләнүләргә дучар булып, мең төрле афәт-михнәтләр чигеп татарлар яшәгән төбәкләргә, ерак шәһәрләргә йөреп, күп вакытта юл билетлары һәм ашарларына алырга да акчалары булмыйча, ачлыктан-ялангачлыктан интегеп, халыкка сәнгать нуры, сәнгать рухы таратып ил гизеп йөргән бу труппаның бәяләп бетергесез зур эшчәнлеге башка халыкларның театр тарихларында булса, белмим, ничек итеп кенә олылап бетермәсләр иде! Моннан биш ел элек, Габдулла Кариевның 120 еллык юбилее бернинди кичә-фәлән-нәрсез «тиха гына» үтте дә китте. Мәдәният министрлыгы да, театр эшлеклеләре дә, Габдулла Кариевка карата булган үзләренең «хөрмәтләрен», мәрхүмнең рухын «олылауларын» әнә шулай күрсәттеләр...



*«Сәйяр» труппасы Бохарада. 1914 ел. Алда: Камал I, ... . Сулдан уңга утырганнар: ..., ..., Габдулла Кариев, Гөлсем Болгарская, ... . Басканнар: Исмәгыйль Рәмиев, Бари Болгарский, Касыйм Шамил.*

Ә бит татар халкынын Театр тарихы–әнә шундый «Сәйяр», «Нур» һәм башка труппаларда үзләрен аямыйча иҗат иткән һәм беренинди авырлыклар алдында да чигенмичә халыкнын рухын тәрбияләгән күпсанлы фидакарь артистларнын һәм башка сәнгатькярләрнен каны белән язылган...

Татар Театрына нигез салып, аны аякка бастырган, Театрны һәртөрле афәтләр, һәлакәтләр, аяусыз репрессияләр, сугышлар, үзгәртеп корулар аша калып исәнимин җинеп чыгып, гасырлардан артык яшәтә алган барлык Татар Театр Сәнгате Әһелләренә дан!... Аллаһы Тәгалә аларнын урыннарын Җәннәттә кылсын иде!

**Әнвәр ХӘЙРИ,**

***

*Габдулла Кари берлә 5-6 ай бергә дип әйтерлек тордык. Яхшы вә кабилиятле артист булып килә. Аның истикъбале парлакъ.*

*Гайнетдин кари чүплегеннән котылганына куана.*

*Мин дә аның әрәм булып, теләнче булып калмавына шатланам.*

*Әйдә теләнсен Гайнетдин кари, әйдә теләнсен Фәссах кари!*

*Габдулла Кари хәзер труппада үзе баш. Әле Оренбургта. Хатлары килеп тора.*

**Габдулла ТУКАЙ**
*1909*

***

*Татар халкының иң киң гаммәсенең (халык массасының) сөеклесе бу зат—татар сәхнәсен оештыру, хәтта аны башлап җибәрүдә, аны тәрәккый иттерүдә иң күп хезмәт иткән, иң күп көч һәм гайрәт сарыф иткән, шул юлда иң күп мәшәккать чиккән бер артист, татар сәхнәсенең мәгънәви атасыдыр.*

**Фатих ӘМИРХАН**
*1920*

***

*Үзе тудырган «Сәйяр» труппасы байрагы астында үзенең идеалына омтылды, татар дөньясы өчен иртәрәк туган Кариев, татарның тупас хәяты белән көрәшеп аны җиңде. Ул мохитка иярмичә, мохитны үзенә ияртә алды. Гасырлар буенча эшләнә торган зур эшне, татарга театр тудыру эшен, театр эшенең татарлар арасында гражданлык казану эшен гайрәтле Кариев унөч ел эчендә эшләде.*

*Менә шул авыр хезмәт, чиксез авыр хезмәт саглям Кариевның бөтен хәяты җелеген суырды.*

*Ул чахотка алды. Ачлыктан аңа катар желудка булды. Бөерәге бозылды.*

*Җисмән авырса да, аның рухы чиксез нык, көчле, шуның белән бергә саф иде. Менә шул иманлы рух аңар зур эшләр эшләргә имкян бирде.*

*Кариев унөч ел эчендә төрле тарафтан орылган каты зарбәләргә карамыйча, башка милләтләрнең йөз елларча яхшы шартлар, көчле химаяче канатлар астында яшәгән театрлары белән, үзе тудырган татар театрын— «Сәйяр» труппасын тиңләштерерлек дәрәҗәгә күгәрде.*

**Кәрим ТИНЧУРИН**
*1920*

# «МАТБУГАТ.РУ»ДАН БЕЗНЕ УКЫГЫЗ

## Сәйлән. Авыл мәктәбен япкач мөгаллимнәре ни диләр? 2011, февраль.

*Сатирик әсәрләр конкурсына килгән бу әсәр сайтка эленгәч, аны 17 000гә якын укучы укып карады, шуларның 500гә якыны фикерен язып калдырды. Моңарчы «Матбугат.ру» сайтында мондый рекордлы күрсәткеч булдымы икән әле?.. Әйдәгез, комментарийларның кайберләренә күз салыйк.*

Шә-ә-әп! Көлә-көлә укыдым, аннары елыйсы килеп китте, укыту сферасында калган элекке коллегаларны кызгандым. Сәйлән бернәрсәне дә онытып калдырмаган дисәм, укытучыны «ручка күтәреп кенә йөрүче, эшләмичә генә акча алучы» дип «олылаучылар» турында да язасың калган.

Взрыв «Матбугат»та! Шәп...

*Мәрьям*

Елый-елый укыдым...

35 ел мәктәптә укытып, бер генә тапкыр да(!) зарлану сүзе әйтмәгән әниемне уйлап утырам. Вәт менә Сәйлән! Олы юлдан узган машиналардан атып калдырылган дөнья пычрагын жыюларны да онытмаган бит, әй! Елга әллә ничә жыялар аны безнең укытучылар.

*Укытучы кызы*

Укытучылар үзләренә бала мәхәббәтен, ата-ана хөрмәтен күптән югалтты. Бала икейөзлелекнең нәрсә икәнен мәктәпнең тәүге көненнән үк аңлый. Кемнең кем баласы булуына карап мөнәсәбәт кору, бер үк хаталар өчен ике баланы ике төрле бәяләү, кычкырып торган гаделсезлек оештыру, сәләтсез, ялкау түрә балаларына өстенлек бирү—болар мәктәпнең гомерлек чирләре. Ә бүгенге ата-ана—шул сез оештырган гаделсезлекнең уртасында кайнап, кимсенеп, хурланып үскән балалар. Шуңа күрә алар теше-тырнагы белән балаларын яклый. Һәркемгә баласы кадерле.

*Ата-ана*

Сезнең юри генә кызыксынганыгыз бармы: ни өчен яңа гына укытырга килгән көчле, яшь укытучылар мәктәптән китү ягын карый? Юк, авырлыктан курыкмый алар, ә менә шул күп кенә ата-аналарның мәгънәсезлекләреннән туялар. Аларны бернинди эш тә куркытмый. Киткәннәре базарда да сата, кибеттә дә эшли, гаиләсендә дә тынычлык. Чөнки эш сәгате чыккач ул өендә, балалары янында тыныч күңел белән утыра.

*Кояшкай*

Сәйләннең шигырьләрендә миңа бик тә ошаган бер сыйфат бар—кыюлык! Уйлаганын, әйтергә теләгәнен borгаланмый-сыргаланмый гына турыдан яра. Кайбер

шагыйрьләр шикелле «бездә тәртип юк инде ул, бераз гына бар да кебек» дип язып, үзен страховать итеп утырмый. Башы белән алдан бара. Бер генә шигем бар: киләчәктә зур бер шагыйрьгә әйләнергә уйлаганда, бу «житешсезлеген» мәҗбүри төзәттермәсме зур абзыйлар?

Шигырьне мәгариф министрына да укыйсы иде...

*Хөппи*

Ә бит Сәйлән күпме кешене сискәндерде! Точно, «бомба замедленного действия».

*Да!*

Район мәктәпләре арасында беренче урыннарда йөргче булсак та, мәктәбебезне тугызьеллыкка калдырабыз диюләре бик кызганыч. Без сыйныфта 18 укучы.

*Сәфәр мәктәбе*

Авылда гына түгел, шәһәр мәктәпләрендә дә кыскартулар белән укытучыларны куркытып кына торалар. Түбән хезмәт хакы һәм укытучының дәрәҗәсен төшерү дәвам итә. Эшләп торган мәктәпләрне ябалар, ә менә кайсы районда, кайсы авылда яна мәктәп ачыла икән?

*Егет*

Хоккейга, спорт комплекслары төзергә акча табыла, мескен авыл кешесенә генә юк. Башта больницаларны яптылар, хәзер мәктәпләрне.

*Биби*

Шундый шигырь язган өчен Сәйләнгә бер рәхмәт булса, журналда бастыручыга ике рәхмәт! Мин журналдан укыгач та аны мәктәпкә алып бардым һәм кычкырып укыдым. Бәя бер генә булды: «бишле»!

*Рифма*

Бу илгә акыллы кешеләр күптән кирәк түгел. Ике дистә ел буе акыллы халык калмасын дип тырышалар бит инде. Булганнары качып бетте, калганнары елап, сыкрап, үләбез, бетәбез дип шигырь язып ята. Фурсенко тәкъдим иткән программа буенча дүрт кенә фән кала, аның да берсе физкультура. Димәк, укытучы дигән һөнәр иясе тиздән бу илдә кирәк булмаячак.

*Сабыр*

«Казан утлары»ның сатира өлкәсенә игътибарын юнәлтүе бик тә вакытлы һәм унай күренеш. Чөнки сатира, бераз сарказмлы да булса, үсеш, үзгәрешләр өчен бик көчле стимул.

*Мин әйттем!*

Мәктәптә җыелышып укыдык, күпләр, бигрәк тә өлкәннәр, елады. Күпме түбәнсетүләр аша узган мескеннәр икән шул без.


*Татар теле укытучысы*

Бу сан пожалуй сатуда калмагандыр инде. Равил абый урынында булсам, ун тапкыр артыграк бастырыр идем.

*Да!*

# ӘЙДАМАН

Һәр гасыр үз шәхесләрен тудыра. Гасырлар чигенә генә сыймаганнар милләт горурлыгына әверелә. Ни кызганыч, үзе исән чагында телдән төшмәгәннәрнең бакыйлыкка күчкәч үк онытылганнары, исемнәре идеология чикләреннән дә уза алмаганнары байтак. Шулай ук вакыт уза барган саен иҗатына игътибар көчәйгәннәр дә бар. Шундыйларның берсе— Тәүфикъ Әйди.



...60нчы еллар урталарында, җәйләрен, аркасына биштәр тулы газета-журналлар төяп, Чуаш, Мордовия, Мари якларында велосипедка утырып сәяхәтләр кылып йөргән, шундагы татарлар белән очрашып, аларны телебезне саклап калырга өндәгән, 70-80нче елларда СССР төбәкләрендәге татарларны барлаган, таркала башлаган империянең «тимер пәрдәләре» күтәрелүгә беренчеләрдән булып чит илдәге милләттәшләр язмышы белән кызыксынган Т.Әйди әле кайчан гына юк эш белән шөгыльләнгән совет кешеләренең берсе санала иде. Әдип белән Черек күл буендагы оешма кызыксына, милли азатлык өчен көрәшне ике дистә елга алдан башлаган Т.Әйдинең бу эшчәнлеген төрлечә тыярга тырышалар. Хакимиятнең күп гасырлар дәвамында сыналган алымы да читтә калмый—әдип авыр тормыш шартларында иҗат итәргә мәҗбүр ителә: үзгәртеп кору елларына кадәр газета-журнал редакцияләре аның милли рухлы мәкаләләрен бик еш кире бора, ул матбугаттан ерак торган өлкәләрдә эшли, фатирсызлыктан интегә (1996 елда гына бирелә). Әмма Т.Әйди бу кисәтүләрдән сабак алмый. Тагын да үҗәтләнеп эшкә керешә. Күпләр әдәби журналларда да фәлән центнер ашлык суктыру, фәлән тонна сөт савып алу турында күләмле очерклар язып мәш килгәндә, редакцияләргә татар теленең куркыныч астында булуы, татар мәктәпләренең ябылуы хакында чаң суккан мәкаләләрен китерә. Әлбәттә, баш мөхәррирләр аны «дөрес» язарга өйрәтәләр, «киңәш»ләрен бирәләр. Кайберәүләр аның милләт, тел өчен шулкадәр «тавыш кубаруын» аңлап җиткерми. Кемгә кирәк ди ул бетеп барган татар теле, янәсе. Т.Әйди ялкынланып шундыйларга каршы көрәшә башлый: чикләнгән, яшеренгән тарихи чыганакларга юл эзли, каләм тибрәткән яшь иҗатчылар исемлеген төзи (ул 800 йөзләп яшь каләм иясен барлый. Шулай итеп ул татар халкының, төгәлрәге, әдәбиятының киләчәге өметле булуын мисаллар ярдәмендә исбатларга тырыша), Эстония, Болгария, Молдова, Румыниядә булып, андагы милли вәзгыять белән таныша, бу илләрдәге азчылык халыкларның (әйтик, гагаузларның) хәлен өйрәнә, аларны безнеке белән чагыштыра, романнары өчен азык туплый... Туксанынчы еллардагы үзгәрешләр күпләрдә милли хисне, хәтерне уяткач, Т.Әйди әсәрләренә дә игътибар бермә-бер көчәйде. Димәк, ул киләчәккә карап эш иткән. Бүген, милли богаулар тагын да тартып кысылган бер вакытта, ул әсәрләргә мөрәҗәгать итүчеләр артканнан-арта.

Еш кына әдипләребезнең рәсми биографияләренә күз салгач (хәзер бигрәк тә!): «И-и, бер дә авырлык күрмәгән бит ул: фәлән елда шунда укыган, тегендә эшләгән, фәлән елда монда хезмәт куйган»,—дип берьяклы фикер йөртүчеләр бар. Ә шул даталар арасында никадәр вакыйгалар, авырлыклар, кичерешләр

яшеренгән! Тәуфикъ Әйдинең исә шул рәсми тәржемәи хәле дә шактый ук чуар һәм катлаулы булып кычкырып тора. Анын сәяхәтче әдип, кин карашлы публицист, бай мәгълүматлы һәм оста телле сәяхәтнамә-юлъязмалар остасы булуын әнә шул биография дә берникадәр раслый.

Тәуфикъ Рамазан улы Әйделдинев 1941 елнын 1 маенда Мәскәү өлкәсе Шатура районы Туголеевский Бор поселогында сезонлы эшче гаиләсендә туган. Бала һәм үсмер чагы Татарстаннын Апас районы Түбән Балтай (1941—51; 1955—57), Олы Бакырчы (1954), Омск өлкәсенең Азов районы Төк (1951—53) авылларында уза. Татарстанда—татар, Себердә казакъ мәктәпләрендә укып, жиде класс белем алгач, 1957 елдан 1960 елга кадәр Алабуга китапханә техникумында укый, аннары өч ел Апас районынын Урта Балтай авылында китапханә мөдире, 1962 елда Казанга килеп, төзелештә—ташчы, милиция бүлегендә—бригадир, «Оргсинтез» берләшмәсендә—слесарь һәм аппаратчы, мәктәптә—укытучы, Татарстан халык ижат йортында—методист, газета-журнал редакцияләрендә—әдәби хезмәткәр һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә әдәби консультант булып эшли. 1973 елда, читтән торып укып, Казан дәүләт университетынын татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. 1983—1985 елларда ул Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы ике еллык Югары әдәби курсларда укый. 1985-1997 елларда «Казан утлары» журналы редакциясенең проза бүлеген житәкли, 1997-1998 елларда «Татарстан» журналы баш мөхәрриренен урынбасары, 1998-2001 елларда «Аваз» исемле хосусый нәшриятнын башкаручы директоры булып эшли... Никадәр борылышлар! Т.Әйди язучылык эшенә урау юллар аша килә һәм сонгы көннәренәчә үзен ижатка багышлый. Вакытсыз үлем арабыздан алып китмәсә, Т.Әйди татар әдәбиятын тагын да яңа темалар белән баетыр, милли изүгә, гаделсезлеккә каршы атлаучыларнын алгы сафында булыр иде. Мөгаен, гаделсезлек хөкем сөргән системага каршы көрәшеп яшәү анын желеген суыргандыр, кыйммәтле вакытын тартып алгандыр. Шуңа да карамастан, ул үзеннән соң бай ижат мирасы калдырды. Алар «Сайланма әсәрләр»дә унбер том (!) булып дөнья күрделәр. Әлбәттә, язучынын талант кимәле сан белән билгеләнми. Т.Әйди әсәрләре исә сыйфат югарылыгын саклап язылган. Мона инану өчен әдипнең ижат мирасына мөрәжәгать итик.

## I

Тәуфикъ Әйди әдәби ижат белән алтмышынчы елларда шөгыльләнә башлый. 1967 елда «Яшь Ленинчы»да һәм «Ялкын»да анын балалар өчен язылган беренче хикәяләре дөнья күрә. Шуннан бирле татар вакытлы матбугатында әсәрләре, китап нәшриятында—китаплары басыла тора. Т.Әйди ижатынын төп юнәлешен, алдарак искәртелгәнчә, төрле кыйтгаларга сибелеп яшәгән татар милләтенең киләчәк язмышы, татарнын Татарстанда һәм Рәсәй төбәкләрендә, хәтта бик еракларда яшәүче күренекле шәхесләре, чит илләрдәге татар диаспорасы, халкыбызнын тарихи туганлыгы тәшкил итә. Әдипнең зур күләмле романнары—«Елан угы» белән «Иблискә ришвәт» тә чит жирләрдәге татарлар язмышына багышлана.

Безнең әдәбиятыбыз татар мөһажирләре тормышын чагылдырган әсәрләргә бай түгел. Иң күренекле әсәрләр дип Мәхмүт Галәүнең 1897 елгы халык исәбен алу, авыл халкынын фетнә күтәрүе һәм Төркиягә күчеп китүе вакыйгаларына багышланган «Мөһажирләр» («Ил өреккәндә») романын, Ибраһим Салаховнын татар казаклары тормышын чагылдырган «Имәннәр тамыр жәйгәндә» исемле роман-эпопеясын атый алабыз. Тәуфикъ Әйди әсәрләре дә әнә шулар белән янәшә аталырга лаеклы.

1920нче елларда Урта Азиядә барган фажигале вакыйгаларнын безнең татар әдәбиятында тулы килеш чагылыш тапканы юк иде әле. «Елан угы» аларны колачлап, татар әдәбиятын яңа тема белән баетты. Т.Әйди ул якларда булгалаган, анда яшәүче халыкларнын теленнән, йолаларыннан азмы-күпме мәгълүматлы кеше.

Г. Ибраһимовнын «Тирән тамырлар» романы «Фәхрине үтереп ташладылар», дигән аталы жөмлә белән башланып китә дә, фабула жебе шуңа бәйле рәвештә сүтелә. «Елан угы»нын төбендә дә шул ук алым ята. Алдынгы карашлы, һәр яктан килгән, унай герой комиссар Шиһабетдиновны чит бүлмәдә үле килеш табалар, шуннан тикшерүләр, төрле төркемнәр арасындагы көрәш һәм атышлар башланып китә.

«Елан угы» 1982-89 еллар арасында язылa. Бу вакытта әле җәмгыятьтә коммунистлар идеологиясе хөкем сөрә. Шунлыктан язучы да, сәнгатьчә фикерләүдәге торгынлыктан арынмыйча, Бохара әмирлеген битәрләү юлына баса. Ягъни үз милләтенең мөстәкыйльлеге өчен көрәшкән бохаралылар түгел, ә ничәмә дистә еллар үзенең эчке тәртипләре белән яшәп яткан илгә бәреп кергән чакырылмаган кораллы көчләр—инкыйлабчылар унай герой буларак тасвирлана. Чекага Үзәктән җибәрелгән революция пәһлеваны хәрби комиссар Баһаветдин Шиһабетдинов, теркәү бүлеге башлыгы Фарукҗан Байкучатов аек акыллы, ифрат намуслы, Ленин фиркасе эшенә бирелгән кешеләр. Аларда әхлакый үкенү дигән нәрсәнең эзе дә юк, киресенчә, чит мәмләкәтләр эшенә тыкшынып, Мәскәү хакимияте юлын уздыралар. Илдәге тәртипне вата-җимерә үз властен урнаштырган Чеканың терәге—ярлы-ябага Иргәш, көтүче Амантай, чәйханәдә хезмәт күрсәтүче нәселсез кыз... Бу эшләргә шул якларда туып-үскән татар егетләре Рахманкол, Симиниев, Әминевләр Рәсәйдән ингән бәхетне кабул итә алмыйлар, алар иҗтимагый аңнары артта калган кешеләр буларак сурәтләнә.

Әлбәттә, алдынгы карашлы, чит илләрне күп иңләгән, язмаларыннан чыгып фикер йөрткәндә, большевиклар сәясәтен куралмаган Т. Әйди бу кимчелеген үзе дә тойган. Тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин шуларны күз уңында тотып, болай дип яза: «Т. Әйди романында Урта Азия фаҗигасендә катнашкан татарларны яңачарак сурәтләү, аларның җирле халыкларның омтылышын аңларга, төрки халыкларны бүлгәләүгә алып килгән төеннәрне үзәккә алырга мөмкинлек бар иде. Ул—файдаланылмаган».[1] Бүгенге көн күзлегеннән чыгып фикер йөрткәндә кайбер кимчелекләре булуга карамастан, «Елан угы» романында Бохара төбәгендә яшәүче татарларыбыз тормышы, аларның җирле халык белән бәйләнеше җанлы тасвирланган.

Икенче Бөтендөнья сугышында дистә меңләгән татар хәрбиләре дошманга әсир төшә. Германиядә барлыкка китерелгән Татар комитеты шулардан Идел-Урал легионы оештыра, аны Советларга каршы әзерли.

Нинди җир ул Ватан? Сатлыклар кемнәр? Татар хәрбиләре ни өчен легионга керә? Әсирләрнең алман хәрбиләре белән бәйләнешләре нинди була—әнә шушы сорауларга җавап эзләгән «Иблискә ришвәт» романы 1995-1996 елларда иҗат ителә. Роман Германиягә әсир төшкән татарларның тормышын һәм язмышын үз эченә ала. Укымышлы, совет хакимиятен куралмаган әсир татарларны берләштерүче сыйфатлар уртак: алар барысы да үз юлларын сайлый алмый икеләнә. Кайсы империянең җиңүе татар милләте өчен отышлырак? Ничек исән калырга? Ялчы хезмәтендә булган Хәлимәләр, Саматлар өчен әсирлек вакытлы күренеш. Алар мөмкинлек туугa моннан качып, туган илләренә кайтачаклар. Көнчыгыш министрлыгында хезмәт иткән, укыган, гыйлемле Янгураз һәм Шәмсирләр киләчәкләрен Германия белән бәйләп карыйлар. Алар СССР яшәгәндә татар милләтенең киләчәге юклыгына төшенәләр, үзләре әйткәнчә, «иблисләр» идарә иткән империягә кире кайтсалар, гомерләренең төрмәдә төкәнәчәген дә бик яхшы аңлыйлар. Вакыйгалар геройларның максатка ирешү, исән калуга омтылышлары белән үрелеп үсә бара. Төп каһарман Янгуразны гына алыйк. Ул берьюлы ике алман кызының башын әйләндерә. Җитәкче даирәләр белән элемтәсе булган Софи исемле хатын да, яшь алман кызы Рина да аңа исән калу, киләчәктә чит илдә ныгу, канат җәю өчен кирәк. Әсирлектәге Хәлимәне дә ул күз уныннан ычкындырмый. Ин соңгы чиктә Сталин исемле иблис идарә иткән илгә кайтырга туры килә икән, коммунистлар идеологиясенә тугры кыз аны коткарырга тиеш. Автор бик оста алымнар белән эш итә. Ул милләтче, татар халкының киләчәге өчен борчылган, укымышлы, үткән тарихыбыздан хәбәрдар, СССРга яшәүгә караганда Германияне өстен күргән һәм монда яшәп кенә татар милләтенә ярдәм итеп була дип фикер йөрткән Янгуразның һәр адымын хуплый кебек. Шул ук вакытта ул туган илен өзелеп сөйгән, нинди генә авыр шартларда да шунда яшәүне бар нәрсәдән артык күргән, үз милләте – татарлар турында сөйләшүгә караганда, интернациональ дуслыкны өстен күргән Хәлимәнең хисләрен дә аңлый. Совет гаскәрләре Германия чигенә якыная барган саен роман геройларының хис-кичерешләре, кыйблалары үзгәрә башлый. Баштан ук үз сүзендә нык торган Янгураз,

[1] Галиуллин Т. Дәгъва / Үткәнеңнән гыйбрәт ал... // Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 256 б.

Шәмсир кебекләр кыйблаларына тугры кала. Самат, Рәмзи ишеләр кисәк үзгәрә, милләт сүзен кулланудан тыела, үзләрен аяп калу өчен алман ягына чыккан татар әсирләренә каршы фетнә оештыра башлыйлар. Саматның Янгуразга һөҗүме шуна дәлил. Совет гаскәрләре Германиягә бәреп кергәч, Хәлимәләр, Саматлар аларга кушыла. Аларны исә анда газиз ватаннары түгел, Сталин төрмәләре көтә... Алман гаскәрләре чигенә барган саен, житәкчеләренең сәясәте дә тәгаен ачыклана. Аларга үз башлары гына кадерле, татар әсирләренә булган хөрмәт вакытлы гына күренеш, сугыш аларның җинүе белән тәмамланса, татарларның язмышы төгәл билгеле түгел. Аларнын да алманнарга кол булуы бик ихтимал. Шәмсирнең Янгуразга әйткән сүзләрендә үз дәүләте булмаган милләтләргә кайда да бер кояш икәнлегенә ачыну сизелә. «Өметләребез акланмады сыман, туганкай. Бердән, без итәгенә ябышырга тырышкан жан да Иблис бугай. Икенчедән, безнең өчен аеруча күнелсезе—бу Иблис беренче Иблистән көчсезрәккә охшый», — ди ул. Шулай да татар милләте күтәреләчәк әле. Моның өчен Янгуразлар бар. Ул икенче бер иблискә ришвәт бирә башлаган икән, әлбәттә, тагын бер иблис идарә иткән илгә кире кайтмаячак. Димәк, ана лагерьны какшату көрәшен дәвам итәргә язмыш үзе куша. Рухны изеп тора торган бер генә көч тә мәңгелек түгел. Вакыт укмашканны тарката, сибелгәнне жыя, тарих сәхнәсенә яңа күренешләрне, яңа каһарманнарны күтәрә. Т. Әйдинең «Иблискә ришвәт» романы Бөек Ватан сугышына милли күзлектән чыгып бәя бирү, шул чордагы татар әсирләре тормышын тасвирлау ягыннан үзенчәлекле.

«Божра» кыйссасында авторның милициядә эшләү чоры чагылыш тапкан. Ф. Мусин билгеләвенчә, әсәр «саф» детективка якын тора.[2] Ул «Тасманур» заводыннан бер тонна көмеш урлаучыларны эзләп тотуны тасвирлый. Игътибарын тулысынча диярлек шушы жинаятьне тикшерүгә юнәлтеп, автор бу эшнең шактый катлаулы төс алуын, ана тотынган геройлардан бик күп эзләнү, уйлану, криминалистик осталык соравын күрсәтә. Әйтергә кирәк, әсәрдә жинаятьләрне ачу эшенә романтик караш белән полемикага керү сизелә. «Кайберәүләр уйлаганча, жинаятьчене тотар өчен ах-ух килеп, машинадан машинага утырып куа бару, жәрәхәтләнгәнче көрәшү генә житми. Андый мажаралар бөтенләй булмаска да мөмкин», — диелә анда. Шушындый фикердән чыгып, автор ялтыравык мажаралыктан качарга тырыша, жинаятьне ачуның прозаик ягына күбрәк игътибар итә кебек. Караклар төркеме белән каршылыкка кергән өлкән тикшерүче Айбулат Байчурин үзе дә аздан гына аларның корбаны булмый кала. Нәжибә Габдуллина, Жәмил Гайнуллинны һәм Айбулат Байчуринны берләштергән ясалма мәхәббәт өчпочмагы төенләнештән чишелешкә кадәр озата килә. Нәжибәнең асылда Жәмилләр белән бер караклар төркеменнән булуы һәм тикшерү эшләрен ялган эзгә төшерү өчен үзенә күптәннән гашыйк Айбулат белән мәхәббәт уенын башкаруы әсәрне мажаралы итә.

Күп жанрларда ижат иткән әдип кайбер әсәрләрен тәмамларга өлгермәде. Аның яртылаш язылган хезмәтләренең берсе—моңарчы беркайда да басылмаган «Ак жилкән» әсәре. Анда 20—30—50 нче елларда системалы рәвештә юк ителгән милли интеллигенция һәм алардан соң килгән «югалган буын» язмышы, һәм дә «курпы» булып калыккан яшь милли хәрәкәт хәлләре тасвирлана. Т. Әйдинең бу әсәре дә, һичшиксез, татар әдәбиятын яңа тема белән баеткан булыр иде...

## II

Шулай да Т.Әйдине халыкка романнары, күп санлы хикәяләре түгел, сәяхәтнамә-юльязмалары танытты. Күп йөргән күпне күрә, күпне ишетә, күпне белә. Гомеренең шактый өлеше сәяхәтләрдә узган Т.Әйди чын мәгънәсендә киң белемле шәхескә әверелде, аның әсәрләрен яратып укучылар да бу юльязма-сәяхәтнамәләрдән күп мәгълүмат алды. Нәрсә мәжбүр иткән соң Тәүфикъ Әйдине ерак жирләргә, илләргә чыгып китәргә? Жавабы мәгълүм: татар язмышы, татар тормышы кызыксындыра аны.

Татар язма традициясендә бу жанрның тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Аның жанлануы, үсеш кичерүе исә XIX йөзнең икенче яртысы белән XX гасырның башына туры килә. Шиһабеддин Мәржани («Рихләте Мәржани»), Заһир Бигиев

[2] Мусин Ф. Детектив турында // Казан утлары. 1985. №10. 170 б.

(«Мауәраэннәһергә сәяхәт»), Фатих Кәрими («Аурупа сәяхәтнамәсе», «Кырым(г)а сәяхәт» һәм «Истанбул мәктүбләре»), Садрый Максуди («Англиягә сәяхәт») һәм башкалар юлъязма-сәяхәтнамәләре ярдәмендә татар җәмәгатьчелеген яңа җирләр, яңа мәдәниятләр белән таныштыралар. Совет хакимияте елларында сүнеп калуга дучар ителгән бу жанр 80нче еллар ахырында тагын җанлана, терн әкләнә башлады. Шулар арасында тирән эчтәлекле, күләмле һәм мәгънәле, мәсьәләне өйрәнеп-белеп язылуы белән Тәуфикъ Әйди әсәрләре аерым бер урын алып тора. Аның юлъязма-сәяхәтнамәләре дөньяга сибелеп яшәгән төрки халыкларның һәммәсен дә колачлый диярлек. Ул әсәрләрдә тарих та, бүгенге иҗтимагый тормыш та бердәй чагылыш тапкан. Үткән белән бүгенгене бәйләп, Т.Әйди нәтиҗәләр ясый һәм төрки халыкларның киләчәген дә күзалларга тырыша. Ин мөһиме: Т.Әйди кайсы илдә генә булмасын, кайсы милләтне тасвирламасын, аның әсәрләрендә үзәккә татар язмышы куела. Ул татарның төрки халыклар тормышындагы урынын билгеләргә омтыла, тугандаш милләтләрнең уртаклыгын һәм үзгәлеген эзли. Т.Әйди юлъязма-сәяхәтнамәләренә хас үзенчәлек: ул өйрәнә торган илләргә, төбәкләргә кабат-кабат сәяхәткә чыга, яңадан-яңа мәгълүматлар туплый, тагын да мөһиме, шушы эзләнүләре барышында тугандаш милләтләр арасындагы бағланышларны ныгыта. Бу юлъязма-сәяхәтнамәләрнең географиясе гаять бай. «Йөртә безне язмышлар» китабындагы беренче әсәр 1990—91 елларда Германиядәге Ной-Үлм, Мюнхен шәһәрләрендә булып, шундагы милләттәшләрнең кайберләре белән очрашуларны, әңгәмә һәм бәхәсләрне, шул илдә үзе күргән гыйбрәтләрне тасвирлауга багышланган. Т.Әйди күргән-белгәнен, ишеткәнен ничек бар шулай кәгазьгә төшерми. Тарихи һәм башка чыганакларга мөрәҗәгать итеп, әсәрләрен мәгълүматлар белән баета.

Эстония сәяхәтенә багышланган «Кечкенә дә төш кенә» әсәре 1976-1994 еллар арасында Эстония якларына берничә мәртәбә барып кайту, сәфәрләр арасында төрле белешмәләрне, эстон әдәбияты үрнәкләрен ныклап өйрәнү һәм, иң мөһиме, шул халыкның кайбер вәкилләре белән якыннан танышуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Т.Әйди 1 миллион чамасы булган эстон халкының казанышларын бик теләп тасвирлый. Аларның язучылары, әдәбияттагы уңышлары белән таныштыра. Чагыштырмача аз санлы милләтнең курыкмыйча һәм бердәм рәвештә мөстәкыйльлек юлына аяк басуына соклана.

«Идел тамагында» Әстерхан якларындагы милләттәшләребезнең борынгы һәм бүгенге хәлләренә багышланган һәм 1976—1991 еллар дәвамындагы сәфәрләр нәтиҗәсендә язылган. Т.Әйди юлъязма-сәяхәтнамәләрен чит илләрдә һәм элекке СССР илләрендә, Россия төбәкләрендә гомер итүче тугандаш халыкларга, милләттәшләребезгә багышлануы ягыннан да төркемләп булыр иде. Бу әсәре бер илнең бүтән төбәгендә яшәгән татарларның тормышын чагылдыруы белән актуаль.

«Аһ, туган каумем газиз!» дип Дәрдеменд шигыреннән алынган өзек белән аталган китапта Көнбатыш Кытайда, Шәркый Төркестанда, Үзбәкстанда, Себердә һәм Идел-Урал буйларында яшәүче татарлар хакындагы язмалар урын алган. Әлеге китаптагы әсәрләргә мәгълүматларның бай булуы, тарихи фактларның күплеге хас. Бу аңлашыла да: сәяхәт кылган җирләрнең тарихыннан, иҗтимагый тормышыннан хәбәрдар булмый торып тулы канлы әсәр язу мөмкин түгел.

«Оҗмах утравы» дип исемләнгән китап 1984—1994 еллар арасында Болгария, Молдова, Румыния һәм Кыбрыс-Кипр утравына ясаган сәяхәтләре, шул якларда күргән-белгәннәре шактый тәфсилле һәм кызыклы итеп тасвирланган. Болгариядә төрки халыкларның җәберләнүе, Румыниядә Дабруҗа төбәгендә көн күргән төрек-татар кешеләренең эзәрлекләнүе, гаепләнүе, телләренең, диннәренең кысылуы, Молдовадагы гагаузларның изелүе, үз ирекләре өчен көрәшкә күтәрелүе сурәтләнә. Безнең татар халкы өчен дә бик таныш вакыйгалар түгелме бу? Т.Әйди әнә шул халыклар тормышыннан мисаллар китереп, суверенлык дәрте белән яна башлаган милләттәшләрен булачак авырлыкларга алдан ук әзерләгән.

«Кардәшләр кочагында» томы тулысы белән 1992—1993 һәм 1999 елларда Төркиягә оештырылган сәфәрләр вакытында туган тәэсирләргә багышланган. Сәфәрләрнең кабатлануы, очрашуларның шактый булуы, Төркия дәүләтенең, төрек

халкының тарихына зур игътибар бирелүе китапны мәгълүматлы да, укылышлы да иткән. Татар халкының киләчәктәге үсешен Т.Әйди төрки халыклар белән дуслыкта күрә. Тарихтан беләбез: алдагы гасырларда да бу идея милләт өчен янып йөрүчеләрнең күбесенә хас булган. Димәк, без бүген дә телебезне, динебезне саклап калу юлында кардәшләребез белән бергә булырга тиешбез.

Т.Әйди юлъязма-сәяхәтнамәләрен галим Миркасыйм Госманов югары бәяли. «Тәүфикъ Әйдинең бу хезмәтләре белән бездә монарчы татарлыкка карата хөкем сөргән тар карашны, ягъни милли даирәне бары республика кысалары белән чикләүгә—махсус юнәлтелгән идеологик киртәләрне җимерү эшенә саллы өлеш кертелә»,—ди ул.[3]

Т.Әйди юлъязма-сәяхәтнамәләре чит илләрдәге һәм төбәкләрдәге тугандаш халыклар, милләттәшләребез тормышын өйрәнү, аларның мәдәни казанышларын житкезү ягыннан гына түгел, төрки халыклар арасында багланышларны арттыруда да зур әһәмияткә ия.

Милләт өчен янып-көеп яшәүчегә матбугат үзе бер мәйдан ул. Тәүфикъ Әйди дә һәр мөмкинлектән файдаланырга тырыша, матбугатта үзен борчыган мәсьәләләрне күтәрә, фикер-борчулары белән уртаклаша. Алар соңрак «Безгә ни булды?» һәм «Тылсымлы көч» китапларында тупланып дөнья күрде. Әдип очерк, документаль публицистика жанрында аеруча күп эшли. Халкыбызның күренекле галимнәре һәм сәнгать эшлеклеләре—СССРның халык артистлары Ришат Абдуллин, Мәрзия Даутова, Галия Измайлова, рәссамнар Фәйзрахман Әминев, Чыңгыз Әхмәрев, Әхмәт Кытаев, композитор Латыйф Хәмиди, галимнәр Шәүкәт Ибраһимов, Шәрфыйка Шәрәф һәм башкалар турындагы очерклары ((Бу язмалар 1984 елда «Кайда да кадерле» җыентыгында да басылып чыктылар) иҗат диапазонының киңлеген күрсәтә.

***

Тәүфикъ Әйди исеме «Казан утлары» журналы өчен бигрәк тә кадерле. Бу редакциядә ул 12 ел эшләде. Т.Әйди журналның зәвыгын күтәрү, аны яңа рубрикалар белән баету өчен күп көчен куйды. «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә», «Чит илләрдәге милләттәшләребез иҗаты» кебек рубрикаларны ул тәкъдим итте. «Казан утлары» да аңа үз әсәрләрен бастыру мөмкинлеге бирде, нәкъ менә безнең журналыбызда ул киң катлам укучыларга танылды.

1 майда Тәүфикъ Әйдигә 70 яшь тулган булыр иде. Кызганыч, гомере буе дөнья йөген тарткан ир-атларның дилбегәне яшьләргә тапшырып, тәҗрибә уртаклаша, киңәшләрен бирә торган хөрмәтле чагын үзе күрә алмады. Ә аның ялкынлы чыгышлары, фикерле язмалары, тәэсирле әсәрләре бүген татар халкына бик тансык! Тәүфикъ Әйдинең: «Берләшик әле, егетләр, күтәрелик!» дигән сүзләре әле дә булса күпләрнең колагында чыңлап тора. Бүген, атаклы Казан университетында татар факультетының язмышы хәл ителгәндә, татар мәктәпләре бер-бер артлы ябылганда, татар матбугаты бик авыр көннәр кичергәндә, әдәбиятка, сәнгатькә игътибар кимегән бер заманда таянып булырдай, милләт язмышы өчен көрәшкә күтәрелердәй шәхесләрнең—милли әйдаманнарның һаман да сирәгәя баруы күңелгә пошаман сала. Т.Әйди исә, һичшиксез, шундый әйдаманнарыбызның берсе иде...

**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН**

[3] Госманов М. Жанрның язмышы һәм яңаруы. //Казан утлары.-2001.-№1.-161-168б.

*Миңназыйм Сәфәровка 50 яшь*

# «ЧЫН ЖУРНАЛИСТИКА—ИМАНГА ТУГРЫЛЫК УЛ»



*Журналист булу хыялы Чуаштанның Татар Согыты авылында туып-үскән Миңназыйм Сәфәровны Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына алып килә. «Татарстан яшьләре» газетасында хәбәрче, аннан өлкән хәбәрче, бүлек мөдире, 13 ел баш мөхәррир урынбасары булып эшләү дәверендә ул аналитик фикер йөртә торган, йөгерек телле журналист булып танылды. Инде сигез ел дәвамында ул Татарстанның төп дәүләт газетасына—«Ватаным Татарстан»га җитәкчелек итә. Журналистлык эшчәнлеге белән берррәттән, 19 ел инде Казан университетының (хәзер КФУ)журналистика һәм социология факультетында укыта.*

—Журналистика шагыйрьлек кебек үк бер шаукым ул. Элегрәк татар авылында «мин» дип сөйләгәнне яратмыйлар иде—коллективлык хисе безгә нык сеңгән. Башкалардан фикереӊ белән дә, тышкы кыяфәтеӊ белән дә аерылып тормаска тиешсеӊ дигән караш яшәп килде. Мәктәптә укыганда яшьтәшләрем язган мәкаләләрнеӊ барысы да диярлек пионер җыены, металлолом, көл җыю турында иде. 7нче класста укыганда мин колакны торгызырлык бер мәкалә яздым. Аның эчтәлеге болай: әнинеӊ үзе утырткан һәм су сибеп үстергән агачлары бар иде. Беркөнне шулар янына балта тотып бер әби килде дә агачларны екты, аннан ваклап турап, өенә ташый башлады. Мин өйгә йөгереп кайтып, булган хәлне әнигә сөйләдем. «Нишләтәсеӊ инде, улым. Әбинеӊ караучысы юк, утын кирәк булгандыр»,—диде ул. Бу вакыйга мине тетрәндергән иде. Мәкалә яздым да аны «Яшь ленинчы» газетасына җибәрдем. Мәкалә Гомәр Бәширов алып барган «Туган ягым—яшел бишек» рубрикасында әбинеӊ исем-фамилияләре белән басылып чыкты. Ул дөнья күргә теге әби өйгә килгән. Әнигә: «Малаеӊ мине гәҗиткә язып чыккан»,—дигән. Әни мине бик нык ачуланды. Шул вакытта журналистика һөнәренеӊ авырлыгын беренче тапкыр татыдым. «Кискәнеӊ күрдем!»—дим. «Киссә соӊ,—ди әни.—Безгә бит монда яшисе». Шунда һөнәрнеӊ тагын бер кыен ягын аӊладым: синеӊ язмаларыӊ әти-әниеӊә, туганнарыӊа, дусларыӊа да авырлык китерә икән. Соӊрак, инде газетада эшли башлагач, колхоз таралу турында «Фетнә» исемле мәкалә язган идем. Ул чакта үзләре теләгән колхоз рәисен кую өчен халык урамга сәнәкләр белән коралланып чыкты. Мәкалә басылгач, якташлар ул санны күбрәк алып кайтуымны сорадылар. Газеталарны автобуска салып җибәрдем. Халык җитәкче итеп сайларга теләмәгән кеше моны каяндыр белгән һәм иптәшләре белән бер тукталыш алдан килеп, автобусны көткән. Газеталарны алып яндырганнар. «Ә-һә, «Сез язганнан нәрсә үзгәрә соӊ?»—дигән сүз дөрес түгел, журналистиканыӊ көче дәлилле язмаларда икән»,—дип уйладым. Мәкалә ихлас язылырга тиеш. Чын журналистика—иманга тугрылык ул. Ялгышырга мөмкинсеӊ, әмма алдарга, ялганларга ярамый...

**—Нинди авырлыклар көтәсен алдан ук белеп торсагыз да «Татарстан яшьләре»нә эшкә килгәнсез...**

—Студент чагымда мин «Татарстан яшьләре»ндә ике тапкыр гамәли практика үттем. Хыялым газетада эшләү иде. Әмма диплом алуга мине Сабага эшкә тәгаенләделәр. Казан тормышына күнеккән идем, шуна да районга кайтасым килмәде. Тормыш очраклыклардан тора. Мине дә шул коткарды. Балтасы суга төшкән кеше кебек Үзәк парк тукталышында аптырап утыра идем, троллейбус туктады. Кемдер троллейбусның ачык тәрәзәсеннән: «Минназыйм!»—дип кычкырды. Шагыйрь Газинур Морат икән. Ул «Татарстан яшьләре»ндә эшли иде. Аның: «Харис абый (Әшрәфҗанов, баш мөхәррир) сине чакырды»,—дигәнен ишеттем. Шуннан редакциягә бардым. Харис абый: «Бездә вакытлыча урын бар. Эшләп тор, аннан күз күрер»,—диде. Шулай эшләп киттем.

**—Киңәш бирүчеләр, тәҗрибә уртаклашучылар табылдымы? Беренче адымнарны хәтерлисезме?**

—Ин элек университетта укыткан Мирхәт Хөснимәрданов турында әйтим әле. Бик матур сөйләүче, фикерле, ак чәчле чибәр кеше иде. Ул безгә журналистиканың нигезләрен өйрәтте. Аны авызыбызны ачып, шаккатып тынлый идек. Ул дәресләр миңа зур сабак булды. «Татарстан яшьләре»ндә мине Рәфикъ Юныс (бүген «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары) белән бер бүлмәгә утырттылар. «Аның белән эшли алсаң, киләчәктә дә булдырырсың. Юк икән—юк»,—диделәр. Рәфикъ абый хәрбиләрчә төгәл кеше. Фәлән сәгатьтә эштә булырга, фәлән сәгатьтә кайтып китәргә тиешсең. Ул чакта командировкаларга еш йөрдек. Тема күп очракта бер—удар төзелешләр, комсомол-яшьләр бригадалары турында язасы. Бу темалар бүгенге көн күзлегеннән караганда саташу кебек тоела. Әмма ул чорда шуларны да кызыклы итеп газетага тәкъдим итәргә кирәк. Рәфикъ абый кулдан тотып дигәндәй укылышлы мәкалә язарга өйрәтте. Ул кырыс кеше. Мәкаләне пыран-заран китереп сүтеп ташлый иде инде. «Монысы бармый, тегесе булып чыкмаган»,—дип өр-яңадан яздырта. Сынармы-сынмасмы икән дип тикшергәндер, мөгаен. «Егерме баш исем әзерләп бир миңа»,—ди бу. Аның берсен табуы да бик кыен бит әле. Эшләгәнең минем өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен дигән сүз дөрес икән ул. Бүген мин баш исемнәрне рәхәтләнеп куям. Исем—мәкаләнең иң җаваплы өлеше. Ул мәкаләгә алып кереп китәргә, аны ачып бирергә тиеш. Исмәгыйль Шәрәфиевне остазларымның берсе дип атар идем. Бергә эшләү дәверендә хәтта бертөрле фикер йөртә башладык. Озаграк күрешми торсак, хәзер дә бер-беребезне эзлибез. Рина апа Зарипова озак еллар «Татарстан яшьләре»нең «Сердәш» рубрикасын алып барды. Эшли башлауга, иң беренче командировкага ул җибәрде. Газетада «Хат юлга чакырды» дигән рубрика бар иде. Әгерҗе районының Салагыш авылына чыгып киттем. Район үзәгенә килеп төштем, ул авылга юл юк, өзелгән, барып та йөрмә, диләр. Нишләргә? Беренче командировкадан: «Булмады!»—дип кайтыйммы инде? Беренчесеннән үк кире борылсам, алга таба эшли алмаячакмын. «Ничек тә авылга барырга!»—дигән фикергә килдем. Университеттагы сабакташым Рәмзия Әгерҗедә эшли иде. Шуны эзкә җиктем. «Салагышка таба егерме чакрым барып була. Аннан автобус йөрми. Шул авылдан бер кеше таптым. Ул апа клубта эшли, сине шуңа ияртеп җибәрәм»,—диде. Безгә исә нәкъ менә шул ападан зарланып, клубның начар эшләве турында шикаять килгән иде. Аның белән юл буе клуб турында сөйләштек, авылга төнлә кайтып җиттек. Яшьләр белән шул төнне үк күрештек. Апаның кимчелеге шунда: ул һәрнәрсәне үзе генә эшли, башкаларны ярдәмгә чакырмый икән. Шуңа да күп нәрсәгә өлгерми. Мәкалә «Ялгыз калган—ялкынсыз янган» исеме белән басылып чыкты. Рина апа: «Аның баш исемнәренә кадәр әйбәт итеп куелган»,—дип бик мактады. Шул уртача язылган мәкаләгә зур бәя биреп миңа канат куйды ул. Гомумән, «Татарстан яшьләре» миңа бик зур мәктәп булды. Анда аңлашып, хөрмәт итешеп эшләдек. Үзе бер гаилә кебек иде ул. «Ватаным Татарстан»да да шундый атмосфера тудырырга тырышам...

**—Егерме ел эшләгән газетадан китү җиңел булмагандыр?**

—Мин элегрәк «Ватаным Татарстан»да эшләрмен дип башыма да китереп карамаган идем. Бу—җитди орган, алар үзләрен бездән—«Татарстан яшьләре» журналистларыннан өстен санап йөриләр иде. Көтмәгәндә-уйламаганда тәкъдим ясадылар. Мин шундук

каршы килдем. Өйгә кайткач, шөкер, шундый зур җаваплылыктан котылдым бугай дим. Тугыз айдан дәүләт структураларына чакырып, тәкъдимне кабатладылар. «Т.Я»нең баш мөхәррире Исмәгыйль Шәрәфиев: «Минназыйм, андый җиргә өченче тапкыр чакырмыйлар»,—диде. Аның сүзеннән соң тагын бер кат уйландым һәм ризалыгымны бирдем. Монда килгәч нинди халәттә булуымны үзем генә беләм! Ярык тагарак янында калган бабай хәлендә идем. Тамактан үтми, йоклап булмый, башта рәтле бер фикер юк. Нишләргә? Коллектив зур: редакциядә алтмышка якын кеше эшли. Көндәлек газета, аккан су кебек, көн саен чыга. Баш мөхәррир итеп куелганның икенче көнендә яна санны чыгарырга кирәк. «Каян тотынырга икән соң?»—дип баш ватам. Эшне мәкалә исемнәрен үзгәртүдән башладым. Яналыкны иң беренче булып Исмәгыйль Шәрәфиев сизеп алды. «Яна себерке янача себерә»,—диючеләр артты. Аннан кадрларга күчтем. Иң элек бер мәкаләдә «төртелдем». «Кем язды моны?»—дип кызыксындым. «23 яшьлек егет»,—диләр. «Нәрсә? Ничек инде?»—дидем аптырап. Язганына караганда авторга һич кенә дә кырык яшьтән кимне биреп булмый. 23 яшьтә дөньядан бу кадәр туярга кирәк бит! Егетне чакырып алдым. «Ник болай язасың? Ни өчен син дөньяга шулкадәр нәфрәтле?»—дим. Ул аптырап карап торды да: «Соң, Минназыйм абый, мина шулай язарга куштылар. Элек үз фикерләрем белән яза идем, төзәтеп, үзгәртеп бетерәләр иде. Шул сәбәпле чыкмый калган мәкаләләрем байтак минем». Кулъязмалар арасында чыннан да «безнең идеологиягә, сәясәткә туры килми» іше җөмләләр сырланып, архивка тапшырылган мәкаләләргә тап булдым. Алар бастырырга яраклы, мәкаләләр укучылар өчен дә кызыклы. Шуннан соң коллективны үзгәртергә дигән карарга килдем. Яналыкларны күп кеше кабул итмәде. Калыплашкан коллективны җимерәсең, эчтәлекне үзгәртәсең, диделәр. Газета ул катып калган булырга тиеш түгел. Ул—кешеләрдән җыелган заман бизәге. Һәркем аңа үзенең кабатланмас төсмерен өсти.

**—Баш мөхәррир булсагыз да, газетаның күп санында язмаларыгыз чыгып тора. Күбесе сәяси темага язылган. Тәнкыйди рухлылары да аз түгел. Кәнәфи биләгән кеше өчен ят күренеш түгелме бу?**

—Мин бу урынга сорап килмәдем. Кәнәфи өчен борчылган кешедә газета кайгысы булмый. Мина җитәкчеләрнең: «Алай язма, болай яз»,—дип әйткәннәре юк. «Эләктергәнсең икән, артыграк җибәргәнсең»,—дигәннәре бар анысы. «Татарстан яшьләре»ндә эшләгәндә мина күбрәк эләгә иде. «Авылларның таралуы, оптимальләштерү—милләт бетүгә китерә»,—дип язган өчен мине өлкә комсомол комитетының секретаре чакырып алды. «Син ник шулай язасың, ни өчен халыкны котыртасың?»—ише сораулар яудыра башлады. Кып-кызыл булып тынлап утырдым да чыгып киттем. «Кешенекен тынла, үзенчә эшлә»,—ди иде әни. Тәҗрибә арткан саен тире калыная башлый. Журналист беркайчан да сынмаска тиеш. Артык кирелек тә ярамый. Андыйлар кисәк сына. Диварны баш белән бәреп тишәм дип дуамалланырга кирәкми. Анда ишек бар, менә шуны ачар өчен тырышырга кирәк. «Ватаным Татарстан»да эшли башлаганның икенче елында Зөлфәт Хәкимнең «Ватансызлар вата Ватанымны» дигән мәкаләсе басылып чыкты. Анда җитәкчеләр төгәл исем-фамилияләре белән аталып тәнкыйтьләнде. Әй, күпләр сөенде дә инде шул язма чыкканнан соң. Бездә бит кеше башын кискәнне яратып карап торучылар бар. «Нишләр бу, башын кискәндә елармы, кычкырырмы? Каны күп чыгар микән, ак кан чыгармы, карасымы?»—дип кызыксына алар. Мәкалә чыкты, кемдер минем белән сөйләшергә тели, кайберәүләр читтәрәк чыш-пыш килә. Җитәкчеләр укыганнар, тик мина бер сүз әйтмәделәр. Киресенчә, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев җаен табып рухны күтәрергә, сиздермичә генә якларга тырыша иде. Моны һәрдаим сизеп тордым. Мин үзем җитәкчеләрдән ераграк торырга кирәк дип саныйм. Кызганыч, журналистлар белән җитәкчеләр алар бер үк функция үтәмиләр. Журналистлар—җитәкче күрмәгәнне күрүчеләр. Күпне, «кирәкмәгәнне» күрүчене исә бездә бөтенесе дә яратмый. Шулай да дөрес тәнкыйтькә уңай карыйлар. Хәзерге Президент Рөстәм Миннеханов та күп тапкырлар: «Әгәр журналист дәлилле итеп, безнең фикерне үзгәртерлек мәкалә яза икән, мин тәнкыйтьне кабул итәм»,—дип белдерде. Журналист сүзен курыкмыйча әйтә һәм аны дәлилле белергә тиеш. Ә инде мәкалә язуга килгәндә, минем фикеремчә, укучы

газетаны алдыра икән, аның житәкчесе кем, ул ниндирәк кеше икән дип кызыксынырга тиеш. Шуның өчен дә күп очрашуларда катнашам, укучылар белән аралашам...

**—Кызганыч, газета алдыручылар гына кимегәннән-кими...**

—Мин эшли башлаган чорларда «Т.Я»нең 260-270 мең тиражы бар иде. Дөрес, ул чорда өч кенә газета чыкты. Бала укый башлауга ана «Яшь ленинчы» алдыралар. Үсә төшә, комсомолга керә— «Татарстан яшьләре»н укый. Аннары өйләнә, тормыш кора, житдиләнә—«Социалистик Татарстан»га күчә. Кеше, кызыксынуына карап, «Казан утлары», «Азат хатын», «Чаян» журналларына язылa, район газетасын укый. Шулар белән вәссәлам. Хәзер матбугат чараларының саны бик күпкә артты. Дәүләт газета-журналларына шәхси басмалар өстәлде. Баштарак мин сары матбугат кешене боза дигән фикердә тора идем. Ләкин вакыт белән барысы да үзгәрә. Бүген алар да аналитикага йөз тота, сәясәт, каршылыклы хәлләр турында яза. Эшкә артистлар тормышын, гайбәт язудан, баш, аяк авыртканда нишләргә кирәклеген аңлатудан тотынганнар иде. Тик бу темалар укучыны тиз туйдыра. Кеше барыбер ахыр чиктә: «Иртәгә нәрсә булыр икән?»—дигән сорауга җавап эзли башлый. «Кем, нәрсә, кайда, кайчан, ничек һәм ни өчен?»—журналистика әнә шул сорауларга җавап эзли. Бүген дөнья күргән матбугат чараларының тиражларын бергә кушсаң, ул теге чаклардагы тираждан артыграк та әле. Хәзер кеше укымышлырак. «Газетага көн бетә»,—дигән сүз күптәннән килә. Радио сөйли башлагач та газеталар юкка чыга дигәннәр. Телевизор барлыкка килде, интернет пәйда булды—теге куркытулар һаман ишетелеп тора, ә газеталар яши бирә. Алар икенче кимәлгә генә күчә. Ул интернетта булмаган әйберләр турында яза. Интернет ул—чүп оясы. Әзерлексез кеше анда керсә, нәрсә кирәген белмичә югалып кала, куркыту, котырту турындагы язмаларга тап булып, хәтта юләрләнергә, авыруга сабышырга мөмкин. Журналист исә анализларга тиеш. Без укучыларны газетага уйларга өйрәтү юлы белән тартырга тырышабыз.

**—Шундый укучыларның ихтыяжларын канәгатьләндерерлек яшь каләм ияләре әзерләнәме бездә?**

—Чит илләрдә журналистика факультеты юк диләр. Минемчә, журналист бер өлкәне яхшы белергә тиеш. Мәсәлән, авыл баласы буларак, мин авыл хуҗалыгы тармагын беләм. Аннан яши-яши аналитик фикер йөртергә өйрәндем, сәясәткә тартылдым. Студентларны да журналистиканың бер өлкәсенә өйрәтергә кирәк. Йөрәгенне бирсәң, күңеленне ачсаң, журналистикага мәхәббәт уятырга мөмкин. Университетта укыта башлавыма 19 ел булган икән. Студентлар белән аралашу, алар белән яшьләрчә сөйләшү миңа биологик яшемне киметергә мөмкинлек бирә. Элек нәрсә укытасын студентлардан сорап тормыйлар иде. Менә шундый фән, фәлән дәреслек—өйрән, укы! Заман, тормышка караш үзгәрде. Хәзер без студентлар алырга теләгән белемне бирергә тырышабыз. Шулай ук яшьләргә мәйданны да җәлләмибез. «Ватаным Татарстан»дагы «Яшьлек» битен тулысынча студентларга бирәм. Ана алар үзләре хужа. Редакцияләргә килеп-китеп, атнага бер мәкалә калдырырыр өчен генә кереп чыгу—совет заманы калдыгы. Алар редакция эшендә кайнарга тиешләр. «Журналистлар белән чәй эчегез, сөйләшеп утырыгыз»,—дип киңәш бирәм. Көндәлек матбугат—яшьләрнеке булырга тиеш...

**—Остаз үзенең шәкертләре белән горурлана инде ул...**

—Кечкенәдән үк, әйдә, журналист бул, дип үстергән кешеләрне күпләп атый алмыйм, чөнки мин мәктәптә укытмадым. Шулай да бер-ике мәктәп укучысының язмасы белән танышып, аларга хәер-фатиха бирдем. Журналист булам дигән кешенең әйтер сүзе һәм күзендә очкын булырга тиеш. Иң беренче булып хәтеремә Раиф Усманов килә. Ул мәктәптә укыганда яза башлады. Шакмаклы дәфтәргә вак хәрефләр белән язылган мәкаләләрен миңа җибәрә иде. Укыйм да: «Моны унынчы сыйныф укучысы яза алдымы икәнни?»—дип аптырый идем. Фикерләре ким дигәндә егерме биш яшьлек кешенеке кебек. Коеп куйган журналист! Шуннан аңа: «Раиф, синең урының—журналистикада»,—дип җавап хатлары яза башладым. Ул тормышның теләсә кайсы өлкәсендә үз юлын табар иде. Киров ягы татарлары алыпсатарлыкка маһир кешеләр. Раифның да андый сәләте бар. Ул да эшмәкәр

булырга әзерләнгән. «Миңназыйм абый, син мине журналистикага әкрен-әкрен генә тартып китерден»,—диде ул мина. Бүгенге «Татарстан» телеканалының житәкчесе Фирдүс Гыймалтдиновның журналистикага килүенә дә үз өлешемне керттем кебек. Журналистика—конвейер түгел, ул берәмтекләп сатыла торган товар кебек...

**—Шулай да бер шәкертегезнең исемен атамадыгыз, Миңназыйм абый. Кызыгыз Гөлназ турында әйтәм...**

—Ә-ә... Шәкерт буламы икән инде ул? Мин аңа беркайчан да: «Журналист бул яки гаиләгә берәү житкән, киләчәгенне бу өлкә белән бәйләмә»,—димәдем. Бу юлны ул үзе сайлады. Хатын татар-инглиз гимназиясендә татар теле һәм әдәбиятын укыта. Кызларым да шул мәктәптә белем алды. Кызлар гел әниләре тирәсендә кайнашкач, мин аларны укытучы булырлар дип уйлаган идем. Әмма кызның олысы—Гөлназ башта ук: «Мин укытучы булмаячакмын»,—дип әйтеп куйды. Укытучы хезмәтенең авырлыгын, аның кадере булмауны күргәч, гайрәте чиккәндер, мөгаен. Без өйдә гаиләбез белән жыелып, төн урталарына кадәр сөйләшеп, аралашып утырырга яратабыз. Көннең ничек узганын, нәрсә булганын бер-беребезгә сөйлибез. Сизәм: Гөлназда сөйләү сәләте бар. Балалар бакчасында, мәктәптә күргәннәрен гаҗәпләнеп, күзләрен түгәрәкләндереп, хисләнеп, тәэсирләнеп сөйли. Үзенең фикере дә бар. Сөйләп кенә калмый, «Ник шулай ул?»—дип сорауларын да бирә. Алтынчы класста укыганда беренче мәкаләсен язды. Арчага электричкада кайтканда вагон буйлап берәү хәер сорашып йөргән. Бу күренеш балага бик нык тәэсир иткән. «Аның балалары бардыр бит, әтием, ана ник пенсия бирмиләр икән?»—дип, төрле яклап килеп, моның хәленә кермәкче була. «Кызым, сөйләгәннәреңне миңа язып бир әле»,—дидем. Язды. Укыдым: әйбәт кенә мәкалә килеп чыккан. Үз фикерләрен белдергән. Иң элек мәкаләне Исмәгыйль Шәрәфиевкә күрсәттем. «Баланың язу сәләте күренә башлады әле»,—дидем. Укыгач: «Үзең язышмадыңмы син аңа?»—диде. «Юк. Бер җөмләсенә дә тимәдем»,—дим. «Кызда Ходай биргән талант бар. Әзер журналист бит бу. Мәктәп балаларының ничек язганын беләм мин. Ул исә фикерләрен белдергән, шуның белән җәмгыятькә чакыру ташламакчы була»,—диде. Мәкаләне «Сабантуй» газетасына бирдем һәм ул басылып та чыкты. Гөлназда азарт барлыкка килде. Ул һәммәбезгә дә хас. Матбугатта чыктыңмы—сиңа вирус керә. Шуннан соң яза башлады, активлашты. Ләкин беркайчан да миңа аркаланмады. Кастинг аша үтеп, телевидениегә—«Тамчы» балалар тапшыруына барып керде. Аннан «Татар радиосы»на алып баручы эзләгәннәрен ишетеп, шунда үзен сынап карады һәм җинеп чыкты.

**—Димәк, гаиләдә сезнең эшчәнлекне дәвам итүче бар. Гомеренең 50 яшьлеген каршылаган Миңназыйм Сәфәров киләчәктә татар журналистикасы үсешенә нинди өлешен кертә алыр икән?**

—Мин үземне өлкән кеше итеп күз алдына да китерә алмыйм. Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» мелодрамасында: «Бәдри—кырык яшьләрдәге татар карты»,—дип бирелә. Ул хәзер ирләрнең иң егет чагы. Юбилейны да зурлап үткәрмим. Анда төче сүзләр ишетәсем килми. Мин үземнең кемлегемне, күпме торуымны яхшы беләм. Исем-медальләргә мин битараф. Аларны җыю белән мавыкмадым. Катыргы белән генә ат казанып булса икән ул! Киләчәктә элек йөргән эзләремне тагын бер урап чыгасым килә. Шул вакыттан алып нәрсә үзгәрде икән тормышта? Берничә ел элек, газетаның 90 еллыгына әзерләнгәндә, истәлекләргә кереп баттым. Без тарихны саклый да, барлый да белмибез. Минем журналистика тарихын барлап, шуны тәфсилләп язасым килә.

**—9 май—Җиңү көнендә туугыз кызыклы. Тормышта иң зур җиңүегез нинди?**

—Үзеңне үзең җинүдән дә зуррак җиңү юктыр ул. Кешене җинәргә була. Аны сугып, төртеп егып, кыйнап була. Кешене җиңү кыен түгел. Үзеңне җиңү бик авыр. Әмма ул күңелгә канәгатьлек бирә. Бәхет әнә шул ул.

*Әңгәмәдәш*—**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН**



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

Ирек Сабиров

# ИКЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

**2006 елның июле**

И Ходаем,менә бит ул— онытылып бетә язган ләззәтле халәт! Тәнгә яңгырдан соң бераз җилләп өлгергән басу юлыннан «сәпитем» җиңел тәгәри,шау чәчәкле дымлы болыннан кайнар пар күтәрелеп, әллә нинди җәннәти хуш исләре белән хисләрне исертә. Борчылырлык-кайгырырлык нәрсә юк дөньяда!.. Чынлап та юкмы? Юк,юк! Хатын инде хәзер,уянып,кухнәдә кайнашадыр: бүген шимбә,Чиләбедән Фәрит кайтырга тиеш, аның җәйге каникулы башлана. Дүртенче курсын тәмамлады улым. Хәйран гына укый малай. Үземнең дә хәлләр зарланырлык түгел: эшем бара,баш инженер дип юкка гына аталмыйм бугай; абруемны кешеләрнең ихтирамлы мөнәсәбәтеннән сизәм. Сәламәтлегем—Аллага шөкер: ял көннәрендә шәһәрдән егерме биш чакрымдагы урманнарга барып йөрим «сәпит»кә утырып. Җитмешәр чакрым урап кайткан көннәрем була. Бүген дә өйдән ике дистәләп чакрым үтелгәндер. Кечкенә шәһәрләрнең өстенлеге шунда: кай тарафка юнәлсәң дә,кала читенә егерме минут, һәм—урман-кырлар җәелеп ята... Ни кирәк тагын тормышта? Шөкер,шөкер...

Әле бит күптән түгел генә уйлап куйган идем: яшь чакта,янәсе,куанычлы,якты илаһи мизгелләр еш була иде. Мәсәлән,кая да булса барасың—автобустамы,тимер юлданмы: дөнья матур,алда шатлыклы очрашулар,артта—тыныч вөҗдан... Соңгы вакытта,андый очышлы халәтне тагын кичерү бәхетенә ирешү насыйп булмас инде, дигән төшенке уйлар кергәли иде башыма. Юк,менә бит: тәндә шундый җиңеллек хәзер,җанда шундый илһам—дөньяны үзгәртеп корырга да көчем җитәр кебек.

...Талгын җилдә тубылгы башлары чайкала. Мәтрүшкәләр өлгереп килә—шәмәхә төсләргә утраучыклар ерактан үзенә чакырып тора. Үлән бик куе булмаган калкулыкларны ап-ак төскә күмгән, җир җиләге чәчәк атып утыра. Кара әле, җиләге дә бар түгелме? Йа,Раббым,шулкадәр күп! Киләсе шимбәгә кызарып җитә бит инде ул!

*Болыннарга чыгам яңгырдан соң—*
*Тәнгә-җанга ләззәт вә сихәт.*
*Әй, тыңлагыз, кала әсирләре:*
*Табигатьтә бөтен хакыйкать!..*

Их, көннәр буе урман-болыннарда йөреп, шигырь ятлап кына яшисе иде, ә? Дүшәмбедән тагын завод «казанында» кайнау дәвам итәр инде, ие. Директорның кыланышларына теш кысып, Котельников белән Шияковны сүгеп, Валидовның яңа проектларын тикшереп, выж-выж итеп узачак көннәр. Яратаммы мин эшемне? Белмим. Унбиш ел эшлим бит заводта. Барыбер төп эшем, үз эшем дип саный алмыйм. Әйтерсең лә,ике тормышым бар минем. Завод—чын тормыш түгел. Юри генә эшлим кебек мин монда. Карьерага омтылмадым. Ләкин үстерделәр. Чираттагы

һәр вазифага үгетләп күндерделәр. Бергә башлаганнар әллә кайда югалып калды: кайсы эчеп, кайсы, хирысын тыя алмыйча, «кәкре» эшләр белән абруен югалтты. Ә мин... Шушы җитди хәрби заводта эшләвем—чын тормышым түгел, мин монда уйнап кына эшлим, дип кемгә дә булса әйтсәм, акылга җиңеләйгән бу, диярләр иде. Йә «кирәк җиргә» хәбәр итәрләр иде. Ләкин мин бит тырышып, барысын да җиренә җиткереп эшләдем. Бары тик җаным өчен кирәксез, тамак туйдырырга акча гына бирә торган шушы тормышым белән параллель рәвештә тагын бер дөньям бар минем: китап дөньясы. Бу—чын тормышым, төп тормышым. Татар, урыс язучыларын-шагыйрьләрен сәгатьләр буе, көннәр буе укып утыра алам, хәзер төрекчәне дә үзләштереп барам. Заводның нервылы-сүгенүле кырыс атмосферасында түзеп яшәргә миңа менә шул «альтернатив» тормышым ярдәм итә. Юк, үземә язу иҗаты сәләтен бирмәгән Ходай. Дип уйлыйм. Һәрхәлдә, чынлап торып ниятләнеп караганым булмады. Кем әйтмешли, язучы түгел мин, укучы. Инженер дипломым була торып, гомер буе әдәбият белән мавыгып яшим. Өй тулы китап. Хәзер исә тагын зур дөнья ачык: Интернет дигән могҗизада теләсә кайсы язучыны, әсәрне табып була.

Ләкин—бусын үзем дә аңламыйм—кырык өч яшемне тутырып уздым, «юри генә» яшәгән тормышымда баш инженер булырга өлгердем, ә яшәвемнең мәгънәсе дип санаган юлымда нәрсәгә омтылам мин? Нинди максат белән яшим мин җирдә? Нәрсә калдырам үземнән соң? Бу ракеталарны-шартлаткычларны заводларда миңа кадәр дә эшләп чыгарганнар, миннән соң да дәвам итәрләр: нинди генә башлы инженер булсам да, бу вазифаларны бүтәннәр дә башкара ала. Ә менә әдәбиятта-шигърияттә мин ишеткән моңнарны, илаһи фикерләрне миннән башка беркайчан беркем аңлый алмаячак. Хәтердә тупланган шулкадәрле мәгълүмат, Кол Гали, Мөхәммәдьяр һәм Тредиаковскийлардан башлап Мөдәррис Әгъләм, Солженицын, Әмирхан Еники һәм Андрей Вознесенскийларга хәтле үзләштерелгән иҗатның күләме кайчан да булса сыйфатка күчәргә тиештер бит ул. Нишләргә тиеш мин ул байлыгым белән, нинди куллану табарга тиеш? Уртаклашырлык кешем дә юк әйләнә-тирәмдә...

Һәй, әллә кая китеп китте уйларым!.. Һава сафлыгы, шушы табигать белән хозурлану уйлатадыр. Туктале, фикер йөртү куәтен шигырьгә юнәлтергә кирәк:

*Безнең фани дөньябызга илаһи бер моң ия,*
*Бу гаҗәеп могҗизаның исеме—гармония.*
*Әнкәм назы, әткәм сүзе, сөйгәнемнең күзе ул;*
*Ахры инде—гармония Хак Тәгалә үзе ул...*

«Сөйгәнемнең күзе...» Лена белән егерме бер ел яшибез. Яратам. Яратмасам, никахлашуыбызның беренче елында ук, әти рәнҗүенә, туганнарның, «марҗага өйләнгән», дип кырын каравына түзмичә, бизгән булыр идем бит. Юк, яшибез. Улыбыз үсеп җитте. Дөрес, кайчак үз-үземә: «Хисләреңне тикшереп кара»,—дигән чакларым да була, ягъни —«ялгыштым шул»,—дияргә үҗәтлегем комачаулый түгелме? Юк-юк, бернинди хата юк, нишләгәнемне аңлап, киләчәгемне, язмышымны үзем планлаштырып кордым мин тормышымны. Хәзерге заманда, җенси мөнәсәбәтләргә карашлар коточыргыч җиңеләеп киткән чорда, Лененың моннан егерме ел элек, институтның дүртенче курсында, үземнең беренче мәхәббәтем булганын хәтта иң якын кешеләремә дә сөйлисем килми. Егерме яшеңнән узып та кыз үпкәнең булмадымени, диярләр. Ләкин пәри башка, җен башка дигәндәй, үбешү—мәхәббәт дигән сүз түгел бит ул. Лененың исә... әйе, булган миңа кадәр. Булса ни. Мин аны белмим дә, белергә дә теләмим. Дөрес, көнләшү хисе әле дә вакыт-вакыт бугазымны кысып ябырылгалый. Шуңа күрәме—яшьрәк чакта, Лененың эшендә, конструктор бүлегендә, ир-егетләр артыграк бөтерелә кебек тоела иде миңа, һәм Лена үзе дә алар белән аралашканда артыграк ачык һәм артыграк елмаючан шикелле иде. Хәер, аек акыл белән аңлыйм үзе: минем сөю катыш көнләшү сәбәбеннән туган ялкынсынулы фантазия генә инде бу. Ул—минем бердәнберем. Мин аның бердәнбере. Әле менә кичә генә, башыма килгән уемны аның белән уртаклашып: «Безнең көмеш туебызга да дүрт ел гына калып бара

икән»,—дигән идем,ул турыда башыңны катырма,бүгенге көн белән ләззәтләнеп яшик,дигән кебегрәк итеп җавап бирде.

*Күзләреңә карыйм—күз камаша...*
*Шул микәнни сөю шаукымы?*
*Җан эреткеч нәфис челтәр аша*
*Кулым тоя билең ялкынын...*

Бер аяныч—мин мавыккан дөнья, китап-шигырь дөньясы белән кызыксынмый матурым. Юкса шигърият—кыз-хатыннар холкына якынрак та бит ул. Һәм, күпме тырышсам да,татар теленә күнектерә алмадым хатынымны. Сүз байлыгы «исәнмсез»,«рахмат»тан артмады. Хәзер дә,без Фәрит белән татарча бер-ике авыз сүз әйтешеп алсак,иреннәрен турсайтып,кухнәгә чыгып китә. Юк-юк,бу очраклы эпизодлар гына,алар безнең арабызны суытмый. Нигездә,безнең мөнәсәбәтләр чын мәхәббәт хисенә корылган. Дип ышанам. Без бер бөтен. Без дөньяга бер-беребез өчен яратылган. Тормыштан ләззәт табып яшәү өчен. Дип беләм.

Ә бит чынлап та,ләззәтләнерлек нәрсә күп тормышта! Тирә-якта—кояшлы-чәчәкле табигать,уйлар әллә нинди шигъри киңлекләргә оча,гаиләм имин,сөйгән хатыным бар,тормышның иге-чиге юк,дөнья матур,дөнья якты!

## 2008 елның октябре

Дөм караңгы дөнья.

Елыйсым килә. Ленаның вафатына ике ай тулды. Аның вафаты—минем вафатым. Миңа кырык биш. Тормыш бетте. Бәлки берникадәр яшәгән булырмын әле. Тик ялгыз тормыш—тормыш түгел ул. Кичә мәчет картларыннан Мәхмүт бабай кергән иде. «Шәригать өйләнергә куша,»—ди. Чын күңелдән кайгымны уртаклашып кергән инде ул. Ләкин тупас сүз әйтүдән көч-хәл белән тыелып калдым. «Тыкшынмагыз»,—димәкче идем. Чынлап та, кайда мәгънә? Лена урынында һичкемне дә күз алдына китерә алмыйм бит мин, ничек шуны аңламыйлар? Әле тагын да эштә үземнең урынбасарым Котельников җенемне чыгарган иде. «Вы завидный жених, к вам очередь выстроилась»,—ди. Ягъни байлары да бар,чибәрләре дә; бай да,чибәр дә булганнары да байтак. Бусын инде, тыелып тормыйча, аты-юлы белән сүгеп куып чыгардым. «Миңа хатын эзләп йөргәнче, үз хатының турында кайгыртсаң, файдалырак булыр иде»,— дидем. Чынлап та,аның Тамарасы бигрәк... җыйнаксыз гына түгел,йөгәнсезрәк димме. Ни буе-сыны,ни килеш-килбәте,ни өсте-башы. Үзеннән гел әллә нинди парфюмерия исе аша махмыр катнаш тир исе аңкып тора.

Елыйсым килә. Бар иде гаиләм,бар иде яшәү теләгем. Хәзер шул бәхетем менә шушы агач тәре астында калды. Тәрегә: «Ахтямова Елена Владимировна. 1963-2008»—дип язылган. Рак дигән афәтнең иң явыз төре. Бик кызу тотты. Ун ай. Өлкә хастаханәсенең баш табибы белән көн саен очрашып тордым үзем, «Ниссан»ымны кызганмыйча,илле чакрым араны бар дип тә белмәдем. Ришвәтне кызганмадым. Алалар икән. Күпме бирсәң дә. Бернәрсәнең дә ярдәме тимәде. Акчасының да, химиясенең дә.

Чардуганны зур итеп кордырдым. Үземә дә урын калдырдым Ленаның янәшәсендә. Бер дә шигем юк: озакламамдыр. Кызыгы бетте тормышның. Хәзер көз. Насыйп булса,язга чыккач зур итеп таш куйдырырмын. Зур итеп. Беркемнекенә дә охшамаганча итеп. «Әле дә яратам»,—дип яздырырмын. «Мәңге бергә»,—диярмен. Минем үземә исә—куйдырыр кешем бар. Шулай икәүләшеп ятып калырбыз мәңгегә. Аның ташында тәре булыр,минекендә—минеке... Нишләмәк кирәк—заман галәмәте. Без гаепле түгел. Яраттык. Яраттым. Мине кечкенәдән шулай тәрбияләделәр. Мәктәп. Комсомол. Бәйнәлмиләл. Рус туганнарыбыз. Кала институты. Авыл мәктәбеннән чыккан малай өчен—бөтенләй бүтән дөнья иде бит ул. Марҗа кызлары—тагын да аерым бер дөнья. Безнекеләр,авыл кызлары,йомык. Болар исә ачык,назлы. Хәзер мохит үзгәрде,тигезләнде. Ә ул чакта... Спецкурс имтиханына әзерләнү. Лена белән очраклы гына бергә туры килгән идек. Өч сәгать буе,әллә каян килеп чыккан назлы-наян хистән исереп, бер-беребезнең «яшерен» мөһере сугылган дәфтәрләребезгә

тузга язмаган җүләрлекләр язып утырдык. Чирек гасыр узган.

«Өйлән»,—дигән иде миңа Ленам. Хәленең өметсез икәнен аңлагач әйтте ул аны. Ә мин исә—мөмкинмени! Аерылышуыбызның котылгысыз якынлашып килүен белә торып: «Син савыгачаксың,мин сине барыбер аякка бастырам»,—дип,үз ялганыма үзем ышанып,тукып тордым. Юк,бүтәннәр үйгә да керми. Ниндидер үкенү хисе күкрәктә. Гарьлек. Кадерен белеп җиткермәдем кебек. Рәнҗеткән чакларым булды бугай. Салкынрак булдым шикелле. Назга саран булмадыммы? Бүгенге тәҗрибәм,бүгенге аңым белән узган елларга кайтып булса икән!.. Хәер,юк-юк! Аллам сакласын кабат узган заманнарга кайтудан. Ахырын белә торып...

Яраттым. Юкса шулкадәр мәшәкать аркылы үтеп,шушы Чиләбе кырыендагы шәһәрчектә оя корып яшәүгә ирешә алмаган булыр идем. Казанда тулай торак иде. Ленаның Залесныйдан,Васильеводан иксез-чиксез санда туган-тумачалары өзелмәде. Көн саен кунак. «Ну чо, зятёк, выпьем!..» Эчмәсәң, үпкәлиләр: «Да-да,ваша мусульманская вера... Ну маленько,Аллах не заметит...» Яисә: «Безнең венчание бүген...» «Бүген безнең крестины...» Ел ярым эчендә чиркәүдә ничә тапкыр булырга туры килде! Мәчеттә бу кадәр булганым юк. Бармасаң—«Родственников не уважаешь». Яратмасам,шуңа түзә алыр идемме? ...Дипломнарны яклагач,юлламаны үзем сорап Чиләбегә алдым.

...Кырыгын үткәргәндә шул Котельников марҗасы Тамара килеп утырды яныма. Кызмача. Әүвәл,муеныннан асылынган алтын тәресе бал салынган чынаякка килеп төшкәч, берникадәр вакыт шуны тастымалга ышкый-ышкый сүгенде. Аннары, зур бер акыл иясе кебек кыланып,нәрсәдер аңлатмакчы булып,сүз аралаш: «ты понимаешь»—дип,мыгырданып теңкәмә тиде. Мин аңа,тыңламыйча гына,баш кагып утырдым. Кинәт ул симез кулы белән шап итеп өстәлгә сукты: «Ты понимаешь, он спал с ней!» Мин сискәнеп киттем: «Кем? Кем белән?» «Минем Котельников синең Ленаң белән! И не раз! Земля ей пухом...»

Халык күп иде мәҗлестә,бу шау-шуда моны ишеткән кеше булмагандыр. Мин исә, җирәнүемне яшереп тә тормыйча, мәҗлес бүлмәсенең аргы очына күчеп утырдым. Мондый гайбәтләрнең бәһасен беләм мин. Хатыным исән чакта да андый ишарә-кинаяләрне җиткерәләр иде миңа «яхшылык теләүчеләр». Бер заман Шиняков белән бәйләп гайбәт сатып алганнар иде, Валидов исемен дә Лена белән кушып чәйнәгәннәре булды. Ә болар барысы да минем коллегалар. Көнләшүдән, кызыгудан туа андый сүзләр. Ленам, мәрхүмә, бик чибәр, бик сөйкемле иде. Үзем дә төшеп калганнардан түгел. Үз гаиләсендә төзеклек булмаган бәндәләрнең ачуын чыгара бу. Безнең бер-беребезне яратуыбыз күренеп тора иде бит. Дип уйлыйм. Дип ышанам... Беренче мәхәббәтем иде минем Ленам. Һәм соңгысы да. Бүтәнчә мөмкин түгел. Беренче һәм соңгы мәхәббәтем. Бәхил бул,бәгърем... Озакламый очрашырбыз. Беренчем...

## 2010 елның язы

Яшәгән саен яшисе килә!..

Бәхетнең иң югары ноктасы бу. Шундый мизгелдә уяну—үзе бер ләззәт.

Апрель кояшының иртәнге нуры борынымны кытыклый башлаганнан уяндым. Озаграк йокланып киткән. Вакыт сигездән авышкан инде. Бүген шимбә. Рәйханә эшкә китеп өлгергән. Уянмаганмын. Тегү фабрикасында технолог булып эшли ул. Яңа модельләр үзләштергән көннәрдә шимбәләрен дә эшләргә туры килә.

Дөресен әйтим, Рәйханәгә күптән күзем төшкән иде минем. Бер ун еллап инде. Урамда чибәр хатыннарга сокланып карау гөнаһ түгел бит ул. Соклану—кызыгу түгел. Хәер, әзрәк кенә кызыгу да булгандыр. Аны Лена урынында (әстәгъфирулла!) күз алдыма китереп караган мизгелләр дә булды бугай.

Рәйханәне күргәләгән-очраткалаган чаклар урамда гына булмады. Безнең заводта эшләнә торган баллистик ракеталарның пиротехник кабындыру җайланмаларында чәнчә бармак зурлыгындагы дары капчыклары кулланыла: картуз дип аталган шул капчыкларны киндер тукымадан күрше тегү фабрикасында тегәләр. Шуңа ул елларда фабрикада булгаларга туры килә иде миңа. Ягымлы, җитез, чибәр, тирән белемле бу технолог кыз беренче очрашудан ук хәтергә уелып калган иде,әйе.

...Торып,ванна бүлмәсенә чыктым. Анда Рәйханә көзге кырыена язу кыстырып

калдырган: «Сөйгәнем, бердәнберем, кадерлем, газиз ирем! Сәгатьләрне-гасырларны санамый, булганын-булмаганын бүлешеп, мәңге синең белән генә яшисем килә. Көннәреңне яктырак, куанычлырак итә алсам, үзем дә бәхетемә ирештем дия алыр идем. Узгандагы хәсрәтләрең йөген җиңеләйтә алмамдыр, аңлыйм, ләкин яңа хәсрәтләргә юл бирмәскә көчем җитәр, багърем. Чөнки яратам. Чөнки минем бәхетем син. Иң матур көннәребез алда әле безнең!..»

Теге вакытта, үземнең аннан ун яшькә өлкән булуымны белгәч, йөрәгемне йөгәнләргә акылым җиткән иде. Менә дигән хатыным була торып, янәсе... Әле Фәритем дә мәктәптә укып йөргән еллар ул. Рәйхәнәнең үз гаиләсе дә тәзек-имин иде ул чакта. Ире, Валера, — шофер, зур машина белән ерак араларга йөк ташый иде бугай, андыйларны «дальнобойщик» диләр. Командировкаларының берсендә Краснодарда хахул хатын белән чуалып, шуңа йортка кергән. Һәм вәссәлам. Биш ел буе хаты-сүзе дә, кызлары Алисәгә бер тиен ярдәм акчасы да килмәгән. Гаризаларын почта аша алмашып, «читтән торып» аерылышканнар.

«Салкын. Сине уйлап җылынам». «Хыялымда гына булса да, бик тә назлап үбәм сине». «Хәбәрең өчен рәхмәт! Кояш та яктырак яна башлаган кебек булып китте».

Кесә телефоны, әй, шундый могҗиза да инде ул, ә! Бер-беребезгә «эсэмэс» язмыйча ярты көн дә түзә алмыйбыз. Дүрт-биш ел гына элек үземне мондый кыланышка, мондый бала-чагалыкка, җиңел акыллылыкка сәләтле дип башыма да китерә алмаган булыр идем. Зур җитди заводның зур җитди җитәкчесе бит, минсиңайтим... Ә үземне үсмер малай итеп сизәм еш кына. Рәйхәнә җибәргән хәбәрләрне озаклап саклыйм, ялгыз калган минутларда шуларны рәхәтләнеп телефонымнан шыпырт кына укып утырам. «Ә»не «э» дип, «һ»ны «х» дип язарга туры килсә дә, татарча язарга тырышабыз үзебез.

«Минем сүзләремдә, уйлап бетермичә әйтелгәннәрендә дә, әллә нинди яшерен мәгънә эзли күрмә. Мин синеке, мин сине эчкерсез яратам. Минем сиңа мөнәсәбәтемне беркем үзгәртә алмый. Хәтта син үзең дә». «Алтыным, миңа берни кирәкми. Син кирәк. Үзең исән-сау кайт». (Бусы мин Чиләбегә, Министрлыкка барган көндә булгандыр). «Әйтсәм көлмә, яме: көнозын сине уйлыйм, син исән булсын дип догалар укыйм. Сиңа файдасы юктыр аның, бәлки, ә миңа юаныч».

Ләнаның вафатыннан сигез айлап вакыт узган иде инде — Культура сараенда, тегү фабрикасының илле еллык юбилей тантанасында урыннарыбыз бергә туры килде Рәйхәнә белән. Фатирларыбыз бер якта булгач, урам буйлап бергә кайттык. Шул ярты сәгать эчендә бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә ни генә сөйләшенелмәде! Фабрика теккән картузларның сыйфаты турында да, мәктәп тормышы турында да (аның Алисәсе җиденчене тәмамлый икән), һәр икебезнең Татарстанда яшәп ятучы туганнарын да барлап чыктык. Аның ялгызлыкка, ирсез яшәүнең михнәтләренә зарлануын көтеп: «Кызыңны берүзең үстерәсең икән», — дип сүз башлаган идем, ул шундый күтәренкелек белән: «Бер дә авыр түгел, тормышым түгәрәк, бик тә бәхетле кеше мин, кияүдә яшәгән чагыма караганда күп тапкыр бәхетлерәк», — дип авызымны япты — мин хәтта югалып калдым. Шундый ягымлы, сүзчән сылу белән төне буе сөйләшеп йөрергә әзер идем. Үземнең исә — унбиш яшьлек малай төсле, саубуллашу алдыннан, тотлыга-тотлыга: «Ни... Бәлки, әзрәк дуслашып китә алырбыз?» — дияргә генә тәвәккәллегем җитте. «Бәлки!» — диде дә, ишегенә кереп югалды.

«Кояшым! Юри котырта дип уйлый күрмә, ләкин чынлап та мин сине бик сагындым!» «Чакырсаң, йөгереп килəм! Йөзеп килəм! Очып килəм! Чакыр гына!»

Ләкин беренче айларда мондый җылылыкның эзе дә булмады әле. Ял саен Чиләбе театрларына йөреп, җәйге кичләрне көн саен диярлек бергә табигать кочагында үткәрсәк тә, язмышларны кушу турында ишетергә дә теләмәде Рәйхәнә. «Без болай гына бит...» Әйтерсең лә арабызда әллә нинди киртә. Узган тормышы, ачы тәҗрибәсе мөмкинлек бирмәдеме аңа ачылып китәргә? «Без иш түгел идек бит, — дип аңлатты ул моны соңрак. — Син зур нәчәлник, читтән бик кырыс, туң йөрәкле бәндә булып күренә идең, миңа уенчык итеп карыйдыр дип уйладым. Мондый икәнеңне белмәгәнмен». «Нинди ул — «мондый?» «Менә... мондый... саф күңелле, самими...»

«Син бит бик көчле кеше: үзең беләсеңме шуны? Очрашкан саен синең куәтеңдә коенып рәхәтләнәм». «Кадерлем, аңлыйм: син мине яратасың, шуңа күрә артыграк мактап җибәрәсең. Андый ук идеал түгел бит мин!»

Менә шулай, үземнең кешеләр каршында кемлегемне, кем булып күренгәнемне

белмәгәнмен дә. Ләкин киләчәк тормышымны Рәйханәсез күз алдыма китерә алмый идем инде. Берзаман,Тирәнкүлдән кайтышлый: «Әйдә,киләсе җәй Казанга бергә кайтып килик»,—дигән идем: «Әй,киләсе җәй кайда да,без кайда әле»,—дип җавап бирде. Ягъни безнең мөнәсәбәтләрнең гомере озын булмавы да мөмкин дип аңла. Шуннан соң,төшләремә әллә нәрсәләр кереп,төннәрен сискәнеп уяна башладым. Кара әле,шушы яшемә җитеп,шулкадәрле тормыш тәҗрибәм белән, гади бер кыз аркасында тынычлыгымны җуйдым бит,ә!

Бусы,менә,мин язган «эсэмэс»лар: «Тавышыңны,күзләреңне,ирennәреңне сагындым! Ә син?» «Иреннәреңне, чәчләреңне үбәсем килә. Диагноз—«ычкындым» бугай. Менә нишләттең».

Өметләрем-теләкләрем ташкыны, хисләремнең дөрләгән ялкыны күзләремдә дә, кыланышларымда да чагылып торгандыр—берникадәр вакыттан аның битарафлыгы бераз җылырак мөнәсәбәткә алышына башлады. Август башында Алисәне бер төркем сыйныфташлары һәм укытучылар белән ике атнага Кара диңгезгә,Дагомыс лагерена озаттык. Шунда гына Рәйханә тәүге тапкыр миндә куна калды. Минем өчен (аның өчен дә дип уйлыйсым килә) яңа тормыш башланды. «Яратам»—дигән сүзен дә ишетелер-ишетелмәс итеп шунда әйтте ул.

«Синең ярдәмең белән мин үземнең кемлегемне,үземнең бәямне аңладым. Миңа мине бүләк итеп бирдең син,рәхмәт сиңа!» «Тәнем иреннәреңне әле дә хәтерли...»

Шуннан да артыгын көтмәгән булса кирәк Рәйханәм: көзнең кояшлы бер якшәмбесендә: «ЗАГСта язылышып,сиңа үземнең фамилиямне биреп,тыйнак кына булса да туй үткәреп,үз фатирымда синең белән яши башласам гына тулысынча бәхетле дип санар идем мин үземне»,—дигән идем, күкрәгемә капланып үксеп елап җибәрде. Ниятләремнең җитдилегенә соңга кадәр ышанып бетмәгән икән. «Үкенмәссеңме?»—дип сорады ул. «Миңа ярты бәхет кирәкми,—дидем мин.—Син миңа тулаем кирәк. Бербөтен. Мин «болай гына» яшәргә теләмим. Миңа чын гаилә кирәк. Синең чын мәхәббәтең кирәк. Шуны бирергә тырышсаң, үкенмәм». «Алай булгач, мин бүгеннән гомеремне сиңа тапшырам»,—дип пышылдады акыллым. Шул ук көнне,ул үтенеп сорагач,зур чәчәк бәйләме күтәреп зиратка, Лена янына бардык. Үпкәләмәсен димәкче булгандырмы?

...Чәй өстәле янындагы урындыкта Гомәр Бәшировның «Намус»ы ята. Китапларны укыган җирендә калдыра торган гадәте бар. Тиз укый—әле өченче көн генә «Мастер и Маргарита»ны күргән идем кулында.

...Ишек төбендәге шүрлектә кесә телефоны Бетховен көен уйнап җибәрде: Алисә онытып калдырган—хәзер дәрестә кайгырып утыра булса кирәк. Параллель сыйныфтан иптәш кызы шалтыратадыр. Бүген Фәрит кайтырга тиеш: Чиләбедә яшәсә дә,һәр шимбә кайтып йөри ул. Һәм һәр шимбә кичке аш—бәйрәм ашы безнең өчен: барыбыз бергә җыелып озаклап сөйләшеп утырабыз.

«Әле генә аңладым: мин гомер буе сине сагынып яшәгәнмен бит». «Үлеп яратам сине. Аңлатып бир,дисәләр,булдыралмас идем. Мәхәббәтнең ни икәнен, аның төзелешен беркем белми бит».

...Мин дә белмим, бәгърем. Әүвәл—гомер буе: тормышта беренче мәхәббәттән бүтән чын мәхәббәт булмый дип ышанып яшәдем. Аннары, язмышымны фаҗига актарып ташлагач,бакыйлыкка җыена башларга вакыт җитте дип уйладым. Ә сине тапкач,бу да,бүтән ялгыз хатыннар кебек,бер дәшү белән кочагыма атылып,муеныма асылыныр дип ялгыштым. Бер калып кануннарына буйсынган нәрсә түгел икән ул мәхәббәт. Беренче булса да, бишенче булса да—чын булсын.

Тәрәзә төбенә таянып,йөземне төшкә якынлашып килгән кояшка куйдым. Йөрәктә бернинди шом-тәшвиш юк бугай. Борчусызлык гадәттә сагайта күңелне. Чынлап та юкмы кайгырырлык нәрсә? Юк,юк! Тәндә шундый җиңеллек,җанда шундый илһам—дөньяны үзгәртеп корырга да көчем җитәр кебек. Менә бит ул—онытылып бетә язган ләззәтле халәт!..

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ РАФАЭЛЬ

## Дөньяга килүем

Әти-әниләрем 1931 елда Баулының Фрунзе урамында, бер сукыр карт өендә торганнар. Әтием райисполкомда жир инженеры-землемер булып эшләгән, әнием гаилә тәрбияләгән.

2 май көнне әтием белән әнием кунакка барганнар. Ашаганнар, эчкәннәр. Әтием әзрәк салган, әнием исә аракыны авызына якын да китермәгән.

Кайтканда әнием бик авырлык белән генә, жай гына кайта икән. Әтием әйткән: «Күтәреп кенә алып кайтыйммы әллә үзеңне? Тизрәк булыр иде»,—дигән. «Кит аннан!—дигән әнием.—Дөньяда булмаганны. Үзем кайтып житәм, үз аягым белән...»

Шулай әкрен генә кайтып житкәннәр. Ә таң алдыннан әниемне тулгак тота башлаган. Әтием кендек әбисенә йөгергән. Әби шундук килеп житкән, баланы кабул иткән, кендеген кискән. Шуннан соң әтием атын жиккән дә күрше авыл Ак Буадагы фельдшерны алырга киткән. Фельдшер да берсүзсез килеп житкән, икебезне дә бик жентекләп караган. «Барысы да дөрес, барысы да тәртиптә», —дигән. Ул мине бик мактаган. Туп кебек таза-түгәрәк, дигән. Бәхете булыр, дигән. Зур кеше булгач, мине исегезгә төшерерсез, дигән. Әниемне дә бик мактаган. Мондый матур хатын-кызлар сирәк була, дигән. Әзрәк салам кыстырган инде. Әниемнең күңелен күрергә тырышкан. Әтием дә аны буш калдырмаган. Алдан алып, әзерләп куйган яртысын тоттырган да, тарантаска утыртып, кире илтеп куйган. Менә шул...

## Миңа багышланган тавык турында языйм әле

Ул елны яз бик иртә килгән. Өченче май көнне әтием тәрәзәдән карап тора икән. Көн кояшлы, матур, искиткеч жылы. Чирәмнәр ямь-яшел, хәтта алмагачлар да чәчәк аткан. Мондый еллар сирәк була. Әнием моны минем бәхетемә юраган.

Шул ук көнне күрше хатыны тавык утырткан икән. Минем туганны ишеткәч, бер күкәйне кара белән буяп, миңа багышлаган. Тора-бара шул күкәйдән сап-сары, матур бер чебеш чыккан. Тап-таза булып үскән, менә дигән тавык булган. Беркөнне күрше хатыны тавыкны суйган, бик әйбәтләп йонын йолкып, эчен-башын чистартып, әниемә алып килгән. Әнием шул тавыкны пешереп, шулпасын миңа эчерткән, итен үзләре ашаганнар.

Боларны сөйләгәндә әнием күрше хатынның исемен дә хәтерләми иде инде. Ә бит ул да миңа яхшылык кына теләгән. Мин үсүем белән аңа да бурычлымын!

Күпме булгандыр минем язмышымда шундый эчкерсез ярдәм итүчеләр! Халкым мине үстергән, тәрбияләгән. Мин дә халкым алдында бурычлы икәнлегемне тоеп яшим.

## Ике туган көнем

Һәркемнең туган көне бер генә була. Мин исә бу дөньяга килгән көнемне елына ике мәртәбә билгеләп үтәм. Өченче һәм ундүртенче майда.

Ничек алай булуы мөмкин, дисезме?

Әнием сүзенә караганда, мин Баулы район үзәгендә өченче майда иртәнге якта дөньяга килгәнмен.

1931 ел—колхозлашу чорының иң кызган чагы. Әти районда җир бүлеп йөргән, вакыт ягы да бик кысан икән. Ә вакыт табып мине яздырырга ЗАГСка килгәч, минем әллә кайчан туган булуымны әйтергә уңайсызланып, шушы көнне, ягъни «14 май» дип яздырган.

Ике туган көнең булу бик җайлы икән. Өченче майда туганнарым, иң якын дусларым җыела. Өйдә генә гөрләшеп бәйрәм итәбез. Ә 14 май көнне, паспортта язылганча туган көнем килеп җиткәч, бәйрәм берникадәр рәсмирәк төс ала. Төрле оешмалардан, мәктәпләрдән шалтыраталар, котлаулар, рәсми очрашулар... Ул көнгә тантаналы кичәләр, банкетлар да билгеләнә...

Ләкин бу күренешнең икенче ягы да бар. Ике туган көнең булгач, ике кеше өчен эшләргә, җавап бирергә, икеләтә тырышырга да туры килә.

## Балан суы



—Синең белән авырлы вакытта кинәт кенә балан суы эчәсем килеп китте, —дип сөйләгән иде бер вакыт әни. —Авырлы вакытта була бит инде ул. Күнелең тели икән—берни эшләп булмый. Халыкта шундый сүз бар: «Авырлы хатынның җаны ни теләсә, шуны ашатырга кирәк. Югыйсә баласы зәгыйфь булуы мөмкин».

Шул... Теләвен телим, әмма баланны каян алырга? Кыш уртасы, инде язга авышкан. Февраль ахырлары, март башлары. Сорашып-сорашып карадым күршетирәдән—берсендә дә юк. Кайсы кипкән алма, кайсы җиләк, кайсы карлыган кагы тәкъдим итә. Әтиең дә Баулының буеннан-буена айкап эзләп карады—тапмады.

Шунда кемдер әйтте: «Булса, Зөләйха түтидә генә булыр. Ул баланны көздән җыеп киптерә.» Киттем Зөләйха апаларга. Аңлаттым хәлемне. «Әйе, —ди.—Бар иде шул әзрәк. Иртәгә чормага менәсем бар, шуннан алып төшәрмен, килерсен.»

—Юк, мин әйтәм, иртәгә хәтле түзәр хәлем юк, миңа хәзер үк, шушы минутта ук кирәк. Көлде дә, чормага менеп китте апакай. Күп итеп бирде. Алып кайттым да шикәр белән кайнатып, туйганчы эчтем. Шунда күңелем булды да инде. Югыйсә синең берәр җиреӊ камил булмас иде.

Рәхмәт Зөләйха түтигә. Авыр туфрагы җиңел булсын...

## Мавыктыргыч китап дөньясы

Минем нәни чагым зур калаларда, рус халкы арасында узды. Әтием хәрби кеше булганга, аны әле бер, әле икенче урынга күчереп йөртә иделәр. Казан каласында мин балалар бакчасына йөрдем, Мәскәүдә беренче, Ленинградта икенче сыйныфта укыдым. Ватан сугышы башлангач исә әтием безне туган якларына —Оренбург өлкәсе, Шарлык районы, Яңа Муса авылына эвакуациягә кайтарып җибәрде.

Монда килү белән мин үзем өчен бөтенләй яңа дөнья ачтым. Бала-чага уеннарыннан бигрәк өлкәннәр белән аралаша, алар сүзенә колак сала идем.

Ни өчен дигәндә, мин кечкенәдән шактый үткер булып үстем. Биш яшем тулыртулмас үзлегемнән укырга өйрәндем. Бу болай булды. Әнием татар мәктәбендә революциягә чаклы укыганга, рус грамотасын белми иде. Әтием исә —кызыл командир, өлкән лейтенант, Мәскәүнең Фрунзе исемендәге Хәрби академиясендә укый. Буш вакытларында әниемне рус хәрефләрен танырга өйрәтә. Без тар гына, бәләкәй генә бүлмәдә яшәгәнгә, мин дә шунда ук бөтереләм. Әнием төшенеп җиткәнче, мин инде хәрефләрне отып алам. Соңыннан, урамда йөргәндә, төрле язуларга карап, әнием белән сынаша идек. Ул ялгыш укыса, мин төзәтәм,мин берәр хәрефне онытсам, әнием искә төшерә.

Шул чактан ук китапханәгә йөреп, башта балалар өчен язылган, матур итеп

бизәлгән, рәсемле, сонышнан шактый калын китапларны укый башладым. Русча,әлбәттә. Беренче сыйныфка йөри башлагач, укытучы апа башкаларга хәреф анлата. Мин исә, парта астына яшереп, Жюль Верн, Майн Рид , Дюма романнарын йотлыгып укыйм. Укытучы мине орышып та карады. Соңыннан, хәреф тануымны күргәч, кулын гына селтәде.

## Сугыш газаплары

«Бәхетле балачагымнын» хәтердә ин нык уелып калган истәлеге —эвакуация вакыйгасы. Без әнием белән Ленинградтан камалышта калу алдында —1941 елның август ахырларында китеп өлгердек. Эшелон Оренбург өлкәсенә кадәр унжиде тәүлек буе барды. Юлда чакта фашист самолетлары эшелоныбызны берничә мәртәбә бомбага тотты. Аеруча көчле һөҗүм Тула станциясе янында булды. Поезд тупикта туктап тора иде. Паровозны нинди дер хәрби эшелон өчен алдылар, һава тревогасы игълан ителгәч, халык, вагоннардан сибелеп, тирә-яктагы әрәмәгә йөгерде. Әнием дә мине, ун яшьлек малайны, кулыннан ычкындырмыйча, читкә чапты. Ул арада бомбалар коела башлады. Ниндидер юеш канау очрагач, әнием мине шунда көчләп диярлек йөз түбән яткырды, үзе, мине пычракка батырып, өстемә ятты.



Шуннан китте мәхшәр!.. Бомбалар колакны тондырып шартлый, кыйпылчыклары сызгырып баш өстеннән уза... Жир тетрәп тора—әйтерсен, таганда атынасың. Кемдер сүгенә, кемдер ләгънәт укый-укый ыңгыраша. Якында гына әрнеп кычкырган бала тавышы ишетелә. Әмма мин әллә ни курыкмадым. Чөнки мине үз тәне белән әнием каплаган, әнием саклый. Киресенчә, башымны күтәреп, немец самолетларын күреп каласым килә.Әмма әнием мине, башыма басып, кире сазлыкка батыра... Күпме кеше һәлак булгандыр ул көнне, әйтүе кыен. Безнең дынгычлап тутырылган вагонда шактый урын бушап калды. Стансаларны бомбага тотканга күрә, поезд күбесенчә йә кыр, йә урман уртасында туктый иде. Әнием юлга азык-төлек әйберләрен шактый алган булса да, башкалар белән бүлеште. Үзең ашаганда ач бала-чага күзенә карап торса, ничек түзәсен? Шулай итеп, алган ризыгыбыз өч-дүрт көнгә генә житте. Калган юлны ипи валчыгын күрмичә, хәтта кайвакыт эчәргә бер йотым су таба алмыйча үттек. Оренбург өлкәсенә килеп житкәнче икебез дә коры сөяккә калган идек инде.

## Бабам васыятьләре

Мин мәктәпне тәмамлап Казанга укырга китәргә жыенганда, әтием урынына калган бабам (әтием сугышта һәлак булды) каршысына утыртты да: «Тынла, оныгым, сиңа тормышта ничек яшәргә—васыятемне әйтеп калдырам, —диде. —Безнең нәселдә беркайчан да аракы эчүче булмады. Кеше булырга телисең икән, ул агудан саклан». Әйтү генә бер хәл, ул үзе дә миңа үрнәк иде, гомергә авызына хәмер алмады. Бергә Оренбургка барганда, жәйге эсседә мин квас алам, бабайга да тәкъдим итәм. Ул исә: «Юк, юк, йә спирты булыр, мин су гына эчәм», —ди торган иде.

Бабамның икенче васыяте: «Безнең нәселебездә гаиләсен ташлап, хатынын аерып жибәргән кеше булмады. Әлбәттә, син үзенә яхшырак хатын таба алырсың, әмма балаларыңа яхшырак әни таба алмассың. Өлешеңә тигән көмешеңне саклап, шуңа тотынып яшә!»

«Нәселебездә кеше белән талашып, дәгъвалашып, судлашып йөрүчеләр булмады, шуңардан саклан. Хәтта үзең хаклы булсаң да, бәйләнмә!»

Бабамның бу киңәшләре күңелемә сеңде. Гомер буе шушы өч васыятькә ябышып яшәдем.

## Әнием фатихасы

Миңа инде 80. Һәрвакыт Баулыга, әнием янына кайта идем. Ул анда сеңлемнең гаиләсе белән яшәде. Әнием йөзне узып яшәде. Ул һәрвакыт миннән тормышым турында сораша, кайгырта, киңәшләрен бирә иде. Ничектер ярдәм итәргә тырыша. Мин исә үземне әнием янында бала кебек хис итә идем, «улым» булып калдым. Әйе, әниле булу бик зур бәхет. Иртән уянганда өйгә таба исе таралган була—әнием минем нәрсә яратканымны белеп, пәрәмәчләр пешерә иде.

Әниемнең исеме Фатыйма иде. Яшь чагында «матур Фатыйма» дип йөрткәннәр аны. Күңеле дә бик матур иде аның, беркайчан да кешегә карата үч, кара хис сакламады. Миңа да гел: «Улым, кешегә күңелеңдәгенең, турысын әйт. Үч сакласаң, кешегә яман күз белән карасаң, картаясың», —ди торган иде.

Каян белгән диген тормышны шулай яшәсәң әйбәтрәк буласын? Рәхмәт ана! Ходай Тәгалә аның хәер-фатихасыннан аермасын!

**Рафаэль МОСТАФИН**

---

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

## Бүген

***Йокыдан уянып та җитмәстән, Наилнең башына шундый уй килде:*** булды, житте! Бүгеннән ташларга кирәк! Ничә ел инде? Әһә! Икенче курста укыган вакытта башланды бугай. Бүлмәдәш егет инде мәктәптә укыганда ук тарта башлаган булган икән. Башта аңа иптәшкә тартты Наил. Рифат җәлләми иде сигаретын; хәер, булганда җәлли торган нәрсә түгел, булмаса читен! Күпме тартырга була кешенекен, Наил баштарак чатта сатучы әбиләрдән берне-берне алгалады, тора-бара ул гына да җитмәде, пачкалап... Кесәдә вакытта алай күп тартылмый үзе, лекция араларында, тәнәфесләргә чыккач кына пыскыталар иде, качыбрак кына. Ни дисәң дә, институт бит, яхшы түгел.

Наилнең хәтерендә әле: армиядә хезмәт иткәндә дә тартмады ул, тәмәкече егетләрнең бер сигаретны әллә ничәү тәмләп имгәнен, тартырларына юк чакта офицерлардан калган төпчекләрне җыюларын күреп гаҗәпләнгән чаклары аз булмады. Кайбер кыюраклары юмартрак офицерлардан да сорарга җөрьәт итәләр иде. Бервакыт Казан егете Робертка өеннән посылка салганнар икән. Бер блок «Казанская астра» җибәргәннәр моңа. Сырлы кәгазьле иде ул, әллә нәрсәсенә әнә шул сигаретлар модада иде ул чакта. Робертның дәрәҗә күтәрелгән иде шул вакыт. Ун пачканы байтакка җиткерделәр егетләр.

Наил елмаеп куйды. Ул чакта әле: «Төтенме—төтен, нәрсәсе бар инде шуның, ник шул тиклем мөкиббән китәләр икән шул «Казанская астрага»?—дип уйлаган иде ул. Инде үзе дә бу эшкә хирысланып киткәч, чамалый башлады. Ниндиләрен генә тартмады ул: болгарский да калмады, «Сабантуй» да, «Бонд» та.

Бүген якшәмбе, сонрак торсаң да була. Наил тагын хатирәләргә чумды. Мәктәптә тугызда укыган чак. Җәйге каникул вакытында колхозда төзелеш бригадасында эшләгән иде алар. Рәшит абыйлары—старшийлары. Иртән җыелып беткәч, эш башлаганчы—бер тартып алу. «Спонсор»—Рәшит абый. Бер дә саран түгел иде, мәрхүм. Берчак кибетләрдә тартырга тәмам беткәч тә, анда бетмәде тәмәке. Хатыны кибетче иде. Кеше «төрдемгә» калгач та Рәшит абый өзелмәде аннан. Шулай бер көнне барысы да эш урынына җыелдылар, Рәшит абый юк та юк, югыйсә иң беренче килә торган иде. Төпчек улы аша ярты пачка сигарет биреп җибәргән иде ул, үзе авырып киткән икән... Шул берөзлексез тартканга инде.

«Акыллы түгел тәмәкечеләр!—дип уйлап куйды Наил.—Үзеннең газиз организмына шул агуны дыңгычлап тутыр инде, югыйсә зыяны турында бик яхшы белә бит алар!» Чыннан да, акча убыры инде; өченчесе дә бар әле: эш башлар алдыннан, әйдә, бер тартыйк, әйдә, бер перекур ди-ди күпме вакытны әрәмгә уздыруы турында бер генә тәмәкеченең дә уйлап караганы юктыр, мөгаен. Исәпләсәң...

Караваты янында торган өстәл өстендәге сотовыена үрелгән вакытта тагын өянәге кузгалды, буылып йөткерә башлады Наил. Сигез тулып киткән икән, торырга кирәк, әнә абзарда сыер да мөгри башлаган, чыгарга кирәк.

Все! Бүгеннән тартмыйм, житте! 20 ел тартты инде, көн саен бер пачка бит ул! Ходай мене дигән сәламәтлек биргән үзенә, шуның кадерен белмә инде. Әле беркөн исәпләп караган иде, шул вакыт эчендә 146 мең (!) сигарет тартылган. Коточкыч! Житте, бүгеннән ташларга кирәк! Ничу тәмәке фабрикасы директорларын баетып ятарга! Әнә хатыны да колак итен гел тукый. Ташларга тек ташларга!

Әй, тукта инде, аяк киемен өйдә калдырып чыккан бит, тавыкларга дигән әчеткене дә ала чыгарга кирәк... Хәзер, хәзер, Йолдыз, аз гына сабыр ит инде, су да бирәм, башак та. Хәзер...

...Куллар үзеннән-үзе җәһәт кенә кесәгә кереп чыкты; уң якта—кызыл пачкалы «Максим», сулында—шырпысы. Үнәчне яндырып үпкәгә әчкелтем зәһәр төтен тулды. «Тукта, мене бу башлаган пачканы гына бетерим дә...»

**«Сүнмәс утлар балкышы»**
**китабын дәгъвалаучыларның берсе...**

## Танышу

***Төн уртасы булгач, шәһәр автобуслары йөрми иде инде. Юл читендә берүзе басып торган Алия янына номерсыз машина килеп туктады.***

«Утырыргамы, утырмаскамы?—дип уйлады Алия.—Бик шикле күренә бу машина.»

Алгы ишек ачылды, шофер:

—Утырыгыз!—дип кычкырды.

Арткы утыргычта тагы берәү шәйләнә. Кызның башка чарасы калмаган иде, утырмаса да аны сөйрәп алып кереп, алып китә алалар иде, тирә-якта эт тә юк.

Кыз утырды. Арттагы кеше дә кыймылдап, пошкырып куйды. Мохит бик киеренке иде. Әллә каян башына килде, машина кузгалуга ук, ул үзенә хас булмаган тавыш һәм кыюлык белән:

—Мине әле генә көчләделәр!—дип сулкылдый башлады.

—Кем? Кайда?—дип кычкырды арттагысы.

—Куаклар арасында!—диде кыз яшенә буылып.—Мине тиз генә әнә теге хастаханәгә илтеп куегыз, зинһар... Мин ул егетләрнең берсен таныдым. Ул безнең күрше подъездда яши. Ике тапкыр утырып чыккан. Ул сифилис, спид белән авырый.

Машина алга ыргылды. Хастаханәгә житәрәк кыз әйтте:

—Туктагыз!—диде.—Мин төшәм.

—Хастаханәгә житмәдек бит әле,—диде шофер егет.

—Минем йортта атаклы венеролог яши, мин аңа гына күренермен!—дип, кыз машинадан төште дә кырый йортка таба йөгерде. Ул подъездга кереп, ишек борысына посып кына машина ягына карады. Машина бераз алга китте дә туктады.

Котылганына сөенеп, кыз каравыл янынннан үтеп китте.

—Соңга калдың, кызый!—диде төнге каравылчы.—Язып куям.

Кыз атылып бүлмәгә килеп керде, кызлар йокламый иде әле, алар имтиханга әзерләнә.

—Кызлар!—дип кычкырды соңлаучы.—Мин маньякларны алдап качтым!

Ул аларга мажарасын сөйләде, кызлар тәгәри-тәгәри көлә башладылар.

Шулчак ишек шакыдылар, ишектән каравылчы, ике милиционер һәм баягы

машина шоферы күренде.

—Кайда ул көчләнгән кыз?—диде милиционерларның берсе.

Шофер егет әлеге кызга күрсәтте.

—Хәзер без протокол төзибез дә, сезне хастаханәгә алып китәбез!—диде милиционер.

Кыз ни булганын сөйләргә мәҗбүр иде. Шофер исә атасын аэропорттан алып кайтып килгәндә шушы кызны утыртканын сөйләде.

Аңлаштылар. Көлештеләр. Шуннан соң егет гел аны машинасы белән каршы алып, тулай торакка китереп куя торган булып китте.

Озакламый алар өйләнештеләр.

**Турай**

## Көзге күбәләк

***Идел үзенә кирәкмәгән бөтен нәрсәне ярга чыгарып аткан. Камилә «Fanta»дан бушаган шешә эчендә түгәрәклэп бөтәрләнгән конвертлы хат күреп өнсез калды...*** Елаганнан шешенеп беткән күзләре белән хәлсезләнеп калган, дер-дер калтыраган кулларындагы кәгазьнең уйнаклап торган хәрефләрен тыныша-тырыша укырга маташты. «Камиләм, матурым, мине исенә төшереп күңеленне телгәләмә. Зинһар һәр елны үзенең кечкенә йортчыгында сине зарыгып көтүче әбиең хакына булса да, бар көченне кулкайларыңа җый да, яңа тормыш башла. Мин киттем дип тормыш бетми бит!..»...

...Сап-сары кояш нурларында иркәләнеп, җылынган суларын акрын гына каядыр билгесезлеккә таба агызган бөек елга ярында күбәләкләр кебек бер-берсе артыннан очынып-очынып куышкач, сулыш алырга дип бераз туктап, Айнур:

—Камиләм, сандугачым, әйдә, җырлап җибәр әле,—дип, кыргый бәти кебек һаман уйнарга теләп, сикерүеннән туктарга җыенмаган сөеклесенә таба якынлашты; Камилә үзенә күрә бер төрле моңлы җырын сузгач, кочаклашып, акрын гына «медляк» бии башладылар.

—Мин сине яратам,—дип пышылдады Айнур.

Бу көнне Камилә һич онытмас, ялганып, мәңге җаның-тәненә ашып торган ратуын белән бүлешкән, күңеленә сөю белән ялганып, кадерле булган кешең су буе чирәмендә ята. Кулларыңны як-якка аккош кебек җәеп салган көе син аның кырында йокымсырап, изрәп кояш нурларында күзләреңне уйнатасың. Шул вакыт аның йөрәгеннән ташып торган хисләре җылысын тоясың.

...Камилә кеше чүп-чар ташлап пычратып бетергән бөек елга яры комы өстеннән шушы язуны тапты. Һәлакәткә очрап вафат булган Айнурын оныта алмый бит. Күңелендәге хисләр ташкынын туктата алмыйча, тавыш-тынсыз елап җибәрде ул.

«Юк, елама, сөеклем, җанымны борчыма тәккә, тамызма бүтән күз яшенне. Тиздән кар явар, бураннар килер, синең битеңне чеметерләр, матурым, алтыным. Төштә күрдем, бер төнне гүя мин һавага күтәрелдем дә, аннан кош булып кире синең тәрәзә төбенә килеп кундым... Бәлки, бу төш чынга ашар?..»

Камилә яшьләренә буыла-буыла елга ярыннан урам тротуарына чыкты. Күктә кояш юк, бөтен җирне караңгы болыт өерләре каплап алган... Вакыт-вакыт салкын, ачы көз җиле сөякләргә үтәрлек итеп исеп куя. Шул вакыт аңа «Мин дә синнән көчлерәк бит!» дигәндәй, саташып калган соңгы күбәләк очып үтте...

**Миләш,**
*15 яшь.*

***Конкурс дәвам итә. Шартларын 1нче саннан карагыз.***

## Табигать үзе шәбрәк белә

Күзенне ачыбрак йөрсәң, кайчагында сәер күренешләргә юлыгасың. Ун ел элек, юан, куе яшел яфраклары коела да башламаган зирек ботагының агымга каршы хәрәкәтенә шаккатып карап тордым. Бу могҗизаның ничек тәмамланасын күрәсем килде, шыпырт кына яр буйлап атлый башладым. Ерак бармаячагымны белә идем, чөнки «сәяхәтче ботак»ның юлында су өстенә ауган агач кәүсәсе күренә иде. Шулай да шактый озак атларга туры килде, «үзлегеннән йөзүче» агач агымга каршы акрын барды. Кәүсәгә килеп терәлгәч, ни хикмәт, агымга аркылы юнәлештә кәүсәне буйлап, ярга якынлашты, һәм, ниһаять... ботак астыннан зур кондыз, су асты көймәсеннән җибәрелгән ракета шикелле, киртләч ярга ыргылып күтәрелде. Яңа буа корырга җыеналар икән бу җан ияләре!



Ә кайбер очракларда сәер күренешләргә юлыгыр өчен әллә кая йөрүнең кирәге дә юк. Быел яз көнне иртән торып ишегалдына чыксам, ни күрим: яңа төзелә башлаган янкорма түбәсе кыегыннан боз сөңгеләренең эреләре, вертикаль белән барысы да бер чама зурлыктагы почмак хасил итеп, көнчыгыштан көнбатышка авышып катканнар. Ә ваклары вертикаль юнәлештән әлләни тайпылмаганнар. Тиз генә фотоаппаратны алып чыктым. Югыйсә, кояш нурлары җылыта башласа, сөңгеләр коелып та төшәрләр иде.

Өйдәгеләрем бу күренешкә әлләни гаҗәпләнмәде. Киресенчә, аларны минем шул фоторәсемне еш каравым гаҗәпләндерә. «Һии, исең киткән шуңа! Түбә кыегыннан тамчы тамган чакта җил көчле булган, шуңа күрә тамарга өлгермәгән су тамчылары, җил этәреше нәтиҗәсендә, уннан сулга тайпылыбрак, сөңге очында катып кала барганнар. Тапкансың уйланыр нәрсә!» Ике вектор суммасының нәтиҗәсен алар шулай популяр телдә җиңел генә аңлатып бирделәр. Әмма иң кызыгы анысы түгел бит әле. Шулай зур почмак тәшкил иткән юнәлештә боз сөңгеләре катып калсын өчен җилнең шактый көчле, ә һава температурасының нульдән шактый түбән булуы шарт. Ярый, мондый шартлар булсын да ди. Әмма боз сөңгеләрен «үстерү» өчен аларның башлангыч нокталарына җилле дә, салкын да һавада тиз генә туңып катмыйча «сөңге» очына тиклем агып төшәрлек җылы су агымы булырга тиеш лабаса! Янкорма әле төзелә генә башлады, аның эчендә идәне-түшәме дә, бернинди җылылык чыганаклары да юк. Кыскасы, үткән елның көзендә башланып, көн салкынаю белән киләсе яз көннәрендә дәвам итәргә дип «консервация»дә калган кечкенә генә бер төзелеш инде.

Менә шундый хикмәтле боз сөңгеләренең ничек пәйда булганын авторыгыз үзенчә аңлата алды. Әмма бу аңлатманы укучыларыма ачып салсам, алар арасында шактыеның, «чәйнәп каптырылгын нәрсә тәмле булмый» дип, үпкәләве дә ихтимал бит әле. Шуңа күрә, андый укучыларны баш эшләтү, уйлану һәм фикерләү ләззәтеннән мәхрүм итмәс өчен, язмама әлеге фотоны «ябыштырып», сүземне тәмамларга булдым. Язмамның исеме итеп үткән гасырның житмешенче елларында америкалы галим Барри Коммонер тарафыннан ачыкланган дүрт экология канунының берсен сайладым.

**Ким ШАКИРОВ**

---

**Журналыбызның узган санында басылган ребусның җавабы:**

*«Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,*
*Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам»*



Казанда Габдулла Тукай музеен



Шагыйрә Бикә Рәхимова (1939-2011).



Рәссам Хәнәфи Нәфыйков.



*ачу күренеше. 1986 ел.*



*Журналыбыз тарихында зур эз калдырган шәхесләр: шагыйрь Сибгат Хәким, әдәбият галиме, язучы Рафаэль Мостафин. 70нче еллар.*

Радик
Фәизов

## Чаналар китте

Без, хәзерге мүкләнеп беткән өлкәннәр, әле борын асты да кипмәгән малайлар һәм кызлар чагында, һәркайсыбызның чанасы бар иде. Теге утырып таудан шуа торган кечкенә чана түгел, ә ике метр озынлыгындагы шактый зур чана. Ошбу транспорт чарасын без ат чанасы кеби итеп матурлап үрәчәли идек, шуңа салып печәнен-саламын, утынын ташый, ашлык салып Жилгелде тегерменәнә он тартырга йөри, әти-әниләр әйткән бүтән йөкләрне күчерә идек. Әлбәттә инде, үзебез тарту көче булып.

Ул чаналарны Әтнә базарында саттылар һәм бәяләре дә арзан гына булды. Чөнки ул заман барча халык бердәй тормышта яши, беркем дә аерылып торган бай түгел, кешеләр оят белә, бер-берсеннән зур акча каеруны чамаламый, үзара килешеп көн итә. Ә без исә әти-әниләр алып биргән ул чаналарны үзебезчә бизибез, шома табанлы булуы, шәп шуууы белән үзара мактанышабыз.

Ә инде озын вә салкын кышлар үтеп язлар якынлашкач, көндезләрен кояш яхшы кыздыра башлагач, безнең өчен печән өсте житә. Чын-чынлап печән өсте, һәм әле жир кардан да арчылмас борын. Хикмәт шунда ки, язга таба болыннардагы печән эскертләренең төпләре ачыла. Кыш көне ташыганда эскерт төбендәге печәнне калын кар астыннан тартып ала алмыйлар, байтагы шунда кала. Кояш кыздыра башлагач, ошбу хәзинә өскә калкып чыга.

Үр өстендә матур булып утырган безнең кечкенә генә Дусым авылына Әтнә болыны ерак түгел, нибарысы бер чакрым. Әтнә халкы борынгыдан ишле вә кодрәтле булган, болыннарны бүлешкәндә алар безнең аз санлы Дусым гаскәренә каршы күсәкләр күтәреп чыкканнар, аны Ашыт суына кадәрле диярлек китереп кысканнар. Ахыргы нәтиҗәдә безнең болын тар гына, ә алар болыны биниһая иркен һәм... безнең авылга яп-якын булып калган. Әгәренки озын итеп сузасың икән, кул да җитәрлек булып ...

Һәм менә язгы кояш Әтнә өстенә кадәр күтәрелә, үзенең чакырулы нурларын сибеп җибәрә, шунда инде безнең куллар һәм аяклар да чыннан да озынаеп китә. Без яшь тайлар сыман чаналарыбызга җигеләбез дә, тыгыз һәм бердәм колонна булып Әтнә болынына юл тотабыз. Эскерт төпләрендә калган, кояшта күпереп хуш исләр бөркеп яткан печәнне чаналарыбызга төйибез. Биек итеп, күнелләр тулы куану хисләре белән. Шулай булмыйни! Моның өчен безне абзардагы сыерлар рәхмәтле мөгрәп, ә әти-әниләр аркадан сөеп каршы алалар бит. Тагын бердәм колонна булабыз да, җырлар җырлап авылга юнәләбез.

Ярый. Беркөн шулай бик матур тезелешеп нәүбәттәге сафаридан кайтып килә идек. Инде күп тә калмады, үр өстендә авыл күренә дә башлады. Шунда

---

*Дәвамы. Башы 4 санда.*

каршыбызга бер жигүле ат килеп чыкты һәм безгә якынаеп туктады. Билгеле инде, безнең колонна да тукталып калды. Теге атлы чанадан өстенә кыска тун, шәп бүрек кигән, укытучы кыяфәтле бер абый төште. Дустанә елмаеп колонна башындагы сыйныфташыбыз Таһирҗан янына килде.

—Кайдан алдың бу печәнне, үскәнем?—диде ул чанага ымлап һәм һаман да елмая биреп.

—Әтнә болыныннан, абый, эскерт төбеннән. Анда сезгә дә күп калды әле,—диде Таһирҗан, үзенең сары сипкелле түгәрәк йөзе белән кояштай балкып.

Шунда ... йа Аллам! Теге абыйның йөзенә галәмәт тә усал кыяфәт чыкты һәм ул киң селтәнеп Таһирҗан дустыбызга берне китереп тә сылады. Таһирҗан кулларын киң җәеп карга килеп төште, башындагы бүрке еракка очып китте. Күз ачып йомганчы бушап калды юл. Дөресе, юлда безнең печән төялгән чаналар гына торып калды. Без үзебез исә барчабыз юл читендәге карга сибелдек. Котларыбыз алынып, куркудан кычкыра-йөткерә. Инде теге абый куып җитмәслек арага киткәч кенә тукталдык, артыбызга борылып карадык.

Теге атлы чанадан тагын ике кеше төште. Алар атларын кире борып куйдылар, бик әйбәтләп кенә безнең чаналарны олауга төяделәр, печәненние белән. Өстән бастырык бастылар да китеп тә бардылар. Теге абый олау өстеннән безгә тагын бер кат кодрәтле йодрыгын күрсәтте.

Без бичаралар исә борыннарны да, кулларны да салындырып карап калдык. Әле дә булса онытмыйм, арабыздан иң озын борынлы, нык гәүдәле сыйныфташыбыз Мәрьям озын итеп борынын тартты һәм әйтеп куйды:

—Чаналар китте!

Һәм чыннан да, ул чаналар шул китүдән инде безгә кире әйләнеп кайтмадылар. Соныннан белдек, бу адәмнәр Әтнәдән килгәннәр икән, Таһирҗанга шул колхозның бер бригадиры китереп суккан икән.

## Чабаталар... биектә!

Безнең халыкта «Татар түрә булса, чабатасын түргә элә» дигән әйтем бар. Бу гыйбарә ни дәрәҗәдә дөрестер, анысын чамалавы кыен. Һәрхәлдә, мин, әле чабата киеп йөрү полный ходка модада булган заманда яшәгән адәм, ул чактагы бер генә түрәнең дә офисы түрендә чабата эленеп торганын күрмәдем. Аның каравы чабатаның,җитмәсә, бик күп чабаталарның тагын да биек урынга менеп кунаклауларына шаһит булдым.

Чабата димәктән, хәзерге яшь буын аның ни икәнен дә белми булыр. Бераз гына аңлатма бирик. Кайчандыр ошбу аяк киемен иксез-чиксез Рәсәйнең күпчелек халыклары кигән, хәтта ки дөнья халыклары арасында «Чабаталы Рәсәй» дигән кимсетүле гыйбарә дә йөргән. Дөрес, без татарларның борынгы бабалары чабата түгел, читек кигән диләр. Әмма мин белгәндә инде бу аяк киеме безнең халыкка да үтеп кергән иде.

Чабатаны өй шартларында гына ясасалар да, технологиясе шактый катлаулы. Моның өчен урманга баралар, яшь юкә агачларын табалар, аларның кайрыларын тунап алалар. Аннан килеп бу кайрыларны курыпсаларга бәйлиләр. Аның мәзәге дә булган. Дусымнан ерак та түгел Әйшияз дигән авыл бар. Аның кешеләре чабатаны күпләп ясыйлар, Әтнә базарында саталар. Безнең авыл малайлары Күәм мәктәбенә төшеп йөргәндә юлда болай дип җырлыйлар икән.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр курыпса.

Без чабата кимәс идек,
Әйшиязны жир упса.

Әйшиязлылар моны ишетеп алганнар да Авыл советына жалу белән килгәннәр.

Моның белән генә эш бетми әле. Бу курыпсаларны гали пәкеседәй үткер пычак белән бармак киңлеге телемнәргә кисәләр һәм мич буендагы киштәгә элеп куялар. Аннан инде янәшә утыралар да, тез башына бәйләп шул телемнәрдән чабата кайтаралар. Кулга шөшле алып. Чабата ясауның чын осталары була, алар ярты сәгатьтә бер кием чабатаны үреп тә куялар. Безнең Дусым авылында Шәйхетдин, Әхми, Нәбиулла абзыйлар оста чабатачылар иде. Хәер, ул заманда аз гына иренмәгән һәр адәм аны ясый белә иде. Менә мин үзем дә әле дә булса чабата үрә беләм.

Киләчәк буыннарга Ходай үзе язмасын, һич кенә дә әйбәт аяк киеме түгел! Аз гына яңгырлы вакыт булса, аны киеп чыгуга аякка шаулап су үтә. Әгәренки пычракка кереп бассаң, киндерәсе өзелеп аяктан төшеп калырга да күп сорамый. Юлың ерак булса, запасын да алырга кирәк. Бара торгач тишелә дә чыга. Без Дусымнан Казанга барганда Коркачык станциясенә җәяү йөрдек һәм барган саен ике кием чабата туздыра идек.

Ул заман безнең Дусымнан Олы Әтнәгә болыннар аша гына туры юл бар иде. Ошбу юлдан халык күп йөри, шул исәптән Мари Иленең Шинше, Куян авылы ягыннан атна саен Әтнә базарына килгән марилар да. Әйтик, килә кеше болын буйлап, базар хәлләрен уйлап, нәрсәсен күпмегә сатасын чамалап. Шунда ... стоп! Аягындагы чабатасы тишелеп чыга моның. Әмма ул аптырап тормый, юл буена утыра да, искесен салып ташлый, аягына иңбашында йөрткән запас чабатасын киеп тә куя. Ялт иттереп. Ә тишелгәнен кая олактырырга? Монда да аптырап калмый, иске чабаталарны киндерәләре белән бер-берсенә бәйли дә, юл читендәге телеграф чыбыклары өстенә чөеп тә җибәрә. Ә тегеләре шунда чайкалып та калалар. Шундый югары урынга менеп кунаклаганнарына масайган сыман.

Адәмнәр йөри торды, чабаталар туза торды һәм әнә шулай югары менеп кунаклый торды. Кайда ничек булгандыр, анысын белмим, безнең болында чабаталар еллар буена шулай телеграф чыбыклары өстендә чайкалып тордылар. Берләре киндерәләре тузып җиргә коелсалар, икенчеләре аның урынына менеп кунакладылар. Инде тормышлар бераз рәтләнеп, кешеләр чабатаны салгач, итек, ботинка, туфли ише затлы әйберләр киеп йөри башлагач кына бу хәлгә чик куелды.

Ә күнелдә нindидер кызыклы, хәтта җылы хатирә калды.

## Беренче радио, беренче машина

Безнең балалык авыр һәм хәсрәтле, шул ук вакытта гаҗәеп кызыклы, янарышлы елларга да туры килде. Беләсезме, мин малай чакта безнең Дусым авылында әле электр уты да юк иде! Минем абый-апайларым кичен дәресләрен керосин лампасы яктысында әзерләделәр. Ә аның яктысы бик зәгыйфь. Әйтик, ул заманда иң якты саналган унлы лампа яктысы хәзерге иң кечкенә кырыклы электр лампочкасы яктысының чиреген генә тәшкил итә! Җитмәсә, күп кешеләрдә җиделе, хәтта бишле лампа да бар иде. Әтнәдән болыннар аша баганалар утыртып, чыбыклар суздылар, өйләргә электр лампочкалары куйдылар һәм бөтен дөньябыз ялт итте. И куанды инде шунда авыл халкы!

Ә инде түгәрәк картон радиолар куелып, алар өйләрне янгыратып сөйләп, хәтта җырлып та җибәргәч, кайберәүләрнең мона ышанасылары

да килмәде. Шундый хәбәр иреште: кайсыдыр авылдан радио сөйләвенең чынлыгын тикшерү өчен бер мужикны хәтта Казанга җибәрәләр. Ә тегесе аты-юлы белән сүгенмичә ике сүз дә ялгап әйтә белми икән. Казаннан торып бөтен Республика эфирына: «Бу—мин, анагызны фәлән-төгән! Казаннан сөйлим, инде ышандыгызмы?!»—дип кычкырып җибәргән. Йомры сүзләрен ишеткәч, ышанганнар, билгеле. Бездә беренче телефонны да берне генә, колхоз кәнсәләренә куйдылар. Аны да Әтнәгә барып сөйләшеп караучылар табылды.

Бер тапкыр авыл урамы буйлап беренче җинел машина үтте. Югары очтан түбән очка, тузаннар туздырып. Райком кешеләренең Түбән Шашыга үтеп барышлары икән. Шул машинаны карарга бөтен авыл халкы кубып капка төпләренә чыгып басты. Ә без малайлар Шашы тавына чаклы артыннан йөгереп бардык. Шулай итеп без, хәзерге өлкәннәр, авылга цивилизация үтеп керүнең шаһитлары булдык. Уйласаң исең китәрлек, бер кеше гомере дәвамында авылда нинди үзгәрешләр булды, никадәр яналыклар керде һәм тормыш әнә кая барып житте. Шунысын күз алдына китереп карагыз әле!

## Ачлык корбаннары

Ошбу дөньяларда минем иң изге теләгем шул: хәзерге яшь буын ачлык газапларын күрмәсен иде. Менә без, өлкәннәр, тормыш китереп салырга бик ихтимал булган бу иң авыр, ачы җәфаны артыгы белән татыдык.

Авыл җиренә ачлык сугышның үзе белән бергә түгел, ә бераз соңрак, 1943нче елларда килеп керде. Аңарчы әле халыкта электән килгән дым бар, сугыш алды елларында колхозлар хезмәт көненә ашлыкны мул итеп биргәннәр иде. Тора-бара келәт төпләре тәмам такырланды, ә хезмәт көненә граммлап кына тия башлады. Авыл кешесе үстереп алган бар ашлык фронтта явыз дошман белән көрәшүчеләргә, шәһәрләрдә корал ясаучы эшчеләргә җибәрелә иде. Крәстиян мичтә пешкән хуш исле, тәмле ипине көзге айларда гына күреп калды, озын кышта инде идән астындагы бәрәнгегә күчте, язга таба кайберәүләр шул чикмәнле бәрәнгесез дә калдылар. Елгаерымтылардан, болыннан ат кузгалагы, балтырган һәм башка шундый үләннәр җыеп ашадылар. Ошбу нигъмәтләр асылда тамакны туйдырмыйлар, кеше организмына кирәкле энергияне бирмиләр. Шулай итеп, авылда ачлык патшалык итә башлады.

Айлар буена тамагы туйганчы ашамаган, ачыккан адәмне ерактан ук белеп була. Ул аякларын өстерәп, авырлык белән атлый, сүзен дә ярым пышылдап, акрын сөйли, йөзендә бер үзенчәлекле талчыкканлык, йокымсырау була. Озак вакытлар ипи күрмичә, гел бәрәңге белән генә тукланып торган кешедә дә шул ук хәл күзәтелә. Тамагы ул кадәр ачыккан булмаса да, андый кеше дә гел йокымсырап йөри. Моны табиблар болай дип аңлаталар: бәрәнгедә крахмал күп, кеше организмында ул крахмал шикәргә әйләнә. Ә шикәрдән, үз чиратында, спирт хасил була. Менә шуңа күрә бәрәнгене күп ашаган кеше, бичара дип әйтимме, шул спирттан аз гына исереп, мәлҗерәп йөри. Ял итәргә утырса, шунда ук йоклап та китә.

Боларына аның түзәр дә идең инде, әмма бу имансыз патша тиз арада үзенә корбаннар да ала башлады. Иң куркынычлысы шул булды, кешеләр иртә язда, җирләр аз гына кипшерү белән, басулар өстеннән былтыргы уракта төшеп калган башакларны җыйдылар. Андый башакларда агу туплану ихтималы бик зур булу турында табибларның кисәтеп торуларына да карамастан. Ачлык яман шул ул. Кайберәүләр шундый башакларны җыйдылар, он итеп тарттылар, көлчә пешерделәр һәм... һәлак булдылар.

Кайсыбер авылларда гаиләләре-гаиләләре белән. Мондый тетрәндергеч хәбәрләр байтак йөрде.

Безнең Дусым авылын, исеме дә матур булгангамы, Ходай үзе саклады тагын. Былтыргы башакларны җыеп ашаучылар булды, әмма аннан беркем дә зыян күрмәде. Колхозыбыз рәисе Шәфыйк абый да, яхшы күнелле кеше, саклык кирәклеге турында зинһарлап гел кисәтеп торды. Анын каравы урамда хәйран гына барган җиреннән кисәк кенә хәле бетеп егылучылар, өзлегә язып калучылар җитәрлек булды. Күбәүләр ачлыктан шешенделәр, йөзләре артык түгәрәкләнеп ямьсезләнде, кечерәеп калган күзләреннән яшьләре агып торды. Менә мин үзем дә, шәхсән, хәлем бетеп егылдым.

Безнең гаилә бик ишле, җитмәсә, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, көз көне язга дип базга күмеп калдырган бәрәңгебез черегән. Җәй уртасында без инде барыбыз да беренче сортлы ачлар идек. Беркөн шулай, җылы һәм тымызык кичтә, тау астындагы бозауны бәйдән алып менәргә төштем. Бозауны җитәкләп үргә атладым. Хәлсезлектән күз алларым караңгыланып-томаланып китсә дә, үр башына менеп җитә алдым һәм... тәмам хәлсезләнеп сукмакка егылдым. Башта өстемнән бозау атлап үтте, аннары озын чылбыр шуды. Бозауга нәрсә, ул өйгә менеп китте, миңа борылып та карамады, мин исә сукмакта ятып калдым. Кич булса да кояш әле кыздыра, бөркү. Шунда сизенәм, яңакларымны инә белән чәнчеп-чәнчеп алгандай итә, капшап карыйм, алар шешенеп килә икән. Берничә кат торып басарга талпындым, барып чыкмады. Күнелемне менә хәзер шушында, тау асты сукмагында үлеп калам икән дигән курку тотып алды. Үләсе бер дә килми, яман да моңсу иде. Акрын гына елап җибәрдем.

Шунда яныма кемдер килеп туктады.Карасам, күрше Мәһирә апай икән. Бу шактый усал әби мине тирги башлады.

—Тор, ристан! Нишләп ятасың монда сукмак бүлеп.

—Торып булмый шул, Мәһирә апай,—дидем мин телемне көчкә әйләндереп.

Әби өстемә иелде, хәлемне аңлады һәм мине күтәреп алды.

—Һай, балам, өзлегергә ятасың икән ич син монда. Әйдә әле!—диде ул һәм мине җитәкләп ындыр артыннан гына өйләренә алып керде. Өйалды баскычына утыртып, бер тәлинкә аш чыгарып бирде. Сөтле, бәрәңгеле, умачлы, искитмәле тәмле аш! Бер саллы гына телем ипи дә тоттырды әле. Бу мәрхәмәте өчен мин Мәһирә апайга гомерем буена рәхмәтле булдым. Менә хәзер уйлыйм ки, анын шушы бер тәлинкә ашы мине өзлегүдән, ә бәлки үлемнең үзеннән дә саклап калгандыр. Мәһирә апайның ире Сәет абый авылның тимерчесе, аларның тормышы ярыйсы гына иде.

Ул ачлык белән мәзәк хәлләр дә килеп чыккалады. Бер кичтә ашап утыра идек, өстәл уртасында табакта бәрәңге, һәркем шуннан үрелеп ала, чиратны саклап кына. Шунда кисәк ут сүнде, өйне караңгылык басты. Форсаттан файдаланмакчы булып мин чиратсыз гына кулымны табакка суздым. Ә ул табакта... куллар, куллар! Бар да бәрәңге кармалый...

Ул еллардагы ачлык минем күнелемдә мәңге төзәлмәслек яра калдырды. Сугыш вакытында безнең әниебез вафат булды, аннан әле нибары сигез айлык сеңлебез Асия калды. Минем матур сеңлем, бәгырь кисәгем, өч яше дә тулмастан ачлыктан вафат булды. Анын матур елмаюлары әле дә булса күз алдымда.

Корбаннар тагын да булды. Авылдан хәер эстәргә чыгып киткән бер агай шул китүеннән әйләнеп кайтмады. Аны каядыр җирләп, рәсемен генә җибәрделәр. Ә икенче карт, Нәҗметдин бабай, инде авыл янына кайтып җиткәч...

Без, малайлар, җәйге бер көндә уфалла арбалары тартып югары басуга

менеп киттек. Анда сөрелми калган җирдә куе булып әрем үскән, шул әремне йолкыйбыз, арбаларга төяп төшәбез. Ул кибә, шуны мичкә, учакка ягалар. Авылдан чыгып аркылы юлга житкәч күрәбез, юл буенда Нәҗметдин бабай утыра. Әллә ничек сәер итеп, гәүдәсен туры тотып. Үзе сәламебезне дә алмады, безгә таба борылып та карамады. Мин бу тәбәнәк буйлы, юка гына гәүдәле картны яхшы беләм. Ул безгә бәрәнге базы казып бирде. Бер көрәк балчыкны ташлаган саен «һүп-пә, һүп—пә!» дип. Бабай моннан бер атна элек мари якларына хәер эстәргә чыгып киткән, шуннан кайтып килешедер инде. Без аптырап кына юлыбызда булдык.

Инде арбаларыбызга әрем төяп кайтып килгәндә күрәбез, бабай әле һаман кузгалмаган. Шул урында, шул рәвешендә утыра бирә. Сәерсенеп тукталдык. Иптәшебез, арабыздан иң йөрәкле Нурулла карт янына килде, аның иненә кагылды.

—Нәҗметдин абый!

Шунда бабаебыз утырган җиреннән түнеп тә китте, һаман да сәер төстә, аякларын бөкләгән килеш. Ул инде әллә кайчан үлгән, гәүдәсе дә катып беткән икән...

Мин хәзерге тормышны мактарга җыенмыйм. Әмма шунысы хак, хәзер беркем дә ул кадәр ач та, ялангач та түгел. Хәзер барыбызның да тамагы тук. Бу яктан зарлансак, зур гөнаһ булыр иде.

## Танкистлар җиңде

Үткән гасырның 50нче елларында без, Арча районыннан урта белемле өч егет, Ульяновск шәһәрендәге танк училищесына бардык. Олы Мәңгәрдән Таһиржан, Бәрәскәдән Рафаил һәм Дусымнан мин Совет армиясе офицерлары, танкистлар булырга. Монда безне әйбәт каршы алдылар, әлегә матур курсант киемнәре бирмәсәләр дә, солдат гимнастеркасы, аякка кирза итекләр киеп алдык. Ишегалды себерергә, кухняга бәрәнге әрчергә йөртә башладылар. Әлегә без курсантлар түгел, кандидатлар гына икән.

Безгә монда бик ошады. Танкларга, кодрәтле сугыш машиналарына карап сокландык, якын киләчәктә аларны үзебез йөртә аласыбызны уйлап күнелләр һаваланды. Ашханәдә бик әйбәт ашаталар, безгә, авылдан килгән бәрәнге корсак егетләргә, андагы ризыклар искитмәле тоела. Казармаларда чисталык, тәртип. Безнең монда укыйсыбыз, укалы погоннар тагып чыгасыбыз бик килә иде. Әмма бәхет безгә аркасы белән борылды. Училищеда атна-ун көн яшәдек микән, бер төркем суворовчылар килеп төште. Аларны инде бернинди чиратсыз, имтихансыз алалар, һәм безне, соңрак килгәннәрне, исемлектән сыздылар да ишекнең кайсы якка ачылганын күрсәттеләр.

Безнең болай гына кайтып китәсебез килмәде. Училище директоры генерал янына кереп карадык.

—Мин сезне бик алыр идем, егетләр,—диде генерал, безне ихластан жәлләп.—Мин татар егетләрен сугыштан ук беләм, алар ышанычлы, батыр. Ләкин менә расписаниегә сыймыйсыз бит. Әнә урам аша гына элемтә училищесы, шунда барыгыз да керегез!—диде.

—Һе! Телефончылар булыргамы? Теләмибез!—дидек без һәм Казанга, үзебезне монда җибәргән Татвоенкоматка кайтып киттек. Биредә безгә:

—Без сезне көз көне барыбер армиягә алабыз. Чиләбедә авто-трактор училищесы бар. Шунда китегез!—диделәр.

—Һе! Тракторчылар булыргамы? Кирәге юк!—дидек без һәм өйгә кайтып киттек.

Менә яшьлек тилелеге белән зур хаталар ясаганбыз. Бу уку йортлары

югары кимәлдәге белгеч—офицерлар әзерләп чыгаралар икән. Ул заман хәрби уку йортлары, гомумән, югары белемле һәм культуралы хәрбиләр әзерлиләр иде. Көз көне, чынлап та, безне армиягә алдылар. Кышларын зәмһәрир салкыннары хөкем сөргән Байкал артына, саперлар батальонына илтеп тыктылар. Шулай итеп иптәш Фәизов атаклы танкист түгел, ә инбашындагы кара погонына аркылы-торкылы көрәк белән кәйлә сурәте төшерелгән миналар куеп йөрүче, җирдә казынучы сапер булып калды. Безнең өйрәнүләрне тикшерергә килгән генерал безне:

—Исәнмесез, саперлар, сугыш шахтерлары!—дип сәламли һәм гөрләтеп көлә иде.

Шулай итеп, Ульяновск танк училищесында безгә бәхет тәтемәде. Алай да без анда шул вакытта хәбәре астыртын гына бөтен илгә таралган бер вакыйганың шаһиты булдык.

Курсантларны, гомумән хәрбиләрне, ял көннәрендә увольнениегә, ягъни шәһәрдә йөреп керергә чыгаралар. Бер көнне училище курсантлары шәһәрдә авиация училищесы курсантларын очрата. Тегеләре киләчәктә һава кинлекләрен гизәчәк очучылар буласы бит инде. Алар ташбака шикелле җирдә шуышып йөриячәк танкистларны мыскыллый башлыйлар. Күбрәк булалар, эш сүздән узып эшкә, ягъни танкистларны кыйнап ташлауга барып җитә. Безнең бер курсант йөгереп казармага кайтып керә дә, разбой сала:

—Очучылар танкистларны кыйный!

Шундук дәррәү куба казарма. Җиңнәрне алдан ук сызганып, очучылар казармасына яу чабарга әзерләнә, һәр әмерне берсүзсез тыңларга күнеккән курсантлар бу юлы үзләрен үгетләп маташкан офицерларны да, хәтта акыра-бакыра туктарга әмер биргән генералның үзен дә санламыйлар. Бердәм вә тыгыз колонна булып очучылар казармасына юл тоталар. Ишек төбендәге кораллы сакчыларны чөеп кенә ташлыйлар, эчкә үтәләр. Баталия башлана. Йодрыклар, аларга ярдәмгә тимер прәшкәле каешлар эшкә җигелә. Танкистлар, ни генә әйтсәң дә, җиргә береккән халык бит, һавада очучыларны тар-мар итә башлыйлар.

Үзенең кара «Волга»сына утырып авиация училищесы генералы килеп җитә. Машинасыннан чыгып һавага ата башлый. Танкистлар ошбу генералга зур хөрмәт күрсәтәләр. Шоферы-ние белән машинасына бөгәрләп тыгалар да, ошбу машинаны җинел генә күтәреп алып, койма аша кычыткан баскан чокырга чөеп ташлыйлар.

Баталия танкистларның тулы җиңүе белән тәмамлана.

Бу вакыйга бөтен Ульяновскига шаулады. Ул заманда мондый хәлләр турында хәбәр тарату, бигрәк тә язып чыгу катгый тыела иде. Тик безне капчыкта яшереп буламы? Тиз арада бөтен ил халкы белеп алды бу хәлне.

Сүз ахырында зур өметләр баглап Ульяновскига барып йөргән иптәшләремнең дә истәлекләрен яд итим инде. Таһирҗан да, Рафаил да бу якты дөньяларда күптәннән юк. Урыннары оҗмахта булсын.

*Ахыры киләсе санда*

## Фатих Урманчега 75 яшь

Фатих Урманче—үзенең гомерен татар халык иҗатын, бәет-дастаннарның килеп чыгышын, йола-җырларның туу һәм формалашу үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлаган галим.



Фатих Ибраһим улы Урманчеев 1936 елның 28 маенда Омск өлкәсенең Азов районы Кызыл Маяк исемле татар авылында туа. 1955 елда Омск шәһәрендәге Казах педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, ул укуын әлеге шәһәрнең педагогия институтында дәвам итә. Институттан соң берничә ел туган якларында тарих, рус теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта. Әнисе көйләгән мөнәҗәтләр, авыл яшьләренең әйлән-бәйлән уеннары вакытында яңгыраган халык җырларына мәхәббәт аны 1962 елда ерак Себердән Казанга алып килә. Шуннан бирле ул татар халык иҗатыннан аерылмый. Биредә Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурага укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң, 1965-69 елларда институтның халык иҗаты һәм халык сәнгате тарихын өйрәнү секторында кече фәнни хезмәткәр вазифасын башкара. Кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң, берничә ел Казан Дәүләт педагогия институтының рус теле һәм чит телләр әдәбияты кафедрасында эшли. 1971-80 елларда Алабуга педагогия институтында читтән торып уку бүлеге проректоры, уку-укыту эшләре буенча институт проректоры була. 1980-84 елларда Венгриянең Эгер шәһәрендәге педагогия институтында венгр студентларына рус әдәбияты тарихын укыта, 1989 елда Ташкентта докторлык диссертациясен яклап гыйльми дәрәҗә ала. 1992 елдан исә Татарстан фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының Халык иҗаты бүлеге мөдире вазифасында.

Ф. Урманче татар фольклористикасына, этнографиягә, аерым шагыйрьләрнең иҗатларына багышланган дистәләрчә фәнни монография, берничә йөз фәнни мәкалә, очерк-рецензияләр язып, татар әдәбиятын, фәнен баетуда, үстерүдә үзеннән күп көч, хезмәт куйган, тарихи-этнографик юнәлешкә нигез салучы фидакарь галим. Аның «Халык авазы: татар халык бәетләре тарихыннан очерклар» (1974), «Дастаннарга лаек замана: борынгы фольклор, хәзерге поэзия» (1990), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997) һ.б. китаплары татар әдәбиятының мөһим өлеше булып тора.

Ул үзенең хезмәтләрендә бүгенге көн шагыйрьләреннән Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Р. Миңнуллин иҗатларын да киң яктырта.

Ф. Урманче—Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1996), Халыкара төрки академия академигы, 1977 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Юбилярны олуг бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.



## Гафур Коләхмәтевнеӊ тууына 130 ел

Язучы-драматург, публицист һәм революционер Габделгафур Юныс улы Коләхмәтев 1881 елның 5 маенда Пенза шәһәрендә сабынщәм заводы хуҗасы гаиләсендә туа. 1902 елда Казан шәһәрендәге Укытучылар мәктәбен тәмамлый. Казанның Пороховой бистәсендәге өч класслы рус-татар училищесында (1911 елның җәенә кадәр), «Касыймия» («Апанай») мәдрәсәсе каршында оештырылган рус классларында (1911-16 елларда) укытучы һәм мөдир булып эшли. «Урал» газетасын таратуда, татарча спектакльләр куюны оештыруда актив катнаша, публицистик мәкаләләр яза. 1909 елда аның «Тарих сәхифәләре» исемле өч кисәктән торган китабы, 1911 елда арифметика укыту алымнарына өйрәткән «Ысулы тәгълиме хисап» исемле методик кулланма китабы нәшер ителә.

Язучы-драматург буларак, ул «Ике фикер» һәм «Яшь гомер» драмалары белән данлыклы. Бу әсәрләр татар әдәбияты тарихында эшче-революционер образларын һәм пролетариат идеяләрен сәнгатьчә гәүдәләндерүнеӊ беренче уңышлы үрнәге буларак әһәмиятле.

Озак еллар үпкә авыруыннан җәфаланган язучы 1918 елның 1 апрелендә вафат була.



## Солтан Габәшинеӊ тууына 120 ел

Солтан Хәсәнгата улы Габәши 1891 елның 13 маенда Казан губернасы Казан өязе Алат волостеның Тенивраг—Солабаш (хәзер Татарстанның Биектау районы Рече Солабаш) авылында мулла гаиләсендә туа. 1913-15 елларда беренче әсәрләрен яза («Кәккүк», «Рөкыя-гөлкәем», «Вальс», «Пикник», «Татар кызы»).

Солтан Габәши татар драма труппасының берничә спектакленә (Г.Исхакыйның «Зөләйха», Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә», К.Рәхимнең «Бүз егет» әсәрләре) музыкалар яза. Г.Әлмөхәммәтов һәм В.Виноградов белән берлектә, С.Габәши беренче татар опералары—«Сания» (1925) һәм «Эшче»не (1930) иҗат итүдә катнаша.

Республиканың музыка сәнгате өчен бөтенләй яңа булган хор сәнгатенең үсешенә зур өлешен кертә.

1942 елның 8 гыйнварында вафат була.



## Шырияздан Сарымсаковның тууына 100 ел

Режиссер, актер һәм педагог Ширияздан Мөхәммәтҗан улы Сарымсаков 1911 елның 12 маенда Казакъстандагы Акмулла өязенең Атбасар шәһәрендә туа. 1936 елда Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) режиссерлык факультетын тәмамлап, Казанга эшкә кайта. 1965 елга кадәр ул Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында режиссер булып эшли. 1942-44 һәм 1953-61 елларда театрның баш режиссеры вазифасын үти.

Ш.Сарымсаков татар, рус һәм чит ил драматургларының житмештән артык пьесасын сәхнәгә куя. 1958 елда К.Тинчурин пьесасы буенча куелган «Җилкәнсезләр» спектакле өчен аңа Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. Ул М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Н.Җиһановның «Ирек», М.Мозаффаровның «Галиябану», Ж.Фәйзинең «Башмагым» һәм «Тапшырылмаган хатлар» музыкаль спектакльләрен сәхнәгә куя, Казан киностудиясендә «Салих Сәйдәшев», «Туган як моңнары» фильмнарын иҗат итә.

1999 елның 30 сентябрендә Казанда вафат була.

Içtimaği-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ЭШЛЕКЛЕ ОЧРАШУЛАР

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов Финляндиядә эш сәфәрендә булып кайтты. Бирелә ул татар җәмгыяте вәкилләре белән дә очрашты. Әлеге илдә бүген 800ләп милләттәшебез гомер итә. Аларның зур өлеше—Хельсинкидә яши. Финляндия татарлары иң бердәм, актив диаспоралардан берсе булып тора. Аларның ижтимагый оешмалары Бөтендөнья татар конгрессы белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Президент татар җәмгыяте вәкилләре белән ана телендә аралашты.

Аннары Рөстәм Миннеханов Лахти шәһәрендә «Энергон» тикшеренү үзәгендә, «Паякулма» компаниясендә булды.

Соңыннан Татарстан делегациясен Финляндия Президенты Тарья Хапонен кабул итте. Очрашуда Финляндия белән Татарстанның элемтәләрен тагын да ныгыту буенча фикер алышу булды. Очрашу тәмамлангач, Р. Миннеханов журналистларга, әлеге визит Финляндия белән мөнәсәбәтләрне яна дәрәҗәгә күтәрәчәк, безнен төп бурыч—Татарстанга фин компанияләрен мөмкин кадәр күбрәк җәлеп итү, дип белдерде. Татарстанда Финляндиянен мәгариф системасы аеруча зур кызыксыну уята. «Без элемтәләрне бөтенләй яңа дәрәҗәгә күтәрәчәкбез һәм Россия белән Финляндия мөнәсәбәтләрендә Татарстанның роле сизелерлек булачак»,—диде Президент.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК НЫГЫЙ

Татарстан депутатларының Мәскәүгә сәфәре барышында парламентара хезмәттәшлекне үстерү турында килешү имзаланды. Документка Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән Мәскәү шәһәре Думасы рәисе Владимир Платонов кул куйды.

В. Платонов сүзләренә караганда, шундый ук документ моннан 15 ел элек тә имзаланган. Ә хәзер килешүне яңартыр вакыт житкән. Ф. Мөхәммәтшин исә Мәскәүдәге коллегаларыннан үрнәк алуларын яшермәде. «Чөнки сез федераль хакимият, димәк, ил күләмендәге карарларны кабул итү эшенә дә якынрак торасыз,—диде ул.—Ә яңа протокол безнең араларны тагын да якынайтачак». Әлеге килешү нигезендә яңа закон проектларын алмашу, комитетлар арасында элемтә булдыру, уртак чаралар уздыру күздә тотыла. Ф. Мөхәммәтшин әйтүенчә, әлеге документ ике төбәк арасында башланган зур эшнен дәвамы булып тора. Мәгълүм булганча, күптән түгел Татарстан белән Мәскәү житәкчеләре сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турындагы килешүне имзалаган иде.

Ф. Мөхәммәтшин журналистлар белән очрашканда, каләм әһелләре аңардан Россия Хөкүмәте башлыгы урынбасары Дмитрий Козакның милли сәясәт мәсьәләләре өчен җаваплы кеше булып билгеләнүенә мөнәсәбәте турында сорады. «Күп милләтле һәм күп динле Россиядә бу проблемалар белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнүче структура булырга тиеш,—диде парламент башлыгы.—Шуңа күрә әлеге яңалыкны алга таба житди адым дип бәяләр идем. Бу эштә милли төбәк вәкилләре дә катнашыр, дип өметләнәм. Алар халыкны берләштерү өчен кирәкле чаралар тәкъдим итә ала. Бу эшне вакытны сузмыйча, кичекмәстән башларга кирәк».

## МИЛЛИ КОМПОНЕНТ БУЛЫРГА ТИЕШ

Чаллыда Россия Дәүләт Думасы Рәисенең беренче урынбасары Олег Морозов булып китте.

Рәсми визит барышында Мәскәү кунагы эре предприятиеләр житәкчеләре, «Бердәм Россия» сәяси партиясенең Чаллы бүлекчәсе активистлары, җәмәгать эшлеклеләре, журналистлар белән очрашты, шәһәр югары уку йортлары студентларына исемле стипендияләр тапшырды.

Шагыйрь һәм публицист Айдар Хәлим, О. Морозовка мөрәҗәгать итеп, мәгариф системасында милли компонент темасын күтәрде. «Бүгенге көндә әзерләнә торган «Мәгариф турындагы» яңа федераль закон проектындагы милли компонентка кагылышлы пунктны тулысынча үзгәртергә кирәк»,—диде ул. Аның сүзләре белән килешеп, О. Морозов милли компонент мәсьәләсе һәр милли республиканың үз карамагында булырга тиешлеген әйтте.

## ХӨКҮМӘТТӘ ЯҢА МИНИСТР

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов Указы нигезендә, Айрат Миннемулла улы Сибагатуллин Татарстан мәдәният министры итеп билгеләнде.

Айрат Сибагатуллин 1958 елның 31 мартында Татарстанның Саба районы Байлар Сабасы авылында туа. Казан дәүләт педагогика институтын тарих белгечлеге буенча тәмамлый.

1989 елдан 1991 елга кадәр ВЛКСМның Казан шәһәре Бауман районы комитеты инструкторы була. 1993 елда Татарстан Кинематография дәүләт комитеты рәисе урынбасары булып эшли. 1997 елдан Татарстан Министрлар Кабинеты аппаратының мәдәният һәм сәнгать бүлеге башлыгы, 1998 елдан Татарстан Премьер-министры киңәшчесе була.

1999 елдан 2002 елга кадәр А. Сибагатуллин «Татарстан» дәүләт теле-радиотапшырулар компаниясе рәисенең беренче урынбасары, 2002 елдан—«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры урынбасары вазыйфаларын башкара. 2002 елда «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе рәисе итеп билгеләнә. 2005 елдан ул—«Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры.

## БӘҺАСЕЗ БҮЛӘК

Россия Ислам университеты базасында Ике мәчетнең хадиме, король Абдалла бин Абдел Азиз эл Сауд исемендәге китапханә ачылды.

ТР Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиеваның әйтүенчә, китапханәне Казанда ачу ике җөмһүриятнең Мәдәният министрлыклары тарафыннан 2007 елда имзаланган килешүдә каралган булган. Ниһаять, бу изге теләк гамәлгә ашты.

Согыйд Гарәбстаны мәдәният һәм мәгълүмат министры урынбасары Адел Азиз бин Салих бин Салама, Согыйдиянең Россиядәге илчесе Хәсән Али Жәгъфәр, ТР Дәүләт Советы комитеты рәисе Разил Вәлиев, ТР мөфтие вазыйфасын башкаручы Илдус хәзрәт Фәиз, РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин китапның бәһаләп бетергесез байлык булуы турында сөйләде. Шунысы кызык: хәзерге вакытта республикабызда 75 миллион данә китап бар икән. Хәзер менә шуңа тагын бер хәзинә—40 мең данә китап өстәлде. Монда Ислам диненә һәм гарәп теленә, әдәбиятына гына түгел, география, социология, политологиягә... кагылышлы күп төрле әдәбият бар. Гарәп телендәге әлеге китаплар илнең үзендә генә түгел, Мисыр, Ливан, Сүрия һәм Иорданиянең иң алдынгы нәшриятләрендә басылган. «Бәһасез байлык дигәннең дә бәясе бар—500 мең долларлык хәзинә бу»,—диде Рәфыйк Мөхәммәтшин тантана ахырында.

Согыйдия мондый китап тупланмаларын дөнья буйлап шактый илләр таратса да, әле безгә килеп җитә алганы юк иде. Ниһаять, сәгать сукты. Бу хәзинәдән РИУ мөгаллимнәре һәм шәкертләре генә түгел, республикабызда Ислам динен, гарәп телен өйрәнүче барча вуз, мәдрәсә укытучылары һәм укучылары да файдалана алачак.

## БӘЙГЕ ТӘМАМ, БӘЙГЕ ДӘВАМ ИТӘ

«Яңа татар пьесасы-2010» бәйгесенең җиңүчеләре билгеле булды. Җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче Фәндәс Сафиуллин рәислегендәге жюри конкурска килгән 50ләп әсәр арасыннан иң яхшы дип табылган 8 пьесаны сайлап алган.

Кызыксындыру премиясенә өч автор лаек булды. Алар—«Самат һәм Кара король» пьесасы авторы Сөмбел Гаффарова (Казан), «Әҗәт» пьесасы авторы Зөбир Гыймаев (Түбән Кама) һәм «Көтү» пьесасы авторы Булат Сәлахов (Чаллы).

«Балалар һәм яшүсмерләр пьесасы» номинациясендә Илгиз Зәйниевнең «Ак чәчәкләр һәм кара көчләр» пьесасы җинеп чыкты.

Проза әсәренә нигезләнеп язылган иң яхшы инсценировка дип Равил Сабырның (Чаллы) «Ком ял итми» пьесасы табылды.

35 яшькә кадәрге авторлар өчен тәгаенләнгән махсус премияне «Бөке» пьесасы өчен янә Илгиз Зәйниев алды. Знче урын «Дөньясы шундый, балакай, дөньясы» пьесасы өчен педагогика фәннәре докторы, профессор Әлфис Аязовка (Уфа) бирелде.

2нче урыннарны «И, минем яктыртучым» пьесасы авторы Ркаил Зәйдулла һәм «Бармы ришвәткә дәва?» сатирик комедиясе авторы Зөлфәт Хәким бүлеште.

Татарстан Мәдәният министрлыгының махсус премиясе шулай ук Ркаил Зәйдуллага тапшырылды.

Жюри рәисе Фәндәс Сафиуллин белдергәнчә, быелгы конкурста 1нче урынга лаек булырлык пьеса табылмаган.

## «ТАНТАНА»НЫҢ ТӘҮГЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ

27 март—Халыкара театр көнендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстан Мәдәният министрлыгы гамәлгә куйган «Тантана» милли театр премиясенең беренче лауреатлары игълан ителде.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева рәислегендәге жюри 10 номинация буенча театр өлкәсендәге казанышларны билгеләде. «Дебют» номинациясендә Әлмәт Татар дәүләт драма театры артисты Эльмира Яһүдина һәм М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры балеринасы

Кристина Андреева; «Иң яхшы курчак театры актеры» номинациясендә «Әкият» Татар дәүләт курчак театрыннан Татарстанның халык артисты Наталья Егорова һәм Чаллы курчак театры артисты Дилүс Хуҗиәхмәтов; «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрыннан Татарстанның халык артисты Люция Хәмитова; «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә А. Баталов исемендәге Бөгелмә Урыс дәүләт драма театрыннан Татарстанның халык артисты Александр Кочетов; «Иң яхшы төп хатын-кыз роле» номинациясендә К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрыннан Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Исламия Мәхмүтова; «Иң яхшы төп ир-ат роле» номинациясендә Чаллы Татар дәүләт драма театрыннан Татарстанның халык артисты Рафил Сәгъдуллин; «Намус һәм тугрылык» номинациясендә В. Качалов исемендәге зур дәүләт драма театрыннан Россиянең халык артисты Вадим Кешнер; Казан яшь тамашачылар театрыннан Татарстанның атказанган артисты Нина Колаганова; Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрыннан Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Алсу Гайнуллина һәм С. Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театрыннан Татарстанның халык артисты Венера Нигъмәтуллина; «Иң яхшы ансамбль» номинациясендә «41нең арбалы хатыннары» драмасында уйнаган бер төркем артистлар; «Иң яхшы тамашачы» номинациясендә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының тугры тамашачысы Александр Лаврентьев; «Спектакль-вакыйга» номинациясендә Әлмәт Татар дәүләт драма театрының «Гашыйк Кәриб» спектакле бүләкләнде.

### ФОНДКА ЯРДӘМ

Казанда Россиянең беренче Президенты хатыны Наина Ельцина булып китте.

Ул Ельцин кубогына үткәрелгән беренче халыкара теннис турниры җиңүчеләрен бүләкләде. Башкалага килер алдыннан Наина Ельцина республика халкына да бүләк ясады. Ул «Янарыш» фондына 1 миллион сум акча күчерде. Мәгълүм булганча, ел башында Наина Ельцина башкалада Борис Ельцинның 80 еллыгына багышланган күргәзмәне ачу тантанасында катнашты.

### БЕЗГӘ КИҢӘЮ КИРӘК

«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте, 2010 ел нәтиҗәләре буенча, Россия Милли тираж хезмәтенең «Ел тиражы» премиясенә лаек булды. Ул, генераль директор Айдар Сәлимгәрәев белдергәнчә, милли газета-журналларны саклап калган өчен бирелде.

Статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, бүгенге көндә Татарстанда татар, чуаш, һәм удмурт телләрендә 195 мең данә вакытлы матбугат нәшер ителә. Укучылар да яшәрә. Республиканың эшне оештыру тәҗрибәсе исә башка төбәкләрдә дә яклау таба.

«Татмедиа» агымдагы елда басма газета-журналларны интернет челтәренә чыгаруга да игътибарны арттырачак. Шул рәвешле милли матбугат белән танышучылар даирәсе киңәячәк. Моннан тыш, Россиянең төрле төбәкләрендә татарча чыгучы 31 газетаны Татарстан, милләт тормышына кагылышлы 8 битле кушымталар белән тулыландыру мәсьәләсе дә хәл ителәчәк. Яналык-хәбәрләр редакцияләргә интернет челтәре аша җибәреләчәк.

### ХАК ДИН ХӨРМӘТЕНӘ— ИСТӘЛЕК БИЛГЕЛӘРЕ

Кремльдә Татарстан Дәүләт Киңәшчесе, тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне торгызу буенча республика фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев борынгы Болгар шәһәрендә 922 елда Идел буе болгарларының Ислам динен рәсми кабул итүе һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәләре хөрмәтенә Истәлек билгеләрен кору мәсьәләләре буенча киңәшмә уздырды.

Истәлек билгеләренең икесе дә «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя шәһәр-утравы» проектына кертелгән. ТР Мәдәният министрлыгы Истәлек билгесе проекты эскизына бәйге уздырган иде. Бәйге нәтиҗәләре буенча Рөстәм Габбасов проекты иң яхшысы дип табылды. Тиздән ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды Истәлек билгесен төзү эшләренә керешәчәк.

Ә 922 елда Идел буе болгарларының Ислам динен рәсми кабул итүе хөрмәтенә Истәлек билгесен төзү эшләре, Минтимер Шәймиев билгеләп үткәнчә, инде әйбәт темпта алып барыла. Быел ул тәкъдим итүгә әзер булырга тиеш.

### ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗНЕҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле шагыйрь, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташка 70 яшь тулу уңаеннан «Матурлыкка сусау» (яки «Гөлләр һаман су сорый...») дип исемләнгән юбилей кичәсе булды.

Шигърияткә 60нчы елларда килеп, ярты гасыр буе әдәбиятка хезмәт иткән шагыйрьне тәбрикләргә күпсанлы әдәбият-сәнгать әһелләре, галимнәр, шигырь сөючеләр килгән иде.

Р. Гаташны юбилей бәйрәме белән Татарстан мәдәният министры урынбасары И. Әюпова, Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, каләмдәшләре Т. Миннул-

лин, Р. Батулла, Х. Миннегулов, Г. Рәхим, Р. Миннуллин, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары К. Аралбаев тәбрик итте. Камал театры артистлары Ә. Шакиров, Р. Тажетдин, Н. Ихсанова, Н. Гәрәева, Р. Шәрәфи, Н. Дунаев аның шигырьләрен укыды, җырчылар З. Сөнгатуллина, З. Сәхабиева, М. Галиев, Б. Насыйрова шагыйрь шигырьләренә язылган җырларны башкарды.

Кичәне нәфис сүз осталары Л. Шакирҗан һәм И. Кыямов алып барды.

## ӘДӘБИ ПРЕМИЯЛӘРГӘ ТӘКЪДИМ ИТЕЛДЕЛӘР

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең әдәби премияләренә кандидатлар күрсәтелде. Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай», «Остазбикә», «Кәләпүшле кыз» әсәрләре буенча куелган һәм «Мөһаҗирләр» (М. Галәү) спектакльләре өчен С. Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театры; «Язмышлар язылганда» (Татарстан китап нәшрияты, 2007) дигән китабы һәм Г. Исхакый мирасын барлауда һәм пропагандалауда үзеннән зур өлеш керткән өчен шагыйрь, прозаик Ф. Тарханова; Гаяз Исхакый, «Ирдәүкәләр» (Татарстан китап нәшрияты, 2007) китабы өчен прозаик, драматург Р. Сәгъди; Фатих Хөсни, «Кырык кыл» (Татарстан китап нәшрияты, 2008) китабы өчен шагыйрә И. Иксанова; Һади Такташ, «Янарыш юлында» (Татарстан китап нәшрияты, 2008) дигән китабы өчен Ә. Закирҗанов Җамал Вәлиди премияләренә тәкъдим ителде.

## ТАТАР ЕГЕТЕ—«ОСКАР» ИЯСЕ

Республикабызның нәни «йолдызчыгы» Зөлфәт Габдуллин бу көннәрдә Американың Лос-Анджелес шәһәрендә үткән халыкара балалар бәйгесендә җиңү яулады һәм аңа «Балалар Оскары» тапшырылды. Питрәч сәнгать мәктәбен тәмамлаган Зөлфәт шулай итеп халыкара танылу алды. Шунысын да искәртик, дөнья күләмендә танылган Скарлетт Иоханссон, Джулия Робертс, Майкл Джексон кебек мәшһүрләрнең дә «йолдызлы юлы» әлеге бүләкне алудан башланган икән.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм хәзерге татар шигъриятен үстерүгә лаеклы өлеше өчен «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятенең «Казан утлары» журналы редакциясе» филиалы шигърият бүлеге мөхәррире **Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүдә зур өлеш керткәне өчен шагыйрь **Рәшитов Әхмәт Әхәт улы** (Әхмәт Рәшит) Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***


Татарстан Президенты указы белән, Массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә лаеклы өлеше һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятенең «Мәгърифәт» газетасы редакциясе филиалы директоры, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы **Вәлиәхмәтов Хөсәен Хәсән улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Казан елга порты.

*Дүртенче биттә:* язучы һәм галим **Дамир Шәрәфетдинов**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татарстанның әдәби җәмәгатьчелеге зур югалтуга дучар булды. Язучы, әдәбият белгече, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе һәм М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты **Рафаэль Әхмәт улы Мостафин** 14 апрель көнне 80 яше туларга бер ай кала вафат булды.

Р. Мостафин 1931 елның 14 маенда Татарстан АССРның Баулы авылында дөньяга килә. 1954 елда Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң урта мәктәптә укытучы, комсомолның Баулы район комитеты секретаре булып эшли. Р. Мостафин 1960 елдан журналистика эшчәнлегенә керешә. «Литература и жизнь» газетасының (Мәскәү) Идел буе республикалары буенча үзхәбәрчесе, Казан телевидениесе студиясенең сәнгать программалары баш редакторы, «Казан утлары» әдәби-сәнгать журналының баш редакторы, «Татарстан» иҗтимагый-сәяси һәм теоретик журналы баш редакторы вазыйфаларында хезмәт куйды, «Дружба народов» журналының (Мәскәү) редакция советы әгъзасы булды. Чирек гасыр буе диярлек Казан университетының журналистика кафедрасында укытты.

Р. Ә. Мостафин бөтен гомере буе актив иҗтимагый эшчәнлек алып барды, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре, шуннан соң идарә әгъзасы булды.

Ул—«Әдәби портретлар», «Үсеш процессында», «Җаваплылык хисе», «Сибгат Хәким», «Чор образы», «Борынгы һәм мәңге яшь», «Кабан күле серләре», «Казан һәм аның бистәләре» дигән китаплар авторы. Әлеге әсәрләрдә бүгенге татар әдәбиятының актуаль проблемалары, сәнгати тәрҗемә, туган якны өйрәнү мәсьәләләре ачылган.

Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат язмышы Р. Мостафин иҗатының төп темасына әйләнде. Ул шагыйрь һәм көрәштәшләренең фашистлар әсирлегендәге каһарманнарча көрәше турында бик күп яңа фактлар һәм документлар табып, бастырып чыгарды. Рафаэль Мостафинның «Эзләү дәвам итә» (Г. Кашшаф белән бергә иҗат иткән китап), «Муса Җәлил», «Җәлилчеләр», «Өзелгән җыр эзләре буйлап» дигән китаплары җәмәгатьчелектә киң танылу тапты. Р. Мостафин әсәрләре чит телләргә дә тәрҗемә ителде.

Рафаэль Мостафин тарихи тема буенча да актив эшләде. Аның соңгы китапларыннан берсе—«Репрессияләнгән татар язучылары»—2009 елда дөнья күрде.

Ватаныбыз Р. Ә. Мостафинның казанышларын югары бәяләде. Ул «Почет билгесе» ордены, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы, медальләр белән бүләкләнде.

Максатка омтылышлы, намуслы, зыялы кеше арабыздан мәңгегә китте. Талантлы язучы-тикшеренүченең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

**Р. Н. Миңнеханов, М. Ш. Шәймиев, Ф. Х. Мөхәммәтшин,**
**И. Ш. Халиков. Ю. З. Камалтынов, А. М. Сибагатуллин,**
**М. Я. Моратов, И. Р. Метшин, А. Г. Хәбибуллин, И. М. Ибраһимов.**



Дамир Шәрәфетдинов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZANUTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)